

**Гакыйль Сәгыйров**

# *Үзе турында һәм барсы да аның турында...!*

Самара
«Медиа-Книга» нәшрияты
2015

УДК 82-3
ББК 84
А 24

**Проектның җитәкчесе, китапның авторы һәм аны нәшер итү өчен әзерләүче Рәфгать Нәбиулла улы ӘҺЛИУЛЛИН.**

Китап Самара өлкәсе хөкүмәтенең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге губерна гранты акчасына нәшер ителә.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ**
**Үзе турында һәм барсы да аның турында** - Самара: “Медиа-Книга” нәшрияты, 2015. - 320 б.

*Укучыга тәкъдим ителүче бу китап озак еллар Самара өлкәсенең Кошки районы Иске Фәйзулла авылында яшәгән һәм 16 яшендә каты авыруга дучар булып, аягы һәм куллары хәрәкәтсез калгач, каләмен тешләре арасына кабып, шигырьләр, хикәяләр язган, рәсемнәр ясаган каһарман якташыбыз, Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы, Гаяз Исхакый, Шәйхи Маннур, Сахаб Урайский, Габделҗаббар Кандалый әдәби бүләкләре, халыкара “Филантроп” премиясе лауреаты Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровның тормыш һәм иҗат юлына багышлана.*

*Ул - сигез китап, егермедән артык графика рәсемнәр авторы. Аның әле дөньяга чыкмаган йөзләгән шигырьләре, хикәяләре, рәсемнәре бар.*

*Бүген Гакыйль Сәгыйров күңелләребездә безнең белән яши, халкыбызга хезмәт итә. Бу китап нәкъ шул турыда.*

# Кереш сүз

Мин аның турында, аның ачы язмышы турында беренче тапкыр үткән гасырның алтмышынчы еллары башында ишеткәнмендер, мөгаен. Ә беренче шигырьләрен Камышлы районының татар телендә нәшер ителүче “Югары уңыш өчен” газетасында укыганмындыр, дип уйлыйм. Моны ул елларда Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлап, юллама буенча нәкъ шушы басмага эшкә җибәрелгән, аннан соң Татарстанның Лениногорск һәм Чирмешән районнары буенча “Социалистик Татарстан” (хәзерге “Ватаным Татарстан”) газетасының үз хәбәрчесе булган, озак еллар Татарстан радиосы белән җитәкчелек иткән, “Чаян” журналында җаваплы секретарь булып эшләгән Минвагыйз Зәйнетдинов та сагынып искә ала.

Камышлыда эшләгән шушы чорда ул “Югары уңыш өчен” газетасында шигърият түгәрәген ачып җибәрә һәм аның битләрендә җирле шагыйрьләрнең шигырьләре күпләп басыла башлый. Камышлы газетасы өлкәбездә татар телендә нәшер ителүче бердәнбер басма булганга, күрше Кошки районының Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылында яшәгән Гакыйль Сәгыйров та, иҗатын дөньяга чыгару өчен, үзенең шигырьләрен бирегә җибәргәндер.

- Яшь шагыйрьнең ул чакта язган шигырьләре үзләренең гадилеге, шул ук вакытта ниндидер яңа фикерләр кузгатуы белән башкаларныкыннан аерылып тора иде, - дип сөйли Минвагыйз әфәнде.

Ә инде тумышы буенча Татарстанның Нурлат районыннан булган Гакыйльнең шигырьләрен бастыручы икенче басма ул, әлбәттә, “Дуслык” газетасы (ул елларда бу район Октябрь исемен йөртә иде әле) булгандыр. Шул шигырьләрне укып танышканнан соң, Нурлатта шул ук “Социалистик Татарстан” газетасының үз хәбәрчесе булып эшләгән Рәшит Зәкиев (аннан күп еллар “Чаян” журналының баш мөхәррире булган) яшь шагыйрьне эзләп, Иске Фәйзуллага бара да инде. Шуннан соң республиканың төп басмасында Гакыйль Сәгыйровның, бер хәрәкәтсез калып, түшәктә генә ятып торырга ачы язмыш тарафыннан дучар ителүенә карамастан, тормыш авырлыкларына бирешмичә яшәргә, иҗат итәргә үзендә көч табуы турында журналистның язмасы дөнья күрә, шагыйрьнең беренче шигъри тәлгәшләре басыла.

Умыртка сөягенә уңышсыз ясалган операциядән соң бөтенләй

хәрәкәтсез калып, 17 яше дә тулыр-тулмас түшәктә генә ятарга дучар ителгәч тә, тешләре арасына каләмен кабып яңадан язарга, рәсем ясарга өйрәнгән талантлы шагыйрь һәм рәссам турында бу хәбәр халыкта зур кызыксыну уята, зур теләктәшлек таба. Иске Фәйзулла авылындагы бу кечкенә генә өйгә хатлар һәм кунаклар килә башлый, "Комсомольская правда" газетасы үзенең 1965 елның 5 май санында Гакыйль Сәгыйров турында "Гакыйльнең ялкынлы каләме" дип аталган язма бастырып чыгаргач, аның исеме бөтен илебезгә таныла.

Ә инде 1966 елның көзендә Татарстанның Лениногорск шәһәре телевидениесе беренче тапкыр Гакыйль Сәгыйровның ачы язмышы турында телетапшыру төшереп күрсәткәч (ул аннан соң Татарстан телевидениесендә дә дөнья күрә), шагыйрь янына еш кына нефтьчеләр килә башлый. Алар һәр килгән саен аңа йә телевизор, йә суыткыч һәм башка шуның кебек башка кирәкле әйберләр бүләк итәләр, ничек тә булса талантлы кешенең тормышын җиңеләйтергә тырышалар.

Гакыйль турында хәбәр комсомолның Үзәк комитетына да барып җитә Лениногорски шәһәре хастаханәсендә алты айлап вакыт дәваланып кайткач, комсомол Үзәк комитеты хезмәткәрләре үтенече буенча Иске Фәйзуллага очкыч белән очып килеп, Мәскәүнең Бурденко исемендәге нейрохирургия институты врач-консультанты Гакыйльнең сәламәтлеген тикшерә. Тик барыбер егетнең кул-аякларын яңадан хәрәкәткә китерү мөмкин булмый инде. Кайчакта көчле медицина да көчсез була икән шул!

Гакыйль янына Атилла Расих, Гөлшат Зәйнашева, Роберт Әхмәтҗанов, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм башка танылган татар язучылары бер-бер артлы килеп киткәннән соң, ниһаять, 1968 елда Татарстан китап нәшриятында "Беренче карлыгачлар" дигән исем астында 11 яшь шагыйрьнең, шул исәптән Гакыйль Сәгыйровның да, иң яхшы шигырьләре тупланган күмәк җыентык дөнья күрә. Ул калын тышлыкта, шактый зур тираж — 6 мең данәдә басылган. Шул яшь шагыйрьләр арасында соңрак зур танылу алган Рәшит Гатауллин, Сәлисә Гәрәева, Ренат Харис, Зөлфәт, Разил Вәлиев кебекләрнең дә булуы Гакыйль Сәгыйров иҗатының шул чакта ук югары бәяләнүен күрсәтеп тора. Ә инде 1970 елда Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның кереш сүзе белән Гакыйль Сәгыйровның шигырьләре һәм рәсемнәре тупланган беренче "Тормыш җиле" дип аталган җыентыгы дөнья күргәч, татарның тагын бер зур

талантлы шагыйре һәм рәссамы барлыгына чын-чынлап ышана башлыйсың.

Минем үземә Гакыйль белән якыннан танышу бәхете 1980 елда гына насыйп булды. Төрле дөнья мәшәкатьләре мөмкинлек бирмәгәндер инде. Ул вакытта “Волжская коммуна” өлкә газетасының үз хәбәрчесе булып эшли идем һәм Гакыйль Сәгыйровның тормышы һәм иҗаты турында зур мәкалә язарга йөкләмә алгач, моны бик тә шатланып кабул иттем.

Бу кешенең нинди халәттә булуын яхшы белсәм дә, килеп керүгә исәнләшергә кулларымны сузгач, бернинди дә җавап күренмәгәнгә бераз каушап калсам да, моны сиздермәскә тырышып, аның гәүдәсен сыйпап алдым. Аның куллары да, гәүдәсе дә салкын һәм җансыз иделәр. Миңа таба төбәлгән күзләре генә моңсу елмаялар иде.

Гакыйль белән дә, әнисе Хәбибҗамал апа белән дә бик озак кына сөйләшеп утырдым. Шул сөйләшүдән соң өлкәнең төп газетасында минем “Тормыш җиле” дигән шактый зур күләмле язмам дөнья күрде. Анда шагыйрьнең балачактан алып хәзерге вакытка кадәр булган тормышы яктыртылып, аңа ярдәм итү кирәклеге турында дә әйтелгән иде. Мәсәлән, аңа балачак инвалидлыгы өчен түләнә торган пенсиянең бик аз күләмдә булуы һәм аны ничек тә арттыру, өлкә китап нәшриятында җирле шагыйрьләрнең тәрҗемәсендә авторның шигырьләрен рус телендә бастыру кебек мәсьәләләр дә күтәрелгән иде.

Мин үзем төрле югары оешмаларга бу турыда хатлар язып карасам да, файдасы булмады. Пенсияне арттырырга закон юк, дип кенә җавап бирделәр.

Ә Гакыйль белән икенче тапкыр очрашуым ун ел үткәннән соң гына булды.

1990 елда өлкәбездә “Бердәмлек” татар газетасы нәшер ителә башлап, мин аның баш мөхәррире итеп билгеләнгәч, Иске Фәйзуллага хәбәрчебез Идеал Галәүтдинов белән бардык без. Шуннан соң “Бердәмлек”тә “Тормыш җиле исә дә исә” дигән күләмле язмам да дөнья күрде.

Бу очрашу газетабызны шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты белән бәйләүче беренче җеп булды да инде. Шуннан соң “Бердәмлек”тә Гакыйль Сәгыйровның шигырьләре, хикәяләре, публицистик язмалары, рәсемнәре даими бастырыла башлады. Идеал Галәүтдиновның “Идел моңнары” ансамбле коллективы белән Иске Фәйзуллага барып, шагыйрьгә ярдәм йөзеннән берничә хәйрия концерты да оештырдык. Ә инде 1994 елның

16 апрелендә Самара шәһәре татарлары да Металлурглар Мәдәният сараенда каһарман якташыбызның беренче зур иҗат кичәсендә катнашу бәхетенә ирешә алдылар. Казаннан бер төркем язучылар, шагыйрьләр дә килгән иде. Гакыйль Сәгыйровның әле яңа гына Татарстан нәшриятында 5000 данә тираж белән чыккан беренче күләмле "Кабатланмас моң" дип аталган шигырьләре һәм рәсемнәре җыентыгының тәүге нөсхәсе халыкка тәкъдим ителде. Бу кичәдә шагыйрьнең Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителүе турында хәбәр яңгыратылып, аңа таныклык та тапшырылды.

Шушы иҗат кичәсеннән башлап (ул чакта Гакыйльгә 56 яшь кенә иде әле) аның тормышына һәм иҗатына багышланган кичәләр, очрашулар, күрешүләр даими төс алдылар. Без, Самара, Ульян өлкәләренең, Татарстан Республикасының татар җәмәгатьчелеге, бергәләшеп аның 60, 70 яшьлек юбилейларын да, дөнья күргән яңа китапларын тәкъдим итү кичәләрен дә үткәрә торган булдык. Шуларның берсендә күренекле татар шагыйре һәм рәссаме, өч төбәкнең каһарман якташы Гакыйль Сәгыйровның тормыш һәм иҗат юлына багышланган китап чыгару кирәклеге турында тәкъдим дә яңгыраган иде.

Тик бу эш, җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршыланса да, озак тормышка ашырылмыйча кала бирде. Моңа алынучылар Татарстан язучылары, журналистлары арасында күренмәгәч, бу йөкне мин үз җилкәмә салырга җөрьәт иттем.

Якташыбызның үзе исән чагында барсы турында да сорашып, белеп калырга, аның истәлекләрен диктофонга яздырырга кирәк булган да бит, тик татар акылы төштән соң, диләр. Шулай да шагыйрьнең архивында сакланган, әле беркайда да басылмаган кулъязмаларны, көндәлек матбугатта дөнья күргән истәлекләрне, әңгәмәләрне, язмаларны бергә туплаганнан соң, аның тормыш юлын берникадәр тасвирлый алдым, дип әйтеп буладыр, дип уйлыйм. Бу укучыларыбыз өчен кызыклы да, файдалы да булыр, дип өметләнәм. Ә бу безгә каһарман якташыбызның иҗат үрнәген, рухи көчен шушындый кыен шартларда да яшәргә көч табып, матурлыкка омтылуын раслау мөмкин икәнлеген тагын бер тапкыр күрсәтә.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

# Әхмәт авылында башланган тормыш

## Ишетеп белгәннәремнән, үз күзләрем белән күргәннәремнән...

Бу шактый озын хикәятемне кайсы ноктасыннан башлап китим икән? Яфракларга эре-эре салкын чыклар кунган, торналар тавышы яңгыраган томансу иртәдәнме? Әллә авыл өстенә төшәлгән, дым саркып торган күксел ялкау болытлы көннәнме? Әллә инде көтүләр кайтыр алдыннан гына, офык тирәсен алландырып, соңгы кат дөньяга нурларын чәчеп, дөньяга караган һәм баткан кояш, шуннан соң авыл өстенә төшкән салкынча һавалы кичтән башлап китимме?

Әллә былдыр төбенә үк терәлеп үскән каз үләне өстенә сузылган шушы сукмактанмы? Әнә башына зәңгәрсу картуз каплаган, гади генә пиджак кигән, сызгырына-сызгырына, үзенең эчке уйларына елмая-елмая юл буйлап каядыр ашыгучы унсигез яшьләр чамасы бу егетне мин әллә кайчаннан беләм шикелле. Ул - Шәрифулла исемле. Барлык колхоз милкенә хуҗа кеше - келәтләр мөдире, гади генә итеп әйтсәк, “кладаущик”.

Шушы унсигез яшьлек “малайга” шулкадәр җаваплы эшне ничек ышандырганнардыр? Гомумҗыелышта сайлап куйганнар икән. Шулай, диләр. Күрәсең, сугыш алды елларында яшьләргә ышаныч күбрәк булгандыр.

Егет туп-туры көзге эш кайнап торган ындыр табагына юнәлде. Бер мизгелгә генә булса да шул бөтерчек кыз янында буласы, аның эскәк тимәсә дә нечкә, дугаланып сызылган кара кашын, алсу йөзен, килешле сынын күрәсе килә иде.

Әле яшь-яшь булуына карамастан, шушы кечкенә буйлы, җиңел гәүдәле бу  кызыкай ирләр белән пар басып, ашлык тутырылган авыр капчыкларны олауга төяшә. Аларны берәмберәм ике башыннан тотып алалар да олауга очыралар. Капчык, авырлыгын җуеп, һавага күтәрелә дә нәкъ кирәк урынга лып итеп төшеп утыра.

Ныгып өлгермәгән бу яшь чибәр кызның шундый авыр эштә эшләве егетне йөрәксендереп җибәрде булса кирәк, килде дә тегенең кулыннан капчыгын алды.

*- Бераз ял ит, үзем төяшим. Кем куйды соң сине монда? Малайлар беткәнмени?*

*- Без сеңел белән бик тә җайлы эшлибез, миңа башка кеше кирәкми,* - диде бу сүзләргә каршы кыз белән эшләүче урта яшьләрдәге Мостафа абый.

Шәрифулла көйсезрәк торткан иде, күрәсең. Селтәгәндә дә ниндидер мизгелгә соңга калды кебек. Шуңа да капчык олауга ничектер янтыграк килеп төште. Кыз, эченнән елмайса да, тышына чыгармады, килеп, капчыкка үрелде.

- Ял иттем, рәхмәт, хәзер үзем эшлим...



**Шагыйрьнең этисе Шәрифулла 1937 елда армиядә хезмәт иткәндә.**

Капчык авызында аларның куллары бергә очрашты. Кыз, оялып, тиз генә кулын тартып алды, бите кызарды. Авылда әллә ниткән матур сылулар Шәрифулланы очратуга үзләре юлыңа чыгып басалар, юри турларыннан суга баручылар да күп. Тик егеткә шушы кыздан да чибәре дөньяда юк та, булмас та кебек тоела иде.

Әхмәт авылыннан егерме биш чакрымдагы Иске Фәйзулладан үзләрендә эшләре беткәч, ярдәмгә җибәрелгәннәр иде алар. Берничә ир-хатын һәм яшь кыз.

Шәрифулла вакытын туры китереп, кызга сүз атып караса да, тегесе танышырга да теләмәде. "Мин кияү эзләп килмәдем", - диде. Тик егет аның саен:

*- Мин сине барыбер җибәрмим, алып калам барыбер!"* - дип үзсүзләнә торды.

Ә кыз бирелә эшләрне тизрәк тәмамларга да өенә кайтып китәргә ашыга. Күптән түгел генә вафат булган әнисе, яшь бала белән берүзе калган этисе, тугыз яшьлек Наҗия сеңелесе һәр яткан саен төшенә кереп йөдәтәләр.

Менә, ниһаять, бөтен эшләр дә тәмамланды. Барысы да кайтыр юлга чыкты. Ир-атлар зур юл буенча, ә өч хатын һәм ике кыз кырлар аша турыга яңкүлектән барырга булдылар.

Кырлар урылып-җыелып бушап калган. Көн салкынча, аз гына җилләп тора. Тирә-юньдә көзен генә була торган моңсулык хөкем сөрә. Тары кырында берән-сәрән генә башак җыючылар кыймылдый, яшел уҗым тирәсендә бәләкәй кара коңгыз сыман

ялгыз трактор теркелди — бер тасма җирне сөреп каралткан да инде.

Хәбибҗамалның үтенече белән юл адаштырып киткән хатын-кызлар елга ярына җитеп, түбән төшкәч, иркен сулап куйдылар, димәк, артларыннан чыкмаганнар яки күрмичә-тапмыйча кайтып киткәннәрдер. Юк, алай түгел икән шул. Кыр уртасындагы калкулыкта тарантаска җигелгән ат күренде. Андагылар да хатын-кызларны күргәннәр иде.

Шәрифулла тарантастан сикереп төште дә кызның кулыннан килеп тотты.

*- Хәбибҗамал, тартылма да, елама да, мин сине алып калам. Әйдә, арбага менеп утыр, йә үзем күтәреп утыртам.*

Уналты яшьлек кыз бу минутта ниләр уйлагандыр. Бәлки, үз-үзен чын ирләрчә тоткан бу унсигез яшьлек егет аның күңеленә кай ягы белән булса да хуш килгәндер. Ә, бәлкем, башы әйләнеп китеп, ни уйларга да белмәгәндер. Тик шушы нык сүзле, чибәр егет кыяфәтендә каршысына килеп баскан язмышына буйсынып, күз яшенә тыгылган хәлдә ул тарантаска үзе менеп утырган. Ә ат әкияттәге “Дел-дел” сыман авыл ягына “очкан”.

Бу яшь килен белән яшь кияү минем әтием белән әнием булганнар.

Алар ничек кайтып төшкәнне, кемнәр ничек каршы алганны мин белмим. Безнең әни генә ул әтисе өйләнгәнне бәләкәй чакта: “Мин әтинең әнине алып кайтканын капка башыннан карап тордым”, - дип сөйләгән, диләр. Ә мин белмим, мин ул чакта әле юк идем шул.

Иртәгесен кыз хәбәрен илтергә әби белән бабай әнинең туган авылына Иске Фәйзуллага киткәннәр. Яшь килен өйдә иркенләп үзе генә хуҗалык иткән - керләр уган, тәрәзәләр чистарткан, бүлмә такталарын, идәннәрне юган, барысын да эшләп, өйне ялт иттергән. Лампа пыяласын чистартып, кичен ут та кабызып куйган.

Кайнана белән кайната төн җиткәч кенә кайтканнар. Бабай тәрәзәдән өй эченә күз ташлаган да карчыгын чакырып:

*- Кил әле, син, күр әле, өй эчебез нурга чумган бит, күр әле, кара әле, син аны, ә!* - дип телен шартлаткан.

Менә шулай итеп әниебез бу гаиләнең якын кешесенә, тулы хокуклы әгъзасына әверелгән. Әниемнең әтисе - бабам да Иске Фәйзулла авылындагы моңа кадәр беркемгә дә кияүгә чыкмаган өлкән яшьтәге бер кызны өенә хуҗабикә итеп алып кайткан.

Бик йорт җанлы, эшкә гайрәтле, әйбәт холыклы кеше булган ул безнең Зөһрә әбиебез.

Әтием белән әнием беренче тапкыр Иске Фәйзуллага кунакка килгәч, бабам стаканнарга шешәдән аракы салган да, кияүне:

- *Иптәш, йә, тот әле,* - дип кыстый башлаган.

Әтием моңа каршы:

- *Бабай, туктагыз әле, иптәш дип ялгышасыз түгелме, иптәш дип теләсәң нинди кешегә әйтеп була ул, ә мин урамнан узучы гына түгел бит,* - дип бабайның сүзен бүлдергән.

- *Гафу ит, кияү, мин син нәрсә әйтерсең икән дип кенә шулай эндәшкән идем...* - дигән бабай, гафу үтенгәндәй.

Яшь булса да, кияүнең "төшеп" калганнардан түгел икәнен белү кыз атасының йөрәгендә канәгатьлек хисе уяткандыр. Кода-кодагыйларның да гап-гади бәндәләр булуы шулай ук ышаныч тудыргандыр.

Хәбибҗамалның Наҗия сеңелесе артык сагынудан нишләргә дә белмичә, апасы яныннан китмичә, аның кулын тотып, янында утырган. Бу күренешнең соңгы тапкыр икәнлеген сабый йөрәге әллә сизенде микән?

Апасы белән җизнәсе авылга килеп китүгә берәр ай чамасы вакыт үткәч, Наҗия мәктәптә парта артында утырганда кинәт агарынып, идәнгә егыла. Хушсыз калган баланы күрше авылга хастаханәгә алып барсалар да, аңа бернинди дә ярдәм күрсәтә алмыйлар. Әйтүләренчә, күз тиюдән, күзен дә ачып карамыйча, икенче көн иртән кызарып кояш чыкканда Наҗия дөньядан китеп бара. Шулай итеп, әнием үзенең бердәнбер туганын да югалта.



**Әнисе Хәбибҗамал апа.**

Мин биредә һич кенә дә "үлә" сүзен куя алмыйм. Җир өстендә чәчәк булып яшәргә туган балаларның гомере кыска булу — минем өчен гайре табигый нәрсә ул, мин аны бернинди төстә-сында да кабул итә алмыйм — чирле бала күрсәм дә,

аның савыкканын ишетмичә, күңелем тынычлана алмый җәфа чигәм.

Минем әни яшь кенә булса да, бөтен эшләрне дә белгән, аларны яратып башкарган, чөнки моңа ул балачактан өйрәнеп үскән. Кырга киткән өлкәннәрне көтеп тормыйча, кызчык бала да караган, өй эчен дә җыештырган, казан асып, аш та пешергән. Буе казанга җитмәгәч, әтисе аңа эскәмия ясап биргән булган. Буш вакытларында Хәбибҗамал чыралардан энә ясап бәйләргә өйрәнгән. Унбер-унике яшендә өлкәннәр белән узышып, урак та урган ул.

Хәбибҗамалның әнисе — Сәйриҗамал әбиебез дә осталарның остасы булган, диләр. Унбер яшендәге кызын киндер сугу станогы артына кертеп утырткан да, аңа:

- *Әйдә, бераз чүпли тор әле, мин боламык пешереп алыйм. Кара аны, бутама,* - дигән.

Моңа кадәр дә әнисе киндер сукканда ул гел аның тирәсендә булып, барысын да белергә тырышкан. Кыз булачак сөлгенең катлаулы рәсемен ясарга беренче тапкыр алына һәм бер җирдә генә кечкенә хата җибәрә.

Сугу станогы кылычын тартырга да, тәбәндереккә басарга аягы җитәр-җитмәсә дә, шул көннән ул сөлге чүпләргә дә, тула сугарга да өйрәнә. Бу һөнәрләрнең барысы да тормышта бик кирәк булып чыккан. Шуңа да уңган яшь киленгә һичбер яктан да теш-тел тидерелмәгән.

Яшь киленнең һәр эшкә куллары ятып, барысын да җиренә җиткереп, җан кинәнерлек итеп башкаруын күргән кайнанасы - минем әбием:

- *Юк, бу уналтыда гына түгелдер, күпкә олырактыр, бөтен эшне белеп эшли бит,* - дия торган булган.

Авылда яшьләрнең матур тормышына көнләшүчеләр дә табылган. Каршы йортта гына яшәүче бер хатын-кыз яшь килен коега суга чыккач, тегенең кайнанасын сүгә башлый.

- *И, мескенем, эшләтә-эшләтә үтерәчәкләр биредә сине. Ары-бире булганчы торма син, балакай, торма, кит!* - ди икән бу.

“Ары-бире”нең нәрсә икәнен дә аңлап бетермәгән Хәбибҗамал:

- *Ярар, ары-бире булганчы торыйм әле, аннан китәрмен,* - дип җавап биргән.

Бу гайбәтче хатын элек Шәрифулланы яратып, аңа күз салып йөргән кызның олы апасы икән.

Менә тагын бер мисал. Килен үзе дә сәбәбен әйтә алмыйча, ире янында төннәр буе елап чыга башлый.

Шәрифулласы уңайсызланып:

*- Әллә син мине яратмыйсыңмы?* - дип тә төпченгән, ә Хәбибҗамалы берни дәшмичә, елый гына икән.

Авылда яшәүче, тылсымлы көчкә ия Кабәм кушаматлы әбигә мөрәҗәгать итәргә туры килгән. Ул бер карау белән Хәбибҗамалга:

*- Кабәм, сиңа бозым ясаганнар,* - дигән һәм бер дога укып өргәч тә, аның шифалы тыны киленнең ямьсез фигылен бөтенләйгә алып калган.

Әтинең абзасы Гарифулла исемле иде. Без аңа Зур әбзи дия торган идек. Ул атлар карый иде. Беркөнне иртүк Кабәм әби аның янына барып:

*- Хәзер генә синең хатының Фәйрүзәгә сихерләнгән аракы китерделәр һәм шуны Шәрифуллага эчертергә куштылар,* - дигән.

Кабәм әби бу турыда кайдан-ничек белгәндер, анысы сер инде, аның белән күптән җир астында ята.

Тик моны ишетүгә, Зур әбзи эшен ташлап, өенә кайта һәм хатынын, безнең җиңгәчине:

*- Әгәр шул балаларның аралары бозылса, син дә рәхәт күрмәссең,* - дип кисәтә.

Кияү белән килен бик тату яшиләр, тик өзек-өзек бергә яшәүләре нибарысы биш елга да тулмый кала. Нишлисең бит, язмыш шулай язгандыр инде. Әти әнигә яратам дигәннән башка беркайчан бер авыр сүз дә әйтмәгән, аракы эчеп тә интектермәгән. Хәер, шундый бер очрак булган икән бит.

Кар көпшәләнеп, астына су төшә башлаган, кинәт кенә җылытып җибәргән язгы көннәрнең берсендә, Шәрифуллага Нурлатка барып, соңгы чана юлы белән авыл кибетенә вак-төяк тауар алып кайтырга кушыла.

Иртән барганда ярыйсы гына туң юл төштән соң бөтенләй боламыкка әйләнгән. Ә аңа Осиновка чокырында елга аша узарга кирәк. Аның уртасындагы юлны кемнәрдер бата-чума бөтенләй диярлек юкка чыгарганнар.

Башта ул әйберләрне каршы ярга ташырга була. Дилбегәне алып бер очын чанага, икенчесен биленә бәйли дә, су эченә атлый. Карлы салкын су тәнне пешерә, бөтен гәүдәне калтырата, ә ул көч-хәл белән шушы җәһәннәм боламыгын ерып алга таба атлый. Әнә юлның икенче очы да ике адымда гына.

Шәрифулла үзе салган әздән баштан шырпы-шикәр, тоз тартмаларын ташый. Иң кыены - сабынны чыгару була - тартмасы зур да, авыр да. Шикәр капчыклары да җиңелдән түгел. Ә хәзер чана белән атын ничек тә алып чыгарга кирәк.

Яшь ат суга керми җәфалый, курка. Суга төшкәч тә, тизрәк чыгарга теләп, алга таба ташлана, тирә-якка (үрле-кырлы) сикеренә. Ат ыргылган саен чананың алгы утыргычы гына су астыннан мөгезләрен күрсәтеп ала.

Ниһаять, Шәрифулла елганы кичеп, әйберләрен кабат чанага төяп куя да Нурлатта сатып алган аракының яртысын башлап эчәргә була.

Бөтен өсте лычма су, тәне өшүдән дер-дер калтырый аның. Эчми торган кешегә шул бер стакан җитә кала, чанага менеп ятуга йоклап та китә.

Ат хуҗасының йортын белә, билгеле. Кайтып туктавы була, тәрәзәдән күреп йөгереп чыгалар. Ә Шәрифулла йоклый, ә янында буш шешәсе аунап ята. “Раббем, әйберләрен югалтмаган булса ярар иде”, - дип ирексездән уйлап куя Хәбибҗамал. Иелеп караса, Шәрифулласы күкрәгенә кадәр лычма суда ята! Ә төялгән әйберләре барысы да коп-коры! Шунда гына Хәбибҗамал иренең бәлага таруын аңлап ала. Юк, эчүче түгел аның Шәрифулласы.

Ул да ире кебек үк көндә колхоз эшендә. Бигрәк җәйге урак өстендә көлтә бәйләгәндә авырга туры килә. Көлтәне бәйлә дә, зуратка куй, ә төшеп калган башакларны тырмалап ал, кырда кала күрмәсен. Түрәләр картузларын чөеп, соңыннан артыңнан тикшерәләр бит.



**Кечкенә Гакыйль** (уңнан сулга) **энисе Хәбибҗамал һәм этисенең сеңелесе Зөһрә апасы белән** (1938 елда төшерелгән фотосурәт).

Иптәшләрен узып берникадәр алга киткәч, Хәбибҗамал бераз ятып ял итәргә була. Зурат ышыгында изрәп йокыга талганын сизми дә калган ул, шулкадәр тирән йоклап киткән, хәтта якында гына шатырдап ургыч машинасы үткәнен дә, чыбыркы шартлатып атлар куган кешеләрнең тавышын да ишетмичә, төш күреп ята. Әнисе һәм әтисе белән урманга юкә әзерләргә килгәннәр, имеш. Кышкылыкка чабатага кирәк бит. Аның яшьрәген, төзрәген кисеп, кабыгын төшерәсең дә, төргәк ясап капчыкка куясың. Әнә куш табынга җитәрлек ашъяулыктан тегелгән капчык тулып килә инде.

Кинәт шарт-шорт мылтык атып, каравылчы килә башлады. Әтисе җәһәт кенә капчыкны чытырманлык эченә ташлады, ә үзләре бераз арырак китеп биек үлән эченә чумдылар.

Каравылчылар сөйләшә-сөйләшә узып китте. Ә урман шаулый — өстә җил, ә биредә агачлар төбендә хәтта Хәбибҗамалның чәче дә селкенми. Капчыкны күпме эзләп тә таба алмадылар...

Шунда ул күзен ача да, куркынып сикереп тора. Чапкыч дүртенче мәртәбә әйләнеп килгән инде. Башкалардан шул кадәр артка кал, имеш? Уятмаганнар, юри уятмаганнар!

Урдыргыч тагын өч әйләнгәнче, аның ике генә тезем кибәне калган инде. Шәрифулласы аның янына килгәндә ул инде барысын да яңадан куып җиткән, соңгы учмаларын бәйләгән иде. Әмма үзе лычма булып тиргә баткан, иреннәре сусап кипкәннәр.

Чапкычтагылар:

- *Малай, остабикәңне күпме генә артта калдырырга тырышсак та, булмады бит, тәки калмады,* - дип көлешәләр.

- *Сынатуын сынатмас та ул, тик кешене шулкадәр кумыйлар инде, яндырып үтерерсез,* - дип аларга үпкә белдерә Шәрифулла.

Төштән соң ярдәмгә тагын бер чапкыч өстәлде - кояш баеганчы ике машина белән урып, кырны юк иттеләр. Ә көлтә бәйләүчеләр әллә кайда артта калдылар.

Бау ясарга дип арыш көлтәсе чылатып китергән Шәрифулла хатыныннан:

- *Булышырга әллә тагын кызлар җибәримме?* - дип сорады. Тик Хәбибҗамал кирәксенмәде:

- *Юк, бау житсә, үзем дә бетерермен,* - дип әйтеп куйды.

Шәрифулла бауларны ясашты да, тагын китерермен дип, китеп барды. Берәр тыгыз эш чыккандыр инде, килә алмады. Бодай көлтәсенең үзеннән бау ясап бәйләп китте Хәбибҗамал. Болай да бик ярыйсы икән. Әтисе өйрәткәнчә, бауны борып,

көч белән аска тыгып куясың. Мондый көлтәне соңыннан тәртә башына эләктерсәң дә тузылып төшмәячәк инде.

Уручылар кайтып киттеләр, кырда бәйләүчеләр генә калды. Хәбибҗамал үзенең кишәрлеген бәйләп бетерде дә ял итәргә утырды - су эчте дә, күзләрен йомып, кулларын җәеп рәхәтлеккә талган гына иде, аяк тавышы ишетелде. Бригадир Исхак абзый икән.

*- Арыдыңмы әллә, сеңелем?*

*- Аруын да арыдым инде. Үземнекен бетергәч, кешенекенә җибәрерсез дип кенә калдым.*

*- Сеңелем, җаның тыныч булсын, үз эшеңне эшлә дә, бар, кайт. Кирәк булсаң, дәшәрбез.*

Өч көнгә сузылды аның бу ялы. Яшь хатын керләр юды, киледә ярмадан он ясады, өйдәгеләрне мунча ягып кертте. Бикүледән кечкенә әбине дә кунакка чакырып, кунак итте. Җәйге көн бик озын бит ул, анда башкарылган эшләрне санап бетереп булмый, озак йоклап ятмаска гына кирәк.

Урак эшләре тәмамлангач, Әхмәт авылы хатын-кызларының бер төркемен Нурлаттан килә торган юл төзелешенә җибәрделәр. Эш җиңелдән түгел, шулай да, уен-көлке, җыр бер дә тынып тормый.

Өч көн эшләгәннән соң Хәбибҗамалны Кирәмәт авылында бер чуваш карчыгы өендә аш пешерергә калдырып киттеләр. Иртән барысын да ашатып озата да, аннан көн буе эшчеләр кайтканчы эшсез каңгырып йөри. Карчык янына авыл хатыннары кереп: "Безнең авылга кияүгә чык", - дип интектерәләр үзен. Аның: "Ирем бар, мин кияүдә бит, икенче ир миңа кирәкми", - дисә дә, ышанмыйлар. Эшчеләр кайткан саен Хәбибҗамал башка берәү пешерсен әле, дип Нургата абзыйга ялварса да, тегесе аны ишетергә дә теләми, чөнки эшкә китәр алдыннан кайнатасының бригадирга:

*- Ул йөкле кеше, аңа авыр эш ярамый*, - дип кисәтеп куйганын Хәбибҗамал белми. Ә аш пешерү ягыннан аның осталыгын кем генә белми икән? Ә көн буена авыр җир эшендә тир түккән, шундый араны җәяү үтеп, арып-алҗып кайтып кергән кешегә аяк-кул юарга җылы су, пешкән тәмле аш булса, башкача тагын нәрсә кирәк? Ә боларның барысын да Хәбибҗамал булдыра. Әле икенче 1937 ел җәендә дә кыр эшләре арасында юл төзелеше дәвам итеп, Хәбибҗамал тагын анда эшкә барды.

Бу елны кырларда иген бик нык уңып, аны урып-җыю эше бераз озакка сузылды. Югыйсә, хуҗалыкка беренче комбайн

да кайтарылган иде. Анда Хәбибҗамалга да эшләргә туры килде. Нургата абзый моны яхшы аңлый һәм шуңа күрә карарын үзгәртергә җыенмый иде.

Кичен эшчеләр озак утырмыйлар, мескенкәйләрнең башлары урынга тию белән изрәп йоклап китәләр. Кеше күп булганга идәнгә тезелешеп яталар.

Комбайнны трактор тартып йөртә. Аның янтыгына җайланган тартмада Хәбибҗамал белән Нужа Нурҗиһаны (нигә шулай атаганнардыр) бодайны капчыкка тутырып, авызын бәйлиләр дә янәшә баручы арбага ыргыталар. Арба хуҗасы капчыкларны төзәтеп куеп бара, арбасы тулгач, йөкне ындыр табагына алып китә. Алты-җиде ат белән ташысалар да, өлгерә алмыйлар.

Уңыш шулкадәр яхшы булып, хисапчылар әйтүенчә — гектарыннан утыз җидешәр центнер бөртек чыга икән, ә кайсыбер кырларда кырыктан да артып китә, диләр.

Дәүләткә ашлык тапшыру планы да ике тапкыр арттырып үтәлгән. Эшләгән хезмәт көннәренә колхозчыларга ашлык күпләп бирелеп, кайберләренең салыр урыннары да калмаган иде инде.

Көннәр соңга кадәр бик җылы-аяз торды. Мондый матур җәй-көз, белмим, тагын кайчан булгандыр. Түкми-чәчми үстерелгән бөтен уңыш кырдан үз вакытында җыеп алынды. Сугылмыйча калган көлтәләрне кырда эскертләргә өеп куйдылар.

Комбайн хәзер корабль сыман кырда “йөзеп” йөрми инде, бер урынга - кибәннәр янына якорьгә куелган. Шуннан көлтәләрне берсе артыннан берсен йотып кына тора, җайсызрак тузылган көлтә эләксә, ачулана, уфылдый, морҗасыннан куе төтеннәр чыгара.

Мондый чакларда комбайн хуҗасы Хамматшакир абзый ачуланып кашын җыерып куя. Аңа комбайн өстендәге урыннан бар да күренеп тора - ындыр табагы да, авыл да, якында гына тымызык җилдә канатларын әйләндереп торучы җил тегермәне дә, күптән түгел генә дулкынланып утырган арыш-бодай кырлары да. Хәзер алар бушап калган инде. Якын көннәрдә колхозда булган барлык көчне икегә бүлеп, игеннәрне суктырып бетереп, ындыр табагыннан икмәкне җыеп алу һәм мөмкин кадәр күбрәк мәйданнарны туңга сөреп калдыру бурычы куелган.

Бар бит авылда ышанычлы сүзле, хаклык яратучан, тормышны яхшы белүче өлкәннәр. Һәр авылда да бар андыйлар. Халык аларның сүзенә колак гел сала, үзләрен хөрмәт итә.

Шундыйларның берсе дә инде ул Хамматшакир абзый. Комбайнчы кебек, шундый җаваплы хезмәтне, шундый катлаулы машинаны аңа тапшырганнар бит.

Әнә кич тә булып килә, офыкта болытлар күренми әле, иртәгә дә көн явымсыз булырга охшаган, әмма никтер нык җилләп тора, явым-төшемгә түгелме икән?

Кибәннән көлтә бирүче бердә эшли белми, күрәсең. Бер исән көлтә биргәне дә юк, бөтенсен ватып-җимереп учмалап бирә, әйтерсең, кибәндә көлтә дә түгел, ә салам өеме генә. Җитмәсә әле мескен үзе дә бер дә тик тормый — йолкыйказына, җәфалана, тир түгә. Аның азабын карап торырга да кызганыч.

Хамматшакир авыз эченнән нидер мыгырданып, төкереп куйды да бригадир Исхак абзыйны чакырды:

- *Хәзер үк киленне, Шәрифулланың яшь хатынын, бирегә алып килегез!* - диде ул комбайнын туктатып.

Хәбибҗамал кичке ашка кайткан иде. Кайнанасы Миннегыйззәт карчык аңа:

- *Ашап ал да тиз генә мунча кереп, юынып кайтырбыз,* - диде.

Табынга утырып ике кабарга да өлгермәгәннәрдер, тарантасына утырып бригадир Исхак абзый килеп җитте.

- *Хәбибҗамал, сеңелем, әйдә тизрәк, Хамматшакир абзый барыбызны да үтерә анда, комбайнны да туктатты,* - диде борчылган тавыш белән.

Нишлисең бит, аннан-моннан гына капкалап алырга да барырга туры килде.

Хәбибҗамал күренүгә үк комбайнны кабызган Хамматшакир абзый көлтә куючының өстәленә беренче көлтә төшү белән сыктыргычны җибәрде һәм машина җиңелчә калтыранып, күңелгә ятышлы итеп гөрләп эшли дә башлады.

Хәбибҗамалның эшләвен күзәтеп тору үзе бер рәхәт: әнә бит ул ничек, ышанычлы хәрәкәтләр ясап, көлтәләрне алдына өеп куя да, өстәлдә аларның беткәнен көтеп утыра. Көлтәне вату-җимерү, кабаланып көттерү түгел, көнбагыш чиртергә дә вакыт таба ул.

Баганага элеп куелган фонарь яктысында төне буе эш дәвам итә. Таң ягына авышканда гына тукталып, бераз черем итеп алалар.

Таң беленә башлауга рига (ындырның зур бинасын шулай атыйлар) ишегендә Хамматшакир абзыйның зур башлы гәүдәсе

күренә. Кайчан йокларга өлгергәндер, кайчан уянгандыр — белмәссең. Тубал кадәр тарала торган көдрә чәче өчендер, мөгаен, аны кешеләр арасында “зурбаш” дип атаганнардыр.

- *Оланнар, торыгыз, вакыт,* - ди ул салмак кына тавыш белән. Зурбаштан икенче әйттереп тору юк, алай күнекмәгәннәр дә.

- *Әй, тагын әз генә йоклап аласыңмы?* - ди Нурҗиһан, авызын зур ачып исни-исни киерелеп.

- *Зурбаш дәшә бит, әйдә кузгалыйк!...*

Зурбаш инде комбайнны да майлаган, барабанны да чистарткан, суктыргычның башка четерекле җирләрен карап чыгарга да өлгергән. Әнә комбайнны кабызып та җибәрде.

Йокыдан арынып җитмәгәннәр дә сикерешеп тордылар да, бер-берен төртешә-төртешә, көлешә-көлешә көзге суык һавалы, алсу нурлы иртәгә чумдылар.



**Гакыйльнең әнисе ягыннан бабасы Шәфәгыйтдин абзый** (1950 еллар).

Өйдән ярты чакрымда гына эшләсәләр дә, беркемне кайтармыйлар иде. Тиздән әнә иртәнге аш өлгерәчәк. Күп кеше ашханәдә туклана, ә Хәбибҗамалга ашарга өйдән китереп җиткерәләр иде.

Кайнатасыннан килен гореф-гадәт буенча “тел яшерә” иде. Билгеле инде, Сәгыйрь карт аның эчкерсез ягымлы тавышын да, матур, моңлы итеп җырлавын да ишеткәне бар. Бигрәк тә, килене булганга кадәр, ул бу чибәр кызның эшләвен, башкалар белән чыр-чу килеп сөйләшеп-көлешүен күзәтергә ярата иде.

Бәлки, Сәгыйрь карт күңеле белән шагыйрь, йә рәссам булгандыр. Гомерендә бер китап укып карамаган, кулына пумала тотмаган кеше өй тирәсендәге бакчада әллә нинди чәчәкләр үстерә, язгыга шуларның орлыкларын җыеп саклый торган иде. Гомумән, дөньяның матурлыгын сөючән кеше иде ул.

Карт төннәрен каравылда тора, ә көндезләрен буш вакыт күп. Шуңа күрә еш кына киленгә ризыкны үзе илтергә тырыша иде. Ярата иде шул ул Хәбибҗамал киленен!

Аның бу турыда башкаларга да сөйлисе, килене белән мактанасы килә. Бер мәлне ерак авылдан кунаклар килгәч: “Әйдәгез әле, мин сезгә киленемне күрсәтим!” — дип, Хәбибҗамалны мактый-мактый тегеләрне кырга, утаучылар янына иялтеп барган дип тә сөйләгәннәрен ишеткәнем булды.

1937 елның октябрь ахырларында бәрәңгеләр казылып беткәч, Шәрифулланы армиягә алдылар. Ул бер елга соңгарып китте. Шуңа күрә Сәгыйрь карт аны энесе Мотыйгулла белән икесен бергә бер арбада армиягә озатып кайтты.

Шәрифулла озатырга Хәбибҗамалны үзе белән алмады. Капка төбендә төзелешеп баскан бөтен туган-тумачасы белән саубуллашты да арбага менеп утырды. Хатын-кызның күз яшен яратмый иде ул. Җитмәсә - Хәбибҗамал йөкле дә. Әйдә, әниләр янында басып калсын!

Мотыйгулланың беренче солдат хаты яңа төзелеп ята торган Амурдагы Комсомольск шәһәреннән, ә Шәрифулланыкы - чик буеннан - Бурят - Монголиядән алынды. Кайсы яктагы җир икәнлеген мәктәпнең география укытучысы картадан табып күрсәткәч кенә белделәр.

Иренең җылы күкрәгенә башын куеп йокларга күнеккән Хәбибҗамал төннәрен бер ялгызына урын таба алмыйча, йокыга китә алмыйча иза чикте. Ә инде карынындагы баласы үзен ешрак һәм әрсезрәк белдерә барган саен аның ялгызлыгы ничектер кими, онытыла барды. Ул еш кына туачак баласы турында уйланып-хыялланып ятты. Һәм Кабәм әбинең: “Ул табарсың, улың булыр, сының шундый, минем ялгышканым юк әле, кабәм” - дигәнен ишеткәч, ул инде үзенең малай табачагына чын күңеле белән ышанган иде.

Февраль урталары якынайган саен җепшек бураннар үзләрен нығытып күрсәтә башладылар. Кичен башланганы таң атканда туктаган булса да, капкаларны күмеп, юлларны тигезләп, тәрәзәләрне кар белән сылап китә иде.

Колхоз абзарларының капка төбендә көрәкләр тора, юкса кереп тә булмый. Бригадир хатын-кызны көндә кар казырга эшкә дәшә. Терлек караучылар үзләре генә өлгерә алмыйлар.

Хәбибҗамал бүген абзар башына салам күтәрде. Көн аяз, буран туктап юл төшкәндә терлекләргә мөмкин кадәр күбрәк ризык китереп калдырырга кирәк, табигать хикмәтен белеп бул-

мый: өч-дүрт көн суга чыкмаслык бураннар да китергәли февраль ае.

Эштә дә, өйгә кайтканда да берничә мәртәбә аның башы әйләнеп, эче сызлап киткәләде. Хәбибҗамалның ашыйсы-эчәсе дә килми иде, бу турыда уйлагач та, әллә нигә күңеле буталды, укшытып та алды.

Кайнанасына боларны сөйләп бирүгә, тегесе картына:

- *Бар, бүген берәрсенә кунарга кер, киленгә иркенләп бәбиләргә ирек бир,* - дип хөкем чыгарды.

Карышып торуның файдасы юк иде, Сәгыйрь карт киенде дә чыгып китте. Хәбибҗамалның каенсеңелләре пышын-пышын гына сөйләшеп түрдә утырып калдылар.

Ул заманнарда авылларда бала табу өчен генә хастәханәләргә баруның кирәге юк дип санаганнар, авылларда алар бөтенләй булмаган да, ә районга ерак.

Кышкы озын төн үтеп, кызарып таң беленә башлаганда өй эчен бәби тавышы яңгыратып җибәргән. Үзе сигез бала табып үстергән әбиебез сабыйны кулына алуга, аның җитлеккән, сау-сәламәт икәнлеген күреп, чын күңеленнән шатланган һәм кызы Минегайшә апайны чакырып:

- *Бар, атаңа әйт: малай туды, диген, кайтсын, терлекләрне дә ашатырга - эчертергә кирәк,* - дигән.

Әтисенең иске күлмәгеннән ертып ясалган искедә төренеп, кычкырып ятучы малай кисәге — мин булганмын. Мин идем ул!

Бу дөньяда шундый якты, иркен, бераз салкынчарак иде. Мин моңа шунда ук төшендем. Кулдан-кулга күчереп йөрткәндә кинәт егылып төшәрмен дип тә, мәченекедәй мыегын тырпайткан, ике кулын сузып, миңа елмаеп карап торган бу карттан — Сәгыйрь бабамнан бераз куркып шикләнеп тә еладым әле мин. Тизрәк әни дигән, апа дигән кешеләрне күрәсем килде. Ә алар белән танышу шундый күңелле, рәхәт булды минем өчен.

Минем бик тә ашыйсым килә иде. Нигә көйсезләнгәнемне тиз аңлап алдылар. Әниемнең түшеннән сөтне йотлыга-йотлыга имеп алгач та, йоклап кителгән. Туенгач йоклап алу үзе бер рәхәт икән ул.

Мин дөньяга килгәнче үк барсының да тавышларын да ишетәм, ни сөйләгәннәрен дә аңларга тырыша идем. Ә хәзер менә үзләре белән якыннан танышырга туры килә.

Минем - бер әнием, бер әбием, биш апам (ике туган апаларым), бер бабаем бар. Өй эче иркен, туң тәрәзәләргә кагылып-

сугылып нидер сызгыра. Ягылган җылы мич каршында мине коендыралар да агач сиртмәле бишеккә илтеп яткыралар. Миңа күңелсезләнергә вакыт юк: әле апам, әле әбием, әле бабам мине тирбәтә, көлдерә, сөйләтә.

Әниемне сирәк күрәм. Ул көндә эшкә китә. Аннан тәмле сөт алып кайта. Ул кайтканчы миңа чүпрәккә ипи чәйнәп куялар да шуны суырталар. Нишләмәк кирәк, әнкәй ишектән кайтып күренгәнче, түзәсең инде, чүпрәгенә дә риза буласың.

Ыштансыз килеш, идән буйлап шуышып йөри башлаганда минем иң зур эшем менә нәрсә булган: ишек каршындагы карават астындагы чүкеч, башка тимер-томыр тутырылган тартманы алып, сөйрәп чыгарам да барсын да баштан таратып ташлыйм, аннан кире тутырып куям икән.

Минем шунда икәнлегемне күрсәләр, ашарга да чакырмыйлар, чөнки мин килмим, ирексез туктатсалар - елый башлыйм икән. Шунысына гаҗәпсенгәннәр - һәр тимер-томырны дикъкать белән күзәтеп, карап, яңадан урынына куюыма. Эшемне тәмамлап бетермичә, беркая да китмим икән.

Ә бу эш һәр көнне яңадан кабатлана. Бабай да:

- *Тимәгез аңа, нәрсәдер өйрәнә ул, барсын да белергә тырыша*, - дия торган булган.

Дөньяда үземне белештерә башлаган көннәремнең иң әүвәлгесе итеп язгы җылы көнне күз алдыма китерәм. Шуннан алдагыраклары ниндидер тәртипсез - буталгыч рәвештә тезелгән кинокадрлар шикелле күз алдымнан гына йөгереп үтәләр.

Ә бу язгы көнне мин тулысы белән хәтерлим, ул көн җуелмаслык булып, үзенең яхшы нурлары белән рәсемгә төшерелеп калган кебек.

Ни өчендер түрдәге ачылмалы тәрәзәне ачып куйганнар да, мине киендереп, аякларымны урам ягына салындырып, шул тәрәзә төбенә илтеп утыртканнар. Көчле кояш нурлары күзне чагылдыра, бакча буенда кар биек, аны таптап, каралтып, баткан эзләр калдырып сукмак ясаганнар. Сыерчык сайрый-сайрый да, әллә кайдан очып төшеп, сыер өстенә куна.

Янымда гына бабам елмаеп, нидер сөйли, күрсәтә, аңлатырга тырыша.

Эрегән суларны бергә туплап, мөлдер-мөлдер килеп, урам уртасыннан елгачык агып ята. Кояш нурында җемелдәп, селкенеп, кыймылдап кар суы тере нәрсә сыман сузылып, түбән очка таба ага.

Шул елгачыкның аръягында бер абый туктап калган. Аның

нияте - бу якка чыгу, мин моны яхшы күрәм: ул арлы-бирле кардан елганы үтәргә җайлырак урын эзли.

Ә мин аңа юл күрсәтеп:

- Абый, моннанрак чык, моннанрак! - дип кулымны селки-селки кычкырып утырам.

Белмим инде, мин әйткән җирдән чыктымы, әллә башкарак урыннанмы, ул кадәресен хәтерләмим, әмма ул абый, елмаеп минем яныма килде дә:

- *Миңа рәхмәт, син әйтеп тормасаң, бата идем бит, шуның өчен үзеңә бүләк менә тот әле!* - дип бер башы кызыл, икенче башы зәңгәр яза торган карандаш биреп калдырды.

Белмим инде, бу бәлки минем иң беренче карандаш тотуым булгандыр. Апалар укудан кайтканчы аларның ниндидер бер китапларын алып, рәсемнәрен буярга керештем.

Минем бу "эшне" күргән апам мине нишләткән булыр иде икән, әгәр бабай аңа тәлпәче белән сугып җибәрмәсә. Апам да бик артык бәйләнәсе итмәде, бик үк тигез булмаса да рәсемнәр килешле булган иде, соңыннан хәтта үзләре үк миңа нәрсәнедер буярга рөхсәт итә иделәр.

Тик ул карандаш тиз бетте, шуның белән рәсем сәнгатенә бирелүем дә тәмамлангандыр. Акбур-күмер белән өй эчендә сызгалаудан тыялар иде. Миңа апамнар артыннан кабатлап шигырь өйрәнү, рәсемнәрен карый-карый таныш китапны меңенче мәртәбә актару гына калды.

Җаен урамда уйнап йөргәнемне хәтерлим. Бервакыт әби йортыбызны кайдан, ничек танып кайтуымны сораган.

Безнең өй алды бакчасында кызыл җимешле бузина, әллә ничә бояр, гөлҗимеш куаклары үсә. Шулар арасында биек булып үскән йөнтәс киң яфраклы тәмәке дә бар. Безнең бабай мич башында да тәмәке тартып утыра торган иде. Тик үзе тартырга бик яратса да, ә менә аның өч улының берсе генә дә тартмаган.

Бабам кечерәк кенә, какча гәүдәле ир-ат булып, бик нык үпкә чире белән җәфа чиккән кеше иде. Егерме беренче юклык-ачлык елында әллә ничә чакрымнан зәмһәрир суыкларда ярым ялангач көе урман ташулар эзсез үтмәгәннәрдер шул. Ертык чикмән, бер кат оек-чабата гына чатлама суыклардан аны саклый алмаган, билгеле. Ул елларда үпкә чиреннән дәвалау өчен кирәкле дарулары да булмаган бит әле аның.

Мин белгәндә дә әле бабам кырга печән чабарга барсак, әллә ничә төрле дару үләннәре җыеп алып кайта иде. Шуларны үзе

белгәнчә кайната һәм куллана иде. Шуларны эчкәч, бабамның ютәле басыла төшә, иркен тын ала башлый иде. Шундый үләннәрне кышкылыкка да җыеп, киптереп куя иде ул.

Сынлы сәнгать белән мине иң беренче булып бабам таныштырды, дисәм, ялгышмамдыр. Менә уйлап карагыз: салкын кыш көне, тышта күз ачкысыз буран үкерә. Безгә уйнарга чыгу турында уйларга да ярамый, чөнки өлкәннәр дә бик кирәк йомышларына гына чыгып керәләр. Өйдә караңгы, шундый күңелсез. Менә шундый чакларда инде безнең бабай чәй кәгазе һәм бәләкәй кайчы алып сәкегә утыра иде дә кәгазьдән нидер кисә башлый. Мин исә нәрсә туачагын алдан ук белергә тырышып, кайчы барган эзгә кызыксынып карап тора идем. Әһә, ат икән! Бөтенләй чын кебек бит! Менә койрыгы, менә ялы, колаклары да бар бит, әй! Мин аны шатлана-шатлана әле генә бозы эреп беткән дымлы тәрәзә пыяласына ябыштырып куям. Күңелгә шом салып, тәрәз артында гына әллә нинди авазлар чыгарып улаучы буран да колагыма керми башлый. Мин тагын түземсезләнеп бабай кулына карыйм. Монысы нәрсә була соң? Әһә, сыер икән ләбаса! Белми дә торам, безнең ак чәчле зәңгәр сыерыбыз икән бит! Мин аңа да ат янында урын бирәм. Бабам кисә дә кисә. Безнең инде сарыгыбыз да, кәҗәбез дә, этебез дә булды. Чү, бабам тагын нидер кисә әле. Паровоз булып чыкты ул. Аңа инде мин көне буе шатланып туя алмадым.

Бабам кисүдән туктагач, кәгазь-кайчыны алып мин эшкә керешәм. Бабамныкына охшатып берәр нәрсә чыгарып булмас микән, дип маташам...

Тагын бер балачак хатирәсе. Җәй үтеп, көз җиткән иде инде. Ул көз иртәсе минем күңелемә мәңге җуелмаслык булып урнашып калган.

Мин уяндым да кыска күлмәкчән, яланаяк кына тышка йөгереп чыктым. Чыктым да нәрсәгә чыкканымны да онытып капка төбендә тукталып калдым: дөнья гүзәл иде!

Сыек кына томанга уралып, яңа гына чыккан кояшның алтын нурлары бөтен дөньяны тутырган, куакларда, бүрәнәләрдә, җир өстендә дә көмеш бөртекләр булып чыкмы утырган, әллә кырау төшкәнме. Мин исем китеп бакчага карыйм. Анда биек булып үзләре генә утырып калган сап-сары кукуруз калфакларында, киң озын яфракларында зур көмеш тамчылар тезелгән. Алар шундый дәүләр, яфракларда ничек тотылып торуларына әле дә булса гаҗәпләнәм. Ул вакытта да җемелдәшеп торган шул тамчыларга бармагым белән кагылмыйча булдыра алмадым.

Мин бабам кебек кулымны күз өстемә куеп, биектә кычкыра-кычкыра уйнаклап очучы каргаларны күзәтә башладым. Аксыл гына күренеп торучы айга кунмаслармы, дип озак күзәттем мин аларны. Күпме генә ай яныннан очып үтсәләр дә, берсе дә һаман кунмый да кунмый. Әниемнең: "Туңасың, кер!" - дигән тавышын ишеткәч кенә исемә килдем — мин шактый ук өшегән, аякларым вак кына калтырыйлар икән. (Ул чактагы зиһен хәзер булса иде). Шуннан башканы белмим инде. Тик ул көннең кояшлы иртәсе мәңге онтылмаслык рәсем булып күңелемә кереп калган.

# Утлы кәгазь

1941 елның 22 июнендә Нурлатта халкыбызның ел буена көтеп алган иң күркәм бәйрәме Сабан туе иде. Кичтән сөйләшеп куелганча, иртән иртүк әти үзе җигеп йөри торган атын алып кайткан да,чалгысын чүпрәккә чорнап, арбага куйган һәм безне уятырга кергән. Аның тавышын ишетүгә барыбыз да сикерешеп тордык. Күп тә үтмәде, без — мин, әтиемнең дүрт сеңелесе һәм әти үзе, тегермән тыкрыгыннан менеп, Нурлатка юл тоттык.

Өйдә әби белән бабай, тугыз айлык энем Наил һәм әни генә калдылар. Бабай, бик көнче җан, әнине безнең белән җибәрмәгән:«Юк, килен бармасын, матур кешегә анда юри бәрелеп йөриләр!» — дип кырт кискән.

Кыр башына җиткәч, әти, чәчәк тулы печән чабып, арбага салды. Без барыбыз да дулкынланганбыз - кинәнгәнбез, туктаусыз көлешкәнбез, төрткәләшкәнбез. Ә инде хуш исле йомшак печән өстендә утырып баруы тагын да күңеллерәк иде.

*...Күрәсезме җәйге июнь күген:*
*Кояш нурларыннан коелган;*
*Судан кыйммәт әйбер юктыр бүген,*
*— Сабантуйга халык җыелган.*
*Шау-гөр килә, җырлый, уйный-көлә,*
*Әйләнәләр кызык кәмиттә;*
*Ә тегендә— бәйге: атлар килә...*
*Иң беренче булып кем җитә?*
* Япь-яшь малай:*
*Ыргый акбүз аты,*
*Әйтерсең лә оча — канатлы!...*
*Ә артыннан тезелеп бер-бер артлы*
*Тагын ничә: ике... өч... алты...*
*Күз иярми тизлек белән алга,*
*Түземсезлек тулы мәйданга!*
*Бу малаймы? Әллә теге егет*
*Тиздән күмелер бүләк һәм данга?..*

Сабан туенда бигрәк кызык икән: халык шундый күп итеп җыелган җирдә минем әле беренче мәртәбә генә булуым. Аллыгөлле чыбылдыклар корылган кәмиттә (карусель) бизәкле агач атка атланып әйләнүем дә беренче генә иде. Теңгел-теңгел музыка уйнап торган кәмиттә өч мәртәбә әйләнгәч тә әле туймаганмын, күрәмсең, аның яныннан китәргә теләмәгәнмен. «Ярар

алайса, үзеңне генә калдырып китәбез», — диде әти. Ә мин, бер дә исем китмичә: «Кәмит янында сезне көтеп торырмын», — дим.

Тәмле-татлы прәннек-кәнфитләр ашап, акчабыз җиткәнчә апаларга төрле әйберләр алганнан соң, өйдә калганнарга да күчтәнәчләр табылды. Әти миңа да җиде телле кечкенә яшькелт төстәге гармун сатып алды.

Әти өйдә юк чакларда аның гармунын тарткалый башлаган идем инде. Мин кечкенәдән гармун уйнаганны тыңларга ярattым. Гармун җырның сүзләрен үзе әйтеп уйный, ә җырчы гармун артыннан шул сүзләрне кабатлый гына дип уйлый идем. Күпме генә тыңлап карасам да, гармун чыгарган авазлар җырчы әйтеп җырлаган сүзләргә тәңгәл киләләр кебек тоела иде.

Әтинең гармунында ниндидер бию көенә охшаган нәрсәдер уйный башлаган идем...

*...Адым саен (киталмыйсың узып!)*
*Абынасың таныш-белешкә;*
*Утырганнар табын тезеп-тезеп,*
*Чакыралар тавык-бәлешкә...*

Сабан туена килүче туганнарыбыз да, әтинең танышбелешләре, дус-ишләре дә күпләп җыелган икән. Үтеп барышлый безне Чишмәдән килгән үз бабаемның энесе Минсафа бабай гаиләсе чакырып алган. Чәчәкле тәлпәк кигән, ак сакаллы, көләч йөзле ул бабай минем гармунымны күргәч: «Яле, улым, берне әйттереп җибәр әле!» — дип урыныннан сикереп үк торды. Кәшимир яулыгын аркасына җәйдереп бәйләгән, әллә ничә бала итәкле күлмәк кигән бәләкәй карчыгын да урыныннан тартып торгызды. Мин кычкырта башлаган көйгә алар икәүләп тыпырдый-әйләнә башладылар. Тирә-яктагылар көлешә-көлешә кул чабарга керештеләр.

Яңгыр сибәләп үтте. Дөрес, ул озакка сузылмады, шулай да әти безне ашыктыра калды: «Әнә тегеннән яңасы килә, күк күкри, ишетәсезме? Анысы килеп коендырганчы, кайтып калыйк».

Болыт яшенләп-күкрәп безнең арттан куа килсә дә, тота алмады. Мин инде шактый талчыккан булып, соңрак күкрәп яңгыр яуганны да сизмәгәнмен: бүлмә буендагы япма җәелгән сандык өстенә утырган килеш оеп-йоклап киткәнмен.

Уянганда кояш баеп килә иде инде. Аның кызгылт нурлары каршы рәттәге өйләрне, куакларны, көтүдән кайтып килүче сыер-сарыкларны кызыл төскә чумырган. Күктәге сызым-сызым калган болыт кисәкләрен дә буярга онытмаган.

Төн бик кыска булганлыктан, кешеләр гадәттәгечә терлекләр янында эшләрен ашык-пошык бетерәләр дә, ут та алып тормастан, ятып йокларга ашыгалар.

Кичен ирләр янына утырырга чыккан җиреннән әти сугыш башланганны ишетеп кергән. Мин ул чакта йоклаган булганмын инде. Әтинең сагышлы тавыш белән: «Хәбибҗамал, сугыш башланган бит. Бу сугыш фин сугышы кебек кенә булмас, озакка сузылыр, диләр. Син балаларны кара инде, зинһар, тарата күрмә», — дигән.

Әтинең башына берәр кайгы төшсә, ул ятып, бераз черем итеп ала торган булган. Әле дә әнинең итәгенә башын куйган да йоклап киткән. Яраткан иренең җилкәләрен сыйпап, чәчләреннән назлап-сөеп күпме утыргандыр әни, белмим.

Җәйге кыска төннең таңы беленеп килгәндә, кинәт сискәндереп, каты итеп йорт капкасын шакыганнар: «Мурадымов Шәрифулла йорты шушымы?» «Әйе, мин булам», — дип каршы чыккан әти. «Сугыш, җәмәгать, сугыш. Илебезгә ут капты: Гитлер албастысы кичә иртән безгә бәреп кергән. Йоклап ятыр вакыт түгел. Син, Шәрифулла туган, сәгать сигезгә Нурлатка җыелу пунктына барып җит. Соңгарма!» — дигән дә, әтинең кулына «утлы кәгазь» кисәге тоттырган. Шунда ук атлы җайдак, әле берни сизми изрәп йоклап яткан күрше өйләргә шушы хәсрәтле хәбәрне җиткерү өчен атын чаптырып китеп барган...

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**

*Бу язманы әдип "Әткәй гармуны" поэмасына кушымта дип атаган. Анда ул әтисенең әле яшь чагында гармунга гашыйк булуы, шул көмеш телле кыңгыраулы уен коралын, кәләш кебек гомерлеккә сайлап алырга кирәклеген яхшы аңлавы турында бик тә матур сүзләр табып яза. Менә шул гармунда оста уйнавы белән дә аның әтисе әнисен үзенә гашыйк иткәндер дә, бәлки.*

*"Шәрифулла уйный, Хәбибҗамал*
*Тыелып кына җырлый – моңга бай;*
*Матурлык та, җитез уңганлык та*
*Тутырып салып биргән бер Ходай..."*

*Ә гармунның җансыз көмеш телләрен күңелгә керерлек итеп уйнар өчен, сихри моңнарын арттырыр өчен оста куллар, саф йөрәк кирәк шул.*

*Яраткан Хәбибҗамалын, ике улын калдырып сугышка киткәндә Шәрифулла моңа кадәр кәләше кебек саклаган гармунын күрше Фома авылы клубының яшь гармунчысына биреп калдыра. “Гармунның табарбыз өр-яңасын, башлар гына исән-сау кайтсын”, - ди ул.*

*Кайтмый шул, кайта алмый... Тик кичләрендә аның гармунда уйнавы әле дә Хәбибҗамалның һәм ике улының колагында яңгырап тора кебек. Гакыйль улына язмыш гармунчы булырга мөмкинлек бирмәсә дә хәзер гармунда һәм башка уен коралларында Шәрифулла аганың оныклары уйный инде. Әнә Наил улының Ринат улы Гакыйль абыйсы язган күп шигырьләрне җырга әверелдергән. Димәк, әтиләренең һәм бабаларының бөтен моңнары дәвам итеп, җирдә яңадан кабатлана.*

*Ә Шәрифулла ага гармунын бүләк итеп калдырган күрше Фома авылы егете дә аның кебек үк яу кырыннан кайтмаган. Көмеш телле кыңгыраулы гармун бик күпләрнең исендә калса да, әлегә аның кайда югалганын белмиләр.*

*“Яшәп - сынап белмим Фома халкын,*
*Ятлар мактаганын тыңладым;*
*Әллә нигә күңелемә якын*
*Тал - тирәккә чумган тын авыл.*
*Урамыннан үтәм юри кереп,*
*Ул якларга илтсә юлларым;*
*Тирәкләргә сорылып калган кебек*
*Әткәй гармунының моңнары...” - дигән җан өздергеч сүзләр белән тәмамлый шагыйрь үзенең поэмасын.*



*Соңрак Гакыйль үзенең кулсыз-аяксыз яшәргә дучар ителүенә дә карамастан, Иске Фәйзуллада яшь гармунчылар тәрбияләү эшенә алынып, бередә күп гармун осталары үстереп чыгара. Шулардан аеруча күп бәйгеләрдә җиңү яулаган аның авылдашларын Мидхәт Әминовны, Равил Минебаевны гына атау да җитәдер, мөгаен.*

# Укытучы апа һәм мин

Әнә бит ул елмаеп минем күзләремә карап тора — ак күлмәк, кыска кара ыштан кигән ялан тәпиле бу малай ике утыргычлы эскәмия тактасына зур пычак белән “Гакыйль” дип үз исемен язып куйган да “орышмас микән” дип миңа төбәлгән. Мин нишлим сиңа, иркәм, миннән шикләнмә. Әнә, чалгысын янарга чамалап, бүкән янына бабаң якынлашып килә, ул бирә инде синең кирәкне.

Бабай үз эше белән мәшгуль иде әле, өйгә йөгереп кереп киткән оныгын чакырып, чалгы сабын тотып торырга кушты. Бабасы чалгыны чүки-чүки:

- Минем белән барасыңмы? - дип сорады.

Кырда кызык була торган иде, бигрәк тә җәйге илаһи табигать кочагында, тургай җырын, бытбылдык, тагын әллә нинди кошларның матур тавышларын тыңлый-тыңлый бабай белән янәшә чирәм өстенә аның кебек үк аякларны бөкләп утырып, әби әзерләп җибәргән ризыкларны ашау, чәй эчү үзенә бер рәхәт иде.

Әнисе эштә, әтисе сугышта Гакыйльнең Минсәгыйрь бабай үзе белән алганда шатланып бара инде ул. Алар икәүләп бабай белгән, күзләп кайткан җирләрдә - ызан буйларында, чәчелми калган елга буйларында ашъяулык кадәр генә үләнлек очраса да актарып куялар, бераз кипшенгәч, бер тирәгәрәк ташып тараталар. Кичен көтүләр кайткач, чыбык арбага сыерны җигәләр дә тагын икәүләп төяргә китәләр.

Көн арты көн үтә дә китә. Печәнне ташып, эчке лапасны тутырдылар, хәзер йорт артына кибән төбе җыелды, ничек тә булса аны очлап чыгасы иде.

Сугышка киткән әтисен Гакыйль бик аз хәтерли. Аны уйлап утырырга вакыты да юк аның, йә яшьтәшләре белән сугышлы уйный, йә кырга печәнгә бара. Кичләрен әнисенең үксеп елаганын күргәндә генә күңеле әллә нишләп, җаны әрнеп китә аның. Әнисен кочып: “Син, әни, елама, әти кайта ул”, - дип сөйләнеп, әнисен юатмакчы була. Әнисе дә, яшь аралаш елмаеп: “Юанычым минем, әле дә син бар, син булмасаң, нишләр идем мин”, - дия-дия, аны кочаклый, иркәли иде.

Чапкан печәнне төяргә барганнар иде алар. Кинәт, сыер куаклар ягына карап, башын чайкап, ямьсез тавыш белән үкерә

башлады. Арбада утырган малай куркып: “Бабай!” — дип, кычкырып җибәрде. Сыер тавышын ишеткән бабасы, печәнен дә күтәрмичә, үткен сәнәген баш өстендә селки-селки кычкырып килеп җитмәгән булса, җан фәрманга якынлашып килгән ике бүре сыер өстенә ташланган булыр иде, билгеле. Әмма, юлларын бүлгән кешене күреп, шикләнеп калдылар, янга борылдылар да туктап, карап тора башладылар...

Чапкан печәнне калдырып китмәделәр, өемнән-өемгә күчә-күчә төяделәр дә авылга юнәлделәр. Бүреләр сулы елгага кадәр ияреп килделәр. Шунда сыер итен авыз итүдән өметләрен өзделәр булса кирәк, яр астыннан урман артына китеп бардылар.

Кызарып баеп барган кояш нурларында алар аерым ачык булып күренәләр, бер-берсен тешләп егарга теләгәндәй сикерешәләр, уйныйлар кебек иде. Гакыйльне иң гаҗәпләндергәне шул булды — шундый усал ерткыч җан ияләре дә гап-гади малайлар сыман уйный беләләр микәнни? Булмас ла, әле кичә генә көндез авыл башында Зәмзәмияләрнең кәҗәләрен бугазлап киткәннәр иде. Уйнасалар да, ерткычлар шул алар.

... Гакыйль бер дә аптырап калмады — апаларына ияреп барды да, укырга яшем җитми, димәде, китаплар алып кайтты. Беренче класска уйнап кына йөри башлаган малай, күпләрдән уздырып, чынлап укып китте, Зөбәйдә апасының яраткан укучысына әйләнде. Әтисенең сеңелләре янында дәресләрне отып алган Гакыйль бер атна дигәндә әлифбаның ахыргы битенә кадәр укып чыкты. Язуны гына басма хәрефләр белән яза иде.

Беркөнне күңеле төшеп, янәшә партада утыручы Зәмзәмиягә хат язды. Шакмаклы дәфтәр битенең бер ягын тыгыз, матур итеп язып тутырган иде, әле икенче ягына матур чәчәк тә ясап куйган. Апасы буяу карандашларын кызганганга ул зәңгәр яфраклы гына килеп чыккан иде.

Хатны Зәмзәмиянең китабына куйганны күреп калган малайлар алып, укытучы апага бирделәр, үзләре укый белмиләр иде алар. Зөбәйдә апа хатка күз йөгертеп чыкты да, Гакыйль янына килеп, янәшә утырды.

-Син моны каян да булса күчереп яздыңмы? - дип кызыксынды Зөбәйдә апасы.

- Юк, апалар язганда ишетеп калган идем.

Кызарып, оялып киткән малайга укытучы апасы елмаеп карап торды да бер дә ачуланмыйча гына:

- *Бик килешле язгансың, мин моны үземә истәлеккә алыйм әле, ярыймы?* - дип рөхсәт сорап, хатны матур бармак-

лары белән дүрткә бөкләп, күлмәк кесәсенә салып куйды. Аннан Гакыйльне түгел, әләкләгән өчен, кеше әйберенә тыгылып бутанган өчен Минтаһирларны кисәтеп алды.

Зәмзәмиягә әллә нигә күңеле тарта иде шул аның. “Чижык” уйнаганда да кыз көтүче калса, ничек кенә булса да аның хәлен җиңеләйтергә тырыша, ике кәнфит эләксә — берсен аңа саклый, мәктәпкә барганда аны көтеп ала, урманга җиләккарлыганга бару сүзен ишетсә, кызны алдан ук кисәтеп куя иде.

Сугыш елларында кырда калган башакны кар каплаганчы җыеп алыш иде. Хәтта мәктәп балалары укуларын туктатып, урылган кырга башак чүпләргә китәләр иде - колхозга җыеп тапшыралар, күбесенчә үзләренә җыялар иде. Хәтта укытучы Зөбәйдә апасының да торган өенә башак җыеп алып кайтканы бар иде. Ул елларда күпләр ач иде шул. Зәмзәмияләрнең дә ашарларына җитешми, Гакыйль әбиләреннән яшереп, аларга башак җыярга барыша иде.

Көзен Зәмзәмия чирләп китте, мәктәпкә йөрми башлады. Мәктәпкә ялгыз йөрү Гакыйльгә бик күңелсез иде. Мәктәптән кайтышлый ук Гакыйль аларга керә, дәресләрен күрсәтә. Кәгазь табылмаса, такта кисәгенә сүзләр язышып, рәсем ясашып вакыт үткәрәләр. Һәр көнне эшкә йөрүче Зәйтүнә апа малайның керүенә, кызына иптәш-дус була белүенә шатланып бетә алмый иде.

Зәмзәмиягә бик нык салкын тигән, туктаусыз йөткерә, көн үткән саен хәлсезләнә бара иде. Ул бик ябык, беләкләре непнечкә калган, тик йөзендә зур коңгырт күзләрендә генә һич кимемәгән яшәү чаткылары җемелди иде.

Аларның сыерлары юк. Гакыйльләрнең дә ташлатты, үзләренә дә сөт юк. Сыерлары саудырганда ул кызга дип үзе сөт кертә, шунда тагын бергә уйныйлар, соңга калса, кичен әниләре кереп ала иде. Малайга көлеп тә, мәсхәрләп тә бу хакта сүз катучы юк иде.

Беркөнне әбисе генә:

- Улым, үскәч Зәмзәмиягә өйләнеп җибәрерсең инде, энисе дә бик уңган, ул да шундый булыр, - дигән иде, малай уңайсызланып китте:

- Әби, ул бит мин озакламый үләм, диде, - дип, иреннәрен тешләп, башын түбән иде: аның тавышында да олыларча кайгыяшь тулы иде. Карчыкның күзләре ирексездән яшькә чумды — сулкылдап елап җибәрмәс өчен, күзләрен яулык чите белән сөртә-сөртә почмакка кереп китте.

Кышкы каникулга Зөбәйдә апалары каядыр еракка Казан артына авылларына китте. Ике атнага дип киткән апалары бишенче көнне үк янәдән килеп җиткән иде.  Апаларын ишектә күргәч, Гакыйль белән Зәмзәмия аптырап калдылар.

- Апа, әллә безнең каникул бетте дәме?

- Юк, әле, юк, Гакыйль, Зәмзәмиягә кирәкле дарулар таптым, тизрәк китереп җиткерәсем килде. Тышта шундый суык, - дип сөйләнеп, чишенеп, җылымса мичкә сөялде.

Шушы суык кыш үтеп, беренче тамчыларны күрербез, дип кемнәр генә ышанып яшәде икән быел. Шулай да — әнә ничек матур итеп кояш көлә, түбәдән тыпырдашып-ялтырап тамчылар тама. Сыерлар урамда йөри, тавыклар нигезгә җылыга чыгып утырганнар. Авылда каргалар оя корырлык тирәкләр булмаса да, урман имәнлегеннән очып килеп, йорт тирәләрендә җим эзләнеп йөриләр.

Зәмзәмия дә язны күрде — бераз сихәтләнеп килә инде - Зөбәйдә апаларының китергән дарулары шифалы булды. Әле мәктәпкә йөрми, әмма урын өстендә үлем көтеп ятучы кыз түгел инде бу.

Карлар бетеп килә, урам күле ташып чыкты, бүген-иртәгә Сулы елгада ташу китәчәк. Малайлар кичә үк бозлар кузгала башлады, дигән хәбәр тараттылар. Зәмзәмия күрәлмичә кала, нинди кызганыч. Ярар инде,ниләр булганын кайткач сөйләп бирер әле. Нинди кызыклар булганын барын да сөйләр...

Әмма Гакыйль ташуны сөйли алмый калды шул Зәмзәмиягә. Кешеләр елга буеннан ташу карап кайткан җиргә авылда әллә ниләр булып куйган иде.

Киң авызлы ферма коесының эченә боз каткан, кыш буена су агып үскән боз аша чиләк тартулары җайсыз. Өстен чокып кына боз су өстенә тула - ярты җәйсез су алып булмаячак. Кое эченә төшеп, астан ваклап, чиләккә тутырып алуны кем тәкъдим иткәндер - коега савымчы бер яшь кыз һәм Зәмзәмиянең әнисе төшкәннәр. Ун минут үткәндер кое бозы бурасыннан бөтенләе белән кубып, алар өстенә гөбердәп төшкән. Гакыйль кайтканда Зәмзәмиянең өй тирәсенә кеше җыелган, күбесе елый иде...

Ятим калган Зәмзәмияне кая да озатмадылар. Аның янына Зөбәйдә апасы күчеп, икәү тора башладылар. Зәмзәмия еш кына әнисен искә төшереп еласа да ялгызлыкка интекмәде. Зөбәйдә апасы аны яратты, күңеленә сынарга, боегып калырга ирек куймады.

Аның әтисеннән дә бернинди хәбәр килмәде.

Язгы чәчүләр тәмамланды. Басуларны яшеллек биләде. Укулар бетеп, җәйге ял чоры якынлашып килә иде - Зөбәйдә апаның кияүгә чыгу хәбәре дә авылга таралды.

Беркөнне Зәмзәмия үзләренең йорт турысында уйнап утырганда Гакыйльгә сер итеп:

- Иртәгә Зөбәйдә апайның егете килә, мин дә алар белән китәм, - дип пышылдады.

- Ник син дә, әйдә бездә кал, мин хәзер үк әнидән сорап киләм, - диде сикереп торып Гакыйль. - Бездә генә кал, бөтен уенчыкларны үзеңә бирәм, телисеңме?

Әмма Гакыйль кызны никадәр үгетләсә дә, әнисе урынына калган Зөбәйдә апасын тыңламый булдыра алмый иде шул Зәмзәмия.

Иртәгесен хәрби киемле, сул як буш җиңен кесәсенә тыккан бер абый такта белән Зәмзәмияләр өенең тәрәзәләрен кадаклый иде.

- Бу - Илһам абый, Зөбәйдә апаның кияве, төнлә килде, без йоклый идек, - дип пышылдады кызчык. - Районнарында милиция башлыгы... Әзрәктән без китәбез.

Гакыйльнең күңеле боек, кемгәдер үпкәле иде. Аның сөйләшәсе дә, уйныйсы да килмәде. Зөбәйдә апасы аны күреп, өйдән урамга чыкты.

- Син кайгырма, Гакыйль, Зәмзәмия авылга кунакка кайтыр, үзең дә безгә барырсың. Зур үс, яхшы укы, акыллым. Без өчәүләп сиңа хат язарбыз, - диде ул, малайның башыннан сыйпап. Аннан Гакыйльнең колагына иелеп, болай дип пышылдады - Теге хатта нәрсә язганың исеңдәме? Мин аны Зәмзәмия үскәч, үзенә бирермен, ярыймы?

Малай оялып, елмаеп, башын түбән иде...

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
06.04.1993.

*Гакыйль бу хикәятне дә үз тормышыннан алып язса да, аның геройларына башка исемнәр кушкан. Тик биредәге малайның Гакыйльнең үзе булуы әллә кайдан сизелеп, күренеп тора. Шуңа күрә без дә бу китапта аны үз исеме белән атарга булдык, бәлки моның өчен ул рәнҗемәс.*

# Ике прәннек, бер кап шырпы һәм бер стакан

Өченче дәрес тәмамланугa класс җитәкчесе Рания апа ишектә күренде. Ул гадәттәгечә елмая-елмая өстәл янына килде дә яңгыравыклы матур тавышы белән әйтеп куйды:

- Балалар, бүген дәрестән соң каласыз, газета чыгарабыз...

Кемнәр калырга икәнен тәгаен әйтмәсә дә, газета төзүчеләр билгеле - иң беренче чиратта мин калырга тиеш. Тик газета белән мәшәкатьләнеп, өйгә кайтырга да соңга калыначак. Мин Бикколга күрше Әхмәт авылыннан килеп йөрим - күнегеп беттем инде хәзер: җиде чакрымны үтү тоелмый да кала. Безнең авылда башлангыч мәктәп кенә бит - шуңа бишенче класска укырга бирегә йөрибез.

Стена газетасын чыгаруда минем белән бергә утыручы Әминә дә калачак - үзе кебек язуы да бигрәк матур, килешле аның.

Ул иң баштан зур кәгазь битенә газетаның исемен язды, "Пионер" дип аталгач, кызыл галстук, значок та кирәк бит инде. Шулар өстенә алтын нур чәчтереп кояш та ясап куйгач, апасы да, кызлар да моңа сокланып туя алмадылар. Аннары мәкаләләрне аерым битләргә күчереп, билгеләнгән урыннарга әлеге зур кәгазьгә ябыштырдылар.

Газетаны эшләп бетергәч тә әле кызлар чәчәкләр ясатып мине җәфа чиктерделәр, Әминәдә мин ясап биргән чәчәкләр бар иде инде. Укулар башланып, ун көн үттеме-юкмы, кыз өенә кайткач, букчасыннан дәфтәр битенә бик гүзәл итеп ясалган роза чәчәген тапкан иде. Җитмәсә тагын, чәчәкнең бер яфрагына беленер-беленмәс кенә: "Мин сине яратам", - дип тә язылган иде.

Икенче көнне Әминә, дәрес вакытында шул чәчәкне күрсәтеп:

- Апага биримме? - дип пышылдады. Кызның зур коңгырт күзләре көлемсериләр - димәк, юри генә кылана, әйтергә теләгән кеше пышылдап тормый ул, елмаеп карамый. Мин кызның дуслыгын тоеп, аңа рәхмәт йөзеннән тагын да асылрак чәчәк төшереп килгән идем. Рәсемне күрсәттем дә:

- Сиңа ошыймы? - дип сорадым.

- Ошый, - диде Әминә, үзе оялып, читкәрәк карарга тырыша иде.

Бүген дә Әминәгә ясап биргән алсу мәкләр бөтенләй диярлек чынга ошый иделәр.

Газетаны төгәлләп элгәндә көн кичкә авышкан иде инде. Ни

өчендер бик тиз караңгыланып китте - күкне болыт сорган икән: әле генә айнышып киткәндәй, кызлар:

- Апа, Гакыйль ничек өенә кайта инде? - диештеләр.

- Бүген Гакыйль өенә кайтмый, бездә куна, хәзер бергә китәбез, - дип, Рания апа сумкасына өстәлдән әйберләрен тутыра башлады.

Ул арада тышкы яктан: “Апа! Апа! Рания апа!” - дигән борчулы тавышлар ишетелде. Бүлмәгә Әминә йөгереп кереп:

- Апа! Гакыйль китә бит, әйдәгез тизрәк! - дип кычкырды. Рания апа да нык борчылган иде.

- Гакыйль, мин бит уйнап әйтмәдем, төнгә каршы мин сине беркая да җибәрмим. Әйдә, әйдә, безгә киттек.

- Юк, апа, мин китәм, - дип үссүзләндем. - Төн булганчы кайтып җитәм әле.

- Тыңла, акыллым, әнә кара болыт та килә, мин сине ничек җибәрим, ди. Син мине елатырга тырышасың инде...- диде укытучы апа, еламсыраган тавыш белән.

Чыннан да Рания апа еларга җыена иде булса кирәк. Җитмәсә, шул чакны урман өстендә яшен ялтырап сузылды, күп тә үтмәде, коточкыч дәү чүкеч белән җиргә бәргәндәй күк күкрәде. Әллә шул тәэсир иттеме, әллә укытучы апасын артык борчылдырасы килмәдеме, Гакыйль бераздан калырга булды. Иң баштан Әминәне өенә озата киттеләр.

Әминәләрнең йорты тыкрыктан икенче генә булып чыкты һәм ул хушлашып, кереп калды. Рания апаның фатиры (ул да бирегә эшләргә читтән килгән иде) мәчет каршында икән. Мәчет иске булса да, манарасы әле аумаган. Килгәндә һәр көн иртән Гакыйль иң әүвәл шул манараны күрә, аннан соң гына тау астыннан кинәт кенә авыл үзе калкып чыга иде.

Рания апаның хуҗа әбисе кайтучыларны капка төбендә каршы алды:

- Әллә, мәйтәм, мәктәптә куна калганмы, ачка үләсең ич көне буена ашамыйча торып. Бу нинди кунак егете соң әле, безнең авылныкымы? Яшьләрне танымыйм да бит хәзер...

Танышканнан соң бергәләшеп чәй эчеп алдылар. Ә тышта - мәшһәр. Тәрәзәләрдән үтеп кергән яшен яктысы күзләрне камаштырып җибәрә иде. Хуҗа карчык бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен корып чыкты, ишекләрне япты.

Иртәгә рәсем дәресе булырга тиеш. Шуңа да мин буяу-карандашларымны, дәфтәремне алып, рәсем ясарга тотындым. Рания апа мине кызганып:

- Ярар инде, Гакыйль, ят та йокла, хәзер урын әзерләп бирәм. Иртәгә мин үзем укытучыгыз Нинага әйтермен, ул орышмас, - дисә дә, мин:

- Мин хәзер, бу озак түгел ич, - дидем. Шундый ачык төсле буяу карандашларың булу - үзе бер бәхет бит ул. Ярый әле шунда алып калды - югыйсә, әллә кайчан сатылып беткәннәр инде. Хыянәткә керсә-керде - барыбер алды. Соңыннан әнисенә үзе үк әйтте ләбаса. Әнисе биреп калдырган акча ике кило шикәргә җитерлек кенә иде бит. Үзенең дә башына килүен әйт әле син. Башта буяу карандашлары - калганына шикәр... Күргәч, түзеп булмады - алар да кирәк ич... Әтиләре бар кешеләр икешәр тартма алганнар әнә, ә аларныкы сугыштан кайтмады шул. Кайчагында әниләре тиргәп тә ташлый: Камалиның "сарыгы" да исән кайта алган бит, сыңар куллы гына булсаң да ярар идең әле, - дия торган иде.

Әтисен ачык кына хәтерли алмый инде хәзер Гакыйль, әнисе сөйләгәннәрне күз алдына гәүдәләндерепме, әллә күңелендә шул рәвешчә бикләнеп калганмы, зур йортның капка төбендә ямь-яшел чирәмлектә казлар үртәп уйнап йөри. Әнә, чирәм өстенә түшәлгән җәймәдә әтисе белән чәбәк-чәбәк уйнап Наил энесе утыра, үзе шырык-шырык көлә, әтиләре дә көлә. Шундый кызык, шундый рәхәт...

Күп тә үтмәде, әтиләре сугышка китеп барды. Аннан берничә хаты һәм берникадәр вакыттан соң "Хәбәрсез югалды" дигән "кара мөһерле" кәгазе генә килде.

... Төн уртасында өйдә күтәрелгән шау-шуга уянып китте Гакыйль. Бер мәлгә кайдалыгын абайлап өлгермәгән малай өй эчендәгеләр арасыннан әнисе белән энесен эзләде, Рания апасы күзгә чалынгач кына үзенең кайдалыгына төшенде. Тик бу кешеләрнең ни өчен бирегә җыелганнарын, болай кемне кызганып, кемне тиргәп сөйләшүләрен генә һич тә аңламый иде.

Ул өстәл янында йоклап киткәндер, күрәсең, чишенеп, шушы урынга килеп ятуын хәтерләми. Ә купкан бу ыгы-зыгының сәбәбен соңыннан гына төшенде Гакыйль.

Әбинең күршесендә сугыштан гарипләнеп кайткан сыңар аяклы һәм терсәктән бер кулы юк абзый яшәгән. Ул үзенең ни дә эшли алмавына, артык тамак булып өйдә генә утыруына бик тә көенә, гарьләнә торган булган. Хурланган бу кешене ике мәртәбә инде элмәктән төшергәннәр. Пычак-балта ише әйберләрне ул таба алмаслык урынга яшергәннәр. Тик бу юлы сизми калганнар - төнлә абзарга чыгып, кырына торган үткен

пәкесе белән үзен-үзе чалган... Хатыны, карт анасы һәм өч баласы калган.

Биш ел элек безнең җиңү белән тәмамланган канкойгыч сугыш шаукымы җиңүчеләрне дә аямый икән шул.

Сәгать төнге өченче генә булса да, йокы күздән качты. Бу фаҗигане ишетеп җыелган кешеләр күршедән дә кергән иделәр. Кермәвенә озаксынып ире артыннан чыккан хатыны да хушыннан китеп шунда ауган - иренең җаны чыгып бетмәгән булган әле...

Иртәгесен сүз бары тик шул турыда гына барды. Бүген әле тикшерүчеләр килгән. Ирне күмгән көнне каберенә чәчәк илтергә сөйләштеләр. Кызлар, ул абыйны жәлләп, яшертен генә елашып та алалар иде.

... Сумкасында ике сум акча барлыгы ярты юлда очрый торган "Сабанчы" поселогының бәләкәй генә өйдә урнашкан кибетен күргәч исенә төште Гакыйльнең. Иртән тәгам ризык капмыйча юлга чыкканда, берәр нәрсә алып ашарсың, дип ул акчаны әнисе биргән иде.

Кибеткә керү белән ак прәннек тартмасына күзе төште малайның, авыз тутырып тешләп алгандай төкереген йотып куйды. Карый торгач стаканны да, шырпыны да күреп алды. Әнисе шырпы юклыктан зарлана иде, күпереп торган ак прәннек тә кызыктыра - авызга алып, татып карыйсы килә иде.

Гакыйль бер стакан һәм бер кап шырпы алды. Калганына әнә шул прәннекне үлчәргә кушты. Сатучы апа көлемсерәп, стакан һәм шырпы янына өч прәннек куйды.

Кайтып җитәргә ерак калмаган иде инде. Ул юл кырыендагы салам өеме өстенә утырып сумкадан сатып алган әйберләрен чыгарды.

"Ярый әле өчне бирде", - дип уйлады Гакыйль шатланып, өчесенә дә берәр чыга ич. Шырпы да ярап куяр - өйдә гел бетеп тора, стакан да кирәк - моннан соң чәй эчкәндә энесе белән бер-берсеннән чират көтеп тормаслар инде.

Прәннекнең әнә шул өсте купшылганын алыр инде, матурлары аларга калыр. Акча аның карамагына бирелгән иде. Шунда ук өчесен дә йотып җибәрсә дә аңа кем дә үз әйтмәс иде, билгеле. Ләкин алай эшләргә уена да килмәде малайның.

Әнә - ике тәрәзәле, салам түбәле аларның өе. Ишек алды чыбык-чабык һәм әрем көлтәләреннән корып куелган. Гакыйль арттан - бакча ягыннан кайтып керде. Чирек бакчада бәрәңге алынган икән, эштән соң әнкәй белән Наил байтак азапланганнардыр, дип уйлап куйды ул.

Наил дәрес әзерләп сандык өстендә утыра иде. Абыйсын

күргәч, аның каршысына атлады, сумкасын күтәреп алды, елмаеп, шатланып, канатланып киткәндәй булды.

- Абый, без сине кичә көттек - көттек тә Алмаларга барып, белешеп кайттык. Әй, яңгыр койды гына! Буадагы теге талга тагын яшен сукты. Наилә (кәҗә бәрәненә шулай исем кушкан иде ул) тагын мәктәп бакчасына кереп калган иде...

Наилнең ике көн эчендә җыелган яңалыклары күп булып чыкты. Сөйләнә-сөйләнә, мич алдыннан әлүмин кәстрүлне алып, кыштабакка ашны салды да бүрәнәгә кагып ясалган почмак өстәленә китереп куйды.

Ул арада Гакыйль сумкасыннан ике прәннек, бер кап шырпы һәм стаканны алып, бер прәннекне энесенә сузды:

- Куян үзеңә күчтәнәч җибәрде, ә монысы - әнигә булыр...

Наил дүртенче класста укый инде - күчтәнәч җибәрүче куянга ышанмый хәзер, шуңа көлеп куйды да абыйсыннан:

- Үзең ашадыңмы соң? - дип сорады. Аннан прәннегенең яртысын аңа сузды:

- Бигрәк тәмле, кап менә моннан, әз генә кап, - диде.

Абыйсы кабып тормады - аның эчендә баядан бирле бүреләр улый - энесе алып биргән сөтле умачны йотлыгып-йотлыгып ашый башлады.

Үткән төнне яхшылап ял итмәгән малай әнисенең эштән кайтуын көтә алмады - баш астына кулларын куйган хәлдә идәндә яткан килеш йоклап киткән иде.

Стаканны, шырпыны, үзенә калдырган ак прәннекне күргәч, ана кеше яшен тыя алмады - алар ирексездән күзне яндырып ташып чыктылар да, эре-эре кайнар тамчылар булып, бите буйлап бертөзлексез түбән тәгәрәделәр.

- Әтиегез шундый шәфкатьле кеше иде, бәгырь кисәгем, абыең да аңа охшаган, төсе-бите белән генә түгел, җаны, холкы белән дә охшаган. Исән-сау үсеп кенә җитсен инде, Ходаем, - диде ана, килеп сыенган кече улын күкрәгенә кысып. - Икегез дә исән булыгыз, күгәрченнәрем сез минем, бәхетем сез минем...

Әнисе янәшә урын түшәп, берни белми изрәп йоклап яткан малайны күтәреп салды да берничә кат яшьләренә буйый-буйый битеннән, маңгаеннан үбеп алды, шулай белмәгәндә генә, йоклаган чагында гына сөеп-иркәләп калсын инде, юкса, андый нияте барлыгын сизсә, малай аны якын да җибәрмәс. Зур егет булып үсеп килә бит инде ул.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
09.03.1993.

# Беренче саф мәхәббәт

Бикколга безнең Әхмәт авылыннан җиде чакрым гына. Башлангыч мәктәпне тәмамлагач, иптәшләрем белән мин дә шунда укырга йөри башладым.

Алтынчы класста укый идем инде. Безнең белән Әминә исемле зур яшькелт күзле, кечкенә авыз, матур, килешле борын, кара кашлар белән бизәлгән түгәрәк йөзле бер кызчык та укый. Ул көзен дә, кышын да тезеннән генә булган саргылт якалы искерәк кенә пальтосын киеп йөри. Мин аның үзен белүдән башка кайда торуын да, кемнәре барын да белмим.

Ә кыз шундый сабыр, шундый матур. Начар билге эләктереп, аның алдында хур булмас өчен, мин арып-талып өйгә кайткач, нинди түземлек белән дәрес хәзерләвемне бер үзем генә белә идем. Иртәгәсен таңнан торып, җиде чакрым араны үтеп, мин укырга түгел, аны күрергә бара идем. Белмим инде, нинди хисләр кайнагандыр минем йөрәгемдә. Мөлдерәп тулган язгы су кебек алар үзләренә ташып чыгар өчен юл эзләгәннәрдер һәм, ниһаять...

Мин ул көнне класста дежур идем. Балалар юк вакытны түземсезлек белән көтеп алдым да чәчәкләр белән бизәлеп язылган кош теле хәтле генә хатны Әминәнең букчасы эченә салып куйдым.

Дәрес башлануга, Әминә букчасын алган саен тынычсызланып, дулкынланып, нәрсә булыр икән дип көтәм. Менә инде соңгы тәнәфес тә җитте. Балалар этешә-төртешә залга, урамга ашыктылар. Мин күз чите белән генә Әминәне күзәттем. Ул да башкаларга иярде. Димәк, әле минем хат аңа барып ирешмәгән икән...

Класста үзем генә калган идем.

Шул чакны Әминә килеп керде һәм ак күлмәген җилфердәтеп алдыма ук килеп туктады. Аның зур күзләре каты ачу белән карарга тырышалар иде.

- Нишләдең? — диде ул.

- Беләсең инде... — дип мыгырдандым мин.

- Менә язуыңны апага бирермен дә...

Әминәнең бу сүзләренә мин ничек дип җавап кайтарганымны, белмим. Бәлки бер сүз дә әйтелмәгәндер.

- Җавап көтмә! - диде ул һәм кулларын селки-селки йөгереп класстан чыгып та китте.

Иртәгәсен мәктәптә укытучы апа ачуланган сыман чәчемнән эләктереп алды.

Бераздан Әминә ни өчендер алдагы партага күчеп утырды. Безнең алда утыручы бер кыз белән ул урынын алмашкан иде.

Бер дәрескә кадәр ул минем дәфтәремне сорап алды. Мин нишләргә дә белмичә шатлыгымнан елмайдым гына. Ул дәфтәремне алгач, үз-үзенә, әллә иптәш кызына:

- Яратам да шуның елмаюын, - дип әйтеп куймасынмы. Һәм алар икәүләп көлә башладылар. Тегесе Әминәгә:

- Бөтенләй гашыйк булгансың бит! - ди. Ә Әминә бер мәлгә телсез калды кебек. Бераздан гына:

- Тукта әле, төрттермә, - диде һәм аларның яңгыравыклы көлү авазлары тагын класс эчендә яңгырый башлады.

Шулай көз дә үтеп китте, бураннарын уйнатып кыш килеп җитте. Ә миңа мәктәпне ташларга туры килде. Җиде чакрым арага барып йөрергә аякка-өскә бернәрсәм дә юк. Анда торып укыр өчен аның ризыгы да кирәк бит әле. Бер атна үткәч, минем хәлне белергә дип, Әхмәткә чаңгыда дүрт-биш малаебыз (шулар арасында Әминә дә бар иде) һәм класс җитәкчебез килгән иде. Мине мәктәпне ташламаска кыстап маташтылар. Ә нишлисең бит, аларга үзләренә генә китәргә туры килде.

Мин исә, аерылып калган кош кебек, күзләремне ала алмыйча, алар ерак офыкка китеп күмелгәнче артларыннан карап калдым. Канатларым бәйләнгән иде шул минем. Шулай итеп, мин үземнең беренче мәхәббәтем белән хушлаштым.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**

*Ә берничә айдан аларга Гакыйльнең туган авылы Әхмәт белән дә хушлашырга туры килә. Алар Хәбибҗамал апаның туган авылы Иске Фәйзуллага күчеп китәләр.*

# Кунакчыл, якты чырайлы монда һәрбер бусага...

**Кеше олыгайса да, балачак, яшьлек еллары, шул чакларда таптаган сукмаклары, авылдашлары беркайчан да онытылмыйлар. Алар гомергә хәтердә уелып калганнар.**

### Әхмәтем!

*... Үзгәргән авыл, үзгәргән -*
*Калышмый заманадан:*
*Таш йортларга утлар кергән*
*Биек таш баганадан.*
*Йорт тирәли бакчаларда*
*Күбәйгән алма - чия.*
*Алмагач белән серләшеп,*
*Киленнәр алма җыя.*
*Кызлар килсә, гөрләп китә*
*Безнең ферма тирәсе -*
*Алиясе, Гөлиясе,*
*Чәчәктәй Мөнирәсе.*
*Юк елларда кыштыр тунын*
*Элмәгәндер бер чөйгә, -*
*Тазарып-савыгып киткән*
*Гайникамал әби дә.*
*Авылның үзенә күрә*
*Почетный тактасы бар;*
*Дошманнарны җиңеп кайткан*
*Мәхмүте, Гатасы бар.*
*Бүгенге көн батырлары —*
*Бар да миңа яшьтәшләр;*
*Киләчәге карап тора,*
*Елмаешып - япь-яшьләр.*
*Авылым - мин бәләкәй дип,*
*Бик боегып тормаган, -*
*Илгә танылган кешеләр*
*Монда канат чыгарган.*
*Кунакчыл, якты чырайлы*
*Монда һәрбер бусага.*
*Шагыйре дә бар бит әле,*
*Кечтек кенә булса да.*
**1982 ел.**

...Күптән инде бу якларга килеп чыга алганым юк иде. Сөекле әбиемне соңгы мәртәбә күрүемә унҗиде еллап вакыт үткән дә киткән. Мин машинага чыгып утыргач та, таягына таянып, ул да машина янына килеп, бүтән күрешә алмабыз инде, улым, дип яшьле күзләрен яулык чите белән сөртә-сөртә, саубуллашып калган иде. Ике айдан соң вафат булу хәбәре килде. Яраткан әбием бер сәгать тә урын өстендә ятмаган, тышка чыгып истинҗа алып кергән дә, мин үләм инде, дип урынына ятып күзләрен йомган. Иң саф күңелле, керсез җанлы кешеләрне генә шундый җиңел үлем көтәдер.

Ярата идек без әбиебезне. Ул һичкайчан безне ямьсез итеп тиргәмәс, шуклыгыбыз чамасызга әйләнә башласа: «Әй, сез, төртенгәннәр», - дип кенә җибәрә иде. Бу инде аның безгә карата әйтелгән иң усал сүзләре иде. Аның кайчан да булса бер кул күтәреп безне кыерсытканын хәтерләмим мин. Димәк, булмаган ул.

... Биккол авылы тирәсендә йөзлегенә таш түшәлгән күтәрткән юл башлана, әнә ерак түгел офыкта Әхмәтнең биек куаклары, тегермән түбәсе шәйләнә башлады. Без Бикколга килеп укып йөргән чакларда беренче булып безне тегермән канаты каршы ала иде. Офыкта канат очы күренсә - авылыбыз якынлыгын сизенеп, аяклар ешрак атлый башлый иде.

Килә-килә үк тегермәнне карап - әйләнеп үттек. Канатлары төшеп беткән, стеналары да ишеләм дип тора. Үзе белмәгән кеше аны, төрле давылларга каршы торган, тирә-як авыл халкын көне-төне эшләп, он белән тәэмин итеп торган атаклы җил тегермәне, дип белмәс тә. Тегермәнне салучы Габидулла картның улы Шәйдулла бабай анда тегермәнче булып, йөри алган соңгы елларына кадәр эшләде. Бик картаеп, берничә ел элек кенә дөньядан киткән.

Юл уңаеннан Әхмәт авылыннан ике генә чакрым читтәрәк үтүче тимер юлына күз салып кайттым. Әниләр сугышка корал яки солдатлар төяп үтүче һәр эшелонны, эшләреннән туктап, юл чатына чыгып, озатып калалар иде. Йөгереп үтүче вагон тәрәзәсеннән булса да соңгы кат үзенекен күреп калу өмете һәркемдә янгандыр инде. Без, балалар, кайгының өлкәннәр кебек үк төбенә төшеп йөзмәсәк тә, аларга ияреп чыгабыз да һәр поездны озатып калырга тырышабыз.

Без куаклыкта качыш уйнарга, башка төрле шуклыклар эшләргә дә өлгерәбез, чөнки кыр станында тәмле арыш өйрәсе кояш баеганда гына пешә әле. Без дә әниләр янында бераз

тукланып кайта идек. Безнең вакыт күп. Бөтен эшебез тимер юлда коелып калган патроннарны җыеп, учакта шартлатырга, кыр бәрәңгесе, кузгалак, «газнич» кебек үсемлекләрне табып ач карынга тутыра торырга.

Бервакыт шулай Тәуфыйкъ өр-яңа кубанкасын киеп чыккан иде. Үтүче вагоннар арасыннан теге якка әйбер бәреп чыгарып уйнау китте. Тәуфыйкъ та үзенең кубанкасын атты. Поезд үткәч карасак - әлеге өр-яңа кубанка вагонга «утырып» киткән икән.

Икенче юлы шулай бер акыллы башыбыз: «Әйдәгез, үзебезне сынап карыйк, кайсыбыз курыкмыйча поезд узганчы күпер баганасына тотынып тора алыр?» - диде. Барыбыз да баганаларга ябыштык. Мин юлдан бер метрда гына куелган баганага тотындым да үкереп, дөбер-шатыр якынлашып килүче паровозны көтәм, башкаларны күрмим. Менә әлеге, зур-зур тәгәрмәчле тимер аждаһа минем белән тигезләнде һәм кинәт өстебезгә салкын пар пошкырып, кот очарлык тавыш белән чинап җибәрде. Белмим, ничек куркып чабып кителмәгәндер, пар болыты таралганда тирә-ягымда кем дә калмаган иде.

... Мәктәп элеккечә авыл уртасында. Бакчасында алмагач та үсеп утыра икән. Илле беренче елларны иясез калган мәчетне күчереп мәктәп ясаганнар иде. Билгеле, ул кешеләргә ни әйтергә дә, үпкә белдерергә дә хакыбыз юк. Заманынча эшләгәннәр, үзләренчә балаларга аң-белем алырга мөмкинлек тудырырга тырышканнар. Ул вакытларда авылда 7- 8 класслар да укытылып килде.

«Ә быел авыл мәктәбендә укулар булмый, мәктәбебез ябыла. Сугыш вакытында да булмаган хәл бит бу», - дип гарьләнеп сөйли, зарлана авыл халкы. Бишектән генә төшкән япь-яшь балаларны ачы бураннарда таңнан уятып автобуска йөгертүләр зур кыенлыклар китереп чыгарачак. Әлегә кадәр өч классны булса да тыныч кына авылда укыталар иде. Ә хәзер Нурлатка йөрергә туры киләчәк, мәктәпне ремонтлау, җиһазландыру, укытучы тотуга караганда, автобус белән зур мәктәпкә ташу район мәгариф бүлегенә арзангарак төшәдер, билгеле. Әмма бу хәл укучыларга, ата-аналарына олы мәшәкать тудырачак. Авылда мәктәп булмау, якында гына үзеңә белем бирүче укытучың, кирәк чакта яисә дәресеңне төшенеп җитмәгәндә мөрәҗәгать итәргә ихтирам иткән кешең булмау балаларга мораль яктан зыян китерәчәк.

Мәктәп - авылны оештырып тотучы ныклы үзәк ул. Минемчә, мәчеткә караганда да авыл өчен әһәмиятлерәге - мәктәп. Кечкенә

генә булса да үз мәктәбе, белем учагы яктырып янмаган авыллар таркала, юкка чыга. Туган авылым шундый хәлгә калмасын иде, дип хафаланам.

... Иске мәчет урынына ак кирпечләр, бетон плитәләр ташып өелгән. Авылны үзгәртү планы буенча биредә яңа мәчет төзелергә тиеш икән. Авыл картларының шатлана-шатлана яңа ак мәчеттә намаз укыйсылары да бар икән әле. Насыйп була күрсен: Түбән очта Уксымлы елгасының бормаланып башланып киткән җирендә зур буа төзелеп ята. Биредә күл булачак, һәм «алтын балык»лар үрчетеләчәк. Без бата-чума ташулар карап йөргән урында, ни күзең белән күрерсең, тирәк күләгәсендә «Әттәгенәсе!» дип, кинәнә-кинәнә балык каптырып утырмассыңмы?!

Урамга авылны әйләнеп зират очыннан кайтып кердек. Алдыбызда энәдән-җептән генә чыккан ике «Дон» комбайны күренде. Миңа таныш түгел яшь егет комбайнның ургычын көйләп маташа. Вакыт җитеп килә: киң кырлар, бай уңыш бирәм дип, күңелләрне шатландырып, саргаеп килгән арышлар көтә үзләрен...

Күптән түгел әни - карчыкка берничә арыш башагы кайтарып биргән идем. Башакның бер кырында 12 бөртек үскән, димәк, бер башакта 48 бөртек икән. Шуннан чамалап, әнкәй: «Гектарыннан уртача утыз-утыз биш центнер чыгачак, бу - зур уңыш, артык түкми-чәчми генә җыеп алырга Ходай язсын инде», - дип куйды.

Сугыш елларында әнкәй дүрт ел буена шушы колхозда бригадир булып эшләде, бу кырларны аркылыга - буйга ничәмә мәртәбә җәяүләп үткән дә, ничәмә мәртәбә кул астында эшләүче яшүсмерләрне, хатын-кызларны ачка үлүдән саклап калу турында уйлагандыр.

Әхмәттә кайбер башка авыллардагы кебек ачлыктан халык кырылмаган. Нибары ике кеше вафат булган. Анысы да әйтелгән сүзгә колак салмыйча, күгәргән башак онын кулланудан килеп чыккан.

... Әнием башка машинада, бездән алданрак килде. Без килеп җиткәндә, аны күреп алган күрше-күлән, яшьтәшләре җыелып өлгергән иде инде, кайберәүләре хәл сорашып, чыгып та баралар иде.

- Көтәбез, көтәбез, сез һаман юк, кайларда гына йөреп беттегез? - дип җиңелчә шелтә белән җиңгәчи каршы алды. Әтиемнең энесенең хатыны ул, әнидән берничә яшькә кече,

тормышның әчесен-төчесен җилкәсендә татыган киң күңелле, ачык чырайлы, уңган гына җиңгәчәбез инде. Алты бала үстереп илгә тапшырды: берсеннән-берсе тырыш, уңган, әйбәт кешеләр килеп чыктылар.

Шуларның берсе Минәхмәт. Колхозда эретеп ябыштыручы булып эшли. Без килеп җиткәндә эшендә иде ул. Җиңгәчинең янында шул Минәхәт кенә торып калган. Балаларының калганнары кайсы кая таралып беткәннәр.

Мәрьям җиңгәчи белән безнең әни - килендәшләр. Әтиебез сугышның беренче көзендә үк хәбәрсез югалса да, сугыш беткәч тә, әле әни төп йортта булып, алты ел ике килен бергә торганнар, алар арасында һичнинди низаг килеп чыкмаган.

Кышкы озын төннәрдә чемеки (без үскәндә сукыр лампаны шулай атыйлар иде) тирәсенә утырып, таң әтәчләренә кадәр челтәр бәйләгәннәр. Бервакыт шулай утырганда, урыныннан торып, яннарына әби кергән:

- Сез Мәрхи бәрәннәре кебек чеңгердәп сөйләшәсез. Ике көндәшнең чабатасы мичкә сыйган, ике килендәшенеке сыймаган, ди.

- Без сугышсак, аерырга керер идегезме, әни?

- Юк инде, кызыгып-шатланып кердем, бигрәк матур утырасыз, - дигән ул бу сорауга.

Кеше олыгайса, картая башласа да, бала чактагыдан артык үзгәрми икән. Кулына бер яшь чамасындагы бала күтәргән, машина янына якынлашып килүче хатынны күргәч: «Бу Фатыйма бит!» - дип уйлап куйдым. Чыннан да ул булып чыкты. Улы хәрби кеше икән, әле гаиләсе белән ялга кайткан. Ә Фатыйманың кулында - оныгы Раил. Раилнең апасы да бар икән. Раилә исемле. Бәләкәй генә кызчык йөгереп килеп, зәңгәр күбәләк сыман, әбисе тирәсендә бөтерелә башлады. Фатыйманы шундый сылу оныклары белән рәсемгә дә төшереп алдык.

Балачак истәлекләре күңелдә күп инде ул. Аларны искә төшерә-төшерә, вакыт үткәнен сизми дә каласың.

Без чәй белән булышканда Минәхәт тә кайтып керде. Унбиш минуттан без урамда идек инде.

- Әйдәгез әле, урамны бер әйләнеп кайтыйк, - дидем мин.

Биредә мине беләләр, хәтерлиләр. Кая гына барып чыксак та, уратып алалар, хәл сорашу, истәлекләрне барлау башланып китә.

Таягына таянып, сиксән белән дуслашып килүче Әсма әби якынлаша.

- Улым, мине таныйсыңмы? - ди ул, елмаеп. Танымаган кая инде!... Мин өченче класста укыганда, өй стенасына яңа кәгазь ябыштырса, чәчәкләр ясатырга мине чакырып китә иде. Еллар аның мөлаем йөзенә үзенең челтәрен ясаса да, гәүдәсе бераз түбәнәеп, бөкрәеп калса да, бик җиңел таныдым мин аны.

Аның тормыш иптәшен, әсирлектән качарга әзерләнгәнен сатлык җаннар аркылы белгәч, фашистлар үзеннән баз казытып, тезелеп баскан әсирләр каршында атып үтерәләр. Әсма апа ике малайны үзе генә үстерде. Габдерәшитен әле юлда очраттык. Дүрт классны тәмамлаганнан соң Бикколга имтихан бирергә ничек йөрүебезне кызык итеп искә алды ул.

Аның белән бергә Йөземхан да бар иде. Бала чакта, бәлки, авылның иң усал малае ул булгандыр. Бервакыт нидәндер сугышып киттек. Ул, аста кала башлагач, минем аякны тешләп качкан иде.

Күп хатирәләр өстенә еллар тузаны утыра башлаган. Әмма әлеге хәл һич тә истән чыкмаган. Сөйләшеп, көлешеп алдык.

Әнә - Гөлсем апай, ул әтиемнең туган сеңелесе. Җиде бала үстереп, хәзер алтысы алты якка таралган. Төпчеге - Фәннур, җәен генә армиядән кайткан.

- Ял да итеп өлгермәде, комбайнга чакырып, аптыратып бетерделәр. Әле эштә шул, менә күрмичә дә кала инде, - дип сөйләнде Гөлсем апа.

- Башкалар ихтирам итеп, ышанып, шундый җаваплы эшне сиңа йөклиләр икән, димәк, сине булдыклы, ышануга лаеклы, дип саныйлар. Шундый егет үстерә алуыгыз белән горурланырга кирәк.

Мине белгән күпләр башка якларга күчеп киткәннәр. Алар урынына башкалар авылда чиста, матур ак таш өйләр салып, тормыш корып яшәп яталар. Без малай чакларда өй тирәсендә төрле-төрле, биек куаклы бакчалар сирәк иде. Ә хәзер, хәтта биксез мәктәп бакчасында да алмалары белән мактанып, алмагач үсеп утыра.

Усал бал кортларыннан кача-поса, без, шук малайлар, Идрис бабайның чиясен урларга бара идек. Чия куакларын меңләгән бал кортлары гына түгел, Идрис бабай үзе саклый иде. Безгә усал булып күренгән әлеге олы гәүдәле, көчле тавышлы бабабыз бал аерткан чакларында авыл балаларын хуш исле яңа балдан авыз иттерми калмый иде...

...1921 елны шушы мәңгелек дала булган урынга иң беренче булып Габидулла исемле кеше килеп урнашкан, тегермән сал-

ган. Кул тимәгән, кешедән биек булып әрәм - алабута үскән бу җирләрне эшкәртеп, икмәк бирерлек хәлгә китерү өчен күченеп килүчеләргә бик күп тир түгәргә туры килгәндер, мөгаен. Бигрәк тә беренче кышны үткәрүе бик кыен булган аларга. Уйнарга чыгып, әрем-чытырман арасында хәтта балалар да адашкалаган, тик гомерлек тынычлыклары бозылган бүреләр төннәрен тәрәзә төпләренә килеп улашсалар да, кешеләргә һөҗүм итү очраклары булмаган.

Мәңгелек дала уртасында Совет хөкүмәте җир бүлеп биргәннән соң, Әхмәт һәм Чишмә авыллары барлыкка килгән. Шушы ике авыл да Бикүледән (Бикколдан) аерылып чыкканнар. Баштарак бу яңа авылны Әхмәр поселогы дип йөрткәннәр. Әхмәр - Габидулла бабайның кушаматы. Соңыннан Әхмәт дигән исем рәсми документларда теркәлгән. Бу исем — зур Бикүле авылы халкына өстәмә яңа җир бүлеп бирүне юллап йөрүче Минәхмәттән алынган. Минәхмәт - хәзерге вакытта шушы авылда яшәүче минем классташым Йосыпов Йөземханның бабасы ул.

1922 елның урак өстендә бу яңа авылның төп хуҗасы булып Гайфулла күршебезнең малае Гарифулла туган. Кырда эшләп кайтканда көлтә төягән олау башында тапкан аны Нурия әби. Ә безнең әби Миннегыйззәт — бу малайның кендек әбисе булган, чөнки юлда кемне эзлисең инде? Билгеле, ул чакларда алар әби булмаганнар. Ә безнең әтине әбиебез дә Бикүледә чакта ук 1914 елның сугышы башланган көнендә, зурат төбендә биләгән.



**Гакыйльнең әтисе ягыннан әбисе Миннегыйззәт карчык** (үткән гасырның 70нче елларында төшерелгән фотосурәт).

Әби мәрхүм: «Сугыш елында таптым, сугышта үләргә дә язган икән», - дип кайгырып сөйли торган иде.

Авылда беренче мәчетне, тегермәне кебек үк, Габидулла абзый салдырган. Кемгә дә әйтмичә, урман ягына барып бура бураткан да, олаучылар яллап, мәчеткә кирәк агачларны һәм кирәк -ракның барысын да төятеп алып кайткан. Авыл халкы: «Нишләп безгә әйтмәдең,

алып кайтырга ярдәмләшер идек», - дигәннәр. Габидулла бабай үз заманының бик таза тормышлы тегермәнче Шәйдулла абзыйның һәм Гыйльменурның әтисе булган. Хәзерге вакытта Гыйльменур шушы авылда яши, ә аның сеңелесе Шәмсенур - Тимертауда.

Әхмәттә торган елларда без күршеләр идек. Кышкы озын кичләрдә Гыйльменурның әнисе Шәмсеруй әби үзе кичергән әллә нинди хәлләрне безгә сөйли иде.

Колхоз төзелеше чорында, авыл куштаннарының әләкләве буенча Габидулланы «Кулак нәселе» дип, Себергә озатканнар. Ат урынына җигелгән сыерлары да егылып үлгәч, яшь балалары - уллары, бөтенләй ач калган. «Үзебез үлсәк тә ярар, ичмасам балабыз исән калмасмы...» - дигән өмет белән бер станциядә әлеге баланы «контора»ның ачык тәрәзәсеннән эчкә утыртып калдырганнар. Ә үзләре ачлыктан бик иза чиксәләр дә, исән калганнар. Соңыннан баланы калдырган җиргә барып, эзләп - сорашып йөрсәләр дә, таба алмаганнар.

Габидулла төрле якларда бәргәләнеп йөргәннән соң, мең хәсрәт күреп, Оренбург тирәләрендә беразга төпләнеп калган.

Сугыштан соң Габидулла карт карчыгы һәм чибәр генә ике кечкенә кызы белән туган авылына кайтып урнашты. Гыйльменурга 10-11 яшь тирәсе генә иде әле. Шулай да Оренбург якларыннан искиткеч оста итеп мамык-йон шәлләр бәйләргә өйрәнеп кайткан. Безнең авыл хатын-кызлары андый шәл бәйләүне шул матур кызчыктан өйрәнделәр.

Гыйльменур һәм аның сеңелесе Шәмсенур җиткән кызлар булып киләләр иде. Күпне күргән, күп яшәгән Габидулла карт кышкы төннәрнең берсендә өшегәндәй булып уянып китә, йомышы төшеп тышка чыгып керә, әкрен генә җылы мич башына менеп ята да изрәп китеп, кемгә дә бимаза кылмыйча, үзе дә белмичә, тыныч кына мәңгелек йокыга чума. Иртәнге чәйгә уятырга дип килсәләр... Авылыбызның мөхтәрәм кешеләреннән берсенең гомер юлы әнә шулай тәмамлана.

Гаражда бергә сугышып, бергә уйнап үскән Жирҗизов Вагыйзны да очраттым. Ул тракторын төзәтә иде. Үзгәргән, олыгайган, дөресен әйткәндә, башта мин аны танымый тордым. Тормыш иптәше Рәһәбәр механизаторлар ашханәсендә эшли, ә уллары шунда ук гараж мөдире икән. Күңелләре күтәренке, тормышлары әйбәт булырга охшый.

Берничә сәгать эчендә генә авылдашларның барысын да күреп, сөйләшү дә, бигрәк тә барысы турында язу да мөмкин

түгел. Биредә үзләрен очратмаган дус-ишләр мине гафу итсеннәр. Соңрак тагын бер очрашырбыз әле, дип уйлыйм.

Авылдашларымның шул ягы шатландыра мине: заманалар буталып китте, тормыш итү кыенлашты, кая таба юл яру да хәзергә билгесез дип, күп сөйләшеп, кул кушырып утырмыйлар. Авылда төзелеш җәелгән, кырларда мул уңыш үстерелгән. Авылым кечкенә генә булса да, алга карап, зур өмет белән яши. Менә шул шатландырды мине.

Минемчә, ул өмет-ышанычның канатлары - нефтьчеләр белән бәйләнеш, алар белән дуслыкның ныгуы. Нефтьчеләргә Әхмәтнең иркен кырлары, хезмәтчел куллары кирәк булган кебек, авылдашларыма да аларның ныклы ярдәме бик кирәктер. Бу заманда үзең генә аерым яшәү мөмкин түгелдер.

... Менә аерылышу минутлары да килеп җитте. Күрер кешеләр, сөйләшер сүзләр күп калды. Сезгә иминлек, зур уңышлар телим, авылдашлар. Тормыш сынаулары арта бара, бирешмәгез, дуслар!...

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Июль, 1991 ел.
Димитровград-Нурлат-Самара.

*Бу язмада Гакыйль Әхмәттән Иске Фәйзуллага күчеп китеп, каты авырулар, тән һәм күңел җәрәхәтләре кичергәннән соң, үзендә көч табып, яңа тормыш башлап җибәргәч, унҗиде еллар вакыт үткәч, авылдашлары белән кабат ничек очрашулары турында язган. Бу җитмешенче елларның ахыры, сиксәненче елларның башы булган булырга тиеш.*

*Ә Әхмәттән - әтисенең туган авылыннан, әнисенең туган ягына - Иске Фәйзуллага - Җүрәйгә күчеп киткәч, булачак шагыйрьнең тормышында булган аянычлы да, шатлыклы да хәлләр һәм вакыйгалар турында без киләсе язмаларда сөйләячәкбез.*

# Яшьлек канатланганда



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ**
(1960 еллар).

Җир йөзендәге һәрбер нәрсәнең башы һәм азагы була: бөек елгаларның, бөтен юлларның, сукмакларның, олы һәм кечкенә хисләрнең, шатлык һәм бәхетнең, хәтта кайгы, бәла, газапларның да. Тик галәмнең генә башы да, азагы да юк...

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, мин Пенза художество училищесына хат язып җибәрдем. Аннан килгән җавап мине шатландырды: мәктәпне гел «5»легә генә тәмамлаучылар рәсем һәм композиция буенча гына керү имтиханын тапшыралар икән. Ә мин рәсем ясарга бик ярата идем. Өч рәсемем «Пионерская правда» газетасында да басылып чыккан иде.

Укырга керү өчен, башка документлар белән беррәттән исәнлегем турында белешмә дә кирәк икән. Район хастаханәсенең табибы —чал чәчле, күзлекле апа, мине карагач: «Улым, укуыңны хәзергә кичектереп торырга туры килер, сиңа дәваланырга кирәк. Өлкә хастаханәсенә юллама бирербез», - диде.

Ул вакытта минем сул кулымның әкрен генә көче китә башлаган иде инде. Күрәсең, моннан ике еллар элек, әле Әхмәттә яшәгәндә урманда агачтан егылып төшүем «үз хокукларын» күрсәтә башлагандыр. Ул вакытта кызыксынучанлыгым куркуны җиңде - урман артында нәрсә барын күрәсем килеп, агачның очына хәтле мендем, - һәм кинәт мин утырган ботак сынды...

Күземне ачсам, мине куркынган малайлар уратып алган, ә кечкенә Наил елый иде. Шунысы сәер: тәнемдә бернинди җәрәхәт юк, башым гына әзрәк әйләнә, үзе мамык тутырган кебек һәм күңелем болгана.

Балачактагы мондый хәлләр бик тиз онытыла бит ул. Ә менә бусы ике елдан соң үзен шулай тупас итеп искә төшерде...

... Юлга әнием озатты. Шәһәргә алып килүче шофер

мине хастаханәнең ишек төбендә төшереп калдырды да китеп барды. Шулай итеп, мин, беренче мәртәбә авылыннан чыгып киткән малай, зур шәһәр һәм аның таныш булмаган гадәтләре белән бергә-бер калды. Тик ул куркып калмады, кешеләрнең яхшылыгына, игелекле булуларына ышанды.

Хастаханәдә бу вакытта авыруларны кабул итү тәмамланган булып чыкты. Күзне чагылдырырлык ак халат кигән мөлаем шәфкать туташы минем юлламаны укыгач: «Бүген соңладың шул, иртәгә иртәрәк кил, чиратсыз кабул итәрбез. Онытма!» - диде.

Шау-шулы шәһәр урамында аптырап озак басып тордым - бу көнне һәм төнне кайдадыр уздырырга кирәк бит. Кичкә хәтле вакыт җитәрлек әле, барысы да яхшы булыр, дип шәһәр буйлап йөрергә булдым. Биш катлы матур бина янында кайнар пирожоклар сатып бер апа басып тора. Биш сум акчамны аңа суздым. Пирожокны биргәч, ул миннән ни эшләп йөрүемне сораштырырга тотынды, аннан акчамны кире бирде: «Бу акча сиңа хастаханәдә кирәгер, балам». «Ә пирожок өчен?» «Юк, юк, аша, исәнлеккә-саулыкка булсын». Мин аңа рәхмәтләр укыдым.

Йөри торгач, бер катлы, гади өйләр, коймалар янына килеп чыктым. Кинәт минем «аулак урын» табасым килде. Ачык капкадан ниндидер бер йортка кердем.

Почмакта озын, очлы борынлы бер карчык кайнаша иде. Мине күргәч, чинавык тавыш белән: «Карт, монда бер малай йөри», - дип кычкырды. Күп тә үтмәгәндер ишектә бер карт күренде. Ул «Му-му» хикәясендәге Герасимга охшаган иде: шундый ук озын буйлы, киң җилкәле, көрәктәй сакаллы, озын, киндер алъяпкычтан, иске киез итекләренә зур галошлар кидергән. «Герасим» кулындагы зур себеркесен токкан килеш минем янга килеп басты һәм җитди итеп: «Сиңа нәрсә кирәк, малай?» - дип сорады. Мин сихерләнгән кебек аңа карап торам, үзем уйлыйм: «Әдәбиятта тасвирланган дворниклар хәзер дә бар икән, ә?!» Аннан каушап: «Миңа...бәдрәф кирәк иде», - дидем. «Документың бармы?» Мин бердәнбер документымны, хастаханәгә бирелгән юлламаны суздым. Карт аны кулында әйләндергәләде дә, печатьне күргәч, тынычланды булса кирәк. Язуны кире биреп: «Сиңа өй артлары җитмимени?» - диде.

Гафу ит мине, «Герасим», синең сүзләреңне туры аңлап, үзеңнең үк өй артыңа «чыккан» өчен. Моның турында яз-

мый булдыра алмадым, чөнки дворник белән очрашу минем күңелемдә зур тәэсир калдырды.

Кунарга урын табарга вакыт җитте. Берәүләр - якындагы вокзал, икенчеләре — чиркәүне тәкъдим иттеләр, тик ул вариантлар миңа ошамады. «Дом колхозника» дигән гостиницадагы вахтер хатын диванда кунып чыгарга тәкъдим итте. Кичне болдырга чыктым, анда өч ир-ат тәмәке тартып һәм ниндидер эш турында сөйләшеп торалар иде. Мин дә алар янына бастым, һәм без сөйләшеп киттек. Аларның берсе - кара мыеклы, кара көдрә чәчле Сережа мине аркамнан кагып: «Ярар, мин сөйләшермен дә безнең бүлмәдә йокларсың», - диде.

Мин бик иртә уяндым һәм әкрен генә бүлмәдән чыктым, танышларым йоклап калдылар. Хастаханә ачылмаган иде әле. Колонкадагы салкын су белән юынып, үземнең кичәгедән калган азык калдыклары белән тамак ялгап алгач, бераз троллейбуста утырып йөрергә булдым.

Тәрәзә янына кереп урнаштым. Троллейбус еш туктый, пассажирларның берсе керә, берсе чыга, ә мин селкенмим дә. Тәрәзәгә ябышып диярлек, матур йортлар, тип-тигез итеп киселгән агачлар (соңыннан моның «урам парикмахерлары» эше икәнен белдем) карап барам. Урам тулы машина, халык каядыр ашыга. Зур су яныннан уздык - ак пароход күзгә чалынып калды: Идел! Мин чынбарлыкны оныттым.

«Әй, малай, без бүтән беркая дә бармыйбыз»,—дигән тавышка сискәнеп киттем һәм шунда гына үземнең кайдалыгымны аңладым. Троллейбуста беркем юк, кондуктор апа ишек янында моңсу гына елмаеп басып тора иде.

Хастаханәдә кичәге зәңгәр күзле кыз мине күреп, аптырап калды: «Син? Ник болай соңладың? Нишлим инде хәзер?» Кулындагы кечкенә генә түгәрәк сәгатенә карап алды да: «Тукта, көт, бәлки, соң түгелдер...» дип сөйләнә-сөйләнә өскә йөгереп менеп китте һәм тиздән озын гына бер ир-ат белән төшеп тә җитте: «Бәхетең, табиб китеп өлгермәгән».

Мине больница киемнәренә киендереп, 14нче палатага озаттылар. Палатаның һәм андагы койкаларның саны бер булып чыкты. Койкалар «П» хәрефе кебек урнаштырылып, уртада зур өстәл тора иде. Бүлмә зур, якты. Өстәл артында минеке төсле үк буй-буй пижама кигән ике егет шашка уйный.

Без, барыбыз да, теге яки бу дәрәҗәдә башкаларга бәйлебез. Башка кешеләрнең безгә карата мәхәббәте, игътибары һәм башка төрле мөнәсәбәте булмаса, без - таяксыз нуль кебек. Һәм мин

зур түземсезлек белән башка күршеләремнең дә кайтуын көттем. Прогулкадан иң беренче булып башына чиккән түбәтәй кигән бабай кайтты. Ул татар кешесе иде. Беренче кичне вәт куркытты ул мине: бармагын авызына тыкты да казналыгын тешләре-ние белән тартып та чыгарды һәм сулы стаканга салып та куйды. Мин башта куркудан өнсез калдым, аннан соң гына аңарда ясалма тешләр булуын аңладым, каяндыр укыганым исемә төште.

Бабай Камышлыдан булып чыкты, колхоз келәтләрен саклаган. Бервакыт бурлар килеп бодай урлый башлаганнар, ә ул күреп алган, шуннан тегеләр аның башына балта белән сукканнар. Үлде дип уйлап, бодайны төяп китеп барганнар. Ә бабай исән калган. Тик вакыты-вакыты белән ул туктый да, төптән киселгән агач кебек идәнгә ава һәм аңсыз хәлдә ята. Мин аны бик кызгана идем.

Икенче күршем дарулар таратырга берничә минут калгач кына кайтып керде. Шат күңелле, аралашучан, ул мине шундук үз кешесе кебек кабул итте.

Бераздан бер  тартма дарулар тотып бүлмәбезгә яшь кенә шәфкать туташы килеп керде. Юка гәүдәле, мөлаем йөзле, эчтән нур бөркеп торган зур кара күзле бу кыз мине күреп елмайды да: «О, бездә яңа кеше бар икән, исемең ничек?» Мин: “Гакыйль”, - дидем. «Матур яңгырый. Беренче мәртәбә шундый исем ишетәм», - диде ул. Аның бу сүзләреннән һәм карашыннан миңа уңайсыз булып китте, битемә кайнар дулкын килеп бәрелде.

Бөтенесе кичке ашны ашарга киттеләр, ишек янында ятучы авыру гына калды. Няня аңа ашарга бүлмәгә китерде һәм теге минем турыда да аңа нәрсәдер әйтте. «Юк, үзең ашыйсың. Ничек инде теләмисең? Сиңа тизрәк аякка басарга кирәк, хатыныңа нинди сүз бирдең, оныттыңмы? Ә аны мин ач калдырмам».

Тиздән ул миңа да бер савыт сөтле аш, ипи һәм бер кружка баллы кайнар чәй китерде.

Кичке сәгать унда «Каракүзкәй» ишектән башын тыгып утны сүндерде дә: «Тыныч йокы, тавышламагыз», - диде. Бер тавыштан барсы да :«Юк, юк», - дип җавап бирделәр. «Беләм мин сезнең «юк»ны».

Дөрестән дә йокларга җыенучы да юк иде: палатада чын тормыш «отбой»дан соң башлана икән. Бөтен авыртынулар, күңелсез тойгылар арткы планга күчте. Анекдотлар сөйләү, укыган китаплар турында фикер алышу, күптән түгел тәмамланган сугыш хәлләрен искә төшерү вакыты башланды.

Күрше койкада ятучы Николай икенче көнне үк мине шахмат уйнарга өйрәтте. Мин шашка уенын яхшы белгәнгә, бусын да бик тиз өйрәндем.

Ике атнадан аны хастаханәдән чыгардылар: ул төзәлә алмаслык баш авыртуы белән китте.

Клиник хастаханәдә без аның белән әле яңадан очрашып, тагын янәшәдә яттык. Операция ясау бүлмәсеннән (баш сөяген трепанацияләгәннән соң) аның башын бинтка чорнап китерделәр, борыны белән авызы гына күренеп тора иде. Шәфкать туташыннан мин аның хәлен сораштым. Николай аңында иде һәм мине тавышымнан танып алды. «Әйе, әйе, бу мин Николай». «Сөйләшмә, көчеңне сакла", - дидем мин аңа.

Бу хәл әле өч ел узгач кына булачак. Ә хәзергә...

Безнең палата табибы — невропатолог Людмила Георгиевна, озын буйлы, мөлаем түгәрәк битле 27 яшьлек хатын. Авыруларга ул бик игътибарлы булып, безгә чын күңелдән ярдәм итәсе килә иде. Аның гадилеге магнит кебек тарта. Бер авыру, шаярыпмы, чынлапмы, аңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясагач, Людмила Георгиевна: «Минем ирем бар бит инде, аны кая илтербез икән?» — дип көлеп җибәрде.

Минем рәсем ясаганымны белеп, ул калын медицина китабы белән зур альбом бите китерде һәм кешенең миен китаптан күчереп ясарга кушты. «Стенд өчен кирәк», — дип аңлатты ул. Мин ясаганда, дәваланучылар килеп-килеп карыйлар һәм: «Бигрәк охшаган», - диләр. «Каракүзкәй» дә ишетеп, миңа ак ситсы кисәге китерде: аңа сирень ботагы рәсеме кирәккән, ул чигү белән шөгыльләнә икән. Янында ук ясап биргәч: «Ах, нинди матур!» - дип сокланды ул һәм битемнән үбеп тә алды. Бер атнадан соң чиккән кулъяулыгын да китереп күрсәтте. Аннан соң «Вазадагы розалар»ны чигеп китерде.

Һәр төн саен палатада берәр вакыйга була иде. Антон Васильевич үлде. Урта буйлы, чәчләренә чал кунган, таза ират иде ул. Аяклары авыртканга күрә, гел таякка таянып йөрде. Кичтән барысы белән бергә көлеп, шаярып домино уйнап утырды әле. Болай буласын беркем дә уйламагандыр: ничек сул ягына борылып, кулын баш астына куеп йоклаган, шул килеш теге дөньяга да киткән мәрхүм. Төнлә дежур шәфкать туташы авыруларны карап чыкканда аның сулышы туктаган була инде...

Кызык кеше иде абзыкай: гомер буе бер зур оешмада бухгалтер булып эшләгән, Пушкин һәм Лермонтов турында бик

күп анекдотлар белә һәм аларны кызык итеп сөйли иде.

Ә менә Петя белән без бер районнан булып чыктык. Озын, ябык кына 18 яшьлек егет, көне буе кырда кызу кояш астында эшләгәч, кыр станына килеп, ике зур кружка салкын су эчә. Кичкә таба башы авырта башлый, температурасы күтәрелә, ә иртән инде берсен дә танымаслык хәлгә килә. Бирегә китергәч, чыгып йөрмәсен дип, ыштанын салдыралар. Ә ул мескен аны - моны белештерми, чыга да китә. Үзен табып китерәләр, караватка яткырып укол кадыйлар, ә ул тартыша, ачулана. Бервакыт аны бөтенләй югалттылар һәм тревога күтәрделәр. Ә Петя Самарка елгасы аша чыга торган күпергә хәтле барып җиткән, милиция табып китереп куйды үзен.

Терелә башлагач, без аңа шул кыланышлары турында сөйли идек, ә ул елмаеп: «Бернәрсә хәтерләмим», - дия торган иде.

Безнең бүлектә яңа шәфкать туташы эшли башлады. Лида тулы гәүдәле, сары чәчле, һәрвакыт елмаеп торучан кыз иде. Безнең палатада ятучы Павел Дементьев белән дуслашып киттеләр болар, Лида көн дә аның янына килә иде, йә булмаса хастаханә бакчасында очрашалар. Кыз киенеп-ясанып йөри, озын сары чәчләре бөтен аркасына сибелеп тора. Мин ничек итеп ул шундый озын чәчләрне ак колпак астына яшерә икән, дип аптырый идем.

... Еш кына иртәнге якта түзә алмаслык дәрәҗәдә эчем поша, радиода Кремль курантлары суга башлаганда, минем күзләр әллә кайчан ачылган була инде (радионы мендәр астымдагы наушниклардан тыңлый идем).

Ерак та түгел урнашкан чиркәүнең чаң тавышыннан күңелгә шомлы уйлар керә, чарасызлык белән ала. Яшәеш һәм үлем турында уйландыра. Безгә кадәр дә күпме халык яшәгән. Вакыт үтәр, бездән соң да яшәрләр, ә без онытылырбыз. Беркем дә безне искә алмас. Кызганыч!

Исәнлегем дә начарая бара. Бүтәннәр киләләр, дәваланалар да терелеп кайтып китәләр. Бәхетлеләр! - Ә мин... Людмила Георгиевна ничек кенә тырышса да, барсы да юкка гына булып чыга. Шундый күңелсез уйлардан арынып өчен, китабымны ачам һәм укый башлыйм.

Бүген, ял көне, хәл белергә килүчеләр күп булды. Ләкин мин генә берсен дә көтмим, чөнки әнием килә алмый, ерак.

Николай калдырып киткән «Королева Марго»ны укып ятам. «Көрәшкәч бирерсең әле», — диде ул күңелсез генә итеп, әйтерсең, киләчәктә очрашуыбызны сизенгән кебек.

Кичке процедураларны тәмамлагач, Лида керде һәм Дементьев янына килеп утырды. «Таш кебек катып калган кыз турында ишеттегезме?» Бөтенебез дә аңа таба борылдык. «Иртәгә бөтен газеталар шуның турында язып чыгачак инде, — дип елмайды ул, чәчен төзәтеп. - Ә менә мин бу сенсациянең шаһиты булдым. Үземнән беренче ишетәсез».

Ә хәл болай булган. Кичә кичен Лиданың иптәш кызы Светлана туган көнен бәйрәм итә. Кунаклар арасында күбесенчә кызлар гына була. Ә Светаның егете армиядә хезмәт итә икән. Биюләр башлангач, кыз кулына икона тотып: «Бүген минем сөйгәнем менә шул булыр инде», - дип әйләнә башлый. Аның әнисе бу хәлне күреп, иконаны тартып ала һәм: «Ходай каргар үзеңне, куй тизрәк! И, Ходаем, кичер шул гөнаһлы колыңны», - дип өч мәртәбә чукынып ала да кухняга кереп китә. Тиздән бу хәл онытыла. Кунаклар төнге беренче яртыда гына таралышалар.

Таң тишегеннән ишеккә шалтыраталар. Светлананың әнисе: «Кем йөри инде шулай иртә?» — дип сөйләнә-сөйләнә ишекне ачса, анда бер әби чукынып басып тора: «И, Ходаем, могҗиза! Кайда басып тора соң ул бичара кыз?». “Сезгә кем кирәк, әби?” - ди Светлананың әнисе гаҗәпләнеп. “О, ишетмәгән-күрмәгән могҗиза бит бу! Шул бичарага тотынып карыйсым килә”.

Светаның әнисе көч-хәл белән теге әбинең «кичне икона тотып биегәч, бүлмә уртасында таш кебек катып калган” кызны күрергә килгәнен аңлый. Әни белән кыз аптырап калалар: кемдер шаярып хәбәр тараткан икән... Беренче шалтыратудан соң икенчесе, өченчесе, бишенчесе...Ишекне ачмагач, аны вата ук башлыйлар. Милиция чакыртырга туры килә.

Лиданы әнисе уята: «Күрше йортта халык җыелган, нәрсә дә булса булган, ахры». Читтәрәк торган бер хатын: «Анда бер кыз...әллә үлгән, әллә таш сын булып каткан», — дип аңлата боларга.

Подъезд янында басып торган милиция хезмәткәрләренә: «Мин монда яшим», —дип алдап, Лида Светаларга килеп керә. Әнисе Лена апа: «Әнә таш булып каткан иптәшеңә соклан инде. Уеннан уймак чыгарды», — дип кызын ачулана. Ә Светаның елый-елый күзләре шешенеп беткән.

Бәлки боларга ышанырлар дип, өйгә ике монашканы кертәләр. Ләкин урамдагы халык: «Алладан куркыгыз, күпме түләделәр сезгә? Кемдер анда бернәрсә дә сөйләмәскә кушып утыра», — дип мескен монашкаларны эт итеп сүгәләр. Һәркемнең

барсын да үз күзләре белән күрәсе килә. Төшкә таба яңгыр ява башлагач кына, төркем тарала башлый.

Туксанынчы елларда минем кулыма соңгы йөз елда булган могҗизаларны тасвирлаган җыентык эләкте. Анда мин әлеге Лида сөйләгән «могҗизаны»да таптым, тик соңыннан әйтүләренчә, чыннан да таш булып каткан кызны кая илткәннәре турында гына бер сүз дә әйтелмәгән. Бәлки Лида да дөресен сөйләмәгәндер, без анда барып карарбыз, дип курыккандыр, кем белә.

... Бер елдан соң яңадан шушы хастаханәгә яткач, мин Лиданы танымадым: сөйкемлелеге кая киткәндер, матур чәчләрен кистергән, ябыккан, битендә ниндидер соры таплар барлыкка килгән, күзләрендә кырыслык чаткылары уйный.

Мин аңардан Дементьев турында сораган идем, ул дорфа итеп: «Бернинди дә Дементьевны белмим», — дип кенә җавап бирде. Күрәсең, әлеге таза егет бик нык хәтерен калдыргандыр...

Алдагы тормышында бернинди өмете булмаган авыруның рухи халәте турында бик җәелеп сөйләп булмый шул. Хастаханә бакчасында минем яныма килеп утырган теге чегән хатыны нәрсә турында уйлагандыр, белмим. Тик ул миңа болай диде: «Син күп укыйсың. Укы, укы! Кайчан да булса син бик акыллы кеше булачаксың. Ләкин...» һәм сүзен дә әйтеп бетермичә, чем-кара күзләрен күккә күтәрде. Ә анда зур кара болыт кояшны каплап маташа, һәм еракта күк күкрәү тавышлары ишетелә иде. Минем язмышыма язган авырлыкларны, чиктән тыш зур сынауларны ул, һичшиксез, белгән, күрәсең, шуңа күрә артыгын сөйләмәгәндер дә. Әгәр дә кешеләр киләчәктә ни күрәселәрен белсәләр, аларның яртысы акылдан язган булыр иде...

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**

# Шулай да була...

Миңа әле тагын берничә мәртәбә шушы өлкә хастаханәсендә дәваланырга туры килде. Берсендә Алып батырдай озын таза гәүдәле, урта яшьләрендәге колхоз бригадиры Сашка абый белән янәшә яттык. Ул җор сүзле кызык кеше булды. Әллә нинди уйдырмалар сөйләп көлдереп, унике сырхау яткан палатаны ду китереп тора иде. Аның уң кулы, кинәт кенә зәгыйфьләнеп, хәрәкәтләнү сәләтен киметкән: “Кичен сау-сәламәт яттым, ә иртән кулым күтәрелми иде”, - дип аңлатты ул үзенең кайгысын.

Профессор Злотоверов – тәбәнәк буйлы, юан гәүдәле, җыйнак ак сакаллы кеше һәр якшәмбедә чирлеләрне үзе кереп тикшерә, дәвалаучы табибларны тыңлый, аларга үзенең киңәшләрен бирә иде. «Койрык» булып аңа ияреп йөрүче башка табиблар, практикадагы яшь-яшь студентлар, кәгазь-каләм тоткан шәфкать туташлары аның һәр әйткән сүзен йотлыгып тыңлыйлар, кенәгәләренә аратирә нидер теркәп куялар иде.

Бүген дә үзенең күпсанлы иярченнәре белән чирлеләрне карыйкарый, профессор күршемдә яткан Сашка абыйга килеп терәлде. Аягүрә баскан Сашка абый янында профессор кечкенә генә бер малай - шалай кебек кенә күренә. Әйтерсең лә, болар Штепсель белән Тарапунька инде: Сашка абый профессорга – өстән аска, ә профессор астан өскә карашалар.

Менә әле дә профессор Сашка абыйның олпат гәүдәсен күздән кичерде дә үзенең соклануын яшерә алмыйча елмайды:

- Теге китапларда, исегезгә төшерегез әле, менә шундый пәһлеваннар янында сурәткә төшкәннәр дә инде алар, - дип искәртте һәм, аның алдына чыгып: – Яле, батенька, честь биреп күрсәт әле, - диде.

Сашка абыйның «честь» бирүе бик алама килеп чыкты. Профессор, дустанә көлеп:

- Что ты, батенька, как бабы?! – дип куйды. Сашка абый, шуны гына көткән сыман, үзенең күк күкрәгәндәй көчле тавышы белән:

– Не бабы, товарищ профессор, а женщины! – дип әйтеп салмасынмы.

Профессор абынып киткәндәй кинәт кенә тукталып калды һәм аның йөзе җитди төс алды; аннан ул, исенә килеп булса кирәк, үзен озатып йөрүчеләргә латинча нидер әйтте; тегеләр ләм-мим, хәтта аз гына да елмаймыйча, барысы берьюлы борылып, минем ятак тирәсен уратып алдылар...

Алар чыгып киткәч, бүлмәдәшләр Сашка абыйны «тәнкыйтьләп» көлешергә тотындылар. Сашка абый аларга, бер дә исе китмичә:

- Ә нәрсә булган? - дип, көр тавышы белән яңадан бүлмәбезне дер селкетте. - Белсен: без дә бит төшеп калганнардан түгел!..

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**

# Матур, кайнар мәхәббәт көтә иде Эля!

Яз күңелне тышка тарта. Мин тәрәз каршында яткан килеш, уйнап-уйнап очкан каргаларны күзәтәм. Көн кояшлы, нурлар көзгедәге кебек ялтырап яткан ак кар өстендә сынып, күзләрне кәмәштерә; әллә инде күзне чагылдырырлык шул яктылыктан, әллә инде каргалар өере сыман бөтерелеп йөргән күңелсез уйларымнан күзләремә яшь бәреп чыга. Ачы яшь тамчылары керфек очларына кунып, тәрәзәдән күренгән бөтен дөньяны томанга күмә...

Яз! Күңел кыллары шундый киеренке - сизелер-сизелмәс кенә искән җилләр кагылышы да, давыллар авазы булып йөрәккә үтеп керә. Тормышның яхшысы да, яманы да ак кар уртасында яңа ачылган җир кисәге әллә кайдан күренгән кебек кискенләшә. Онытылып барган хисләр бөреләрен ача; инде элемтәләр өзелгән, кайда яшәгәнлеге дә билгесезләнгән, кайчандыр бик якын кешеләр искә төшә...

Әйе, яшьләремне сөртеп алган шушы матур кулъяулыкны бик авыр көннәремдә миңа бүләк итүче кыз да кайдадыр еракта-еракта... Мин аңа иң матур шигыремне бүләк итәр идем... Мин аңа йөрәгемне биргән идем инде...

Ул яз да шундый кояшлы һәм тыныч иде. Мин яткан больницага практикант кызлар килде. Алар шуклар, яшьләр, сылулар. Ак халатларын киеп алалар да, ак күбәләкләр сыман иртүк, кайда кирәк шунда йөгерешергә тотыналар. Аларга эш табылып кына тора. Берәрсе бүлмәгә килеп керсә, шатлык арта. Кайбер яшь җилкенчәкләр, алар укол тотып керсә, курыккан булып, күбрәк сөйләшеп-танышып калу исәбе белән юри вакытны озакка тарталар. Ә кайберәүләр сызланмыйча, йөз чытмыйча уколны кабул итәләр - алар кызларга артык түзем булып күренергә тырышалар. Тик ул хәйләкәрләр барсын да аңлыйлар - һәрберебез белән үзләрен бертигез якын- дус тоталар.

Температураны үлчәгәннән соң, бүген мин тагын йоклап киткәнмен.

- Абый, уяныгыз әле! - дигән ягымлы тавышка күзләремне ачсам, караватым янында төнлә дежур сестрага булышкан зәңгәр күзле Эля исемле кыз басып тора иде.

- Абый! - дип кабатлады ул, шатлык тулы күзләрен миңа текәп, - каргалар килгән бит иртән! Шундый көн, ә сез йоклап ятасыз! Мин инде бишне күрдем! — дип елмайды ул. Мин аның матурлыгына сокланып карап яттым. Кайсысыдыр:

- Кияүгә чыгарсың инде, шуның өчен бишлене күргәнсең, - дип калды.

- Юк шул, белмәдегез, семьяда без үзебез дә бишәү, - диде Эля һәм тумбочка өстендә яткан минем даруларны күреп алды.

- Даруларыгызны эчик әле. Кайнар чәй алып килимме, яратасызмы?

Аның сораулы күзләре шулай саф иде ки, миңа хәтта аларга карап тору кыен булып китте. Мин кыяр-кыймас кына:

- Яхшы булыр иде, - дип куйдым.

Бераздан иртәнге аш бирделәр. Мине кашык тотып үзем ашый алмагач, авыруларны караучы апа, я эштән бушаган медсестра ашата иде. Әлеге кызлар килгәннән бирле шуларның берсе ашата торган булып китте. Бу юлы ашны Эля күтәреп кергән иде. Нәрсәгәдер кәефем кырылган, ашыйсы килми иде. Бер- ике генә каптым да: “Туйдым”, - дидем.

- Юк, абый, юк! - диде ул. - Моның белән генә безнең песи дә туймый, ә сезгә савыгырга кирәк. Ботканы ашап бетерәсез. Ботка шундый тәмле. Өстәвенә киселен дә эчәсез әле.

- Туйдым бит, нишлим соң? — дидем мин.

- Ашап бетермичә сезнең яннан китмим, - диде Эля һәм капризланып башын читкә борды.

- Алайса мин иртәгә кадәр ашамаска да риза...

- Ә мин алайса бөтән вообще кермим! - Эля елмаеп, күз чите белән миңа карады. Шулай тартыша торгач, теләсәң дә теләмәсәң дә миңа бирелергә туры килде. Өстәвенә әле, Эля әйтмешли, җенем сөймәгән шул киселне дә эчәргә туры килде. Гүзәллекнең таләбенә каршы кемнең генә йөрәге тора ала икән бу фани дөньяда? Ә кинәт йөрәгеңә якынаеп киткән матур кызларга каршы бигрәк тә...

Ул дежур итәсе көнне шатлыгымны көткән кебек көтә башладым. Аның аяк тавышларын ерактан ук таныйм. Төрле йомышлар табам - аны озаграк үз янымда тотасым килә. Минем бу нәни хәйләмне ул үзе дә сизде булса кирәк - берәр буш минуты булса, әледән-әле безнең бүлмәгә кереп утыра, сөйләшә, юк кына кызыкка да рәхәтләнеп көлә иде.

Май бәйрәме дә килеп җитте. Көн аяз һәм салкынча иде. Бүлмә салкын, пар бирүне туктатканнар иде инде. Без икешәр

кат одеаллар сорап алдык - төнлә туң булган, хәтта кар да сибәләп киткән иде.

Бүлмәдә без икәү генә калдык - бәйрәм алдыннан өчесен савыктырып, өйләренә озаттылар. Минем янда призывник Мишка гына калды. Аның кергәненә атналап бар инде.

“Йоклаганда белмәстән астым юешләнә”, - дип сөйләде, ә шул арада бер дә андый хәлгә калганы юк әле. Башка чире сизелми.

- Врачка алдап сөйләдеңме әллә? - дип сорадым мин аннан туп-туры. Ул бераз уйланып торды да:

- Әби бит... “Шулай дип әйтсәң солдатка алмаслар”, - ди, - дип сөйләп китте. — Өйдә әни дә, әби генә минем, әти үлгән, мин бәләкәй чакта ук... Хәзер куркалар инде, мин китсәм, өйдә ир заты калмый дип... Бу хәл белән минем дүрт еллар элек тә ятканым булды. Әби шуны искә төшерде дә, бәлки калырсың, ди. Соңгы ике елда бу чирнең булганы юк инде... Ятмаска да теләгән идем дә, карт кешенең хәтерен калдырмыйм дидем...

Миша янына әнисе килгән, аны урамга чакырып алдылар. Минем өй еракта. Минем янга бүген килүче булмас, шуның өчен генә күңелне бастырып булмый, билгеле. Бүген бәйрәм көн, бүген ял көне - практикант кызлар да күренми. Эля китергән китапны да укып бетердем. Инде ни эшләргә? Төшке ашка кадәр дә вакыт күп бит әле.

Киткәндә бер иптәш табышмак әйтеп калдырган иде, шуны эзләргә керештем. Күземне йомып, күпме уйланып ятканмындыр, җиңел генә кеткелдәгән тавышка борылсам, ишектә елмаеп, Эля басып тора иде.

- Йоклыйсыз дип торам, - диде ул, җиңел генә элгән халатын төзәтә-төзәтә.- Бәйрәм белән сезне... тизрәк савыгуыгызны телим...

Ул урындык алып, яныма ук килеп утырды.

- Кичкә кунаклар булачак бездә. Эш - эш... Әле көчкә генә өйдән чыгып качтым. Күпкә түгел - әни бер генә сәгатькә отпуска бирде, - дип елмайды ул. Һәм шулай матур елмая - елмая, сумкасыннан төрле татлы ризыклар алып, тумбочкага урнаштыра башлады.

- Әни җибәрде...әни сезне белә ул... Ә менә монысына ачуланмагыз тагын, бәйрәм көнне медицина да рөхсәт итә... - Ул ярты “кызыл”ны алып, болгатып куйды.

- Эля, Эля, - дидем мин, үзем дә сизмәстән “син”гә күчеп.

- Нинди чибәр, кыз син. Тик кара аны, болай җилбәзәклегеңне егетең белеп алса, бик яхшыдан булмас...

- Минем егетем әле үсеп җитмәгән...

- Юк инде, Эля, шундый кызның егете булмауга тавык та ышанмас...

Ул елмаеп миңа карап алды да, башын түбән иде һәм нәфис кулларының алсу тырнакларын карый башлады.

- Бар да, юк та, — диде ул бераздан соң. Ни өчендер аның тавышыннан шатлык авазлары югалган иде. Мин беркайчан да аның болай күңелсез чагын күргәнем юк иде әле.

- Ничек инде алай: бар да, юк та?

- Барын бар ул... Тик мин аның сүзенә ышана алмыйм. Сүзенә дә, үзенә дә. Әйткән сүзендә тора белми ул.

- Бәлки ул алай ук начар егет түгелдер. Бәлки син аз гына ялгышасыңдыр, - дидем мин ничек тә аны юата белмичә.

- Бәлки шулайдыр да... Яхшылыгын да белгәнем юк шул...

Бүлмәдә нинди дер авыр тынлык урнашты. Эля да, мин дә сүзсез калдык.

Мин әле соңрак та бу турыда озак уйланып яттым.

Ул аның сөюен көтә. Ул аның үзен өмет итә. Хыялында инде ул аныкы - йөрәгендә, уйларында бары тик ул гына. Ул "көтелмәгәндә" аның белән очраша, көязләнеп, иң чибәр киемнәрен киеп, матур басып турларыннан үтеп китә. Һич тә булмаса, юк йомышны бар итеп, өйләренә үтеп керә, ул кереп йөри торган кешеләр белән дуслаша, ничек тә аңа якынрак булырга, аны күбрәк күрергә, үзе дә ешрак аның күзенә чагылырга тырыша. Ничек тә аның йөрәген яуларга, аны үзенеке итәргә тиеш ул. Әгәр дә аның өчен янып йөрүче көндәшләре сизенсә, алардан арынырга, мәкерлек белән булмаса, матурлык, акыллык, уңганлык, чаялык белән аларны басып үтәргә, урман алдындагы яшь чыршы сыман, бөтен гүзәллеген җәеп, кояшка үзе генә омтылырга тели.

Йөрәгендә булган сөю хисләрен, күкрәгендә булган бөтен кайнарлыгын, сылу тәненең бөтен татлылыгын җыеп, аңа гына, бары аңа гына тапшырырга тиеш ул.

Язмышы да, гомере дә тик аның белән бәйләнгән төсле тоела аңа. Аңардан башка аңа дөньяда бернинди дә шатлык булмаячак. Дөнья буш һәм караңгы булып күренәчәк кебек.

Ярый ла ул егет кешелекле булып чыкса. Кызның шундый якынлык тоеп, саксызлык күрсәтүенә карамастан, аны озату, сөйләшеп торудан узынмаса. Чыннан да, хәлбуки ул әле

өйләнмәгән егет булса да, яраткан ерактагы кызын якындагысы белмәсә дә, сөйгән ярың була торып, икенче бер ышанучан, җилчән йөрәкне алдау аның кебек ир-егет өчен килешми торган эш иде.

Чыннан да озакламыйча ул китте. Кызның йөрәге өзгәләнде өзгәләнүен, тик үкенүдән ачынып түгел, аны каргап, кайнар яшь тә коймады ул.

Егет китсә дә, кызның күңелендә мәхәббәткә ышанычы да, өмете дә кимемәде. Матур киләчәкне көтү сагышына уралып, иртәнге таүге кояш нуры сыман сүнмәс бер нур гына калды кыз йөрәгендә.

Тапталмыйча калган гөл кебек, матур, кайнар мәхәббәт көтә иде ул.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**

*Менә шулай тәмамлана Гакыйльнең өлкә хастаханәсенә багышлап язылган хикәят-язмалары. Күпме генә кәгазьләр арасыннан бу турыда тагын нәрсәдер булса табылмасмы дип эзләсәм дә, башка берни дә күренмәде...*

Хәер, бернәрсә бар икән бит: “Мин өлкә хастаханәсендә операция өстәлендә кырын ятам. Хирурглар (нейрохирурглардыр инде) умыртканың муен өлешен ачып, аркамның муен өлешен генә тыгызлаучы ниндидер шешне алып ташларга тиешләр. Мин операциянең башлануын сизәм, табибларның үзара нәрсәдер турында сөйләшүләрен ишетәм. Менә аларның тавышы әкренләп югала бара. Ә мин кайдадыр еракта күренгән бәләкәй генә түгәрәк яктылык кисәгенә төбәлгән килеш, рәхәтләнеп, яшәү белән үлем арасындагы бишектә тирбәлә башлыйм. Шул ике - өч сәгать дәвамында ул нейрохирург дигәннәре минем белән ниләр генә кылып бетермәделәр икән?

... Кинәт кенә битем янында ук янәшәмдә чүгәләп утырган бер яшь кызның миңа төбәлгән зур кара күзләрен күреп алам. Ул сөенгән тавыш белән:



**“Тормыш белән үлем арасында”**

- Ул күзләрен ачты! - ди, ә үзе күзләремә туры карап елмая-елмая, кулындагы марля кисәге белән маңгаемны, битләремне сөрткәләп ала...

... Менә мин тагын шушы тормышның шау-шулы, мәшәкатьләр тулы көймәсендә тирбәлә башлыйм...”

*Соңрак ул бу турыда үзенең “Тормыш белән үлем арасында” дип аталган рәсемен иҗат итә. Операция вакытында кайдадыр еракта янып торучы ноктаны күрүе, табибларның аңлатуы буенча, бу аның клиник үлүен кичерүе булган. Әгәр тагын аз гына читкә тайпылсаң, анда төпсез “чоңгыл”га эләгәсең һәм ул сине сулап һәм шаулап торган бу галәм киңлегеннән тирән тынычлыкка һәм хәрәкәтсезлеккә алып китәчәк.*

*Ә Гакыйль исә тормышның матур икәнлеге турында гади һәм мәңгелек төшенчәне үзенең шигырьләре һәм рәсемнәре аша башкаларга да аңлату өчен үзендә көч табып, күзләрен яңадан*



**Каләмне авызга кабып, шундый гүзәл рәсемнәр тудырган бит ул.**

*ачкан һәм аяусыз үлем тырнагыннан котылып, тормышка яңадан әйләнеп кайта алган.*

*Тик бу кайту аңа бик җиңел генә бирелми шул. Үз аягы белән килеп, операция өстәленә менеп яткан Гакыйльне өенә аяклары һәм куллары хәрәкәтсез калган килеш носилкага салып алып кайталар. Шулай итеп, елларга сузылган газаплы көннәр һәм төннәр башлана.*

*Мең төрле уй... Башың гына чыдасын. Аңа минут саен авыртулар һөҗүм итә, газаплар, әрнүләр ябырыла. Егет һәрбер һөҗүмне кире кага - аның һәр минуты көрәш белән үтә, һәр минуты! Торабара өметсезлекне ниндидер ашкыну, омтылыш алыштыра. Яшәргә, яшәргә! Ничек тә яшәргә! Ләкин болай гына яшәү, җан асрау аз, бик аз. Нидер эшләргә, ниндидер яхшылык эшләргә кирәк. Язарга иде, рәсем ясарга иде. Кешеләргә әйтәсе килгән сүзләре, фикерләре дә күпме бит аның!.. Николай Островский шундый хәлгә калгач та язган бит әнә.*

*Уннарча китапларны актарып һәм укып, ул алардан: “Ничек яшәргә?” - дигән сорауга җавап эзли. Тагын һәм тагын бер мәртәбә Гакыйль әле балачагында ук яратып өлгергән Николай Островскийның “Корыч ничек чыныкты”, патриот шагыйрь Муса Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре”н укып чыга да аларның ныклыгына, тормышның иң кыен вакытларында да күңел төшенкелегенә бирешмәүләренә гаҗәпләнү һәм соклану хисе белән карый.Һәм һәр яңа көн үткән саен кеше рухының мөмкинлекләре чиксез булуына ныграк ышана бара.*

*Элеккечә Гакыйль рәсем ясау турында хыяллана. Күзләрен бер генә минутка япса да, аның алдына туган як табигате күренешләре килеп баса: беренче язгы гөрләвекләр, өйләре каршында үскән биек тополь агачлары башындагы оя ясаган кара каргалар, көзен көньякка очып китүче торналар төркеме...*

*Ләкин боларның барсын да кәгазьгә ничек төшерергә соң? Ә бит моның өчен куллар кирәк, ә аның куллары тыңламый шул.*

*Ә менә ничек рәсем ясарга?! Бу кабат язарга өйрәнүдән кыенрак бит.*

*Берничә калын китап өстенә әнисе кәгазь бите китереп куя да, Гакыйль тешләре арасына каләмен кысып, шул кәгазьгә үзенә генә билгеле булган бизәкләрне төшерә башлый. Беренче вакытларда ул берничек тә булачак рәсемнең вак детальләрен ясый алмый интегә, сызыклар да кыек-мыек килеп чыгалар...*



**Гакыйль шигырь язган чакта.**

*Тик "яшь" рәссам бернигә дә карамыйча, тешләрен кысып эшен дәвам итә. Нәтиҗәдә бер-бер артлы аның беренче "Март ахыры", "Топольләр" дигән рәсемнәре дөнья күрә.*

*Ә алар белән бергә рәссамның башында кызыклы уйлар туа, алар тора-бара тигез итеп кәгазьгә төшерелгән шигъри юлларга әвереләләр. Мәсәлән, Гакыйль көньякка таба очып баручы торналарны рәсемгә төшерә дә. Шунда ук шигырь дә барлыкка килә.*

*Кояш та мин күкне күзәтәбез,*
*Күзне кысып язның җиленнән.*
*Бик биектә - ефәк зәңгәрлектә*
*Торналардан чигү чигелгән.*
*Торналарым кайта...*
*Сызылышып якты нурлар аста калалар.*
*Әллә инде алар якты кояштан да*
*Биегрәк юллар салганнар?!*

Кырыенда Гакыйль ята торган тәрәзәдән кара каргалар оя корган биек тирәк агачлары күренә.

*Аяз иртәләрдә*
*Бәбкә казлар сыман,*
*Топольләрем очыра мамыгын.*
*Таң нурлары сызылып кабынганчы,*
*Мин аларны кабат сагындым...*

*Аларның кечкенә генә өйләренең ишеге яхшы теләк белән*

*килгән кешеләр өчен һәрвакыт ачык тора. Ә Иске Фәйзуллада андыйлар шактый күп икән бит. Гакыйль үз алдына радиоалгычлар ясау һәм искеләрен төзәтү өстендә эшли башлый. Почта аша бу турыда ул төрле язулар: схемалар, детальләр яздырып ала. Ә аның икенче мавыгуы – рәсемнәр төшерү һәм аларны ясау... Мәктәп балаларын бергә җыеп, ул алар белән фото- һәм радиотүгәрәкләр ачып җибәрә.*

*"Смена" фотоаппараты белән кызлар һәм малайлар Гакыйль абыйлары кушканча төрле темаларга рәсемнәр төшереп киләләр, ә кичләрен бергәләп аларны ясау белән шөгыльләнәләр. Гакыйль аларга ничек фотопленканы эшкәртергә, ничек раствор ясарга кирәклеге турында өйрәтеп, киңәшләрен биреп тора.*

*Гакыйль һәрвакыт яшь дуслары ясаган фотосурәтләрне караганда аның күзләре алдында туган авылының матур табигать күренешләре: ак каенлы әрәмәлекләре, беренче язгы гөрләвекләр, биек топольләрдә кара каргалар корган оялар килеп баса һәм аңарда аларны ак кәгазьгәә төшереп, рәсем ясау теләге көчәйгәннән-көчәя генә бара.*

*Гакыйль көннән-көн каләмен тешләре арасында ныграк, ышанычлырак тота башлый. Көннән-көн аның язган шигырьләренең, ясаган рәсемнәренең дә саны арта тора.*



Сыерчык.

Иртә тордым тышка чыктым
Бардым бакча янына
Күрдем анда бер сыерчык
Кунган бакча тавына.

Ул көмеш борынын сузганда
Шатлыклы хәбәр сөйли
„И, дусларым рәхмәт сиңа" – дип
Матур көйләрен көйли.

Их матур сыерчыккаем
Мин сине яратамын
Шуның өчен мин сиңа



Бөжәрчек

**Сул якта Гакыйльнең мәктәптә укыганда, операциягә кадәр, ә уңда операциядән соң яңадан язарга өйрәнгәч язган язмалары.**

# Ут эчендә янсам да мин, ахыры яшәп туймамдыр...

## (Гакыйль Сәгыйров көндәлекләре)

Шагыйрьнең архив кәгазьләрен актарып утырганда 1966 елның 3 августы белән тамгаланган көндәлекләр дәфтәренә юлыктым. Бу чакта Гакыйльгә инде 28 яшь тулган һәм 1956 елда ясалган операциядән соң ун ел вакыт үткән булган инде. Бер хәрәкәтсез түшәктә яткан якташыбыз каләмен теш арасына кысып, кабат язарга да, рәсем ясарга да өйрәнгән. Аның шундый пөхтә, матур итеп язылган язмаларына карап хәйранга каласың. Куллары исән чагында язган язу үрнәкләре белән чагыштырганда, болары күпкә төгәлрәк тә төсле әле.

Соңгы вакытларда шактый күпсанлы шигырьләр, рәсемнәр иҗат итәргә өлгергән якташыбыз көндәлегендә аларның бер файдасызга тартмада ятуларына борчылуын да белдерә. Редакцияләргә җибәргән рәсемнәре дә тиешлечә бәяләнмичә кала бирәләр, дип яза ул.

Менә көндәлектәге өметсезлек рухындагы уйланулар әкренләп киләчәккә өмет хисләре белән алышына бара. 1965 елның 5 маенда “Комсомольская правда” газетасында Ирина Цетинаның “Пламенный карандаш Гакиля” дип аталган язмасы дөнья күргәннән соң, Иске Фәйзулла авылына “Социалистик Татарстан” газетасының Нурлаттагы үз хәбәрчесе, яшь шагыйрь Рәшит Зәкиев килеп, аның тормышы, иҗаты белән таныша, Республика басмасында ачы язмышлы шагыйрь турында тәфсилле язма һәм аның берничә шигырен бастырып чыгара. Шуннан соң Гакыйль янына Татарстаннан бер-бер артлы мәртәбәле кунаклар килә башлый: баштан шагыйрь Гөлшат Зәйнашева, Роберт Әхмәтҗанов, язучы Атилла Расих, аннан соң — Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев Сәгыйровның тормышы, иҗаты белән танышып китәләр. Аларның барсын да әлеге дә баягы Рәшит Зәкиев озатып йөри (тора-бара ул Казанга күчеп, озак еллар “Чаян” журналының баш мөхәррире булып эшләде, хәзер аңа 76 яшь инде).

Куйбышев телевидениесе, аннан Татарстанның нефтьчеләр шәһәре Лениногорски телестудиясе журналистлары килеп шагыйрь турында телевизион тапшырулар төшереп китәләр. Алар-



**Луиза Исмәгыйль кызы ӘХТӘМОВА.**

ны Куйбышев, Казан, Мәскәү телевидениеләре дә күрсәткәч, Сәгыйровның тормышы белән кызыксынучылар саны тагын да ишәя төшә. Лениногорски нефтьчеләре килеп, Гакыйль Сәгыйровка телевизор, китап шкафы һәм башка бүләкләр тапшыралар.

Боларның барсын да шул чакта Лениногорски телевидениесендә эшләүче олы йөрәкле журналист Луиза Исмәгыйль кызы Әхтәмова оештыра. Соңрак аның тырышлыгы белән нефтьчеләр берничә тапкыр вертолетта очып килеп, шагыйрьне Лениногорски шәһәре хастаханәсенә алып китеп дәвалыйлар да. Гакыйль Сәгыйров үзенең бу көндәлегендә нәкъ әнә шушы ярдәмчел, гаҗәеп кешеләр турында сөйли дә инде.

Көндәлек шуның белән тәмамланган. Тик шундый кыска гына булса да, вакыйгалар тезмәсе тигез яктыртылмыйча, еш кына өзелеп торса да, Гакыйльнең тойгылары, әйтергә теләгән уйлары яхшы аңлашыла.

Шунысы аянычлы: 2012 елда Луиза Исмәгыйль кызы вафат булган икән. Безгә аның үзен күреп, истәлекләрен ишетү насыйп булмады. Шулай да Лениногорскида нәшер ителүче "Заман сулышы" газетасы мөхәррире Алсу ханым Минебаева миңа озак еллар Лениногорски басмаларында журналист булып эшләгән, Гакыйль белән берүк вакытта хастаханәдә дә дәваланган Римма Вәли кызы Фәттахованың һәм Луиза ханым Әхтәмованың истәлекләрен табарга ярдәм итте.

Алар Лениногорск шәһәре "Заветы Ильича" газетасында 1976 елның 6 сентябрь санында дөнья күргән булганнар.

## Тормышның һәм йөрәкнең үзе кебек бул...

*(Көндәлек)*

**3 август 1966 ел**

*Бүген көн аяз һәм җилле. Көз көнен хәтерләтеп, күктә юка ак болытлар йөзә. Бик матур көннәр. Кайчандыр мин*

*шундый көннәрдә еракларга китеп йөрергә ярата идем. Хәзер дә балаларны өйдә күрү бик кыен. Аларны яңа өлгергән җылы икмәк исе, басулар өстендә туктаусыз күтәрелеп торган машиналар гөрелтесе үзенә чакыра. Бүген табигать исерткеч сихерле көчкә ия.*

*Минем күңел бик төшенке әле. Язарга да, рәсем ясарга да "кул" бармый. Бернинди матур фикер, бернинди рәсем сурәте дә ашкындырмый. Бүген мин буп-буш. Бушатылган мичкә кебек түгел, ә бернигә ярамаслык итеп изеп ташланган кебек буп-буш мин бүген. Менә шундый күңел төшенкелеге белән башладым мин бу көндәлекне. Редакциядән ни өчендер һаман рәсемнәремне кире җибәрмиләр. Шул да бераз күңелне борчыйдыр ахрысы.*

*Җибәрсәләр дә... Ни өчен ясыйм соң мин ул рәсемнәрне? Әллә мин шулай үз-үземне алдап яшәтәм генәме? Кемгә кирәк алар?*

*Һәрнәрсәнең дә үзенә күрә матурлыгы бар. Тик ул матурлыкны күрү һәм күрсәтү ике нәрсәгә бәйле: вакытка һәм шартлы билгеләргә.*

*Матур булмаган акыллы кешеләрнең физик кимчелеге беренче күрүдә артык күзгә ташланса да, вакыт үтү белән, аның рухи матурлыгы ачыла бару белән, тышкы кимчелеге төссезләнә башлый һәм соңыннан бөтенләй югалып кала.*

*Мин бу эшне һич тә эшләмәс идем. Аз гына саурак булсам, кул кысып көрешү өчен бер генә кул булса да кирәк бит миңа! Җаным үкереп каршы торса да, йөрәгем сызласа да, мин аңа: "Килмәгез, хат язышуны туктатсак та начар булмас иде", — дип яздым.*

**4 август 1966 ел**

*Үткән атнада Наил (Гакыйльнең энесе. Редакция) кайткан иде. Мәскәүгә узып барышлый, Башкириядәге таныш кызы туктап киткән, өйләнешү турында сүз чыккач, ул болай дигән икән: "Сиңа ник инде шулай ашыгыч кирәк соң? Абыйларым укып бетергәнче ике ел көтсәң иде... Әниемне ялгыз калдыра алмыйм мин"... Минемчә, акыллы һәм сабыр кыз сүзе бу.*

*Бүген дә минем көн бушка үтте. Каяндыр хат көттем. Юк, килмәде. Иртәгәсе көн миңа нинди дә булса яңалык китерерме икән? Шатлыклырак көн булсын иде.*

**5 август 1966 ел**

*Бүген иртүк бер сәбәпсез башым әйләнергә тотынды. Бик начар хәл бу. Күрәсең, минем тормышымның да соңгы ноктасы куелырга күп калмаган.*

*Л.дан хат алдым. Бик рәнҗегән. Әмма кешене йөз мәртәбә кимсеткәнче, бер генә мәртәбә рәнҗетү хәерледер(?).*

**10 август 1966 ел**

*"Кеше үзенең тышкы кыяфәтен үзе сайлап ала алмый, шулай да, ул тагы да мөһимрәк нәрсәне — характерын сайлый ала. Кеше үзе нинди булырга теләсә, шундый булып тәрбияләнә ала".*

**С.Лавочкин.**

*Үткән ял көнне тагын Наил кайткан иде. Түшәм такталарын кысты. Шунда биш такта югалу беленде. Чама белән кемнәр кереп чыкканын белеп була. Биредән дә килеп алгач инде, ул, мескен, такта юклыгыннан тәмам тинтерәгәндер.*

*Кичә әни белән күрше Мәрьям апа "борчак" бәрешеп алдылар. Аның бозаулары безнең бакчада "йөзгәннәр" икән.*

*Вәли икенче мичебезне чыгарып маташа. Иртәгә бетерер иде дә, кибет артын "сакларга" китмәсә.*

*Куйбышев телестудиясе минем тапшыруда кулланган рәсемнәремнең фотоларын җибәргән. Тапшыруның үзен дә күрсәң иде!*

**17 август 1966 ел**

*Яшьли сөйгән ярым ятка калды,*
*Әйтегезче, дуслар, нишлием...*

*Үзәк өзгеч инде тынычланып бара торган хисләреңне таутау дулкынга әверелдерүче җыр бу. Көе дә, сүзләре дә, башкаручысы да ничек туры килгән!!!*

*"Мең дә бер мәзәк" китабын укыдым. Гаҗәп хәл: минем дә "Чаян"да басылган бер мәзәгем бу җыентыкка кергән. "Чаян"да ул - "Безнең фамилия" дип исемләнсә, биредә "Фамилиясен корбан итеп" исеме астында бирелгән. Шунсы кызганыч: мәзәкнең авторы билгесез диелгән. "Чаян"да язылган иде бит. Күрәсең, билгеле булыр өчен әсәрне язу гына җитешми, тагын нидер кирәк булып чыга.*

**20 август 1966 ел**

*Кичә колхозыбызның яшь механизаторлары Габбас һәм*

*Миннехан күрше районга эшкә киттеләр. Бездә урып-җыю беткән һәм бу комбайнчыларны колхоз шунда ярдәмгә җибәргән. Китәр алдыннан минем белән саубуллашып чыктылар. Шундый минутларда күңел күтәрелә, җанга рәхәт булып китә. Бик истәлекле минутлар алар. Мин бит сезгә гел яхшылык кына телим, егетләр. Өйрәнегез, эшләгез, чын кеше булыгыз!!!*

**21 август 1966 ел**

*Куллар, куллар, нигә сез миңа буйсынырга теләмисез?! Мин аларның шулай ничек эшләргә кирәген белмичә аптырашып йөргәннәрен тешем шыгырдатып карап ятканчы, үзем тотып эшләр идем, үзем теләгәнчә эшләр идем, һәм ул күңел шатланырлык эш булыр иде. Әй, куллар! Нигә сез мине шулай хур итәсез, нигә?*

**23 август 1966 ел**

*Колхоздан бер олау салам сораган идек, бирмәделәр. Киләсе язга чәчү җиткәч, шул ук саламны кибәне-кибәне белән ут төртеп тә яндыралар. Ну и ну!*

*Алар инде мине үлемгә дучар ителгән, йөрәгендә бернинди хис тә булмаган адәмчек итеп саныйлар. Нишлисең бит, таш кыялар арасына кысылган фил дә чебеннәргә азык була ала.*

**14 сентябрь 1966 ел**

*Без инде хәзер (26 августтан бирле) яңа өйдә яшибез. Теге иске өй кебек кысан түгел. Әмма җылыга бик саран булыр ахрысы. Кышын суык булса, бер дә эшли алмам дип куркам.*

*Барсы да өегез матур булган, диләр. Үзем йөреп, кирәген үзем табып, балтасын да үзем тотып эшли алсам әгәр - күрер идегез шунда матур өй нинди булганын! Ә болай - ошамаса да ошый инде, нишлисең, ошатасың инде. Ачка тәмсез, ялангачка ямьсез юк, ди, бит ул.*

*Үз теләгеңне, үз кичерешләреңне тыгыз итеп, тыйнак, матур һәм аңлаешлы итеп тулысы белән әйтеп бирә алганда гына, бераз яза беләм икән дип ышанырга мөмкин.*

*Минем кайбер шигырьләремне укыгач, кара әле, ул да мәхәббәт турында уйлана, космоска очу турында хыяллана, дип мыскыллап әйтүчеләр табылыр бәлки. Исем китми,*

*рәхәтләнеп әйтеп калсыннар. Бөркетнең канаты сынса да, тормышка мәхәббәте сүрелмәс, очу турында теләге кимемәс.*

*Күңелем саф, йөрәгем сау минем. Ул синең хәлсез тәнең белән исәпләшеп тормый, хыял канатында гына булса да сөяргә, замандашлар эшләгән бөек эшләрдә катнашырга омтыла. Менә шундый бит ул минем йөрәк, дусларым. Сез аны гаепләмәгез инде...*

**14 октябрь 1966 ел**

*Минем күптәннән бирле яза алганым юк. Көннәрем шундый берсенә берсе охшамаганнар, язсаң гел бер турыда язылыр иде. Гадәттән тыш хәлләр безнең өйдә бик сирәк була. Болыт арасыннан бер генә минутка күренеп киткән көзге кояш кебек, алар да минем тормышыма нур сирпеп алалар да вакыт чоңгылына төшеп югалалар. Кыска шул аларның гомере.*

*Мәскәүдән сынлы сәнгать институтыннан башлангыч курсны тәмамлаганга язу алдым. Һәр яктан да рәсемнәремә уңай бәя биргәннәр, һәм өч "бишле" тезелеп тора. Тик аларның киләчәге юк дәрәҗәсендә бит. Чөнки мин инде физик яктан беркайчан да хәзергегә караганда тазарак булмаячакмын. Күпме генә тырышсам да, рәсемнәрнең сыйфат ягын шуннан югары күтәрә алмамдыр. Беренче яктан, техникамның бик примитив булуы теләгәнчә эш итәргә ирек бирмәсә, икенче яктан, мин яңа күренешләргә, яңа тойгыларга сусыйм. Кое нинди генә тирән булмасын, аңа чишмәләр су өсти тормаса, бервакыт ул кибәчәк. Кеше йөрәге дә, җаны да шулай ук.*

*Беренче төп курс өчен дәреслекләр дә җибәргәннәр. Программа бик җиңелдән түгел. Ул бит сәламәт кешеләр өчен төзелгән. Белмим инде, ничек кенә үтәп чыга алырмын икән?*

*Менә нәрсә: ни өчен шигырь җыентыкларын вак-төяк китаплар итеп чыгаралар икән. Берничә авторның әсәрләрен бергә туплап, 400 - 500 битле кечерәк форматта бер җыентык ясап чыгарсыннар иде. Тышы киндер, гомуми исемле. Эчендә һәрбер авторның китабы (нәкъ менә шигырьләре түгел, ә китабы) бер-бер артлы тезелеп киткән. Бу китапның юлында нинди кыенлыклар тора торгандыр, ансын күз алдыма китерә алмыйм, әмма шундый җыентык басылып чыкса, укучылар теләп каршы алырлар иде. Бәясе дә артык кыйммәт булмас иде кебек, ә укучы кулына нинди зур хәзинә килеп керер иде!*

**18 октябрь 1966 ел**

*Ике көн элек минем белән очрашырга Зирекле мәктәбе укучылары килгән иде. Ике укытучы, унике бала. Сбор үткәрделәр, мине почетный пионерга кабул иттеләр, миңа багышлап язылган шигырьләрен укыдылар, минем дә берничә шигырем укылды. Җырлар башкарылды. Мәдинә исемле бер бәләкәй кызчык күбәләк кебек очынып-очынып биеп ташлады. Миңа бүләк итеп китаплар алып килгәннәр. Гади укытучылар, гади авыл балалары бит инде, ә дулкынлануымның чиге булмады. Ни өчен? Белмим үзем дә. Җавап итеп берничә сүз әйтергә кирәк булгач, мин бөтенләй югалып калдым. Кирәкле сүзләрне дә әйтә алмаганмын. Нишлим инде, мондый очрашуга мин хәзер түгел идем. Мондый очрашу гомерем дә беренче генә булды бит әле. Сәнгать баскычының иң түбән басмасына аяк куйган булсам да, үзем турыда начар фикергә килеп китүләрен теләмәс идем. Нишлисең бит, теләк кенә җитми икән шул...*

**14 ноябрь 1966 ел**

*Күптән инде мин бу битләрне актарганым, серләремне салганым юк. Байтак вакыт үтте инде. Җир өстен ак кар япты, беренче суыклар килеп, тәрәзәгә чәчәкләр ясап күрсәтте. Инде бөтенләйгә кыш килеп урнашуга да карамастан, кайбер куакларда кызарып кипкән яфраклар җилфердәп торалар. Шундый нык береккән яфраклар да була икән. Нинди куаклар икән алар, картаеп та яшь күңелле булып калган кешеләр кебек, чатнама суыкка, кар-буранга да илтифат итмичә, һаман да әле яфракларыннан аерылырга теләмиләр?*

*Бөтен җир тип-тигез, ап-ак булып калган. Чокырлыклар, вак-төяк елга сызымнары, тирес өемнәре, ямьсез булып күренеп торган башка урыннар күмелеп калган. Тирә-як искитәрлек матур-саф. Суык аяз көнне һәр кар бөртеге көзге кыйпылчыгы булып күзне чагылдырырлык ялтырый. Тимерчыбыклар өшеп "мамыкка" чолганалар. Ә агачлар!.. Әйтерсең лә бер төн эчендә әллә нинди сихри яз килгән дә аларны ап-ак куе яфракка киендергән. Гомеремдә дә әле мин бүгенге кебек искитәрлек булып, дөньяның (табигатьнең) бәскә киенгәнен күргәнем юк иде. Кичке томан эшедер инде бу.*

*Кемдер - бер ялкавы, пумала алып, ак буяу белән зәңгәр күк ефәгенә сирәк-мирәк кенә болытлар сызгалаган. Җил юк. Гүяки ул да дөньяның гүзәллегенә таң калып, әнә шул үрдәге*

*куаклар буенда ял итә. Җилкәй, җилкәй! Бозма әле син бу матурлыкны, койма әле куактан бәсләрне, кар тузаннарын да куып китермә! Бу матурлыкны башкалар да авыз итсеннәр, күреп шатлансыннар. Аннан соң без синең белән икәү ул бәсләрне коярга чыгарбыз. Ул да кызык бит!..*



**Рәшит ЗӘКИЕВ**
(1960 еллар).

*Рәшитнең (Рәшит Зәкиев — ул чакта күрше Татарстанның Нурлат шәһәрендә яшәүче яшь журналист һәм шагыйрь) зарисовкасын һәм минем шигырьләремне "Социалистик Татарстан" газетасында бастырып чыгарганнар. Билгеле, бу минем өчен зур шатлык. Шулай да, ул шигырьләр мәкаләне бераз нигезләү өчен генә басылганнар, дип уйлыйм мин. Чөнки аларның берничәсен мин элек тә шул газета редакциясенә тәкъдим итеп караган идем. Төрле кимчелекләр табылып, газета битенә үтә алмадылар. Инде менә, кимчелекләреннән арындыра алмасам да, мәкаләгә ияреп, газетада күренү "бәхетенә" ирештеләр. Бу минем уңышым түгел, әлбәттә. Белмим инде, минем шигырьләр кайчан да булса "юлбашчысыз" гына матбугат басмаларында күренерләр микән? Булыр микән шундый көн?*

**15 ноябрь 1966 ел**

*Әти, әти! Син бүген безнең белән бергә исән булсаң иде! Син исән булсаң, бәлки мин дә, канаты каерылган кош очарга тилмергән кебек, күзләремне ерак-еракларга төбәп, шул җирләрне күрергә теләп ашкынып ятмас идем. Эх, нинди генә бәхетсезлекләр китермәде бу сугыш адәм баласына!*

*Әле дә бит еракта сугышлар бара. Бомбалар шартлый, тыныч тормыш өчен корылган оялар янып көлгә әверелә. Әле генә үлем турында уена да китермәгән кешеләр мәңгегә күзләрен йомалар. Тол калган хатыннар, ятим балалар яше ага. Әле дөньяның якты нурларын күреп тә өлгермәгән нәниләр ана карынында пуля тигән ана йөрәге белән бергә яшәүдән туктыйлар. Моннан да коточкыч вәхшилек, моннан да зуррак явызлык бар микән дөньяда?!*

*Эх, әти, әти! Беләм мин: сез менә шундый ерткычларга каршы көрәшеп һәлак булдыгыз. Азат илем халкы һичкайчан да батыр улларын оныта алмас!*

*Без дә сине онытмыйбыз.*

*Ул көннәрне вакыт киңлеге ерагайта барган саен сине юксыну күңелләрне ныграк телгәли, сине сагынуыбыз һаман саен арта бара. Әни беребезгә карый да: этиеңә бигрәк охшагансың, ди. Йә берәр эшебезне мактап: этиегез дә шулай итә торган иде шул, дип куя. Һәм безгә әлеге сүзләрне син әйтәсең кебек тоела, җиңел һәм рәхәт булып китә. Син үзең янәшәбездә басып торасың кебек.*

*Берәр кыенлык туса, мин синең рәсемеңне алам да күзләреңә карыйм. Алардан шундый ныклы сабырлык, саф яктылык сирпелеп тора. Гүяки алар: тыныч бул, егетем, бу кыенлыклар вакытлыча гына, син аларны ерып үтәчәксең, мин сиңа ышанам. Юкса, минем карашым да бу кадәр үк тыныч булмас иде, дип әйтәләр кебек. Рәхмәт, эти! Мин синең ышанычыңны акларга тырышырмын.*

*Эти! Син Монголиядә хезмәт иткән вакытта бер иптәшең белән рәсемгә төшкәнсең. Икегез дә хәрби киемнән. Бу рәсем хакында әнигә шулай сөйләп калдыргансың: ул иптәшең казах егете булган икән. Мин туган хәбәрне алып сиңа авылдан хат барып төшкәч, иптәшеңнең дә минем белән бер көндә туган нәни кызчыгы барлыгы беленгән. Һәм сез казах йоласы буенча без нәниләрне ярәштереп тә куйгансыз. Күрәсең, ул дустың белән бигрәк тату яшәгәнсез. Кызганычка каршы, ул дустыңның исемен генә булса да белмибез. Эх, берничә урынга язып карасам да, җавап ала алмадым шул. Беләсе иде ул гаиләнең бүгенгесе көндә кайда-ничек тормыш иткәнен! Кайда соң син, нәни кызчык? Кайда соң син, аның этисе? Кайда соң сез, гүзәл кешеләр?..*



**Гакыйльнең этисе Шәрифулла абзыйның** (уңда) **Монголиядә хезмәт иткәндә казах иптәше белән төшкән фоторәсеме** (1937 ел).

## 21 ноябрь 1966 ел

*Рәсемнәрем - сез минем күзләрем, шигырьләрем - сез*

*минем йөрәгем. Рәсемнәрем, мин сезне ясаудан туктап сукыр калыйммы? Шигырьләрем, сезне язудан баш тартсам, минем өчен ул йөрәгем тибүдән туктауга караганда да авыррак булыр иде. Нишлим соң? Икегезне дә дәвам итәргә минем хәлемнән килми башлады.*

*Рәшит! Син кайчан да булса бу юлларны укырсың. Белеп булмый, бәлки сиңа очрамаслар да алар. Шулай да, биредә генә булса да, мин йөрәгемдәгене әйтмичә кала алмыйм. Рәшит! Минем беркайчан да әле синең кебек эчкерсез чын дустым булганы юк иде. Чиксез рәхмәт сиңа, дустым!*

*Синең якты киң маңгаең, кара кашларың, эчке уйлану-лы коңгырт күзләрең белән бизәлгән түгәрәк, ягымлы йөзең һаман саен күз алдымда тора.*

*Рәшит! Син миңа табигать турында күбрәк язарга, җыр язып карарга киңәш бирдең. Синең киңәшне мин тотарга телим. Ничек булдырып булыр, анысын инде язмыйча белеп булмый. Тик минем шигырьләр бик авыр туалар шул. Чын язучылар болай авырлык кичермиләр инде, билгеле.*

**22 ноябрь 1966 ел**

*Бүген күк йөзен тип-тигез итеп карасу сыек болыт каплаган. Болыт күк гөмбәзенә шундый тигез җәелгән ки, бер генә җыерчык та күренми, кая таба ачылганы да сизелми.*

*Көн җепшек. Түбәдән тамчылар тама. Агачлар да йоклар-йокламас яткан кеше шикелле - уяныплар иде, әле вакыт җитмәгән шул. Әле бу - тирән йокы алдыннан ялның беренче татлы минутларын кичерү генә, һәм агачлар ара-тирә салмак кына, иренеп кенә, хәрәкәтләнеп куялар.*

*Юлларда уйдык-уйдык су җыелган. Казлар да, язны хәтерләткән мондый көнгә шатланып, кызыл тәпиләре белән шул сулар өчендә йөриләр, канатларын кагынып, әллә кайларга яңгыратып каңгылдашалар. Чыпчыкларның да тавышы дәртлерәк чыга. Күмәкләнеп анда-монда очып йөриләр.*

*Табигатьнең шундый минутларын тасвирлаган бер генә шигырь дә укыганым юк әле минем.*

**23 ноябрь 1966 ел**

*Бүген көн минем өчен бик шатлыклы булды — Мәскәүдән педагогтан әйбәт хат алдым. Рәсемнәрем ошаган. Белмим инде тагын кайчан мин аңа рәсемнәр сала алырмын.*

*Казанның “Яшь ленинчы” газетасында ике шигырем ба-*

*сылган. Ике данә газета җибәргәннәр һәм газетага язгалап торырга тәкъдим иткәннәр.*

*Мондый шатлык яңгырына йөрәгем әле күнекмәгән - дулкынланам. Йөрәгем күкрәгемә сыймый башлый, мин тәмам авыруга әверелеп китәм. Берни эшләп булмый. Ачуланып, үзсүзләнеп, бөтен көчемне туплап тотынмасам, берни дә чыкмый - тиз талчыгам, бар нәрсәдән күңел кайта.*

**1 декабрь 1966 ел**

*Төнлә йоклаган килеш үлеп китәрмен, дип куркам. Иң соңгы минутымда да якты дөньяны күреп үлсәм иде.*

*Бертуктамый исереп йөрүче Вәлигә минем йөрәк тойгыларын бер генә сәгатькә биреп торасы иде! Гаиләсен шикәргә дә тилмертүен ташлар иде бәлки. Эшләп тә таба, шуны эчеп тә бетерә ала. Алай гына булса иде әле!*

*Ничек инде шундый авыр сүзләр белән хатыныңны сүгәргә, аямыйча изге тәненә сугарга кирәк? Малае да үзе кебек булачак бит. Монысы инде тагын да аянычрак. Хәзердән үк анасына "сука" дия ала, үзе беренче класста гына укый бит әле.*

*Исерек Вәли... Киң җилкәле, урта буйлы, көчле кеше, акылы да юк түгел кебек. Исердеме — кызганыч усал бер ерткычка әйләнә. Тубал чаклы башында көлтә кадәр чәче тузган, акайган күзләреннән яшь, зур авыз читләреннән селәгәй ага. Өйләренә кайтып керсә, кем дә калмый. Актык тиенгә кадәр алып чыгып китә. Каршы кем очраса да, "гомерлек" дустына я туганына әйләнә ул кеше. Өч баласы һәм хатыны ничек җитте шулай көн күреп баралар. Әйткәч, син аның кан дошманына әвереләсең.*

*Эх, белми бит ул! Шундый кадерле минутларны аракы томанына күмеп, заяга уздырмасаң да әле, безгә бирелгән гомер бик кыска бит.*

**4 декабрь 1966 ел**

*Бу арада бернинди дә хәлләрнең булганы юк. Хатлар килә, аларга җавап язам. Кичен бераз шигырьләр өстендә эшләргә тырышам. Ничек килеп чыга торганнардыр. Киңәшләшергә янында берәр кеше булса иде. Рәшит бар да бит. Ул шул еракта. Хат бит биредә ике атна йөри. Ни сөйләсәң дә, хат ул — тере кеше сүзе түгел.*

**30 декабрь 1966 ел**

*Хәзер генә әле Лениногорскидан килгән кунаклар кит-*



**Гакыйль энисе Хәбибҗамал апа һәм Луиза ханым белән** (1960 елларда төшерелгән фоторәсем).

*те. Алар миңа телевизор, китап шкафы һәм башка бик күп кирәкле нәрсәләр бүләк итеп китергәннәр. Телевизорга антенна куйдылар. Яхшы ук түгел, шулай да күрсәтә. Күрсәтмәсә дә, миңа ансы кыйммәт түгел. Барыннан да кыйммәтрәге шул - дөньяда Луиза (Луиза Исмәгыйль кызы Әхтәмова шул чакта телевидениедә эшләгән журналист редактор) кебек алтын йөрәкле кешеләр дә бар икән. Монысы миңа - иң зур шатлык. Луиза — 30 яшьләрендәге, чандыр гына, урта буйлы хатын-кыз. Чәче коңгырт. Күзләре шундый саф карашлы. Андый караш балаларда яисә бернинди яшерен уйлары булмаган кешеләрдә генә була торгандыр.*

*Руслар арасында күп йөргәнлектәндер инде, ана телен бозыбрак сөйли. Шулай да сүзләре шундый йомшак, ягымлы булып ишетеләләр. Чын күңелдән чыккан өчендер инде ул.*

*Үзләре белән докторны да алып килгәннәр. Ул мине карагач та: "Сиңа дәваланырга кирәк", - диде. "Мин сине өстәл янында утырган килеш кулың белән язарлык итә алам, ә калганын алдан әйтә алмыйм, соңыннан күз күрер", -ди. Минем өчен бусы да нинди зур шатлык булачак. Шулай да алдагы ул көннәр өчен шатланып куярга иртә әле.*

*- Мин синең кебекләргә күп ярдәм иттем бит. Ник мин*

*сине алданрак белмәдем икән соң? Тугыз ел буена бер дә врачларга күренмәдеңмени? - дип өзгәләнә Луиза.*

*- Юк. Больницадан бөтенләй күңелем кайткан иде инде. Һәм менә ни өчен: Куйбышевта хастаханәдә өченче мәртәбә ятканда бер ара минем хәл бик авыр булды. Шунда бер врач күршемнең соравына каршы: өченче ел безне җәзалый инде дип, кулы белән миңа таба ымлады. Ул сүзләрне кабат ишетмәс өчен, әллә нинди газапка да түзәрсең. Мин бу сүзләрне шушы көнгә кадәр кемгә дә әйткәнем булмады. Ул сүзләр йөрәгемә чын-чынлап хәнҗәр булып кадалганнар. Аларны кузгату миңа бик авыр.*

*- Юк, бездә алай булмас. Врач үзе алына бит. Биредә сине карамыйча, ул берни дә әйтмәгән иде. Хәзер әнә нәрсә ди? Борчылма, җаным, - дип елмая Луиза.*

*Киткән чакта ул мине үбеп алды. Бу минем битемә әле иң тәүге мәртәбә хатын-кызларның ирене тию иде. Мин үзем дә белмәстән: "Рәхмәт", - дип куйдым.*

**16 январь 1967 ел**

*Бүген көне буе вак ярма кар яуды. Җил шул карны йөгерә-йөгерә ышык урыннарга тутырып йөрде. Суык. Нәкъ бездәге кышның төп үрнәге бүгенге көн. Инде икенче атна дәвам итә. Әйтерсең лә яңа елга кадәр кар яудыра алмый торган ачуын чыгарырга чамалый. Радиодан, иртәгә дә буран булачак, диделәр. Димәк, мине алырга иртәгә дә очып килә алмаячаклар. 7сендә Луизадан килгән телеграммадан соң, байтак вакыт үтте бит инде. 2 көн аяз да булып алды. Нигә шул көннәрдә килмәделәр икән? Әллә очып чыккач та берәр бәлага дучар булдылар микән? Андый хәл генә була күрмәсен инде. Ярты тиен тормас башың белән шундый иптәшләрнең бәхетсезлегенә сәбәпче булудан Ходай үзе сакласын. Кайгыдан, ник әллә кайчан агу эчмәдем, дип үкенеп үләрсең.*

*Ходай, әгәр дә син чыннан да булсаң, Луиза кебек мәрхәмәт ташып торган йөрәкле кешеләрне күбрәк тудыр җир өстенә һәм гомерләрен озын итә күр!*

**15 февраль 1967 ел**

*(Көндәлектәге бу юллар Лениногорски хастаханәсендә дәваланганда язылганнар булса кирәк)*

*Төн. Сәгать икеләр тирәсе. Коридорда берәү сүгенә:*

*- Йокларга да бирми, анасын сатыйм, акыра да акыра...*

*Ә теге кеше үлем белән тартыша.*

*Сәгать дүрттә үлде. Көндезен сөйгән кызы китергән чәчәкләрнең берсе чәчәк аткан иде. Ул гына күрә алмады.*

**16 февраль 1967 ел**

*- Кара әле, простыняның бигрәк күп җөйлесе эләккән. Тәнеңне авырттырыр, алмаштырыйм әле.*

*Чын күңелдән яхшылык эшләү бу.*

*- Сестра, күземне сөртегез әле?*

*- Хәзер караучыны җибәрәм.*

*Шул да шәфкать туташы була инде?!*

**1 март 1967 ел**

*Төн. Минем бүлмәмдә ут юк. Ачык ишектән бүлмә эченә тонык кына яктылык сибелә. Мин ни эчендер йоклый алмыйча ятам. Ул килде дә нәкъ ишек турысында туктап калды. Ул минем сулышымны тыңлый. Ул бүген дежур. Мин әле аны беркайчан да ак косынкасыз күргәнем юк. Аның кыска чәче бусагадан сикергән тау елгасының мул суы кебек иңсәләренә төшеп тора. Коңгырт күзле, ачык чырайлы, түгәрәк йөзле сабыр гына кыз — Валя исемле. Чын мәгънәсендә чибәр. Ул китәргә кузгалды. Мин аны тагын бер генә минут янымда тотасым килеп:*

*- Су бирегез әле, зинһар, - дидем. Ул су эчертте дә тагы берәр нәрсә кирәкмиме, дип сорады. Аны рәсемгә төшереп, башкаларга да күрсәтәсе иде. Тик минем кебек күреп ясаучы булсын иде. Ә миңа кул кирәк шул, кул. Тел белән сөйләп бирә алмаслык.*

**10 июнь 1967 ел**

*- Сезнең кызыгыз бармы? — дип сорадым мин аңардан.*

*- Бар. Җиде яшендә. Ник алай дип сорадыгыз әле?*

*- Сез аңа да үзегезнең холыкны бирергә тырышыгыз. Ул да сезнең кебек шат күңелле, ягымлы, сизгер йөрәкле булсын. Юкса җир өстендә бер гүзәл чәчәккә ким булачак.*

**12 сентябрь 1967 ел**

*Өченче көн инде мин өйдә. Унында әйләнмә канатлы очкыч (вертолет) белән мине китерделәр. Очкыч тавышы ишетелү белән бар эшен ташлап, халык безнең өй янына йөгерә башлады. Халык шундый күп җыелып өлгергән иде.*

*Больницадан үзем теләп кайттым. Минем врач та, Луиза да өйдә юк иделәр. Алар булса, мине җибәрмәсләр иде, "Курортта дәваланып кайткач кына җибәрәбез", - дип тордылар.*

*Үзләре юк вакытта качканым өчен ачуланмасалар ярар иде. Бу ничектер аларны санга сукмаган сыманрак килеп чыкты бит әле. Үземне тынычландырырга тырышам: Луиза язып калдырган хатымны алса, минем хәлемне аңламыйча булмас. Әгәр дә мин анда калсам, чынлап та сагыштан үләдер идем. Минем эчем дә бик яман авырта башлаган иде бит. Ә аның дәвасын әниемнән башка яхшы белүче юктыр, мөгаен. Хәзер барысы да артта калды инде. Шулай итеп, мин бүген өченче көн үз өемдә.*

*Кичен турыбыздан җырлап яшьләр узып киткәндә йөрәгемнең ничек өзелеп калуын үзем генә беләм. Ул төнне миңа караватта урын юк инде. Алар өйләренә кайтып яткач та әле, җыр, сөйләшү-көлешү тавышлары колак төбемдә чыңлап тора. Юк, ул вакытларда минем ялгыш та яшем чыкмый. Күңелгә моң тула да, әллә ничек кенә итеп, хәнҗәр белән күкрәкне аркылыдан-аркылы сызып кына җибәрәсем килә.*

# Без аның янына вертолетта очып барган идек...

Дөньяда хәтердә уелып калып, мәңге онытылмыйча саклanучы кешеләр була. Шундыйларның берсе минем өчен - ул, әлбәттә Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровтыр, мөгаен. Аның белән мине журналист сукмаклары таныштырды. 1966 - 1967 елларда бу гаҗәеп көчле, чын каһарман, зур талант иясе булган шәхес белән күп тапкырлар очрашырга насыйп булды.

"Комсомольская правда" газетасында Гакыйль Сәгыйров турында күләмле язма басылып чыккач, Татарстанның Лениногорск шәһәре телевидениесе мине Иске Фәйзуллага аның турында тапшыру әзерләргә җибәрде. Ул чакта Куйбышев өлкәсенең (хәзерге Самара) Кошки районында да, төбәгебезнең төньягында урнашкан башка районнарында яшәүче милләттәшләребез кебек үк, Лениногорски телевидениесе тапшыруларын карый алалар иде.

Без операторыбыз белән бергә Иске Фәйзуллада берничә көн кунып, шактый гына күләмле тапшыру әзерләп кайттык һәм 1966 елның көзендә ул эфирга чыкты һәм телевизор караучылар арасында зур теләктәшлек тапты. Аннан соң тапшыруны Татарстан Республикасы телевидениесендә дә күрсәттеләр.

Тапшырудан соң ике - өч ай үттеме икән, "Татбурнефть" тресты (аннан аның исемен УБР "Лениногорскбурнефть" итеп үзгәрттеләр) идарәчесе Николай Михайлович Куликов кабинетында Гакыйльгә трест нефтьчеләреннән бүләккә "Концерт" дип аталган зур телекомбайн әзерләнә һәм аны озакка сузмыйча, Иске Фәйзуллага Гакыйль өчен җирле күмәк хуҗалык төзегән яңа өйгә (бу турыда тапшыруда әйтелгән иде) илтеп урнаштырырга карар кылына. "Яңа өйдә яңа мебель дә булырга тиеш бит инде", - диләр нефтьчеләр һәм яңа шкафлар, өстәлләр дә, урындыклар да сатып алалар.

Акчалата ярдәм турында да онытмыйлар: "Лениногорскнефть", "Иркеннефть" идарәләре комитетлары коллективлары тарафыннан шагыйрьгә шактый зур күләмдә матди ярдәм күрсәтелә.

Минем белән авыру янына Лениногорск үзәк хастаханәсе табибы - невропатолог Вил Хатыйп улы Гыйльманов барырга теләк белдерде. "Үзем барып, барсын да ныгытып тикшерим

әле, бәлки ничек тә булса авыруга ярдәм итеп булмасмы?" - диде ул. Һәм без бергәләп юлга чыктык.

Яңа ел алды көннәрендә шагыйрь яшәгән авылга баруыбыз безнең өчен дә, Гакыйльнең үзе өчен дә уңышлы булып, аңа күп шатлык-куанычлар китерде һәм иң мөһиме, аның күңелендә кечкенә генә булса да өмет чаткысы уятты.

Вил Хатыйп улы авыруны ныклап һәм җентекләп караганнан соң: "Лениногорскига хастаханәгә тиз көндә илтергә һәм дәвалый башларга", - дигән карарга килде.

Тик "Хастаханәгә илтергә" диюе генә ансат. Тышта салкын кыш, кар-буран, ә барыр юл шактый ерак - 300 чакрымнан артыграктыр.

Һәм тагын ярдәмгә шул ук нефтьчеләребез килде. Ул чакта нефть ятмаларына разведкалы бораулау үткәрү конторасы директоры булып бик тә ярдәмчел, мәртәбәле, булдыклы кеше - Иван Игънатьевич Лисов эшли иде. Аңардан ярдәм сорап мөрәҗәгать итүгә ул: "Без сезгә нинди ярдәм күрсәтә алабыз соң? Ә-ә, вертолет кирәк дисезме? Рәхим итегез, бирәбез!" - диде.

1966 елның январь азакларында, үтә дә салкын көннәрнең берсендә, Сәгыйровлар яшәгән йорт янына вертолет килеп төште.

Без Гакыйльне Лениногорски шәһәре хастаханәсенә дәваланырга алып китәргә килдек. Иске Фәйзулла авылының




**«Без аны алырга Иске Фәйзуллага вертолетта очып барган идек»** (1966 ел).

бөтен халкы диярлек аны юлга озатырга җыелган иде. Барсы да аңа теләкләр теләп, кул болгап озатып калды. Бер сәгать дигәндә Гакыйль хастаханәдә иде инде. Аны биредә хастаханә хезмәткәрләре: табиблар, шәфкать туташлары һәм башкалар көтеп тора. Авыру өчен аерым палата да әзерләнгән иде.

Шул минуттан ук дәвалау башланды. Невропатологлар Вил Хатыйп улы Гыйльманов, Равил Шакир улы Алибаев, терапевт Евдокия Михайловна Никитина, массаж ясаучы һәм физкультура буенча инструктор Анна Андреевна Пахомова, хастаханәнең өлкән шәфкать туташы Маргарита Евгеньевна Трищенкова, шәфкать туташлары һәм санитарлар Гакыйльнең хәлен ничек булса да җиңеләйтү өчен барсын да эшләргә тырыштылар.

Менә Гакыйльнең дәвалануына ярты елдан артык үтте дә китте. Һәм ниһаять, беренче нәтиҗәләр дә күренә башлады. Гакыйль беренче мәртәбә шул ук нефтьчеләр бүләк иткән коляскада бер минут дәвамында утырып тора алды. Ә моңа кадәр ул операциядән соң бары түшәктә генә ятарга мәҗбүр иде бит.

Шуннан соң аның шулай коляскада утырулары көннән-көн арта гына барды һәм ниһаять, җәйге матур көннәрнең берсендә аны коляскасына утыртып хастаханә йортына алып чыктылар. Әллә кинәт кенә чиста һава иснәгәнгәме, әллә күп еллар түшәктә генә ятып торырга дучар ителгәнгәме, беренче тапкыр дөньяны яткан килеш түгел, ә утырган килеш күргәнгәме, аңа кинәттән ничектер тын алырга кыен булып китте. Бәлки, аңа ярдәм иткән кешеләргә карата зур рәхмәт хисенең шулай күңеленнән ташып чыгуы нык тәэсир ясагандыр.

Ә Гакыйльнең язмышына бу чорда иң зур өлеш кертүчеләрнең исемнәрен әйтеп тә, язып та бетерерлек түгел. Менә алар - “Татнефть” берләшмәсенең элеккеге җитәкчесе Әгъзам Вәлихан улы Вәлиханов (аннан соң ул озак кына СССРның нефть промышленносте министры булып та эшләде), “Әлмәтнефть” идарәсенең элеккеге начальнигы Ришат Тимергали улы Булгаков ( ул соңрак “Татнефть” берләшмәсенең генераль директоры да булды) һәм “Иркеннефть” идарәсе җитәкчесе Виктор Михайлович Шестеркин һәм инде алда телдә алынганча “Лениногорскбурнефть” идарәсе җитәкчесе Николай Михайлович Куликов.

Гакыйльнең бәласен үзенеке кебек кабул итеп, аңа риясыз ярдәм күрсәткән “Лениногорскнефть” идарәсенең кадрлар бүлеге начальнигы Галина Ивановна Столярованың исемен дә әйтеп үтәргә кирәктер.



**Луиза ханым** (сулда) **Гакыйль яткан палатада.**

Гакыйль турында комсомолның Үзәк комитетында да ишетәләр һәм шунда ук пропаганда бүлеге хезмәткәрләре аның янына тәҗрибәле табиб-консультант җибәрүләрен сорап, СССРның Сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгать итәләр. Берничә көн үтүгә үк Иске Фәйзулла авылы кырыендагы болынлыкка санитар очкычы килеп төшә. Гакыйльнең сәламәтлеген тикшерергә Мәскәүнең Бурденко исемендәге нейрохирургия институты белгече - профессор Владимир Львович Найдин килә. Тик ул дәвалау өчен бернинди дә өстәмә ярдәм күрсәтә алмый инде. Шулай итеп, Гакыйльнең аяк-куллары элеккечә хәрәкәтсез кала бирә. Тормышта зур медицинаның көчсез булган очраклары да була икән шул. “Язмыштан узмыш юк”, - диләр бит.

Шул вакытлардан бирле күп еллар үтеп китте инде. Ә башланып киткән элемтәләребез һаман тукталмый әле. Мин ел саен диярлек Гакыйль янында Иске Фәйзуллада булырга тырышам. Шәһәр комсомол комитетының элеккеге секретаре (аннан соң ул партиянең шәһәр комитеты секретаре булып та эшләде) Виктор Константинович Чаплыгин белән Гакыйльнең туган көне уңаеннан “Лениногорскбурнефть” идарәсе коллективыннан бүләк итеп суыткыч тапшырырга баруыбыз хәтердә калган.

1978 елнын̧ июлендә шәһәр комсомол комитетынын̧ идеология бүлеге инструкторы Наталья Титова белән Сәгыйровларда кунакта булуыбыз да истән чыкмый.

Гомумән, мин үземнен̧ гаиләм - ирем, яшүсмер улым белән дә еш кына аларда була идек. Шулай итеп, без чын гаилә дусларына әйләндек, дисәм дә ялгыш булмас кебек.

Мин үземнен̧ Гакыйль Сәгыйров кебек бөек шәхес - күренекле шагыйрь һәм рәссам белән очрашуым белән горурланам һәм ан̧а аз гына булса да ярдәм итә алуым өчен Аллаһыма мен̧ рәхмәтемне әйтәм. Сезгә дә Ходайнын̧ олуг рәхмәте яусын, мәрхәмәтле кешеләр!

**Луиза ӘХТӘМОВА,**
**Татарстаннын̧ Лениногорск шәһәр**
**телевидениесе журналисты.**
Сентябрь, 1978 ел.

# Ул чын ир-егет иде

Кеше китә, эзе кала, ди халык мәкале. Бу, чыннан да, шулай.

... Төбәгебездә кара алтын чыгу бирегә - Лениногорск җиренә бик күп сәләтле, көчле рухлы, кыю кешеләрне туплый. Шуларның берсе - Луиза Исмәгыйль кызы Әхтәмова иде. Кызганыч ки, ул моннан ике ел элек вафат булды. Ә аның иҗади эшчәнлеге, изге гамәлләре һаман истән чыкмый. Менә тагын үзен искә алып утырырга туры килде әле.

Луиза Исмәгыйль кызының Лениногорск телекомпаниясен ачуда турыдан-туры катнашы бар. Төбәгебезнең бик күпсанлы фидакарь нефтьчеләре, газчылары, төзүчеләре турында очерклар иҗат итте ул. Һәм әлеге язмалар радио дулкыннарында яңгырады, телеэкраннарда күрсәтелде.

Ә аның мәрхәмәтлелек йөзеннән башкарган бер эше - тиңсез батырлык үрнәге дияр идем.

...Самара өлкәсенең Иске Фәйзулла авылында туып, бик яшьли гарипләнеп, тулысынча ярдәмгә мохтаҗ булуга карамастан, үзенең табигый сәләтләрен ачуга ирешкән Гакыйль Сәгыйров исемле егет турында ул кайдан ишеткәндер. Бәлки, бу турыда сөйләшкәнбездер, тик хәтеремдә калмаган. Әмма шунысы миңа мәгълүм: Луиза Исмәгыйль кызы үзенең журналист буларак мөмкинлекләреннән файдаланып, Гакыйльне дәвалау чарасына алынды. Лениногорск үзәк хастаханәсе табиблары белән сөйләшеп, шагыйрьне бирегә алып килү мөмкинлекләрен дә кайгырткан ул. Нефтьчеләр ярдәме белән вертолетта алып килгәннәр аны. Нәкъ шул 1967 елның, ялгышмасам, март ае иде, бугай. Миңа да нәкъ шул хастханәгә дәваланырга ятырга туры килде. Шагыйрь-рәссам Гакыйль Сәгыйров белән мин нәкъ шул вакытны таныштым да инде.

Ничек булды соң бу очрашу? Без дәваланган неврология бүлегендә Гакыйль турында авырулар сокланып та, гаҗәпләнеп тә сөйлиләр иде. Гөлҗиһан исемле дус апам белән без дә янына хәл белергә кердек.

Гакыйль аралашуга бик һәвәс иде. Сөйләшү барышында шуны белдем: Гакыйль турында үзәк матбугатта (“Комсомольская правда” газетасында булырга тиеш) күләмле мәкалә басыла. Аның бу ачы язмышы белән кызыксынганнар күпләп хатлар яза башлый. Хастаханә адресына да көненә дүртәр-бишәр хат килә торган иде. Мин аларны Гакыйльгә укыйм, аннары бергәләп хатларга җавап яза идек. Моның өчен ул миңа бик рәхмәтле иде. Яңа язган шигырьләрен дә миңа укый, ә мин аларны дәфтәргә язып бара идем.

Табиб Вилькым Хатыйп улы Гыйльманов ( ул да мәрхүм инде) аны бик озак һәм бик тырышып дәвалады. Гакыйльнең шактый гомер кичереп, иҗат белән ныклап шөгыльләнүендә аның да һичшиксез зур өлеше бар, дип уйлыйм.

Гакыйль турында тагын шуны әйтә алам: дөньяда төрле кешеләр була. Кайберәүләре, типсә тимер өзәрлекләре дә, зарланып, сыкрап гомер кичерәләр. Ә ул, сәламәтлеге булмаса да, безнең белән бер дәрәҗәдә диярлек яшәп, тормышта тирән эз калдырды. Аның тарафыннан ничаклы шигырьләр, рәсемнәр иҗат ителде, күпме китаплар басылып чыкты. Ул Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителеп, югары дәрәҗәле исемнәр алуга иреште. Кызганычка каршы, мин аңа зур ярдәм итә алмадым. Бераз вакыт хатлар язып тордым да, аннары тормыш мәшәкатьләре баскандыр инде, аралашып, хәлен белеп торып булмады.

Хәер, ул моңа мохтаҗ да түгел иде. Миннән башка да аның дуслары бик күп булды. Иҗатташлары бихисап иде. Аларның һәрберсенә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте яусын. Шул исәптән сезгә, янә аның тормышы һәм иҗаты белән кызыксынучыларга да зур рәхмәтләр әйтеп, иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек телим. Гакыйль әнисенә-энесенә, башка туганнарына да бик рәхмәтле иде. Искиткеч олы җанлы, чын ир-егет иде ул. Авыр туфрагы җиңел булсын.

Үзем турында берничә сүз: белемем буенча мин рус теле һәм әдәбияты укытучысы. 5 ел мәктәптә эшләдем. 20 ел Лениногорскида "Заветы Ильича" газетасында, аннары 10 ел татар телендә нәшер ителүче "Заман сулышы" газетында эшләдем (журналист буларак Гакыйль белән аралашкан чакта минем фамилиям Шебанова иде).

**Римма ФӘТТАХОВА,**<br>**ветеран-журналист, Татарстан Республикасының**<br>**атказанган мәдәният хезмәткәре.**

*Бу хатирә язмасын минем соравым буенча Римма ханым Фәттахова (Шебанова) җибәрде. Шагыйрьнең шул алтмышынчы еллардагы архивында мин Римма ханым тарафыннан аерым дәфтәргә язылган шагыйрьнең шигырьләрен дә, берничә җыр сүзләрен дә очраттым. Шагыйрьнең иҗаты һәм язмышына булышырга теләүчеләр ул гына булмаган, әлбәттә. Шул язмалар арасында Дамира Гайфуллина, Нурсинә дип имзалаганнары да бар. Бәлки бу кешеләр дә күңелләрендә шагыйрь турында якты истәлекләрен, хатирәләрен саклыйлардыр.*

# Бу сәяхәттән без яңа шагыйрь алып кайттык...

Яшь шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның исемен беренче тапкыр «Ялкын» журналында эшләгәндә, моннан алты-җиде еллар элек ишеттем. Әдәбият бүлеге мәдире Г. Сабитов ашыгып керде дә безгә бер шигырь укып күрсәтте:



**Күренекле татар шагыйре Илдар ЮЗЕЕВ.**

*Әй кыш килгән, кыш килгән,*
*Морҗа ак бүрек кигән.*
*Кисмәктәге су туңган,*
*Ватып алырлык булган.*

Шигырь безгә шунда ук ошады. Ләкин аның бер кимчелеге бар иде, автор нишләптер шигырен акка күчереп тормыйча, каралама хәлендә җибәргән. Шигырен журналга тәкъдим иттек, ә үзенә, шелтәләп, хат язып салдык. Редакциягә кулъязмаларны ачык итеп, кара белән язып җибәр, алай ярамый, янәсе. Ул егет шул ук вакытта рәсемнәрен дә җибәрде. Алар гаҗәп матур эшләнгәннәр иде.

Безнең үпкәбезгә аңардан җавап хаты килде. Кыска гына язылган юлларда: «Мин бит инвалид», - диюдән башка сүзләр юк иде.

Берничә ел узгач, «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе, яшь язучы Рәшит Зәкиев сәләтле бу егетнең язмышын газета аша укучыларга хәбәр итте. Үзе турында берни дә әйтмәгән Гакыйль урында хәрәкәтсез ята һәм каләмне тешләренә кабып иҗат итә икән.

Аның иҗаты һәм тормышы белән укучылар ныграк кызыксына башладылар.

Яхшы шигырь безне дә ерак юлга чакырды. Шәүкәт Галиев белән бергәләп,ерактагы Куйбышев өлкәсе Кошки районы Иске Фәйзулла авылында яшәүче Гакыйль Сәгыйров янына киттек. Октябрь Норлаты районында безгә Рәшит Зәкиев тә кушылды.

Һәм менә без аның өендә. Ул да, без дә, әнисе Хәбибҗамал апа да башта каушап, сүз табалмыйча тордык. Китап киштәсендәге бер китап сүзне башларга ярдәм итте.

- «Хөсәен Ямашев». Автор үзе бүләк иткәндер инде?

- Әйе, күптән түгел Норлатка килгәч, Расих абый, Гөлшат Зәйнашева һәм Роберт Әхмәтҗановлар кергәннәр иде.

Без алып килгән әманәтләрне, автограф язылган китапларны, хатларны тапшырабыз. Гакыйльдән шигырьләрен күрсәтүне сорыйбыз. Менә балалар өчен язылган бер шигырь:

*«Антеннада ике карга*
*Тирбәлә кунган көйгә.*
*Шуларны күрде дә Дилә*
*Йөгереп керде өйгә.*
*Әнием, телевизорны*
*Тизрәк инде кабыз, ди,*
*Анда кунган каргаларны*
*Күрмичә калабыз, ди».*

Без рәхәтләнеп көләбез. Балаларча, яңача, үзенчә... Шул вакыт бүлмәдәге телевизорга күз төште. Аны Гакыйльгә Татарстан нефтьчеләре бүләк иткән икән. Лениногорск киностудиясеннән килеп, аны кинога да төшергәннәр. Гакыйльне больницага алып китеп, Ленинорск врачлары дәвалаганнар да.. Вертолет туп-туры Гакыйльләрнең ишек алдына төшкән.

*«Яшәве дә авыр, үлеме дә,*
*Тормыш өчен көчең салмагач,*
*Үзең үлсәң, сине күңелләрдә*
*Яшәтерлек эшең калмагач».*




**Гакыйль СӘГЫЙРОВ түшәктә уйланып яткан мизгелләрдә** (1960-66 еллар).

Бу юлларны укыганда кулына кулъяулык тоткан яшь егет килеп керде. Ул сүзсез генә шигырьне тыңлап торды. Бу юллар аңа тәэсир итте булса кирәк, кызлар бүләк иткән кулъяулыгы белән күзен сөртеп алды.

- Сау булыгыз, Гакыйль абый, армиягә китәм.

Солдатка китүче егет кай ягы беләндер Әсгать Җиһаншинны искә төшерде. 49 тәүлек океанда йөзеп, дөньяны шаулатып кайтканнан соң, мин Әсгать Җиһаншинның туган авылы Шенталыга герой янына килгән идем. Ә Шенталы моннан әллә ни ерак түгел. Гакыйль герой якташы турында элегрәк шигырь дә язган:

*«Күргәнем бар кебек,*
*Таныш йөзләре.*
*Туганнарым кебек*
*Якын үзләре».*

Иң авыр минутларда, инде түзәр хәл калмаганда Гакыйль, мөгаен, якташы Әсгатьне күз алдына китергәндер.

Илебезне сакларга баручы егетниләр уйлагандыр, белмим, әмма ул тирән уйга батып чыгып китте.

Гакыйльнең лирик шигырьләрен укыгач, без дә уйга калдык.

*«Килер бер көн — үкенүдән янып,*
*Газапланып, ятып үләрмен,*
*Әмма мәңге хәтеремдә калыр*
*Матурлыгы тормыш-гүзәлнең».*

Әмма болар тормышның матурлыгын раслау өчен күңелдән тулып чыккан утлы сүзләр. Гакыйльнең шигырьләре моңландыра да, түбән иелгән башны югары да күтәрә.

*«Без житәсе жирләр ерак әле,*
*Без барасы юллар киртәле,*
*Бир ышанып миңа кулларыңны,*
*Чын иптәшем булып күтәрел!»*

Гакыйльнең тәрәзәсеннән карга оялары белән чуарланган топольләр күренеп тора. Гакыйль аларны менә ничек күрә:

*«Аяз иртәләрдә*
*бәбкә казлар сыман*
*Топольләрем очыра мамыгын...»*

Моржасыннан төтен чыгучы өйне күргән шагыйрь менә нинди нәтиҗә ясаган:

*«Аяк-кулын бәйләп куйган язмышының*
*Чылбырларын өзеп читкә атты микән?*
*Моржасыннан нинди кара төтен чыга,*
*Әллә соң ул кайгыларын якты микән?»*

Гакыйль дөньяга художник күзе белән карый: аның сизгер йөрәге табигатьтәге, тормыштагы буяуларны, контрастларны, нечкәлекләрне тотып ала белә.

*«Тормыш агай алып күкрәгемнән*
*Бирсә бирде минем кирәкне,*
*Һаман саен һәрбер матурлыкка*
*Сизгеррәк итте йөрәкне».*

Гакыйль шигырьдә - рәссам, рәсемдә - шагыйрь. Бу китапта сез аның кайбер рәсемнәрен дә күрерсез. Шигырь юлларына кергән теге топольләрне ул натурадан кәгазьгә дә төшергән. Әмма Гакыйль фотограф түгел. Ул топольләрне үз хыялы белән баета, сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә. Шул ук вакытта ул топольләрне Гакыйльнең читкә киткән һәрбер авылдашы танып алыр һәм: «Аһ, шул топольләрне кайтып бер генә күрәсе иде!» - дип әйтер...

Гакыйльнең үзен күргәч, яңа шигырьләрен тыңлагач, элек язылган хатыбыз өчен уңайсызланып киттем. Шигырьдәге һәрбер хәрефне язу яки рәсемдәге һәр ноктаны кәгазьгә төшерү өчен күпме чыдамлык, тырышлык кирәк. Шулай да аның почеркының матурлыгын күреп гаҗәпкә каласың. Шигырьдә дә Гакыйльнең үзе генә тапкан почеркы бар. Шагыйрьнең үзенчәлеге кешенең, табигатьнең матурлыгын эзләүгә, укучыда оптимистик рух уятуга юнәлгән. Гакыйль поэзиянең төрле өлкәсендә үзенең көчен сыный: лирика, сатира-юмор, балалар өчен шигырьләр...

Бу сәяхәттән без үзебез өчен яңа шагыйрь ачып кайттык.

...Дошманнары, сәхнәгә чыгар алдыннан, тылсым иясе Паганининың скрипка кылларын өзеп, бер генә кылын калдыралар. Әмма бөек скрипач югалып калмый, бер кылда катлаулы көйләрне шулкадәр матур уйный, тыңлаучылар кылларның өзелүе турында уйламыйлар да.

Язмыш Гакыйль Сәгыйровның да тормыш кылларын өзәргә уйлаган. Ләкин берничек тә батыр егетнең күңел кылын өзә алмаган. Ул әнә шул өзелмәс нечкә кылда тагы да матуррак уйнар әле.

**Илдар ЮЗЕЕВ.**
4 ноябрь 1968 ел

*Бу язманы күренекле татар шагыйре Илдар Юзеев Гакыйль Сәгыйровның иң беренче “Тормыш җиле” китабына кереш сүз итеп язган булган. Илдар Юзеев кебек дәрәҗәле шагыйрьдән шундый мактау сүзләре ишетү, әле моңа кадәр үзенең иҗатына карата бер генә дә яхшы бәя күрмәгән, Казаннан читтә яшәүче яшь шагыйрь өчен зур шатлык булгандыр, әлбәттә.*

*6 мең данә тираж белән тәүге китабының дөнья күрүе дә аның киләчәк иҗатына яхшы этәргеч ясагандыр, мөгаен.*

*Гакыйльнең иҗат архивы кәгазьләре арасында татар шигъриятенең икенче корифее, күренекле балалар шагыйре Шәүкәт Галиев тарафыннан мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлар өчен язылган шигырьләренә ясалган рецензия дә бар. Анда Шәүкәт ага һәр шигырьне укып, тикшереп, үзенең фикерен белдерә, аларны ничек итеп яхшырту, камилләштерү юлларын да күрсәтә. Бу яшь шагыйрь өчен чын-чынлап бер мастер-класс булгандыр, мөгаен. Шигырьләрнең күбесенә югары бәя биреп, Шәүкәт Галиев "Балык шулпасы" дигәненең читенә: "Менә ичмасам бу шигырь инде! Мин язган булсам иде дип көнләшерлек!" – дип язып та куйган әле.*

*Менә, ниһаять, 1970 елның җәендә Татарстан китап нәшриятында кечкенә генә форматта, 60 кына битле булып яшь шагыйрьнең "Тормыш җиле" дип аталган тәүге китабы дөнья күрә. Анда аның кырыктан артыграк авыл тормышына, табигатенә, биредә яшәүче кешеләргә багышланган көчле мәхәббәт хисе белән сугарылган лирик шигырьләре дә бар. Китапның шактый зур – 6 мең данә тираж белән басылуы да яшь шагыйрьне татар дөньясына танытуда зур ярдәмче булгандыр. Тик Татарстаннан, аның башкаласы Казаннан читтә, күбесенчә руслар яшәгән төбәкнең кечкенә генә бер татар авылында гомер итүче, куллары һәм аяклары хәрәкәтсез калып, башлыча түшәктә генә ятарга, каләмен тешләре арасына кысып шигырьләр язарга һәм рәсемнәр ясарга дучар булган бу талантлы шәхеснең халыкка танылуы җиңел бирелми, әлбәттә. Гакыйльнең "Айбагарлар" дип аталган икенче китабы беренчесеннән соң тагын унөч ел вакыт үткәннән соң гына басылып чыга. Монысы да "Тормыш җиле" кебек үк кечкенә форматта булып, шигырьләрне дә (алар ул чакта ук өч йөздән артык булганнардыр инде) нәшриятка әзерләп тапшырырга да ансат түгел бит.*

*Алтмышынчы-җитмешенче елларда шагыйрьнең иҗатын тулы көчкә яктыртып тору өчен татар телендә нәшер ителүче газеталарның ул яшәгән төбәкләрдә ( Самара һәм Ульян өлкәләрендә) булмавы сәбәпле, аның язган шигырьләре һәм хикәяләре күбрәк өстәл тартмасында кала бирәләр.*

*1990 елда баштан Ульянда "Өмет", аннан Самарада (ул чакта әле Куйбышев) "Бердәмлек" газеталарының чыга башлавы бу хәлгә кискен үзгәреш кертә. Бу турыда Гакыйль Сәгыйров Самара өлкәсенең "Бердәмлек" татар газетасында басылган язмасында да язып чыккан иде.*

# Ул язгы кояшлы көн әле дә исемдә

Бүгенгедәй хәтеремдә: 1990 елның май ае булгандыр, тирәкләр яшел ефәк шәлләрен бөркәнгән, дымсу биек күктә тургайлар җырлаган, чәчәк аткан алма агачларына кунып сыерчыклар сайраган, казларның горурланып куана-куана бип-бип дип аваз бирә торган сары мамык йомгакчыкларын ияртеп, мамык үләнле урамнарга тәүге мәртәбә алып чыккан чаклары иде әле. Кояш нурларында коенган кисәк-кисәк ак болытларга карап, күңелдә туган хисләрне сүзләр белән бәйләргә, шигырь юлларына әйләндерергә тырышып ята идем. Өй каршыннан узган юлда җиңел ак машина күренде һәм ул тизлеген киметә төшеп, йорт тирәсен тотып алган рәшәткә янына килеп туктады.

Кемнәр икән? Хәбәрләшүче дә булмады кебек, дип уйлап алдым мин. Машинадан төшкәч, озынрак буйлысы як-ягына карангалап, көр тавыш белән: «Менә кайда яши икән ул!» - дип әйтеп куйды. Болдырга юнәлделәр...

Гөрләшеп, күңелле генә сәлам бирешкәч, үзләре белән таныштырып үттеләр: озынча буйлысы - Идеал Галәүтдинов, икенчесе - Рәфгать Әһлиуллин икән. Рәфгатьнең моннан берничә еллар элек миндә булганы, ул чакта үзе эшләгән «Волжская коммуна» газетасына минем турыда язып чыкканы исемә килеп төште. Ул үзенә тиешле гонорарын да минем исемгә юллаган һәм бу безгә утын сатып алырга бик ярап куйган иде.

Кунакларның икесе дә «Туган тел» җәмгыяте әгъзалары, хәзер өлкәбездә туган телебездә чыга башлаган “Бердәмлек” газетасында берсе — баш мөхәррир, икенчесе бүлек мөдире булып эшлиләр икән. Газетаның беренче саннарын миңа да алып килгәннәр.

Чәй эчеп, сөйләшеп-киңәшеп утырган арада ике сәгатьләп вакыт узып та киткән. Минем берничә шигыремне, хикәяләремне сайлап алдылар. Саубуллашканда да: «Яз, әйберләреңне җибәрә тор», - дип сораддылар.

Иҗат эше белән шөгыльләнүче башкалар кебек үк, минем дә үзем язган шигырьләремне һәм хикәяләремне газета-журналларда басылган килеш күрергә теләвем аңлашыладыр. Бу хаҗәттән «Бердәмлек»нең чыга башлавы минем өчен зур шатлык иде, иҗатымның алга китүенә дә сәбәпче булган этәргечләрнең

берсе ул дип саныйм. Минем генә түгел, «Бердәмлек»нең башка укучыларының да шигырьләре, хикәя-очерклары, кайгы-хәсрәтләрен, шатлыкларын уртаклашып язган язмалары, чын күңелдән язган хатлары яраткан газетабыз битләрендә даими чыга килә һәм киләчәктә дә шулай булыр, дип уйлыйм.

Әгәр дә халкыбызның тормышын бу кадәр начарлатып ташлаган кризис хәлләре булмаса, аның тиражы да беренче вакытларыннан түбәнрәк төшмәс иде. Хәтта хәзер дә газетабыз үзенең төп укучыларын югалтмады бит. Халкыбыз арасында аның популярлыгы бик зур һәм киләчәктә дә шулай булып калыр, дип уйлыйм.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Димитровград шәһәре,
Ульян өлкәсе.

*Гакыйльнең журналистикадагы иҗаты турында аерым сөйләргә кирәктер. Журналистика — ул вакыт белән бергә баручы профессияләрнең берсе. Аның бөтен жанрлары нигезендә реаль вакыйгалар, һәр көннең конкрет эшләре ята. Тик боларны дөрес итеп тасвирлау өчен бар нәрсәне дә үз күзләрең белән күреп, йөрәгең аша үткәрү кирәк. Ә менә бу төшенчәне Гакыйль бөтенләй инкар итә. Әле “Бердәмлек” битләрендә туган авылы, аның кешеләре, милләтебезнең традицияләре һәм гореф-гадәтләре турында аңардан да яхшырак һәм дөресрәк язучы булганы юктыр.*

*“Бердәмлек” газетасында беренче саннарыннан башлап аның балалар өчен язылган шигырьләре, хикәяләре, экиятләре басылып килә.*

*Аның әхлак, тәрбия, ата-аналарыбыз, картларыбыз, туган халкыбызның мәдәнияте алдында рухи җаваплылык темаларына язылган публицистикасын (“Татар кызлары”, “Ул бит минем улым...”, “Зөхрәбану әби”, “Юныс - Пәйгамбәр исеме” һәм башка язмаларын) еламыйча, бөтен күңел аша үткәрмичә уку һич тә мөмкин түгел.*

*Менә шул язмаларның берсен - “Юныс - Пәйгамбәр исеме” дигәнен бу китапта аерым тәкъдим итәргә булдык.*

# Юныс - Пәйгамбәр исеме

## Әфган сугышында һәлак булган авылдашым турында



Юныс Габбас улы
МИФТАХЕТДИНОВ.

Һәр ил, аерым дәүләт буларак, җир өстендә урын биләп тора. Ул үзенең чикләре бозылмавын, үзе территориясендә яшәүче халыкның тынычлыгын, ирегең, иминлеген тәэмин итәргә тиеш. Моның өчен армия булдыра, аны үзе теләгәнчә, заманынча коралландыра. Һәр дәүләт үзенең чикләреннән дошманның ерактарак булуын тели. Әгәр дошман капка төбенә үк килеп басса, сиңа зыян эшләргә, начарлык кылырга төрлечә җаен табачак. Шул күзлектән карағанда, Советлар Союзының гаскәрләрен Әфганга кертүе совет халкы тарафыннан зур каршылык очратмады: безнең гаскәрләр кермәгән булса, НАТО гаскәрләренең анда кереп, базалар төзеп, безнең илгә каршы төрле провокацияләр ясавы көн кебек ачык иде. Ул елларда «салкын сугыш»ның иң кызган вакыты. НАТО илләре яшерен җыелышып, берничә мәртәбә Советлар Союзына көтмәгәндә һөҗүм итәргә һәм Советлар илен бөтенләй юкка чыгарырга җыеналар. Хәзерге вакытта аларның яшерен уй планнары ачыклана бара. Советлар Союзының Кораллы Көчләре мондый һөҗүмне кире кайтарырга сәләтле булуы һәм агрессорларның «җавапсыз калмаулары» гына империалистларны андый башсызлыктан туктатып калган.

Безнең Иске Җүрәй авылы егете Юныс Габбас улы Мифтахетдинов армиянең Әфганстанга кертелүенә өч ел тулганда армия сафларына хезмәткә алынган иде. Әтисе тракторчы булып эшләгәнгә, Юныс та кечкенәдән трактор-машиналар тирәсендә кайнашканга, аларны йөртә, төзәтә дә белә иде. Шуңадыр инде

әзерләү пунктында өч ай укытканнан соң, БТР йөртүчесе һәм мөселман кешесе буларак, ул Әфганстанга җибәрелә...

Бу малай безгә дүртенче-бишенче сыйныфларда иптәшләре белән килгәләсә, җиденче-сигезенче сыйныфларда һәр көнне диярлек минем янга килмичә калмады. Безнең ныклап дуслашып китүгә кечкенә генә бер вакыйга сәбәпче булды.

Бәрәңгеләр өлгереп килә. Әни бакчада әлеге җанга тигән коңгызларны чүпләп йөри. Көн аяз, җилсез, эссе. Бакчадагы куаклар артыннан самокатта Юныс килеп чыкты. Гадәтенчә яла624наяк, балакларын сызганып куйган. Күрәм, нигәдер бик ашыккан, самокатын сөяп тә тормады, җиргә егып салды да ишеккә йөгерде. Артыннан куып килгәннәр шикелле сулышы капкан.

- Нәрсә булды? - мәйтәм. - Ник болай ашыктың!

- Гакыйль абый, мин йомыш белән килгән идем, - ди. - Радионы ваттым бит әле. Әти кайткач, кирәкне бирә инде үземнең. Төзәтеп булмас микән шуны?

- Алып ук киләләр бит аны. Вакыт үткәреп йөрмәскә идең, - дим.

Әтисе Габбас абый бик кырыс кеше иде. Ул елларда радиолар сирәк кешедә булганга, әтисе кайткач, өйдә тавыш фәлән чыгарыр дип шикләнгәндер инде Юныс.

- Самокатка куеп алып килмә, дыңгырдата-дыңгырдата тагын әллә кай җирләрен җимереп бетерерсең .

- Юк, мин аны күтәреп кенә киләм.

«Рекорд» радиосын төзәткәләгәнебез бар иде. Гомумән, исемнәре төрле булса да, радиолар бер принципта эшлиләр бит. Юныс радиосының бер конденсаторы тишелеп чыккан икән, тавыш динамикларга килмичә, шуннан гына агып, әйләнеп йөри. Ярты сәгать тә үтмәде, шатлана-шатлана радиосын алып китте егетем.

Юныс буйчан, какча гәүдәле, таза буынлы булып үсеп килә. Аңардан беркайчан начар сүз ишетмәссең. Кечкенәләргә һәм кызларга аеруча игътибарлы. Безгә килеп йөрүче малайлар арасында ул үзенең йомшак холкы, эшчәнлеге белән аерылып тора. Килгән саен миннән, нәрсә эшлим, әби, берәр эш куш әле миңа, дип кызык итеп әйтеп куя иде. Коедан су китерүме, мичкә утын кертүме, сукмакка өелгән көртне арчып ташлаумы - минуты белән эшләп ташлый иде. Кечкенә малайларның берәр әйбере бозылса да, мин аларны, хәзер Юныс абыегыз килер, ясап бирер үзегезгә, дип тынычландыра идем.

Бервакыт Юныс миннән: «Сезгә кызлар-малайлар күп килә, алар арасында «начар» куллылар бар бит. Берәр әйберегез

югалганы бармы!» - дип сораган иде. Мин аңа җавап итеп: «Бер әйберем дә югалганы юк. Бөтен әйберләрем менә сезнең алдыгызда бит: аласыз, кирәк әйберне төзәтәсез, урынына куеп калдырасыз. Андый кешеләрне мин генә күреп бетерә алмам, билгеле. Сез үзегез дә карыйсыз, андыйлар сездән дә шикләнәләрдер. Мин сездән бернәрсәне дә яшергәнем, кызганганым юк. Шуның өчен нигә соң урлап китәргә?» - мин әйтәм.

Миңа урманнан озын колга кайтарганнар иде. Яңа антенна ясап күтәрдек. Антеннаны катлаулырак итеп, радиосигналлар җәтмәсен куерак иттереп ясаткан идем. Күрәсең, артыграк тырышылган. Колганы кабат егып торганчы, очына үрмәләп менеп, ике чыбыгын кисәргә кирәк. Антенна биек - унбишуналты метрлы. Юниска әйткән идем, ул урамга чыгып озак кына өскә карап торганнан соң, керде дә:

- Куркыныч. Бигрәк биек, - дип әйтеп, урындыкка утырды.

- Колга бик нык, сына торганнан түгел. Астагы аркылысына менеп баскач, кайчы белән кирәксез чыбыкларны кисәргә мөмкин. Әйдә әле, үзем карап, әйтеп торырмын, - дип мин дә коляскага утырып урамга чыктым. Башка балалар да, безнең нидер эшләгәнне күреп, берәм-берәм ныбызга җыелдылар.

Сабантуйларында әтәч куелган колгага Юнисның еш кына үрмәләп менгәне бар иде инде. Хәзер дә, кыюлыгын җыеп, югарыга үрмәләде. Бераздан инде Юнис, кирәк эшне эшләп, түбән төшкән иде. Шунысы кызык: төшкән чакта, бернидән дә курыкмыйча, антенна аумастан тарттырып куелган чыбыкны келәшчә белән эләктереп тотып, шуның буйлап выжлап шуып төшкән иде. «Антенна җилдә селкенеп тора икән, менгәч тә куркыныч булып китте. Өстән карагач, тирә-як тагын да матуррак күренә икән», - дип елмайды.

Юнис турында сүз чыкканда тагын бер эпизодка тукталмый үтә алмыйм. Бу хәл яз көнне ташулар китәр алдыннан булды. Казаннан миңа китаплар килгән, шул посылканы почтадан алып кайтырга кирәк иде. «Күперне су баскач, боз өстеннән генә чыгып йөрибез, бик куркыныч», - диде хат ташучы миңа посылка язуын биргәндә. Ике авыл арасы дүрт чакрым тирәсе, уртадан елга ага, ул мөлдерәп тулган, бозлар китәм-китәм дип торалар, кузгалып китәргә җай гына көтәләр сыман. «Үзем барып кайтам», - диде Юнис. Мин, күңелем нидер сизгән шикелле, теләмичә генә ризалаштым. «Әз генә куркыныч булса да, боз өстенә кермә, кире кайт», - дип кисәттем.

Ә эш болай булып чыккан. Китапларны почтадан алганнан соң, Юныс яр буена юнәлгән, боз өстенә сикереп кергән. Боз, чайкалудан, кузгалып китсә дә, Юныс каушап калмаган. Агып баручы бозлар безнең авылга җиткәндә борылышта сөзәк яр битенә якын ук киләләр, кайберләре хәтта яр өстенә дә менәләр. «Мин бер дә курыкмадым, җырлап та кайттым әле. Теге борылышта башта китапларымны ташладым, аннан үзем сикереп калдым», - дип сөйләде Юныс. Шундый кискен очракта да куркып калмаган, паникага бирелмәгән бу егеткә минем хөрмәтем тагын да арта төште.

Ул Куйбышевта (хәзерге Самара шәһәре) токарь-фрезеровщикка укып чыкты. Анда бер елдан артык эшләде. Кайткан саен, төн уртасында булса да, минем янга килә иде, килмичә калганы булмагандыр, мөгаен. Кайтуының берсендә озакламый армия хезмәтенә алыначагы турында әйтте. «Әтиләр дә армиядә булганнар, безгә дә барып кайтырга кирәк инде. Илне без сакламый, кем сакласын. Ул электән килгән безнең бурыч. Мин моны яхшы аңлыйм. Анда барып дөнья күреп кайту да начар булмас. Безнең солдатларны, безнең коралларны күрәсем, кулыма тотып, сынап карыйсым килә», - дигән иде.

Менә аның да китәр көне җитте. Шәһәрдән кайткач, өйләрендә җыелган кунаклар янына утырганчы, тиз арага минем янга килеп китте. «Менә сиңа күчтәнәч алып кайттым, Гакыйль абый, - дип, кесәсеннән бер төргәк чыгарып өстәлгә куйды. - Сез монда төрле нәрсә ремонтлап маташасыз бит малайлар белән, сезгә кирәк булыр болар». Ул үзенең эшли торган тимер борауларын, кискечләрен алып кайткан икән. Юныс калдырган кайбер әйберләрне әле дә истәлек итеп саклыйм.

Кичен клубта аны озату кичәсе булды. Иртәгесен йөк машинасы әрҗәсен тутырып баскан кызлар-егетләр, гармун уйнатып, авылны әйләнделәр. Юныс һәр йортка диярлек кереп, саубуллашып, өлкәннәрнең хәер-догасын алып йөрде. Минем янга да кергән иде. Истәлеккә дип, матур итеп чигелгән, кызлар бүләк иткән ике кулъяулыгын биреп калдырды. Һәм миңа: «Гакыйль абый, «Айбагарлар» китабың чыккач, миңа да җибәр. Иптәшләрем алдында күрсәтеп, мактанырмын», - дип киткән иде. Кызганычка каршы, ул китабымны мин аңа җибәреп өлгерә алмадым. Бөтен авылны кара кайгыга күмеп, цинк табутта аның гәүдәсен кайтардылар.

«Юныс үлгән» дигән хәбәрне кемдер кереп әйткәч, җаныма якын яшь кешенең шулай вакытсыз гомере өзелүенә, тетрәнеп

калдым. Туганнары, сөйгән кызы бу коточкыч авыр хәлне ничек кичерүләре хакында уйланырга мөмкин.

Юнысның әтисе Габбас абый кадерле улын үз күзе белән күрмичә күмдерергә теләмәде, тимер кискечләр, чүкечләр алып кереп, цинк табутны ачарга керешә. Әмма табутны озатып килүче лейтенант һәм ике солдат моны эшләргә ирек бирмәделәр: «Приказ белән тыелган. Тыңламыйсыз икән, атарга да безнең хокукыбыз бар», -дип, кайгыдан зиһене тәмам тарала башлаган Габбас абыйны юатырга, үзләренчә бераз тынычландырырга тырышканнар: «Сез генә түгел инде, нишләп тә булмый... бәхетсезлеккә каршы, илгә цинк табутларны еш кайтарырга туры килә шул безгә...»

Солдатларның берсе Юнысның ничек вафат булуын сөйләп биргән: "Елга үзәненнән барган чакта безнең БТР танкларга каршы куелаган минага эләкте. Минаның шартлавы алгы рәттә Юныс утырган якта булган, көпчәкне алып очырган, калын тимер кисәкләрен әзеп, бөгеп бетергән, Юнысны китереп кыскан. Ул бик каты яраланган һәм шунда ук җан биргән. Экипаждан тагын дүртебез үлгән, ә калганнарыбыз, шул исәптән мин дә, контузия алган идек. Ул бик яхшы дус, нинди дә булса ярдәм кирәксә, моңа һәрвакыт әзер иде. Туган авылы турында, андагы кешеләр турында кызык итеп сөйләргә ярата. "Минем яратканым" дип, бер кызның фотосын да күрсәткәне бар иде".

Иртәгәсен аны соңгы юлга озаттылар. Ул көнне мәктәптә укулар булмады, бөтен авыл халкы зират тирәсенә җыелган иде. Аны хәрбиләрчә олылап күмделәр.

Юныс — Пәйгамбәр исеме. Бала ана карынында чакта ук аңа кушыласы исемне Аллаһы Тәгалә ата-аналарына, туганнарына эшкәртеп куя икән. Җисеменә күрә исеме дигәндәй, бу киң күңелле, һәркемгә җылы, ягымлы карашлы, игътибарлы, итагатьле егет шундый үкенечле үлемгә дучар булмаса, алдагы көндә күпләр өчен үрнәк ир булып яшәр иде.

Клубка һәм Юныс укыган мәктәпкә безнең өйдә бергәләп эшләнгән фотолары куелып, аның тормышы турында төзелгән стендлар күп еллар эленеп торды.

Юныс турында хәзер күпләр белми инде. Үткән ел аның туган энесе Илдус та, энисен, гаиләсен алып, Самарага күчеп киткән. Минемчә, бу озакка түгелдер. Авылда туып-үскән, авыл тормышына өйрәнгән кешеләр шәһәргә күнә алмыйлар. Әгәр дә мөмкинлек туса, мин үзем дә бүген авылыма кайтып китәр идем.

80нче елларда мәктәп җирлегенә Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларым истәлегенә куелган монументны укучылар карап, тирә-ягын чистартып, чәчәкләр утыртып, тәрбиялиләр иде. Хәзер исә мәктәп бинасы яңа урында булгангамы, әллә мәктәптә башка төбәкләрдән килгән укытучылар булу сәбәплеме (җитмәсә, әле рус телендә сөйләшүчеләр генә), авыл тарихына бик салкын карый башладылар. Авылдагы һәр гаилә өчен кадерле исемнәр язылган монументка да мөнәсәбәт бөтенләй үзгәреп киткән. Ул әрекмән, кычыткан, кырмавык, тигәнәк арасында калган.

Кайчандыр авылыбызның йөзен матурайту, төзекләндерү турында сүз йөри башлаган иде. Дөрестән дә, иске мәктәп бакчасын кечкенә парк иттереп, утыргычлар куеп, җәйге гаҗәеп кичләрдә җырлау-бию, очрашу, сөйләшеп утыру кебегрәк урын итсәң, начар булмас иде. Монументка армия сафларында корбан булган тагын берничә исем, шул исәптән Юныс исеме дә, язылып куелырга тиеш. Әгәр укучылар шул монументны биредә җентекләп кадерли алмыйлар икән, аны яңа мәктәп бакчасына күчереп кую хәерлерәктер. Авылыбызның батыр уллары турында хәтерләтеп, чәчәкләр эчендә басып торырга тиеш бит ул!

Хәзерге кырыс заманалар үтәр. Авылыбыз яңадан хәл алып, аякка басар һәм үзенең 100 еллык юбилеен матурайган, төзекләндерелгән урамнары җыр-биюгә, шатлыкка тулган килеш каршы алыр, дип уйларга тиешбез. Моның өчен уйлану-хыялланулар гына җитми, инициативаны үз кулыбызга алып, җиң сызганып, булган көчебезне куеп эшлик әле. Кайчандыр авылыбызның урамнары бик матур иде бит, килгән кешеләр, кунаклар сокланып туя алмыйлар иде. Күркәмлеге белән киткән кешеләрнең төшләренә кереп, туган авылын сагындырып, елатырлык булсын иде.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Иске Җүрәй авылы.

*Гакыйльнең милләтебез, туган телебез турында борчылып язган язмалары да байтак. Әле 1991 елда ук "Бердәмлек"тә "Милләтебез яшәсен дисәк..." дип аталган язмасы басылган иде. Шуны без сезгә дә тәкъдим итәргә булдык, хөрмәтле укучыларыбыз!*

# Милләтебез яшәсен дисәк...

Күптән инде мин бу турыда үз фикерләремне әйтеп үтмәкче булган идем. Күңелемдә күтәрелгән әлеге уйлар, җир астында көч туплап яткан һәм, берәр җай табылып, бәреп чыккан чишмә сыман, сүзләргә әверелсен өчен этәргеч булып күрше авылдан килгән апай белән сөйләшеп утыру җитә калды.

- Улым беренче класска керде быел, шуны озата барган идем. Беренче сентябрь хәзер «Белем бәйрәме көне» дип атала икән. Уку елын башлап җибәрү тантанасы һәрвакыт мәктәп йортында үткәрелә. Матур киенгән укучылар дуртпочмакланып тезелеп басалар. Җәен колхозга ярдәм итүче укучыларны бүләклиләр, кечкенәләрне беренчегә кабул итәләр, чәчәкләр бүләк итәләр. Милли мәктәп булгач, мин инде, быел мәйтәм, башкача үтәр дип көткән идем, кая ул, тамчы да үзгәреш юк - шул ук урыс телендә җырлау, шулай ук тәбрик итү сүзләре. РОНО хезмәткәре русча да сөйләсен, ди инде, ә бит мәктәп директоры, укытучылар - барсы да үзебезнең кешеләр ич. Ә русча сөйләүчеләрне әйт син тагын - һәр җөмләсе «чыктым аша күпер» генә бит, ичмасам, бер сүз татарча ишетмәдем. Шунысы йөрәккә тия, - дип гарьләнеп утырды Сания апай.

Минем зур игътибар белән тыңлавымны күргәч, сүзен дәвам итәргә булды.

- Күптән түгел шундый кызыклы хәл булып алды. Клубка концерт карарга җыелган идек. Концерт алдыннан авыл Советы председателе сәхнәгә чыкты да, русча: «Хәзер, - ди, - РОВД представителе Сафин Михаил Борисович выступит», - ди. Зал тып-тын калды. «Кем икән бу!» - дип көтәбез. Чыгып басса, зал кычкырып көлеп җибәрде, милициядә эшләүче үзебезнең авыл малае Мидхәт булып чыкты, шуны татарчалап әйбәт кенә иттереп әйтергә була иде, ләбаса. Ә ул - Михаил Борисович! Кешеләр алдында шулай мәсхәрә булырга ярыймы соң!

Дөрестән дә, бу - безнең халык арасында еш очрый торган ямьсез күренешләрнең берсе. Үзләренең чыкылдап торган матур, затлы исемнәрен алыштырып, башка телдәге колакны кисеп үтә торган, безгә килешми торган исемнәр белән аталучы егетләр, кызлар бик күп бездә. Шуны истән чыгармаска кирәк: исемнәр бер телдән икенче телгә турыдан-туры тәрҗемә ителми, ягъни кемнең дә булса исеме башка телдәге шуңа охшашрак исем белән алмашынмый. Әгәр дә без Карл Марксны

русчалатып Константин Маркович яисә башка төрлерәк итеп әйтсәк, кем турында сүз барганны һичкем аңламас, үзегезгә дә көлке  тоелыр иде.

Кайбер рус егетләре, кызлары: «Син татар булгач, синең чын исемең ничек?» — дип сорыйлар. Алар хаклы — кешенең тугач ата-анасы биргән-кушкан бер генә исеме булырга тиеш. Безнең исемнәрне теләсә нинди телдә дә бик матур итеп әйтәләр. Беренче танышкан чакта үк исемеңне дөрес итеп әйтергә кирәк. Әгәр беренче үк дөрес итеп әйтә белмәсәләр, төзәтеп әйт, моның бер дә ояты юк. Руслар да Гөлшатны — Гульшат дип, Рөстәмне — Рустам дип бик матур итеп әйтәләр. Моның белән горурланырга кирәк. Мәскәүдән Айсылу исемле кыз кайтып йөри. Безнең авыл кызы Фисалия - аның дусты. Айсылу Мәскәүдә туып үскән, әйбәт итеп безнеңчә сөйләшә, шәһәр кызы да димәссең. Айсылудан:

— Фисалия белән  ничек табыштыгыз соң? — дип сорадым.

— Метрода. Алар иптәш кызы белән сөйләшеп төшеп баралар. Татар кызлары икән, дип яннарына йөгердем.

— Фисалия, сез Мәскәү урамын яңгыратып  татарча сөйләшеп йөргәнсез. Оят түгелме соң алай?

— Әллә мин урлап тотылдыммы? Үз телемдә сөйләшергә кемнән оялып торыйм, ди, белмәсәң оят булыр иде.

Фисалиягә бу сорауны мин тикмәгә генә бирмәдем. Күплӓрдән ишеткәнем бар: «Зуп-зур шәһәр урамында оялмыйча татарча «лыгырдап» йөри дигән сүзне». Үз туган телеңдә сөйләшү кемгә оят китергәне бар икән, руслар — русча, чувашлар — чувашча сөйләшсен. Ә бәлки алар үзләренең татар булуларыннан хурланалардыр. 150дән артык Советлар Союзы Герое булган татар халкының улына-кызына хурланырга бер дә урын юк. Киресенчә, горурланырга кирәк.

Илленче елларда безнең авыл мәктәбендә татар телен Фатыйма апа Ибәтуллова алып бара иде. Ул вакыттагы укучыларда туган телебезгә ихтирам һәм мәхәббәт уятканы өчен аның алдында баш иеп, чын күңелемнән рәхмәт әйтәсем килә.

Мин укыган чакта ук рәсем ясый, шигырьләр язгалый идем. Кайберләрен мәктәп стенгазетасына да яздылар. Ул вакытларда туган телемне чынлап өйрәнмәгән булсам, хәзер миңа бик кыенга туры киләчәк икән.

Үз туган телеңне белү кемнең йөзенә оят, кемнең тормышына зыян китергәне бар икән соң! Минем күптән язылган бер шигырем бар. Мин аны кая да тәкъдим иткәнем юк, элек

аны басмыйлар да иде. Шуннан берничә юл китереп үтәсем килә.

Урындагы бер абзый укытучылар каршында чыгыш ясый:

*Не слушайте болтуннарны.*
*Безнең вот такой бурыч:*
*Безнең учениклар булсын*
*Не татар и не урыс!*

Дөрестән дә, шундый дәрәҗәгә төшеп җиттек түгелме соң!

Ун еллар элек Казанда чыга торган «Совет мәктәбе» журналына мәкалә язып җибәргән идем. Ул чакта 1 - 4 класста укучыларның математика нигезен рус телендә начар үзләштерүе мине бик борчыган иде. Мин инде күп акылланып: әллә дүрт класска кадәр математиканы татар телендә укыту кирәктер, чөнки гаиләләрендә туган телгә өйрәнгән балалар мәсьәләләрнең эчтәлегенә төшенеп җитмиләр, шуңа уңышлары яхшы түгел булса кирәк, дип язган идем. Җавап итеп: «Бездә андый сорау туганы юк әле», — дип яздылар.

Билгеле, тел мәсьәләсен төптәнрәк күтәрүчеләр дә булгандыр. Әмма яшәеш шартлары үзгәрмичә, яңармыйча торып, андый зур, катлаулы мәсьәлә үзенең дөрес чишелешен барыбер тапмас иде.

Туган телеңне белү, кемне дә хурлыкка илткәне юк әле. Түбәндәге язылган юлларны бер мактануга гына кайтарып калдырмагыз.

Иске Фәйзулла мәктәбен минем энемнең улы Рафаэль дә уңышлы тәмамлады, аннан соң Димитровградта 10нчы классны бетерде. Самара элемтә институтына укырга керде. Диңгезче булу турында хыяллана иде ул. Диңгезчеләр мәктәбенә унҗиде тулмыйча алмыйлар. «Барыбер бу институтта мин бер ел гына укыйм», — диде. Сүзендә торды — икенче елны Владивостокка китеп, андагы Югары Хәрби Диңгез флоты мәктәбенә укырга керде. Үткән ел шушы уку йортын кызыл диплом белән тәмамлады. Шуны кабатлап әйтәсем килә, туган телне яхшы белү аңа бер да зыян итмәде. Ә Рафаэль татарча сөйләшә, теләсә нинди китапны алып укый, матур итеп татарча хатлар яза.

Тагын бер мисал китерәсем килә. Чын тормыштан алып, булган, үз күзем белән күргән вакыйгага таянып язылган хикәям бар.

Безнең авылгаерактагы бер каладан ир белән хатын һәм аларның унөч яшьлек кызлары хатынның энеләренә кунакка кайтканнар иде. Кызчык татарча белми, әнисе-әтисе - татар

кешеләре. Шулай бер мәлне табын янында утырганда бары да татарча гәпләшеп, ниндидер бер кызыктан дәррәү көлеп җибәрәләр. Бу сүзләрдән хәбәрсез утырган әлеге кызчык, битен каплап, үксеп елап җибәрә. Әнисенең төпченеп сорашуына каршы кызчык: «Минем әнием дә татар, әтием дә татар, ник мине татарча өйрәтмәдегез! Нишләп мин һични аңламыйча маймылча каранып утырам? Хәзер үк миңа барын да тәрҗемә ит!» — дип дәгъва белдергән.

Кызчыкның үпкәсе бик урынлы. Мөселман ата-анадан туган бала туган теленнән аерылган. Балаларны ашату-эчертү, киендерү генә бик аз шул әле. Аларны кеше итеп тәрбияләргә, алдагы көндә бәхетле булып яшәрлек итеп тә үстерергә кирәк. Туган телеңне белү, үзеңне шушы асыл халыкның чын кызы яки улы итеп тою горурлыгы - кеше күңеленә башка һични белән алыштыргысыз шатлык ул.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылы,
Кошки районы.
“Бердәмлек” 15 - 20 июль 1991 ел.

# Чын бәхетне белгән кеше

Бу юлы Иске Җүрәйгә Гакыйль Сәгыйров янына без Самараның «Идел моңнары» ансамбле солистлары белән бергәләп килдек. Идеал Галәүтдинов җитәкләгән шушы иҗади коллективның үзешчән артистлары шагыйрьне ел саен диярлек күреп, аның хөрмәтенә җырлар җырлап, гармун уйнап китәләр икән. Быелгы җәйнең соңгы көннәрендә дә алар шушы традицияләренә туры калырга булганнар.

Ишекне киң итеп ачып, безнең барыбызны да, Гакыйльнең анасы, тынгы белмәүче Хәбибҗамал апа каршылый... Келт итеп шул чакта шагыйрьнең анасына багышлап язган шигъри юллары искә килеп төшә:

*Мин тугач та син шатлык кичердең микән?*
*Матур киләчәкне уйлап йөрдең микән?*
*Өметләреңне сүндерде кайгым җиле, -*
*Кичерә алсаң мине, әнкәй, кичер инде.*

Юк, Гакыйль, әниләр алар безне беркайчан да, гаебебез булганда да, гаепләмиләрдер, өметләрен дә бернинди кайгы җиле дә сүндерә алмастыр.



**Гакыйль янына Идеал ГАЛӘҮТДИНОВ җитәкчелегендәге "Идел моңнары" ансамбле еш бара иде** (1990 елларда төшерелгән фоторәсем).

Хәбибҗамал апа безне бер-бер артлы Гакыйль яткан караватянына алып килә. Аңа кулларыбызны сузабыз. Ә ул элеккечә, серле елмаеп, сәламебезне кабул итә. Шатлыгының эченә сыймаганлыгы күренеп үк тора.

Бераз сөйләшеп, Хәбибҗамал апа пешергән тәмле ризыклар белән чәй эчеп алгач, Гакыйльне киендерәбез дә, коляскасына утыртып, якындагы күл ярына төшәбез. Идеал Галәүтдинов тальянын тартып җибәрә. Галия Мостафина аңа кушылып җыр суза. Береаздан барыбыз да шул җырны бергәләп җырлыйбыз инде. Бу Гакыйль Сәгыйров сүзләренә үзешчән композитор Фирзәр Мортазин тарафыннан язылган «Яшермә син миннән күзләреңне» җыры. Шагыйрьнең әле тагын байтак кына матур-матур җырларын искә төшерәбез. Нәфис сүз остасы Рифкать Фәретдинов һәм Гакыйль үзе аның инде күптән һәм әле яңа гына язылган шигырьләрен укыйлар. Иске Җүрәйдә туып-үскән, «Идел моңнары»ның биюче егете һәм гармунчысы Мидхәт Әминов шушында ук аякларын, тыпырдатып, биеп тә җибәрә ... Аны һәм авылның әле тагын ундүрт яшүсмерен нәкъ шушы Гакыйль Сәгыйров абыйлары гармунда уйнарга өйрәткән дә инде. Мидхәт безгә Казаннан һәркайсысына гармун кайтартуы һәм ноталар буенча беренче көйләр чыгарулары турында сөйләде. Ә соңрак Мидхәтнең һәм бер егетнең, бүген авыл җирлеге җитәкчесе булып эшләүче Равил Минебаевның чын гармун остасы булып китүләрен барыбыз да беләбез инде.



**Гакыйль янында кунакта** (сулдан уңга) **Мидхәт ӘМИНОВ, Галия МОСТАФИНА, Рөстәм ВӘЛИЕВ, Рифкать ФӘРЕТДИНОВ, Идеал ГАЛӘҮТДИНОВ.**

Ә кичен авыл клубы халык белән шыгрым тулы иде. Биредә Гакыйль Сәгыйровның авылдашлары талантлы шагыйрь һәм рәссамны хөрмәтләү өчен җыелдылар. Чөнки быел Гакыйльнең


Гакыйль янында кунакта.

туына илле биш яшь булды, ә иҗади тормышына - утыз биш. Шушы вакыт эчендә күпме шигъри юллар язылган, күпме рәсем ясалган. Әгәр аларны бергә җыйсаң - күпме шигырь китаплары бастырып чыгарырга, күпме рәсем күргәзмәләре оештырырга мөмкин булыр иде. Әлегә шагыйрьнең ике китабы «Тормыш җиле» һәм «Айбагарлар» исемле шигырь җыентыклары гына дөнья күргән. Дөрес, шушы көннәрдә Татарстан китап нәшриятында Гакыйльнең өченче сайланма әсәрләре җыентыгы басылырга әзерләнеп ята. Тиздән без ул китапны да кулыбызга алу бәхетенә ирешербез, дип өметләнергә генә кала. Рәссамның рәсемнәрен туплап, Самарада һәм башка урыннарда күргәзмәләр оештырсаң да начар булмас иде.

Гакыйль Сәгыйровның Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителүе дә аның шагыйрь буларак танылуын аңлата түгелме? Кичәдә чыгыш ясаучы авылдашлары, авыл администрациясе башлыгы Зөфәр Насыйбуллин, «Рабочий» авыл хуҗалыгы кооперативы җитәкчесе урынбасары Наил Низаметдинов һәм башкалар талантлы якташларының тормышта күрсәткән батырлыгы, аның кешелеклелеге, вөҗданлылыгы турында бик матур-матур, гыйбрәтле сүзләр әйтә алдылар.

Шагыйрь үзенең бер шигырендә:

*«Җир яшәрмәс, гөл ачылмас -*
*Төшми яңгыр тамчысы,*
*Кайдан алсын шигырь шагыйрь,*
*Булмаса илһамчысы»*, - дип язган. Әйе, Гакыйль Сәгыйров та шушы туфракта шифалы тамчылар белән сугарылып, туган авыл кешеләреннән илһам алып, зур иҗат белән янып-көеп яши. Язмышы нинди генә ачы булмасын, ул «таш кыяны ярып үскән

нарат» сыман, бөгелмичә, «чын бәхетне» белеп яши. Ә дөньяда бу бөтен кешегә дә бирелми шул.

Их, барыбыз да аның кебек саф күңелле, чын йөрәкле була алсак иде без. Чын бәхетне белеп, тирә-юньгә файда китереп яшәү үзе бәхет түгелмени? Гакыйль үзенең тагын бер шигырендә юкка гына:

*«Кирәк түгел*
*Андый-мондый бәхет,*
*Мин тормышка*
*Карыйм тирәннән.*
*Кайгысы да,*
*Шатлыгы да аның*
*Күмелерлек булсын*
*түбәмнән...»* димәгәндер шул. Гакыйль Сәгыйров иҗатына багышланган бу кичәдә җирле авыл Советы, «Рабочий» кооперативы, «Бердәмлек» газетасы редакциясе шагыйрьгә истәлекле бүләкләр тапшырдылар, акчалата ярдәм күрсәттеләр. Концерттан җыелган бөтен акчаны «Идел моңнары» ансамбле дә Гакыйль Сәгыйровка бүләк итте.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**
Август, 1993 ел.

# ...Күпме әле яңа җыр язасы бар...

Бу кичәне уздыру турында фикер беренче тапкыр әле үткән елның августында без «Идел моңнары» ансамбле белән Иске Җүрәйдә Гакыйль Сәгыйровның үзе янында булган чакта туган иде.

Самара шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез моңа кадәр Гакыйль Сәгыйров, аның күпләргә үрнәк булырлык тормышы, искиткеч матур шигырьләре, рәсемнәре белән якыннан таныш түгелләр, аларны «Бердәмлек» газетасыннан гына күреп, укып беләләр иде. Шуңа күрә дә бу иҗат кичәсен үткәрүне барысы да хуплап каршы алды, һәм бу уй күңел түрләребезгә менеп утырды да, тынгы бирми, үзен гел искә төшереп тора торган булды. Инде, ниһаять, Казаннан Гакыйль Сәгыйровка тапшыру өчен Татарстан Язучылар берлегендә әгъзалык билеты әзер булуы, бүген-иртәгә яңа «Кабатланмас моң» китабының нәшрияттан басылып чыгачагы турында хәбәрләр алынгач, кичәне үткәрү көнен билгеләдек, шулай ук оештыру комитеты төзелде.

Хәзерге кыйммәтчелек заманында, билгеле, мондый кичәләр уздыру бик җиңел түгел, бу эш зур чыгымнар таләп итә. Мәдәният сараен алу өчен аренда хакы гына да ярты миллион сум тора. Ә афишалар, чакыру кәгазьләре бастыруга, башка шуның кебек вак-төяккә күпме акча кирәк?



**Шагыйрьнең Самараның Металлурглар сараенда үткәрелгән иҗат кичәсе президиумында** (1994 ел, апрель).

Рәссамның бөтен рәсемнәрен бергә туплап, алардан күргәзмә оештырасы да бар иде. Моның өчен рәсемнәрнең зурайтылган ксерокопияләрен ясатырга туры киләчәк. Барысын да санагач, чыгымнарның бер түгәрәк сумманы тәшкил итүе ачыкланды. Дөрес, акчаны каян алырга да каян табарга дип озак баш ватарга булмады. Кичәнең спонсорларын бик тиз таптык. Самара Губерна банкы, «Океан» сәүдә фирмасы, Красный Яр районыннан «Руно» акционерлар җәмгыяте, Самараның бер азык-төлек кибете җитәкчеләре, милләттәшләребез Шәүкәт Закиров, Сания Каюмова, Равил Яһудин, Сәлимә Краснова берсүзсез ярдәм кулларын суздылар.

Шагыйрьнең туган ягы — Кошки районы администрациясе дә кичә үткәрү өчен әйтү белән акча күчерде. Шулай итеп, без, оештыручылар, җиңел сулап куйдык. Әйе, арабызда изге җанлы, игелек эшләргә әзер торучылар әле байтак кына икән. Самараның танылган эшкуарлары Хәбил Бикташев, Әүһәд Алиев, Вазыйх Мөхәммәтшин да акчалата да, башка төрлечә дә кичәне үткәрүдә зур булышлык күрсәттеләр. Олы ярдәмчеләребездән автохуҗалык җитәкчеләре Наил Таһаутдинов белән Җәмил Вәлиуллинны, машина йөртүче, Гакыйльнең авылдашы Мидхәт Әминовны, сәүдә хезмәткәрләре Рәисә Миәссәр кызы Маринаны, Зәкия Минневәли кызы Мәрданованы да әйтәп үтәргә кирәк.



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ сәхнәдән шигырьләрен укый.** Сулда - **Хәбибҗамал апа,** *уңда* - **Мидхәт ӘМИНОВ (1994 ел).**

....МЕНӘ билгеләнгән көн килеп тә җитте. Кичә башланырга вакыт әле байтак, ә Металлурглар Мәдәният сарае инде халык белән шыгрым тулган. Берәүләр рәссамның күргәзмәсен җентекләп карыйлар, шушында ук рәсемнәрнең ксерокопияләрен сату оештырылган. Күпләр Татарстан кунакларын — танылган язучылар, якташыбыз Камышлы районының Йолдыз авылында туып-үскән Рөстәм Мингалимов, Айдар Хәлим, Фәнзаман Баттал, Зиннур Хөсниярны түгәрәккә алып, үзләрен кызыксындырган темалар буенча гәпләшәләр.

Кичәгә җыелучылар арасында Гакыйль Сәгыйровның яңа «Кабатланмас моң» шигырьләр җыентыгын сатып алырга теләүчеләр бик күп булып чыкты. Тик китапның редакторы, язучы Фәнзаман Баттал әйтүенчә, әлегә аның сигнал данәләре генә әзер. Шуңа күрә җыентыкны сатуны кичәдә оештырып булмады. Бу эшне «Бердәмлек» газетасы хезмәткәрләре үз өсләренә алып, якын вакытларда якташыбызның яңа китабын халык арасында таратачаклар, әлбәттә. Ә менә рәссамның рәсемнәре кичә барышында байтак кына сатылды. Бигрәк тә, «Яшәү һәм үлем чиге», «Буран», «Авылым күренеше» дигәннәре күпләр күңеленә хуш килде.

...Гакыйль Сәгыйровның тормыш һәм иҗат юлы «Бердәмлек» һәм башка газеталар аша тамашачыларга таныш булса да, кичәне алып баручы Идеал Галәүтдинов бу турыда тәфсилләп сөйли башлагач, тамаша залы тып-тын калды. Әйе, якташыбызның фаҗигале, ләкин барыбызга да үрнак булырлык тормышы гаҗәпләндерерлек!..

1970 елда Татарстан китап нәшриятында шагыйрьнең «Тормыш җиле» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Мәскәүдә «Чишмәләр» альманахында шул ук елларда аның «Торналар», «Кыш көне дә ачып куям тәрәзәмне» һәм башка шигырьләре рус телендә, ә 1963 елда Казанда «Айбагарлар» исемле китабы дөнья күрә. Һәм менә, ниһаять, шагыйрьнең һәм рәссамның иң яхшы иҗади әсәрләре җыелган «Кабатланмас моң» исемле яңа китабы әзер. Гакыйль Сәгыйров үткән елны Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

Бу турыда, талантлы якташыбызның тормыш һәм иҗат юлына кагылышлы башка мәгълүматлар турында сәхнәдән чыгып сөйләүчеләр бик күп булды. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рөстәм Мингалимов көчле алкышлар астында Гакыйль Сәгыйровка әгъзалык билетын тапшырды һәм аңа иҗатында зур уңышлар теләде. Башка язучыларның

чыгышларында да якташыбызның иҗатына зур бәя бирелде. «Кабатланмас моң» китабының редакторы Фәнзаман Баттал шагыйрьнең берничә шигырен укып, андагы фәлсәфи уйлануларга, матур, бай образларга басым ясады.

- Шушы китап белән бер үк вакытта мин икенче бер халык шагыйренең шигырьләре җыентыгын да редакцияләгән идем. Гакыйльнең шигырьләрен укып чыккач: "Менә бит аларның кайсысы Халык шагыйре", - дип аның кулъязмасын бөтен редакция алдында күтәреп селкеп, сокланып, кычкырып җибәргәнемне дә сизми калганмын. Самаралыларга шуны әйтәсем килә. Зур шагыйрьләребезнең берсе сездә - ул Гакыйль Сәгыйров. Горурланып яшәгез, исемен дә, иҗатын да югалтмагыз! — диде Фәнзаман Баттал.

Бүләк бирүчеләр дә кичәдә байтак булды, бүләкләрнең дә нindиләре бит әле. Кошки район администрациясе кер юу машинасы, ә Иске Җүрәй авыл администрациясе тузан суырткыч алып килгән.

Бүләк бирүчеләрнең барсының да исемнәрен әйтеп бетерергә мөмкин түгел. Ә менә Башкортстаннан «Бердәмлек» газетасында кичә уздыру турында басылган хәбәрне укып, бәйрәмгә махсус рәвештә килеп, үзенең бер айлык пенсиясен бүләк итүче Гөлшат Басыйр кызы Мөхәммәтгалиеваны аерым билгеләп үтмичә булмый. Татарстанның Яр Чаллы шәһәреннән эшкуарлар Рәфис һәм Нәфис Кашаповлар җибәргән ярымайлар һәм манаралар белән бизәкләп эшләнгән стена сәгате дә Гакыйль Сәгыйров өчен зур олылау, зур хөрмәтләү булды.

Тагын бер тапкыр әле шунысын әйтеп үтәргә кирәктер: кичәдә җыелган бөтен акча, бөтен чыгымнарны түләгәннән соң, Гакыйль Сәгыйров фондына күчерелде. Бу сумма 2 миллион ярым сумнан артыграк. Дөрес, хәзерге кыйммәтчелек чорында мондый акча белән генә әллә ни күп нәрсә майтарып булмаса да, үзенең һәм әнисенең кечкенә генә пенсияләренә яшәүче шагыйрьнең тормышында бу берникадәр ярдәм булачак, әлбәттә.

Кичәдә Гакыйль һәм аның әнисе Хәбибҗамал апа хөрмәтенә күпсанлы матур сүзләр әйтелде, шигырьләр укылды, җырлар яңгырады. «Идел моңнары» ансамбле җырчысы Галия Мостафина аның шигырьләренә композиторларыбыз тарафыннан иҗат ителгән берничә җыр башкарды. Ә Тольяттида яшәүче үзешчән композитор Сания ханым Әхмәтова бүләккә үзенең Гакыйль Сәгыйров сүзләренә язылган «Каеным» җырын алып килгән иде.

*Матурлыгың эчтем, каеным, —*
*Ул бетмәслек чишмә бит синдә,*
*Хисләремдә сөеп йөрттем дә*
*Җырларыма күчтең, каеным.*

ӘЙЕ, Гакыйль Сәгыйровның иҗатын ак каен матурлыгына, саф чишмә суына тиңләп була. Шагыйрь Роберт Миңнуллин әйткәнчә: «Ул ясаган рәсемнәрнең композицион бөтенлегенә, җылылыгына сокланмый мөмкин түгел. Аның шигырьләрендә, рәсемнәрендә яшәү матурлыгы, тормышның ургылып, ташып торуы күзгә ташлана. Бу — Гакыйльнең эчке халәте. Бу — аның табигый хисләре...»

Кичә турында язганда Казанда балалар өчен чыгарыла торган «Салават күпере», Яр Чаллыда нәшер ителүче «Аргамак» журналының баш мөхәррирләре язучылар Зиннур Хөсниярнең,



**Кичәдә катнашучылар шагыйрь янында** (сулдан уңга): **Айдар ХӘЛИМ, Равил ЯҺУДИН, Зиннур ХӨСНИЯР, Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН, Рөстәм МИНГАЛИМ, Мидхәт ӘМИНОВ.**

Айдар Хәлимнең, Самара эшкуары, Бөтентатар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы Равил Яһудинның чыгыш ясаганда әйткән фикерләрен искә алмыйча үтсәм, бик үк дөрес булмас иде. Алар Гакыйль Сәгыйровның иҗатын, киләчәктә өлкәбездә татар теленең үсүен, чәчәк атуын «Бердәмлек» газетасы белән бәйләп күрсәтергә тырыштылар. Бу чынлап та шулай бит. Талантлы якташыбызның иҗатын киң яктыртып баручы «Бердәмлек» газетасы яшәсә, Гакыйль Сәгыйров кебек шагыйрьләр, рәссамнар төбәгебездә даими туып-үсеп торачак. Димәк, «Бердәмлек»не бүгенге авыр чорда саклап калу — ул һәркайсыбызның изге бурычы. Аның шулай булачагына ышанычыбыз зур. Гакыйль Сәгыйровның кичә ахырында соңгы сүзләрен «Бердәмлек»кә багышлавы да бик урынлы булды кебек.

*Бергә булган ил халкына*
*Түгел берни куркыныч;*
*Бергәләп алга атларбыз,*
*«Бердәмлегем», бул тыныч!*

Кичә Самараның «Ялкынлы яшьлек» ансамбле коллективы башкаруында зур концерт белән тәмамланды.

...Ә тормыш дәвам итә. Бу дөньяда һәркайсыбыз Гакыйль Сәгыйров сыман үзебезнең кабатланмас моңыбызны тапсак иде. Ә эшләнәсе эшләр бик күп алар! Гакыйль бер шигырендә әйткәнчә: «...Күпме әле яңа җыр язасы бар!..»

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**
Апрель, 1994 ел.

*Бу кичә турында Гакыйль Сәгыйров үзенең “Лимонлы чәй” дигән көлкеле язмасын да “Бердәмлек”тә бастырган иде.*

# Лимонлы чәй

Минем соңгы китабым «Кабатланмас моң»ны халыкка тәкъдим итү кичәсен өлкәбездә чыгып килгән, без яратып укый торган бердәнбер милли газетабыз оештырган иде. Билгеле, ул мәшһүр кичәгә мине дә алып килделәр.

Зур зал халык белән шыгрым тулы. Кичәне тантаналы итеп Идеал әфәнде Галәүтдинов ачып җибәрде. Олы-олы абзыйлар чыгып сөйләде, яшьләр дә күңелгә ятышлы матур сүзләрне кызганмадылар.

Шундый күп тамашачы алдында минем тәүге утыруым иде. Бик нык дулкынландым: йөзә белмәгән хәлдә шаулы диңгез уртасында чайкалып торган көймәдә сыман хис иттем үземне - тамагым ярылырдай кипшенде, өнем чыкмаслык дәрәҗәгә җитте: маңгаемнан тир бәреп чыкты. Миңа сүз бирелгәндә үземне ниндидер томан эчендә тоеп, ни сөйләгәнемне дә белми калдым. Үземнең шагыйрь икәнемне исбатлау өчендер инде, кайсыдыр язмамны укып үттем. Үзем эчтән: «Тизрәк үтсен иде, тизрәк бетсен иде!» - дип тәкрарлыйм. Микрофон алдымнан китүенә, янымда басып торган егеткә: «Баш әйләнә, шыпырт кына залдан чыгып тайыйк әле», - дип пышылдыйм.

Икенче бүлек - концерт кызганычка калды: карый алмадым - соңыннан сокланып сөйләүләрен генә ишеттем. Концерттан соң зур бер бүлмәдә әзерләнгән табын янына юнәлдек. Биредә алтмышлап кеше: язучылар, җырчылар, кичәне оештыручы якын дуслар...

Чиксез дулкынланудан минем эчәсем дә, ашыйсым да килми. Мин елмаям - күңелемдә шатлык. Кызык: бу олуг, данлы кешеләр минем исемгә оештырылган мәҗлестә утыралар, ләбаса.

Табынны урап, ишек катына уздык, янымдагы өстәлдә самовар гөрләп утыра, мәҗлестә хезмәт күрсәтүче Мәрьям ханым: "Гакыйль абый, нишләп ашамыйсыз-эчмисез? Мин сезгә тәмле иттереп чәй ясап бирим әле", - дип стаканга әллә ничә лимон телеме тутырып, әллә ничә калак шикәр комы салып җибәрде дә, лимон кисәкләрен изә-изә, чәйне болгатты.

- Зинһар, борчылмагыз, - мин әйтәм. - Рәхмәт. Эчәсем дә, ашыйсым да килми бит.

- Шушы тәмле чәйне генә эчәрсез әле, - ул елмаеп стаканны миңа сузды. - Тик кайнар, бераз суынсын!

- Момент суытабыз аны, апа! - дип «төтене» чыгып торган стаканны тәрәзә төбенә илтеп куйды Мидхәт.

Яңа ясалган чәйне мәҗлес алып баручы Идеал әфәнде эләктереп китте. Калган стаканнар табынга таралып өлгермәгән иде әле, гармунын күкрәгенә аскан Идеал, йөгерә-йөгерә килде дә, кулындагы стаканын өстәлгә куйды.

- Мәгез тозлы чәегезне...

Мәрьям ханым аптырап, кызарып стаканга үрелде.

- Көлмәгез инде. Нишләп тозлы булсын!? - Әмма стакандагы чәй чыннан да тозлы иде.

Мәрьям ханым ялгышканын - янәшә яткан ике целлофан капчыкның шикәрлесе өйдә калганын аңлап, куркынып бөтенләй югалып калды.

- Зинһар, гафу итегез, белеп түгел бит, - дип, бу хәлнең ничек килеп чыгуын аңлатырга тырыша иде ул. Кем дә аны гаепләргә җыенмый иде, билгеле, мин дә аны тизрәк юатырга тырыштым.

- Зарар юк, борчылмагыз, аңлыйм ич мин. Бик тә әйбәт булды, бу кызык та килеп чыкты бит әле, - дип көлдем. Мидхәт тә:

- Тәмле булсын әле дип, тозны мул итеп, әллә ничә кашык сала бит! - дип минем алдыма иелеп-иелеп туйганчы рәхәтләнеп көлде.

Мондый мәҗлесләр күңелдә тулырак, бөтен күркәмлеге белән озаграк саклансын өчен, кызык вакыйгалар белән бизәлүе шарт түгел, шулай да әлеге лимонлы чәй хәтергә төшкән саен елмаясы гына килә. Бу мәҗлес тагын да яктырып, аның матурлыгы артып киткән шикелле тоела.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Иске Фәйзулла авылы,
Кошки районы.

# Безне дөньяда изгелек яшәтә түгелме?!

Тормыш кешене төрлечә сынап карый. Матур гына яшәп ятканда кинәт якын кешең каты авырый башлый, ул да түгел, үлеп тә китә. Миңа да балачактан ук ачы хәсрәтләр күп күрергә туры килде. Сугыш елларында, сигез яшемдә әтисез, ятим калгач, Ульян өлкәсенең Әбдери авылыннан әнием белән Оренбург якларына, укытучы апам янына күчеп киттек.

Зиянчура авылында ун классны тәмамлаганнан соң, тагын туган якларга кайтып, техникумга укырга кердем. Шунда булачак ирем Тәлгать Мәрдиев белән очрашып, матур гына гаилә корып җибәрдек.



**Ирле-хатынлы Тәлгать һәм Разия МӘРДИЕВЛАР.**

Тәлгать авыл хуҗалыгы белгече иде. Без аның белән Пестравка районының «Майский» совхозына эшкә барып урнаштык. Йортсыз, малсыз яшьләргә яңа, таныш түгел җирдә тормыш башлап җибәрүе җиңел булмады, әлбәттә. Инде дөньябыз түгәрәкләнеп кенә килгән чакта, безнең гаиләне зур бәла сагалап торган икән. Көтмәгәндә Тәлгать каты авырып китте. Самараның абруйлы хастаханәләрендә озак дәваланса да, култык таякларсыз йөри алмый торган булды. Врачлар катлаулы операция ясарга тәкъдим иттеләр, шунсыз уңай булмас дип куркыттылар. Тик без моңа ышанмадык.

Икенче группа инвалиды дип табылган Тәлгать төрле хастаханәләрдә, врачларда дәвалануын дәвам итте, халык имтомчыларының ярдәменнән дә баш тартмады. Шулай берничә елга сузылган сәламәтлек өчен каты көрәштән соң, ул, ниһаять,

култык таякларын ташлап, яңадан аякларына басу бәхетенә иреште. Каты авырудан соң яңадан терелгән кеше генә безнең шатлыкны аңлый һәм уртаклаша алыр иде.

Шулай итеп, без авылны калдырып, яраткан профессиябезне ташлап, шәһәргә килеп урнашырга мәҗбүр булдык. Яңадан укулар, яңа хезмәтләрне үзләштерү, йортлы булу — болар җиңел генә бирелмәде безгә.

Минем үзебез турында болай җентекләп сөйләвемнең сәбәбе тормышыбызны дөньяда очраган башка гыйбрәтле, фаҗигале язмышлар белән чагыштырып карау өчен генә. Шундыйларның берсе— талантлы якташыбыз, шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сәгыйров, әлбәттә. Без аның ачы язмышы турында «Бердәмлек» газетасыннан укып белгәч, «Кабатланмас моң» исемле яңа шигырьләр җыентыгы белән якыннан танышкач, ниндидер якын кешебезне тапкандай булдык. Әйтерсең лә ул күргән җәфаларны, сызлаулы озын көннәрне һәм төннәрне без үзебез кичердек. Бигрәк тә аяксыз калуны үз башыннан үткәргән Тәлгать өчен Гакыйльнең фаҗигале тормышы тетрәндергеч иде. Беренче минуттан ук бездә аның белән якыннан очрашып, танышу теләге туды.

Ниһаять, менә без Гакыйль анасы Хәбибҗамал апа белән яшәгән Кошки районының Иске Фәйзулла авылындагы кечкенә



**Җырчы Галия МОСТАФИНА һәм Разия МӘРДИЕВА Хәбибҗамал апаны 80 яшьлеге белән тәбрикләгәндә.**

генә өйдә сөйләшеп утырабыз. И Ходаем, дөньяда нинди көчле, сабыр кешеләр бар икән әле. Гакыйльнең яңа шигырьләрен укыгач, рәсемнәрен якыннан күргәч, моның өчен аңа никадәр зур хезмәт һәм көч кирәк булганлыгына тагын бер тапкыр инандык.

Шушы тәүге танышудан соң без Гакыйль янында ешрак булырга тырышабыз. Аның белән очрашу ниндидер аерым ләззәт бирә, тормышка карашны үзгәртә.

Гакыйль белән сөйләшеп туя алмыйсың, нинди генә темага сүз башласаң да, аның һәрнәрсәгә карата үз фикере, үз уе бар. Төшенкелеккә бирелгән кешедә дә ул тормышка мәхәббәт хисе уята ала. Бу турыда ул үзенең бер шигырендә менә ничек яза:

*... Кешеләрдән берни яшермим,*
*Ачык йөзем, ачык күңелем белән,*
*Ачык ишек белән яшим мин,*
*Яшьләремне сыпырып төшерсәм дә,*
*һәр шатлыкка ачык елмаям.*
*Сорап тормыйм, син кемнеке диеп,*
*Сорый белмим, килдең дип каян.*
*Үзе өчен генә яшәүчеләр*
*Никадәр күп әле дөньяда.*
*Шундыйларның боздай карашлары*
*Кагылып узды кайчак миңа да.*

Ульян артындагы «Ундоры» курортында дәваланганда, узышлый гына булса да, тагын Гакыйль янына кереп чыккан идек. Ә инде санаторийда шагыйрьнең иҗатына багышланган махсус кичә оештыру уе туды. Ял итүчеләр арасында татар кешеләренең күп булуы да моңа сәбәпче булгандыр, мөгаен. Санаторийның баш врачы Шәфикъ Ситдыйк улы Усманов та безгә кичәне уздыруда ярдәм кулын сузды.

Гакыйль Сәгыйровның шигырь бәйрәменә татарлар гына түгел, руслар да, башка милләт вәкилләре дә килгән иде. Шагыйрьнең шигырьләрен татарча да, русча да укыдым, рәсемнәрен күрсәттем. Кичә барышында күп сорауларга җавап бирергә туры килде. Якында гына шундый зур талант иясенең яшәве күпләрне дулкынландырмый калмады, әлбәттә. Икенче көнне без яшәгән бүлмәгә Гакыйльгә тапшыру өчен күчтәнәчләр китерүчеләр, акчалата ярдәм бирүчеләр дә байтак булды.

Санаторийда рәссам булып эшләүче, Россия Рәссамнары берлеге әгъзасы Ирек Харис улы Нуретдинов Гакыйльнең рәсемнәренә карата түбәндәге сүзләрне әйтте: “Бу рәсемнәрне

авызга карандаш кабып ясау түгел, кул белән ясар өчен дә зур көч, зур талант кирәк. Әгәр бу рәсемнәрдән күргәзмә оештыра алсак, бу безнең өчен зур уңыш булачак”.

Күптән түгел Гакыйльнең анасы Хәбибҗамал апага 80 яшь тулды. Без, «Бердәмлек» газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин, җырчылар Галия Мостафина, Мидхәт Әминев, бергәләп аны шушы олы юбилее белән котларга бардык. Бу очрашу үзеннән-үзе шигырь бәйрәменә, җыр бәйрәменә әйләнеп китте. Без барыбыз да бергәләп, җырчыларга кушылып Гакыйль Сәгыйров сүзләренә язылган җырларны җырладык, Хәбибҗамал апага һәм башка аналарга багышланган шигырьләрне укыдык.

Гакыйльнең менә бу шигыре минем исемә бик еш төшә, һәм мин үз алдыма кабатлый башлыйм:

*И, Ходаем, чиксез канәгать мин,*
*Шундый сизгер күңел биргәнсең.*
*Һәркайсының хәлен аңлый беләм,*
*Һәркайсының җанын саклый беләм.*
*Багланыш күп минем дөнья белән,*
*Шул яшәтә мине, күрәсең.*



**Хәбибҗамал апаның 80 яшьлек кичәсендәге мәҗлестә катнашучылар.**

Бу юллар безнең һәрберебезгә дә кагыла сыман. Әйе, тормышта башыңа нинди генә авырлыклар төшсә дә, яшәү өчен Гакыйль кебек көч таба белергә кирәктер шул.

Гакыйль Сәгыйров һәм аның анасы Хәбибҗамал апа бик кечкенә пенсия алып яшиләр. Бүгенге заманда кемгә дә яшәү җиңел түгел, ә алар кебек сәламәт булмаган кешеләргә аеруча кыен. Соңгы вакытларда Гакыйль Сәгыйровка ярдәм кулларын сузучылар, Аллага шөкер, табылып тора. Менә аларның исемнәре:

Самараның «Прогресс» ремонт-төзү берләшмәсе җитәкчесе Вазыйх Гата улы Мөхәммәтшин, «Океан» фирмасы директоры Сания Ибраһим кызы Каюмова һәм башкалар.

Иткән һәр изгелек үзеңә кире әйләнеп кайта, диләр бит. Мөмкин булып, кулымнан килсә, мин Гакыйль Сәгыйровка иң зур бүләкләрнең берсен — мәсәлән, Татарстанның Тукай бүләген бирер идем. Әгәр аңа Самара төбәгенең мәшһүр татары дигән югары исемне дә тапшырсак, начар булмас иде кебек.

Әйдәгез, бу турыда бергә уйлашыйк әле, туганнар!

**Разия МӘРДИЕВА.**
Самара шәһәре.

# Сагынам авылымны

Мин Кошки районының Иске Җүрәй авылында илебездә каты сугыш барган 1943 елда туган бала. Бу вакытта абыема - җиде, апама ике яшь булган. Тиздән әтиебез үлеп киткән. Безне ничек аякка бастырганын әниебез үзе генә белгәндер инде, бичара. Ачлыкны да, ялангачлыкны да күп күрдек. Әтиләре сугышта һәлак булган балаларга хөкүмәт күпмедер акча түләп тора иде. Безгә ул да тәтемәде, чөнки әтиебез сугыштан яраланып кайтып, өйдә вафат булды.

Кырдан юа, балтырган, кычыткан кебек үләннәр җыеп ашый идек. Әле булса, бик ашар идең дә, кызурак җәйләрдә алары да кибеп бетә. Язын бакчаларга чыгып, черек бәрәңге казып алган чаклар да булгалады. Әниебез черек бәрәңгедән чумар пешереп ашатканда, шуңардан да тәмлерәк ризык юк кебек тоела иде.



**Хәбибҗамал апа яшь чагында...**

Балачагыбыз шундый авыр булуына карамастан, тормыш барыбер кызык иде. Яшьләр җыелып, күмәк уеннар уйный, җырлый, бии, кич утыра... Үземне әллә кемгә куеп, күтәртмәле чабата киеп ташу карарга барганымны әле дә яхшы хәтерлим. Хәзер кемгә сөйләсәң дә, күтәртмәле чабатаның нәрсә икәнен дә белмиләр.

Җиденче классны тәмамлагач, башта апам, аннары мин Куйбышевка китеп урнаштык. Әниебез авылда берүзе калды. Без еш кына кайтып аңа булыша идек. Колхозда эшләгән өчен әнигә 12 сум пенсия биргәннәрен, аның бу турыда шатланып сөйләгәнен әле дә оныта алмыйм. Заманында ул да акча иде бит. Кызганычка, әниебезнең гомере кыска булды. Ул 66 яшендә үлеп китте.

...Без үскән өй күптән юк инде. Әни үлгәч, аның урынына ике катлы мәктәп салып куйдылар. Аллага шөкер, авылда туганнарыбыз, дусларыбыз калды, сирәк булса да туган туфрагыбызга кайтып йөри алабыз. Сания Туктарова, Сәрия апалар да, дустым Яһудина Хәдичә дә ах итеп каршы алалар, кунак итмичә җибәрмиләр. Кайткан саен өебез янына барам

һәм әнинең тәрәзәсе каршындагы баганага сөялеп үксеп-үксеп елыйм.

Данлыклы, бөтен татар дөньясына танылган шагыйрь һәм рәссам Гакыйль абый Сәгыйровның беренче яшәгән өе дә каршыбызда гына иде. Безнең әниләр ахирәтләр дә иде бугай. Кунакка кайтканда аларның хәлен белмичә китми идем. Аларга безнең авылда да, Самарада да танылган гармунчы Мидхәт Әминов та еш кына килеп керә һәм гармунын сузып җибәрә, ә мин кушылып җырлыйм. Ә Хәбибҗамал апа, Гакыйльнең әнисе, самоварны яңартып кына тора. Җырлап туйгач, тәмләп кенә, сөйләшә-сөйләшә чәй эчәбез...

Туган авылымны, туганнарымны, дусларымны бик нык сагынам. Әнкәй булмагач, авылга еш кайтып булмый икән шул. Әти-әниләрегез исән чакта ешрак кайтырга тырышыгыз, хәлегездән килгән кадәр булышыгыз, хөрмәтләгез, якын булыгыз. Ата-анага да, үзегезгә дә шуңардан да зуррак шатлык юктыр дөньяда.

**Кәримә ПРОЖИВИНА.**
Самара шәһәре.



**... һәм олыгайган көннәрендә.**

# Минем күршем

Миңлехан абыйга кем, кайчан, ни өчен «Салам» дип кушамат кушкандыр – белмим. Хәзер инде аны ачыкларга да мөмкин түгелдер – бөтенләй көтмәгәндә мәңгелеккә безнең арадан китеп барды ул. Бәлки, Дон-Кихот кебек арык гәүдәле, озын буйлы булганы сәбәпледер – әйтүе кыен. Балаларча беркатлы, киң күңелле, дөньяда яшәүче башка адәм балаларына хас яхшы ягы да күп, яман яксыз да калмаган бер кеше иде минем күршем.

Минем яныма кергән саен ягымлы елмая-елмая:

– Нишләп ятасың – әйдә чыктык көрәшергә! Мин сине, малай, себерке алып кереп, караватыңнан бер кыйнап төшерәм әле, – дип яный иде. Хәзер мине «куркытучы» кеше калмады инде...

Бервакыт кышкы бураннан соң иртә белән туңмый калган тәрәзә почмагы аша урамдагы сараеннан кайтып килүче Миңлехан абыйны күреп алдым – салам тутырган кәрҗинен җилкәсенә аскан, кулында – көрәге-сәнәге, төн буе җилләр ташып тутырган йомшак карны сөреп, акрын гына атлый. Үзе дә – «Салам», салам да күтәргән – миңа кызык булып китте – тиз генә янымдагы микрофоннан урамга сөйләүче динамикны кабыздым.

– Күрше! – дим, ул шып туктады да тыңлый. – Сезнең кайсыгыз кайсыгызны күтәргән соң ? – дип кычкырам. Бераз тын гына торгач, ул ике кат тәрәзә аша ишетелерлек итеп шаркылдап көлеп җибәрде дә сәнәген күтәрде: «Белермен әле мин сине, янәсе, яныңа керим генә!..»

Җәен күп кичләрне аның өе алдында кешеләр җыела. Сөйләшәләр-көлешәләр, ярмый калдырылган калын бүкәннәр өстендә кәрт сугалар. Мин дә «тиле» шунда булгалыйм. Ул җыенда үткен-үткен мәзәк сүзләр күп була. Миңа бигрәк тә шунсы кызык...

– Бүген кырдан кайтып, ятып йокымсырап кына киткән идем (Миңлехан абый күп еллар су ташучы хезмәтен үтәде), бүлмәдә кемдер йөргәнне тоеп, күземне ачсам, имәнеп киттем: алгы яктан биш-алты яшьлек малаен ияртеп кап-кара күзле, тузган чәчле чегән хатыны килеп чыкты. «Әйдә, карыйм үзеңне, ни күргәнеңне, ни күрәчәгеңне дөп-дөрес әйтеп бирәм. Рәхмәт әйтерсең соңыннан», – дип бәйләнә калды бит. Имеш,

күп алмыйм, саран булма — ирләр юмарт була ул, малаема өстәлдән кәнфит, миңа әнә шул сабын да җитә, дип кыбырсына башлагач, ачуым килде.

— Әле сиңа кәнфит кирәкме? — дип бер генә кычкырган идем, очып чыгып китүен, күрми дә калдым , - дип көлдерде.

Миңлехан абыйның әнисе белән дә мәзәк хәлләр гел булгалап торган, диләр.

Килен булып төшкәннең икенче көнендәме, ире йортта ат җиккәндә, Минҗиһан әбидән (ул чагында яшь булган әле) чоланнан ыңгырчак чыгаруын сораган. Яшь килен чоланда эзләгән-караган да:

— Юк монда, — дигән.

— Нишләп булмасын — уң якта, агач чөйдә. Кичә үзем элгән идем. Бераздан Минҗиһан кире чыккан:

— Юк, дигәч, юк инде, андый нәрсә күренми, үзең кереп кара...

— Бу — нәрсә соң? — дигән ире ыңгырчакны күрсәтеп.

— Сидилчә ич бу! Кеше сынлы әйтсәң, әллә кайчан чыгарган булыр идем, эзләтәсең тузга язмаганны, — дип иреннәрен бүлтәйтеп, үпкәләп, өйгә кереп киткән яшь кәләш (ул туып-үскән якларда ыңгырчакка «сидилчә» дип әйтәләр икән).

Тапкырлык кешегә әллә нинди четерекле хәлләрдән чыгарга ярдәм итә, кыенлыкларны җиңүгә булыша. «Сез менә тупсаны русча белмәгән килеш ничек сорап алыр идегез?» Ә Минҗиһан әби бер дә аптырап калмаган, сатучы кыз янына килгән дә:

— Дучкы, әнә ул «открывай-закрывайны» алып бирче, — дип сорап алган.

Икенче бер мәлне каз үрчетергә уйлаган Минҗиһан әбигә ата каз кирәк булган һәм ул сорашып-белешеп карагач, күрше авылга юл тоткан. Әнисенең русчасы бик чамалы икәнен белгән улы:

— Ничек сорадың соң, әни? — дип төпченгән.

— Ничек сорасам да, алып кайттым бит әле. Күгәрченемне парлы иттем, — дигән карчык. — Җитмешкә җитеп шуны да сорый белмәсәң — Ходай риза булмас — гусь-мужик кирәк, дип сорадым — булсын!

Минҗиһан әби базардан кайтып килә икән, хәлләрен белеп, бераз ял итеп чыгу нияте белән юл өстендәге авылда яшәүче белеш чуашларына тукталган. Хуҗа хатын бик зур кайгылы

икән — бишектәге баласы чирләп киткән. «Теге чакта бер татар әбидән өшкерткәч, терелгән иде, ул әбине калага алып киткәннәр. Өшкер әле — син дә әби бит», — дип үтенгән Минҗиһан әбидән. Чит диндәгеләрне безнеңчә укып өшкерергә ярамый, имеш, һәм Минҗиһан әби үзеннән дога чыгарып өшкерергә керешкән:

— Мич алдында ун йомырка, бишесен алсаң, биш кала, елап ятма - көл әле, бүскә кебек сикереп йөр әле, тай кебек йөгер әле, шайтаннар шаукым алып килгән — чыгып качсыннар, чыгып качсыннар. Тьфу! Тьфу! Тьфу!

Хуҗабикә тыңлап утырган-утырган да, эче пошып:

— Теге әби укыганда «төрҗәгуны» да бар иде, — дип куйган.

— Ансына җитмәдек әле, — дип, югалып калмаган Минҗиһан әби һәм үзе иҗат иткән догаларны тагын беравык тезгәннән соң, хуҗа хатынны шатландырып, «төрҗәгунны» да кушып җибәргән.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Иске Фәйзулла авылы,
Кошки районы.

# Кеше була белик...

Үзем белән быел җәен юлда килеп чыккан хәлне сөйләр алдыннан шундый ук шартларда, тик берничә ел элек булган бер күренешне искә төшереп үтәсем килә.

«Бердәмлек» битләрендә минем турыда чыккан мәкаләләрдән күпләрегезгә балачактан ук каты авырганым мәгълүмдер инде. Дөнья бит, бер хәрәкәтсез ятып кына торсам да, кайчакта төрле йомыш белән автомашинада ерак юлга да чыккаларга туры килгәли. Бервакыт шулай Яңа Малыклыга барганда үземне начар хис итә башладым һәм руль артында баручы туганымнан машинаны туктатуын сорадым. Ул юрганны җиргә алып җәйде дә, мине шунда китереп салды. Бераздан каеннар шавы, саф һава хәлемне яхшыртып җибәргәндәй тоелды..

Шул мәлне безнең яннан выжылдап «девятка» машинасы үтеп китте дә, бераз үткәч туктап, безнең янга әйләнеп килде.

- Нәрсә булды? Ярдәм кирәкмиме? — дип сорады «девятка» хуҗасы борчулы тавыш белән.

- Юк, юк, рәхмәт, хәзер хәлебез яхшырды инде, - дип аны тынычландырырга ашыктык.

Берни дә булмады кебек: кеше туктады, хәлебезне сорашты... Тик мондый кайгыртучанлыктан ничектер күңелгә җылы керде, көн дә матуррак, дөнья да яктырак күренә башлады.

...Тагын бер хәл. Бу юлы Нурлатка барабыз. Кояш кичкә авышып килә, алда юл озын әле, ә бензин күрсәтә торган стрелка нольгә якынлашып килә. Нишләмәк кирәк? Туктап «голосовать» итә башладык. Дүртенче машина тукталды,

- Үземнең бензин да аз, тик мин инде кайтып җиттем диярлек, - диде автомашина хуҗасы безнең хәлебезгә кереп. - Сезнең юл шактый ерак әле. Ярар 3 - 4 литр бирермен.

Бу очрашулар моннан 4 - 5 ел элек булган иде.

Ә менә былтыр май урталарында шул ук юлда үзем бер эксперимент уздырып карарга уйладым.

Ашыкмыйча гына такыр юлдан элдертәбез. Машинаны йөртүче туганыма: «Туктат әле. Бензиның беткән булып кыланып кара, берәрсе туктар микән?» - дидем. Ул теләр-теләмәс кенә ризалашты да, канистрын тотып, юл читенә чыгып басты. Ә мин үтеп киткән машиналарны санарга керештем. Утыз җиде минут эчендә кырык өч машина узып китте, шуларның берсе бер туктаса?

Ни булган бу кешеләргә? Безне бит кечкенәдән кеше турында

кайгыртырга өйрәттеләр түгелме? Ә хәзер һәрберсенең бармагы үз ягына гына кәкре булып чыга ич!

Мин моңа 24 - 25 июнь төнендә тагын бер кат инандым. Энем Ринатның дус-ишен армиягә алырга тиешләр иде ул көнне. Шәһәрдән соң чыгып китәргә туры килде, кичке унберләр тирәсе иде. Кояш баткан, төнге көмеш һавада карасу болытлар йөзеп йөри. Кошкига бер унбиш чакрым калганда, машина эчендә нәрсәдер гөрселдәп алды, туктадык. Ринат чыгып карады да: «Килеп җиттек, Гакыйль абый, ремень өзелгән, каяндыр тосол ага», - дигәч, сәгатькә карасам, төнге берләр тирәсе иде инде.

Бер сәгатьләр чамасы Ринат бау тотып юлда басып торды. Өметебез өзелде дигәндә, ниһаять, берсе җәлләде ахыры, килеп туктады. Берүзе булуга карамастан, курыкмаган. Юл буендагы бер киоск янына кадәр безнең җансыз машинаны өстерәтеп килде дә: «Монда ичмасам кешеләр бар», - дип китеп тә барды, рәхмәт төшкере.

Бу юлларны укыса, бәлки үзен таныр әле ул кеше. Минем аңа чын күңелемнән рәхмәт әйтәсем килә.

Тагын ярты сәгать узгандырмы, яныбызга бер иске генә «Москвич» туктады. Ул да берүзе генә иде. Иске Җүрәйгә барып җиткәндә Ринат: «Бу ике кеше бер-берсенә шулкадәр охшаганнар, яхшы кешеләр гел шулайдыр инде», - дип әйтеп куйды. Ни гаҗәп, минем дә башымда шул ук уйлар бөтерелә иде.

Килеп җиткәч, акча турында сүз кузгаткан идек:

- Юк, кирәкми, була торган хәл бу, - дип, кул селтәп, кузгалып китте.

Мин әле хәзер дә бу турыда уйлап утыргалыйм: ә кыш, салкын, буран булса? Минем кебек чирләшкәгә җитә калыр иде, үлеме дә ерак түгел. Ник соң без берберебезгә шундый каты күңелле булып калдык әле? Ник кеше кайгысы безне борчымый башлады? Мин үзем авыру, машинам кечкенә генә «Ока» булса да, Ринат энем белән гел туктап, юлда бәлага дучар булган һәр кешегә ярдәм итәргә тырышабыз.

Яңа заман кешене үзенчә үзгәртә: һәммәсе үз-үзен генә кайгыртып яши бүген. Ә минем иң зур мөнбәргә чыгып кычкырасым килә: без бит хайваннар түгел, ярдәмләшик, мәрхәмәтле булыйк, күршебезгә, туганыбызга якын була белик, кеше була белик.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Кошки районы,
Иске Җүрәй авылы.
“Бердәмлек”, № 43, 19-25 октябрь 1999 ел.

# Яшәвебез юкка түгелдер...

УЛЬЯН өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендәге «Восход» Мәдәният йорты тамаша залы халык белән шыгрым тулы. Биредә бүген каһарман якташыбыз, күренекле татар шагыйре һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровның 60 яшьлек юбилеена багышланган кичә уздырыла. Кичәнең тантана өлеше башлануга инде ике сәгатьтән артык вакыт үтсә дә, бәйрәмгә җыелучылар һәр чыгыш ясаучыны зур дикъкать белән тыңлап, көчле алкышларга күмеп озаталар.

Ниһаять, сүз юбилярның үзенә - Гакыйль Сәгыйровка бирелә. Тамаша залына аның бераз карлыкканрак, ләкин көчле һәм горур тавышы тарала башлый. Аны тыңлыйсың да, күз алдыңа шагыйрьнең гүзәл тормыш сәхифәләре, ачы һәм берүк вакытта татлы һәм ләззәтле иҗат ачышлары килеп баса сыман.

Бу мизгелләрдә Гакыйль Сәгыйровның искитәрлек шигырьләре, гүзәл рәсемнәре белән инде күптәннән таныш булганнар, аларны бүген беренче тапкыр ишетүчеләр һәм күрүчеләр дә ниндидер илаһи дулкынлану, горурлану хисен кичергәннәрдер, мөгаен.

МЕНӘ Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районы Исәнтимер авылыннан килгән һәвәскәр Рәисә Шәкүрова башкаруында шагыйрьнең әле шушы көннәрдә генә иҗат ителгән «Канлы бүләк» шигыре яңгырый.



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ - бәйрәм сәхнәсендә.**

*Зиннәтле өстәл—*
*Патша сөяге.*
*Череп таркалган,*
*Кемгә кирәге?*
*Улмы, түгелме?*
*Озын сакаллар*
*Шуны исбатлап*
*Акыл саталар.*
*Болыт—ак кәфен,*
*Ай яткан кереп.*
*Күккә күз яше*
*Тараткан кебек.*
*Урман ягында*
*Бүре улавы.*
*Айны юатып,*
*Дулкын уйнавы.*
*Ана йокламый,*
*Әрни күзләре.*
*Газиз улының*
*Соңгы сүзләре,*
*Тыелгысыз яшь.*
*Чечня ягыннан*
*Хат-хәбәр килгән—*
*Кара ябынган.*

*Нинди каргышлы*
*Иңрәү ул якта.*
*Ничә йөз солдат*
*Күмелми ята!*
*Аналар барды,*
*Хәл табалмады.*
*Балаларының юк*
*Танылганы.*
*Мин, бу мин диеп,*
*Иңрәде бер җан.*
*Канлы кисәкләр.*
*Танылсын каян?*
*Бу канлы бүләк*
*Яңа гасырга.*
*Ояттыр килеп*
*Каршы басарга.*
*Болыт—ак кәфен,*
*Ай яткан кереп.*
*Күккә күз яше*
*Тараткан кебек.*
*Жанга шом салып,*
*Бүре улавы—*
*Ирексез җанның*
*Үксеп елавы.*

БУ шигырьне тыңлаганнан соң залда утыручылар арасында берсенең генә дә битараф калганы булмагандыр, дип уйлыйм. Соңрак бу турыда Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ринат Мөхәммәдиев (ә Казаннан юбилей тантанасына килүчеләрдән, аңардан тыш, Республиканың халык язучысы Гариф ага Ахунов, шагыйрә, Тукай бүләге лауреаты Гөлшат апа Зәйнашева, язучы, Казан Дәүләт университеты профессоры Тәлгать Галиуллин, шагыйрь Мансур Шиһапов та бар иде) бик тә гыйбрәтле, акыллы фикерләр әйтте.

*"Без бүген төрле төбәкләрдән Гакыйль Сәгыйров кичәсенә җыелдык. Күпләребезнең аның белән әле тәүге тапкыр танышуы, - диде ул. - Физик яктан аңарда кешенең дүрттән бер өлеше генә бардыр. Ә рухи яктан Гакыйль нинди зур көчкә ия.*

*Чечня турында аның кебек итеп шигъри юллар аша әйтеп бирүче бармы икән? Әлегә юктыр, мөгаен. Гакыйльнең «Канлы бүләк» шигырен ишеткәч, чәч төпләрем чемердәп китте. Чечняда дүрт йөздән артык татар егетләре генә дә һәлак булган, шуларның күбесен йә бүреләр ашаган, йә аларның үле гәүдәләре танылмыйча шул бозлы вагоннарда аунап ята.*

*Гакыйль бүген шушы шигыре белән безнең күзебезне ачты, моңынчы башкалар әйтә алмаганны гап-гади итеп әйтеп бирә алды.*

*Миңа Джек Лондонның ижат иткән урынын - Колорадоны күрергә насыйп булды, бөек Хемингуэйның йортын да күрдем. Ул үенең беренче катында этләр, икенчесендә—мәчеләр асраган, ә иң өске катында үзе яшәп, иҗат иткән. Бер кеше күрмәсен, бер кеше кермәсен, янәсе. Менә шундый җәннәт кочагында яшәп, үзе өчен нинди шартлар тудырган кеше ул Хемингуэй.*

*Ә без Гакыйль өчен нинди шартлар тудырдык соң? Ун ел Язучылар берлеге рәисе булып эшләсәм дә, бүген мин аны беренче тапкыр күрдем, аның иҗаты белән якыннан таныштым. Миңа шулкадәр оят бүген. Без еш кына башка милләт*



**Гакыйльнең авылдашлары** - (сулдан уңга) **Нәкетдин ХАЛИТОВ, Равил МИНЕБАЕВ, Әнвәр АЛИЕВ.**

*вәкилләрен мактап сөйлибез, Расул Гамзатов дибез, Чингиз Айтматов дибез, ә үзебезнең Гакыйль кебек чын талантларыбызны—батырларыбызны күрмибез дә, белмибез дә...*

*Ул туган авылы Җүрәй турында нинди матур сүзләр табып җыр язган. Авылның исеме дә чын татарча, безнеңчә яңгырый. Без моның белән горурланырга тиешбез. Чөнки без, татарлар, Самарада да, Ульянда да, Мәләкәстә дә - үз җиребездә яшибез, һәм без моның өчен бер кешегә дә бурычлы түгелбез.*

*Без, татарлар - көчле милләт. Бүген Гакыйль Сәгыйров моның шулай икәнлеген, татар халкының матур киләчәге барлыгын тагын бер тапкыр исбат итте, күрсәтте.*

Бу сүзләргә өстәп тагын нәрсә әйтәсең инде? Бик урынлы әйтелгән сүзләр, фикерләр иде болар. Ринат Мөхәммәдиев юбилярга тышлыгына татар Гербы һәм Әләме төшерелгән Язучылар берлеге әгъзасы таныклыгын һәм 250 татар язучылары имзаларын куйган котлау хатын һәм үзенең күптән түгел генә нәшрияттан чыккан яңа китабын тапшырды, аңа яңа иҗади уңышлар, җан тынычлыгы теләде. Аның бу теләгенә башка Казан кунаклары да кушылды. Казан Дәүләт университетының татар теле бүлеге деканы, профессор Тәлгать Галиуллин, мәсәлән, Гакыйль Сәгыйровның татар студентлары тарафыннан почетлы студент итеп кабул ителүе турында белдерде.

ЮБИЛЯРНЫ тәбрикләргә, аңа бүләкләрен тапшырырга теләүчеләр чиксез күп булды. Ульян өлкәсенең Законнар чыгару җыелышы депутаты Валентина Петровна Попова аңа Почет грамотасы, ә Ульян өлкә администрациясенең милли эшләр буенча бүлегенең баш белгече Гөлфинур Измайловна Чулакова өлкә губернаторы Юрий Фролович Горячев исеменнән котлау хаты һәм акчалата бүләк тапшырды.

Самара өлкә администрациясенең милли эшләр буенча бүлек җитәкчесе Рәшит Мигдәт улы Шакиров, бүлекнең баш белгече Светлана Константиновна Жидкова губернатор урынбасары Александр Петрович Жабинның котлау хатын һәм шигъри юллар аша үзләренең юбилярга изге теләкләрен белдерделәр.

ТӘБРИКЛӘҮЧЕЛӘР арасында шагыйрьнең туган ягы Нурлат районыннан, озак еллар әнисе Хәбибҗамал апа белән гомер кичергән Самара өлкәсенең Иске Фәйзулла авылыннан һәм Кошки районы үзәгеннән килгән вәкилләр дә бар иде.

Ульян һәм Самара өлкәләренең татар җәмәгатьчелеге

исеменнән юбилярны милли-мәдәни автономия, «Туган тел» җәмгыятьләре җитәкчеләре, «Бердәмлек», «Өмет» татар газеталары, радио-телевидение журналистлары, мәгариф хезмәткәрләре, дин әһелләре тәбрикләделәр, аңа халык тарафыннан җыелган хәйрия акчаларын тапшырдылар.

Юбилейны оештыру комитеты мөрәҗәгате буенча халыктан байтак кына акча җыелган иде. Гакыйль Сәгыйров фондына яңа акча белән 10 сумнан алып 2000 сумга кадәр бирүчеләр булды.

Мәсәлән, Самарадан «Самара-М» фирмасы (җитәкчесе Гомәр Әмиров) 2000 мең сум күчерде, эшкуарларыбыз Фәхретдин Канюкаев, Нәфисә Исхакова, Равил Низамов—500әр сум, Ирек Нуриев— 350, Сания Каюмова—300 сум, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзалары Әминә Шәмсетдинова һәм Равил Яһудин—300әр сум һәм башкалар бирде. Самараның Җәмигь мәчете мөселманнарыннан 2,5 мең сум садака җыелып тапшырылды. Ә эшкуарыбыз Җәмил Вәлиуллин Самара делегациясенә Мәләкәскә бару өчен зур автобус бирде.

Бу исемлекне озак дәвам итәргә булыр иде әле. Гакыйль Сәгыйров фондына ярдәм күрсәтүчеләр турында «Бердәмлек» газетасы битләрендә даими язылып барыла, һәм бу эш әле бүген дә тукталмый.

БӘЙРӘМНЕҢ дәрәҗәсен Димитровград шәһәре, Кошки районы администрацияләре башлыклары Владимир Алексеевич Паршинның, Геннадий Васильевич Инкинның катнашуы тагын да күтәребрәк җибәрде кебек. Димитровград шәһәре, Нурлат, Кошки, Камышлы районнары җитәкчеләренең юбилярга кыйммәтле бүләкләр тапшырулары да аны чын-чынлап хөрмәтләү, олылау билгесе иде.

Бигрәк тә күп бүләкләрне мәләкәслеләр әзерләгән. Биредә зур төсле телевизор да, ике камералы суыткыч та бар... Шушы бүләкләрне тапшырганда җирле «Транссервиз» фирмасы вәкиле шагыйрь һәм аның энисе Хәбибҗамал апа яшәгән фатирга капиталь ремонт ясарга да вәгъдә бирде. Ә Димитровград шәһәре башлыгы Гакыйльнең яңа шигырьләр китабын бастыру өчен акча бүленәчәген хәбәр итте.

Әгәр без бүген Мәләкәснең «ак байлары» - «Био-Тон» фирмасының генераль директоры Геннадий Шәрифгалиевның һәм «Булгар» фонды җитәкчесе Хәйдәр Галиуллинның исемнәрен әйтмәсәк, бу гөнаһ булыр иде. Чөнки бу ике олы шәхес, үзләренең чын татар икәнлекләрен тагын бер кат раслап,

юбилей кичәсенең төп спонсорлары булдылар һәм үзләреннән бу изге эшкә зур өлеш керттеләр.

Геннадий Сахип улы Шәрифгалиев үзенең чыгышында мондый ярдәм юбилей көннәрендә генә түгел, талантлы якташыбызга даими рәвештә күрсәтелеп торсын иде, дигән теләген белдерде.

Гакыйль Сәгыйровның татар халкына, яшь буынны тәрбияләүдә керткән өлешен, балачак инвалид буларак кечкенә пенсия алып авыр тормышта яшәвен искә алып, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевка, Республика хөкүмәтенә аның пенсиясен арттыруларын сорап мөрәҗәгать кабул итәргә дигән тәкъдимне бәйрәмдә катнашучылар көчле алкышлар белән каршыладылар.

Гакыйльнең якын дуслары, аның иҗатын пропагандалаучылар Разия һәм Тәлгать Мәрдиевлар оештырган рәссамның рәсемнәре күргәзмәсе дә зур кызыксыну уятты. Бәйрәмдә алар белән сокланмаган, зур талант алдында башын имәгән кеше булмагандыр, дип уйлыйм.

КИЧӘНЕҢ икенче сәнгать өлешендәге концерт программасы да, башлыча, Гакыйль Сәгыйров шигырьләренә иҗат ителгән җырлардан төзелгән иде. Шагыйрьнең матур-матур җырлары, баксаң, берничә дистәгә җыела икән ич. Тольяттида яшәүче композитор Сания апа Әхмәтова элегрәк язылган «Каеным» җыры белән бүләккә тагын берне, өр-яңасын алып килгән. Ул шагыйрьнең юбилей кичәсендә берничә тапкыр укылган «Әтием, дип...» шигыренә язылган җыр.

Әтисен сугышта югалткан Гакыйльнең һәм бүгенге көндә дә әтисез яшәүче балаларның аяныч язмышына багышланган бу җыр ифрат та урынлы һәм гыйбрәтле яңгырады.

Димитровград шәһәренең «Сүнмәс йолдызлар» ансамбле солистлары Фәния Хәлиуллова һәм Миләүшә Халитова башкаруында шагыйрьнең «Төнге яңгыр» шигыренә, аның туганнан туган энесе Ринат Сәгыйров иҗат иткән җыр да тамашачы күңеленә хуш килгәндер. Яңа Малыклы районының Исәнтимер авылы һәвәскәрләре дә (җитәкчеләре Гакыйль Шәкүров) Гакыйль Сәгыйров шигырьләренә җырлар язганнар, аларны бик тә матур итеп башкардылар.

Казан кунагы – Татарстан Республикасының инвалидлар ассоциациясе вәкиле, журналист, композитор һәм җырчы Тәслимә Низами (Шәрәфетдинова) да юбилярның шигыренә «Тормыш - гүзәлем» җырын алып килгән.



**Гакыйль һәм аның әнисе Хәбибҗамал апа янында Тәслимә НИЗАМИ - шагыйрь һәм җырчы, Камышлыдан аның иҗатын пропагандалаучыларның берсе - Атлас ТӨХБӘТОВ.**

*Килер бер көн: үкенүдән янып,*
*Газапланып ятып үләрмен,*
*Әмма мәңге хәтеремдә калыр*
*Матурлыгы тормыш — гүзәлнең.*

Көчле шәхес тарафыннан ничек көчле әйтелгән сүзләр болар. Ә җыр, моң аша алар бигрәк тә көчле яңгырадылар,

Юбилей кичәсен алып баручы оештыру комитеты әгъзаларының иң активларының берсе—Идеал Галәүтдинов сәхнәгә яңадан-яңа җырчыларны, биючеләрне, шигырь укучыларны чакырып кына торды.

Әнә Самараның «Идел» ансамбле җырчысы Галия Мостафина Гакыйльнең башына үзе чүпләп чиккән татар түбәтәен кидерә дә, аңа һәм аның әнис Хәбибҗамал апага багышлап җыр башкара. Дөньяда яхшы әниләр күп, ә менә Хәбибҗамал апа кебек аналар бармы икән? Рәхмәт сиңа, Хәбибҗамал апа, батыр улыңның һәм үзеңнең батырлыгың өчен!

Ниһаять, сәхнәгә Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Илгиз Колючев җитәкчелегендәге Самараның атаклы «Ялкынлы яшьлек» ансамбле артистлары чыга. Алар башкаруында Гакыйль Сәгыйров шигырьләреннән һәм җырларыннан төзелгән әдәби-музыкаль композиция юбилей кичәсенең соңгы аккорды булып яңгырады дисәк, ялгыш булмас.

Ә татарның Гакыйль Сәгыйров кебек тагын бер каһарманы Фәнис Яруллинның Илгиз Колючев башкаруында түбәндәге шигыре бүгенге юбилярга махсус багышлап язылгандыр, кебек.

*Син бит, халкым, бөркет нәселеннән,*
*Һич килешми сиңа мескенлек.*
*Милләт үлми, горурлыгың булса,*
*Горурлык ул—безнең таныклык.*
*Саклап яткырмыйча йөрәкләрдә*
*Никадәрле гайрәт, көч барын.*
*Яшә, кеше, бер дә бирешмичә,*
*Башны бөек тотып, татарым!*

Бу шигъри юлларны юбилей тантанасына җыелган биш йөздән артык мәләкәслеләр һәм кунаклар аягүрә басып алкышларга күмделәр.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН, Самара өлкә “Бердәмлек” газетасының баш мөхәррире, Гакыйль Сәгыйровның 60 еллык юбилеен оештыру комитеты рәисе.**

## *ФИКЕРЛӘР:*



**Гариф АХУНОВ.**

*— Миңа, берничә ел РСФСР Язучылар берлеге сәркәтибе буларак, Самарада еш булырга туры килде. Тольяттида Совет әдәбиятының бик зур вәкилләрен җыеп, күчмә утырыш та үткәргән идек, арабызда зур шагыйрь Сибгат Хәким дә бар иде. Менә шул чакта Куйбышевның «За Родину» хәрби газетасын Хәсәнов фамилияле татар егете җитәкли иде. Ул татар язучыларына багышлап тулысынча бер бит тә чыгарды.*

*Гакыйль Сәгыйров иҗатын бездә бик әйбәт һәм югары бәялиләр. Аның дөньяга шагыйрь буларак тууы үзе бер батырлык, авыру хәлендә өзлексез язып торуы, шул ук вакытта рәсем сәнгате белән дә шөгыльләнүе—икенче батырлык. Мин үзем дә рәссам кеше, ә шулай да аның рәсемнәрен күргәч, таң калдым, бик матур, көяшлы рәсемнәр, диясе килә. Гакыйль табигатьне үз йөрәге аша тоеп рәсемгә төшерә белә.*

**Гариф АХУНОВ,**
**Татарстанның халык язучысы.**



**Тәлгать ГАЛИУЛЛИН.**

*— Гакыйль Сәгыйровның исеме татар әдәбиятында 60нчы елларның ахырында 70нче елларның башында күренә башлады. Беренче шигырьләре белән танышканда, аның шундый аяныч хәлдә икәнен белми идем. Ләкин шигырьләре миңа ошады, аларда ниндидер үзенә күрә кешелекле моң, башка кешеләр, башка татар шагыйрьләре әйтеп җиткерә алмаган ниндидер эчке сер, тирән кичереш бар иде. 70нче еллар башында аның беренче шигырь китаплары дөньяга чыкты. Шагыйрьнең язмышын белгәч, шигырьләренә тагын да игътибарлырак була башладым. Аның тормышны яратып язуы бер яктан, әле тагын рәссам да булуы, икенче яктан, минем өчен зур ачыш иде.*

*Ә инде бүген юбилейга килгәч, Гакыйльнең рәсемнәрен ныклап карадым. Чыннан да аның шигърияте белән рәссамчылык таланты арасында тирән бер эчке бәйләнеш ята. Ул Ходай Тәгалә тарафыннан зур талантка ия шагыйрь, рәссам һәм татар халкы, аның поэзиясе һәм рәсеме өчен көрәшүче.*

*Гакыйль Сәгыйров рәсемнәрендә мин яшәү дәрте күрдем. Ул моны табигатьнең иң нечкә серләренә тирәнтен үтеп керүе белән күрсәтә, яфрак күперткелегендә, яфрак күзәнәкләрендә тормыш ямен, тормыш музыкасын, тормыш симфониясен тоя, аңлый. Бу аның зур талант иясе, фикер иясе булуына тагын бер дәлил.*

**Тәлгать ГАЛИУЛЛИН,**
**Казан дәүләт университетының татар филологиясе тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы, филология фәннәре докторы, профессор.**

# Кызыл розалар

Анын эш өстәлендәге вазада кызыл розалар күргәч, якташыбыз, танылган татар шагыйре Гакыйль Сәгыйровның Мәләкәстә үткәрелгән 60 яшьлек юбилей кичәсендә Геннадий әфәнденең, сәхнәгә зур кәрзин белән кызыл розалар күтәреп менеп, юбилярга бүләк итүе күз алдыма килен басты. 60 еллыкка 60 кызыл роза!

Ничектер балачактан ук гашыйк икән ул бу чәчәкләргә. Җырда җырлаганча, кызыл розалар чыннан да сөю гөлләредер алар. Ул сугыштан соңгы авыр елларда да әтисенең, әнисенә туган көнендә хуш исле кызыл розалар бүләк итүен әле дә хәтерендә саклап йөртә. Ә менә яратканы Мәүлидәгә биргән чәчәкләрнең санын да белми инде. Бергә яшәүләренә дә утыз елга якынлашып бара икән инде. Алар гаиләсендә якын кешеләргә кызыл розалар бүләк итү бер матур гадәткә әйләнеп киткән.

*Кызыл розалар, кызыл розалар,*
*Кызыл розалар-- сөю гөлләре.*
*Кызыл розалар, кызыл розалар -*
*Күңелләреңнең кайнар хисләре.*
*Тик озакка җитсен мәхәббәтең,*
*Сулмасыннар бәхет гөлләрең..*



**Геннадий ШӘРИФГАЛИЕВ** (сулдан уңга), **Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН, Геннадий әфәнденең хатыны Мәүлидә ханым, Атлас ТӨХБӘТОВ, Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА, Җәмил САДРИЕВ.**

Ә ул үзен бик бәхетле кеше дип саный. Чөнки бу дөньяда яратып, яратылып, тормышның кадерен, матурлыгын тоеп, кешеләрдән берни дә яшерми яши. Гакыйль Сәгыйров турында беренче тапкыр ишетеп, аның шигырьләре һәм рәсемнәре белән танышкач ук, ул аңа нindидер бер якын кеше булып күренде. Әйтерсең лә алар инде күптәнге танышлар, шагыйрь күңелендәге кайнар хисләр аның күңеле түрендә дә урын алганнар. Шуңа күрә Гакыйльгә юбилей кичәсендә 60 кызыл роза бүләк итүе бик тә табигый булды.

Без Геннадий Сәхип улы Шәрифгалиев белән беренче тапкыр нәкъ шул юбилей алдыннан, февральнең суык көннәренең берсендә ул эшли торган «БИО-ТОН» сөт фирмасындагы эш бүлмәсендә очраштык.

Юбилей кичәсен үткәрер өчен ухырып, матди ярдәм күрсәтергә спонсорлар эзләп йөргән чак иде. Гозеребезне тыңлагач, Геннадий әфәнде безне тынычландырырга ашыкты һәм үзенең кулыннан килгән кадәр булышлык күрсәтәчәген әйтте. Бу шулай булып чыкты да. Юбиляр да, Татарстаннан, Ульян, Самара өлкәләреннән килгән күпсанлы кунаклар да, мәләкәслеләр дә кичәдән бик канәгать калдылар. Шәрифгалиев матди ярдәм күрсәтеп кенә калмыйча, бәйрәмне киң, истә калдырырлык итеп оештыру өчен үзенең бөтен көчен куйды. Аның юбилей кичәсендә талантлы якташыбызга бәйрәм уңаеннан гына түгел, ә даими рәвештә ярдәм күрсәтергә кирәклеге турында әйткән акыллы сүзләре әле дә колагымда яңгырый сыман. Халкыбызның чын зыялылары нәкъ Шәрифгалиев кебек булырга тиешләрдер дә, мөгаен. Ә ул милләттебез, телебез, яшәсен дип үзенең бөтен байлыгын, көчен, сәләтен бирергә әзер торырдай кеше. Мин моны аның белән булган берничә очрашуда ук бик яхшы аңладым. Каян килгән соң аңа шушындый матур милли аң, кешеләргә карата булган мәрхәмәтлелек хисе?

Болар барсы да балачактан ата-ана тарафыннан бирелгән тәрбиядәндер, мөгаен. Алма алмагачтан ерак төшми, дигән әйтем бар бит халыкта... Аның әтисе белән әнисе бергә сугыштан соң кушылганнар. Сугыш башланган беренче көннәрдә үк фронтка киткән Сәхип абый (ул партия райкомында җаваплы урында эшләгән кеше армиядә дә, лейтенант дәрәҗәсендәге офицер булып хезмәт иткән), каты сугышларда камалышка эләгеп, фашистлар тарафыннан әсирлеккә алына һәм Германиягә концлагерьга озатыла. Аңа сугыш тәмамлангач кына туган якларына әйләнеп кайтырга насыйп була. Ә әсирлектә булган

солдатларга ул еллардагы караш һәркемгә яхшы билгеле. Сугышка кадәр яратып өйләнгән беренче хатыны да, аны көтеп тормыйча, башкага кияүгә чыгып куйган. Элеккеге иптәшләре дә аның белән бөтенләй бүтән мөгамәләдә. Сәламәтлеге дә әсирлек елларында нык какшаган—үпкәсендә туберкулез чире.

Ләкин Сәхип абый кыенлыклар алдында баш иеп торучылардан булмый. Яшь хатыны Асия апа да - иренең нинди халәттә икәнлеген, аның эчке кичерешләрен аңлый белә торган кеше. Шулай итен, алар бик тиз уртак тел табып, матур гына тормыш корып җибәрәләр. Тормышының соңгы елларында Сәхип абый инде хезмәткә яраклы булмыйча, гел түшәктә генә ятып торырга мәҗбүр булса да, балаларын тәрбияләүдә (ә алар өчәү, иң олысы Геннадий) үзеннән зур өлеш кертә. Асия апа да балаларында әтиләренә карата хөрмәт тәрбияләргә тырыша.

- Минем исемне дә Геннадий дип әтием биргән, - дип сөйли Шәрифгалиев. - Әсирлеккә алар Геннадий исемле иптәше белән эләккәннәр. Ул Кемерово өлкәсенең Новокузнецк шәһәреннән булган. Шунда бер-берсенә вәгъдәләр бирешкәннәр. Әти, әгәр исән калсам, улым туса, аңа синең исемеңне бирер идем, дигән. Ул үз сүзендә торган да. Миңа, Башкортстанның чын татар авылында (Яңавыл районының Четырма авылы) туган малайга Геннадий дип исем кушканнар.

Геннадий кечкенәдән намуслы, үз сүзенә нык торучы, иптәшләренә һәм дусларына беркайчан да хыянәт итә белмәүче кеше булып үсә. Ана 12 яшь тулып килгәндә, озак һәм бик каты авырудан әтисе Сәхип абый үлеп китә. Асия апа 36 яшендә өч ятим бала белән ялгызы кала.

Әнисе кырга эшкә киткәч, Геннадийга энесе белән сеңелесен дә карарга, бәрәңге бакчасын да утарга, мал-туар астыннан тиресне дә чистартырга туры килә.

Сигез классны тәмамлагач, Удмуртиянең Сарапул шәһәренә азык-төлек техникумына укырга керергә имтиханнар бирергә китәсе соңгы көнгә кадәр комбайннан төшмичә, комбайнчы ярдәмчесе булып эшли.

Сарапулда техникумны тәмамлап, армиядә хезмәт иткәннән соң, Геннадий Ульянда политехник институтта укып, югары белемле белгеч булып чыга.

Бу дөньяда аның дуслары аз түгел. Шундыйлар арасында татар халкының бүгенге атаклы җырчысы Салават Фәтхетдиов, популяр композитор һәм башкаручы Фирзәр Мортазин да бар. Ә менә Гакыйль Сәгыйров юбилеенда ул тагын әллә

күпме яңа дуслар тапты. Татарстанның танылган язучылары Гариф Ахунов, Гөлшат Зәйнашева, Ринат Мөхәммәдиев чын күңелләреннән аңа үзләренең китапларын бүләк иттеләр. Сәламәтлеге какшау сәбәпле аның якташы, Четырмадан берничә чакрым ераклыктагы күрше авылда туып-үскән татар халык шагыйре Илдар Юзеев кенә килә алмаган иде юбилейга. Югыйсә, Гакыйль Сәгыйровның шигырьләрен беренче тапкыр дөньяга күрсәтүче буларак, Илдар абый - бу олы бәйрәмнең иң түрендә утырырга тиешле кеше.

Ә инде Геннадий һәм аның чордашлары барысы да Илдар Юзеевның “Таныш моңнар”ына һәм башка әсәрләренә гашыйк булып, шулар белән саташып үскән егетләр бит. Шуңадыр да татар моңын, татар җырын ишетүгә, хәзер дә үзен шул яшь чакларына әйләнеп кайткандай тоя ул.

Мәктәптән авылга кунакка кайткан Мәүлидәгә дә мәхәббәт турында шигырьләр сөйләве әле дә хәтерендә. Бәлки, нәкъ шуның һәм бүләк иткән кызыл розалары белән шәһәр кызының йөрәген яулап ала алгандыр да Геннадий. Хәзер әнә инде балалары үсеп җитеп, бер-бер артлы зур тормышка аяк басканнар.

Бу мөлаем, көләч йөзле кеше белән теләсә нинди темага, теләсә күпме сөйләшеп утырырга була. Аның һәрнәрсәгә карата үз карашы, үз сүзе бар.

Ул дөньяда халкыбызның тоткан урынына, аның бүгенгесенә һәм киләчәгенә дә битараф түгел. Бу турыда сөйләгәндә Геннадий әфәнденең күзләренә чаткылар тагын да өстәлгән сыман тоела.

Минем күз алдыма бу мизгелләрдә тагын аның тарафыннан Гакыйль Сәгыйровның юбилеенда шагыйрьгә бүләк ителгән кызыл розалар килеп баса. Алтмыш хуш исле кызыл роза!

- *Гакыйль Сәгыйров - минем өчен тере легенда ул,* - ди Шәрифгалиев. - *Мин аның ачы язмышы аша туган халкыбызның язмышын күрәм төсле. Талантлы татар милләтебез дә бүген, Гакыйль Сәгыйров кебек үк, безнең ярдәмгә мохтаҗ. Без бу турыда беркайчан да исебездән чыгарырга тиеш түгелбез.*

Мин тагын бер тапкыр аңа һәм өстәлдәге кызыл розаларга күз ташлап алам.

*Кемнәр генә сезгә сокланмый,*
*Сөю гөле, бәхет гөле - кызыл розалар...*

Әйе, шушы кызыл розалар төсле матур, саф күңелле кеше сез, Геннадий әфәнде.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**
Самара - Мәләкәс - Самара.

# Бар да якын туган якның бизәге...



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ үзенең рәсемнәре күргәзмәсендә.**

Самараның Журналистлар йортында төрле күргәзмәләр үткәрү инде гадәти күренешкә әйләнеп бара. Бу юлы биредә вестибюльне атаклы татар шагыйре, рәссамебез, якташыбыз Гакыйль Сәгыйровның һәр ноктаны тиешле урынына җиткереп, табигатьнең, гомумән тормышның бөтен матурлыгын, хикмәтләрен күрсәтеп эшләнгән кырыктан артык рәсеме бизәде.

Шушы күргәзмә ачылу уңаеннан биредә күпсанлы газета, радио, телевидение журналистлары, якташларыбыз, Гакыйльнең олы талантына баш июче, аны хөрмәт итүче кешеләр җыелган иде. Залга эленгән рәсемнәрнең һәркайсы дикъкатьне шунда ук җәлеп итә. Беренче ак кар, язгы яшен, туган йорттагы тирәк, инеш өстендә искиткеч матур булып ачылып килүче лилия чәчәкләре... Аларның һәркайсы тормышка дан гимны булып яңгырый сыман...

Ә бит ул рәсемнәрне унбиш яшендә умыртка сөягенә уңышсыз ясалган операциядән соң бөтенләй хәрәкәтсез калырга дучар булган Гакыйль Сәгыйров каләмне тешләре арасына кысып язган...

Быел аңа 16 февральдә 60 яшь тулды. Самараның, Татарстан һәм Ульян өлкәсенең татар җәмәгатьчелеге аның олы юбилеен тантаналы итеп билгеләделәр. Ә менә бүген, Гакыйль юбилееның дәвамы буларак, аның рәсемнәр күргәзмәсе ачыла.

Танылган якташыбызның юбилеен оештыруга күп көч куйган, аның оештыру комитетын җитәкләгән Самара өлкә «Бердәмлек» газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин күргәзмәне әзерләүчеләрнең, әйдәп йөрүчеләрнең берсе булды. Шуңа күрә бу тантананы ачып җибәрүне аңа тапшыру бик тә урынлы иде, минемчә.

*- Хөрмәтле дуслар,* - дип башлады ул сүзен. *- Бүген без Гакыйль Сәгыйровның рәсемнәре күргәзмәсе ачылу тантанасына җыелдык. Аның фаҗигале, ләкин шундый гүзәл тормышы һәм улының язмышын уртаклашып яшәүче әнисе— хөрмәтле Хәбибҗамал апаның батырлыгы күпләр өчен үрнәк булып тора. Самарада 1998 ел «Гакыйль Сәгыйров елы» дип игълан ителде, һәм ул, әйтергә кирәк, бик уңышлы бара. Менә бүгенге тантана да шуны күрсәтә түгелме?*

Аның бу фикерләре белән күргәзмә ачу тантанасында катнашкан һәр кеше килешкәндер, дип уйлыйм. Шунда чыгыш ясаучыларның кайбер фикерләрен язып алып, алар белән «Бердәмлек» укучыларын да таныштырырга булдым.

**Рәшит ШАКИРОВ — өлкә администрациясенең милли эшләр һәм иҗтимагый оешмалар белән элемтәләр буенча бүлек җитәкчесе.**

*- Гакыйль тормышында бөеклек һәм әрнеш, игелек һәм афәт, шатлык һәм хәсрәт кебек төшенчәләр арасында тыгыз бәйләнеш барлыгы ачык күренә. Ул авырлыкларга бирешмичә, алардан сыгылып төшмичә, тормышка, яктылыкка омтылышын өзмичә яши. Дөрес, аңа яшәргә дә, иҗат итәргә дә бик кыен. Бу Гакыйльнең кайбер рәсемнәрендә дә, шигырьләрендә дә сизелә. Ләкин ул үзендә табигатьнең матурлыгы, тирән мәхәббәт, хәтта үзе күрмәгән кичерешләр турында да дөрес һәм инандырырлык итеп язарга көч таба. Чөнки Гакыйль аларны шагыйрь һәм рәссам күзлегеннән чыгып күрергә тырыша. Мин Гакыйльнең 60 еллык юбилеенда аның шигырьләрен тәрҗемә итеп, рус телендә китабын чыгаруда катнашырга сүз биргән идем. Менә хәзер пенсиядәге әтием белән бергәләп, шушы эш белән мәшгуль без.*

*Аның шигырьләре һәм рәсемнәре безне уйланырга, тормышка шатланырга өйрәтәләр. Гакыйль Сәгыйров — ачык йөзле, саф күңелле чын шагыйрь һәм рәссам, Бөек Кеше дияр идем.*

**Нурхатим БИКУЛОВ — СССР һәм Россия Рәссамнары берлеге әгъзасы.**

*- Гакыйль Сәгыйровны мин моңа кадәр «Кабатланмас моң» шигырьләр китабы һәм андагы репродукцияләре аша гына белә идем, ә бүгенге күргәзмәдә аларның төп нөсхәләрен (оригиналларын) күреп, шатлыклы дулкынлану кичердем.*

*Гакыйль — берьюлы рәссам дә, шагыйрь дә ул. Гүзәллек, матурлык, нәфислек, күркәмлек сурәтләнгән бу рәсемнәрнең һәркайсы— шигърият дөньясы. Аларга карап, шигырь дә язып*



**Рәссамның Камышлыда оештырылган беренче рәсемнәр күргәзмәсе янында аның иҗатын пропагандалаучыларның бер төркеме** (сулдан уңга) **Фәрхәт МӘХМҮТОВ, Разия МӘРДИЕВА, Атлас ТӨХБӘТОВ, Халидә ГЫЙЛАҖЕВА, Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

*була. Моның өчен талант кына кирәк, ә Гакыйльдә ул бар.*

*Үзем рәссам буларак, мондый рәсемнәрне натурадан ясап булмый, ясаган очракта да алар бу кадәр дулкынландырмас иде, диясем килә. Гакыйль аларны үзенең йөрәге, күңеле, җаны аркылы үткәреп язган.*

*Күргәзмәдәге рәсемнәрнең барысы да даһи. Мин үзем рәсемнәрне буяу белән ясыйм, ә менә Гакыйльнең иҗаты белән танышкач, графика белән эш итмәвемә үкенеп тә куйдым. Рәсемне башкару техникасында да, композициясендә дә Гакыйль - бик югары дәрәҗәдәге профессионал. Самараның график рәсем өстендә эшләүче рәссамнарына аңардан күп нәрсәгә өйрәнергә мөмкин. Шундый эчтәлекле, матур күргәзмә оештырып, Гакыйль Сәгыйровның иҗаты белән якыннан танышырга мөмкинлек бирүчеләргә зур рәхмәтле мин.*

**Атлас ТӨХБӘТОВ – Камышлы район хастаханәсенең баш табибы, югары категорияле врач.**

*– Гакыйль белән беренче тапкыр 14 февральдә–аның 60 еллык юбилеенда таныштым. Шуннан бирле тормышымда нindидер зур борылыш булып, күңелгә, рухка чисталык, сафлык өстәлде сыман. Аның белән очрашасы, сөйләшәсе, аны тыңлыйсы килеп тора. Шуңа күрә дә соңгы айларда аның янында дүрт тапкыр булып, Гакыйльгә яшәргә, иҗат итәргә көч бирүче әнисе–хөрмәтле Хәбибҗамал апа, Наил энесе, киленнәре Халидә ханым, аларның уллары Марат һәм Ринат белән якыннан таныштым.*

*Гакыйль хәрәкәтсез ята. Ләкин тормышның кадерен белеп, аны тирән аңлый һәм аңлата алуы, саф намуслы булуы, нинди генә шартларда да рухи төшенкелеккә бирелмәве белән безнең бик кубебезгә үрнәк ул. Бу мәгънәдә алганда, ул безнең ярдәмгә түгел, без аның ярдәменә мохтаҗ. Безнең арада менә шундый кеше яшәве—үзе бер зур шатлык. Аның искиткеч бай, тирән эчтәлекле иҗаты белән һәр кеше таныш булырга тиеш, дип уйлыйм.*

*Без Камышлы районында бу эшне киң оештырдык. Районыбызда ачылган «Нур» телевидениесе Гакыйль турында өч программа хәзерләде инде (аларны без Димитровградка барып төшереп кайткан идек), «Камышлы хәбәрләре» газетасында рус һәм татар телләрендә зур язмалар бирдек. Безнең үтенеч буенча алар күрше Кләүле, Исаклы һәм Похвистнево районнары газеталарында да басылып чыктылар. Ә хәзер махсус әдәби битләрдә Гакыйльнең шигырьләрен урнаштырырга җыенабыз.*

*Бүген бирედә ачылган күргәзмә дә үзенең юлын Камышлыдан башлады. Районыбызның бик күп халкы Гакыйльнең рәсемнәре белән район Мәдәният йортында оештырылган күргәзмәдә таныша алды. Танылган якташыбызның иҗатын халыкка җиткерү эшен без киләчәктә дә даими рәвештә алып барачакбыз. Бу эшне Самарада да дәвам итсеннәр иде.*

*Гакыйльгә, аның «икенче кояшы» булган сөекле әнисе Хәбибҗамал апага нык исәнлек телим. Аларның икесенең дә гомере кояшныкыдай озын булсын. Ә иңде шагыйрьнең «Икенче кояш» дип аталачак дүртенче шигырь китабын чыгаруда булышу — безнең уртак бурычыбыз, дип саныйм.*

**Азат НАДИРОВ – Самара өлкә «Туган тел» җәмгыяте директоры.**

*- Быел «Бердәмлек» газетасы редакциясе, өлкә «Туган тел» җәмгыяте тырышлыгы белән башланган юбилей хәзерлекләренә Ульян өлкәсендә, Татарстанда яшәүче татар җәмәгатьчелеге дә кушылгач, Гакыйльнең юбилее зур бәйрәмгә әверелде. Ул районнарда, мәктәпләрдә әле һаман дәвам итә. Бүгенге күргәзмә дә шул бәйрәмнең дәвамы.*

*Гакыйль турында сөйләгәндә, иң элек мин аның тормыш кояшы—Хәбибҗамал апа алдында баш ияр идем. Нигә дисәң, армый-талмый, язмышыннан зарланмый, бөтен көчен, йөрәк җылысын улына биреп тора ул.*

*Мин үзем дә рәсем сәнгате белән мавыгам. Шуңа*

*да бирегә эленгән һәр рәсемдә Гакыйльнең рәссамлык таланты тулысынча камилләшкән булуын бик ачык күрәм. Сокландыргыч табигатебезнең төрле күренешләрен буяусыз, графика ысулы белән ясаганда, аларны ул үзенең какшамас рухи көче белән сугарган. Рәсемнәрдә өметсезлекнең шәүләсе дә күренми. Табигать көчен, аның бөеклеген ул, атаклы рәссам Левитан кебек үк, мәгънәле итеп күрсәтә белә.*

*«Кышкы иртә» рәсеме бик саран чаралар белән ясалган булса да, мәгънәсе бик тирән: көчле буранга да карамастан, бу кеше ат җигеп юлга чыккан. Димәк, ул үз алдына кыенлыкларны җиңеп, максатына ирешү бурычын куйган. Ә бу исә зур өмет тудыра. Бу рәсемнең «Кабатланмас моң» китабы тышлыгына куелуы да очраклы хәл түгел, минемчә. Гакыйль үзе дә шул өмет белән яши, эшли, безне дә тормышның ләззәтен танып яшәргә өйрәтә.*

**Таһир МАМЫШЕВ – Самара Җәмигъ мәчетенең мөтәвәллият әгъзасы, хаҗи.**

*– Бисмилләһир-рахманир-рәхим. Әссәламегаләйкүм вә рәхмәтуллаһ вә бәрәкәтүһ! Гакыйльнең татар халкы өчен зур горурлык икәнлеген әйтәсем килә. Бүгенге күргәзмәне аның юбилеенда күрсәтелгән хөрмәт билгесенең дәвамы дип атар идем мин. Танылган якташыбызның иҗатын халыкка җиткерү эшен алга таба да дәвам итеп, аны гомуми тырышлык белән алып бару кирәк.*

**Идеал ГАЛӘҮТДИНОВ – өлкә “Туган тел” җәмгыяте советы әгъзасы.**

*- Мин Гакыйль иҗаты белән күптәннән таныш һәм аны йөрәгем белән кабул итеп, аның таланты алдында баш иям. Шуңа күрә Гакыйльнең 60 еллык юбилеен хәзерләү һәм үткәрүдә дә мин көчемне жәлләмәдем. Киләчәктә дә бу эшемне дәвам итәчәкмен.*

**Разия МӘРДИЕВА - Гакыйль талантын тирән хөрмәт итүче, аңа ярдәм кулын сузарга әзер торучы пенсионер.**

*- Дүрт ел элек Гакыйльнең «Кабатланмас моң» исемле шигыри җыентыгын укыгач, миндә бу талантлы кеше белән якыннан танышу теләге туды. Җәйге көннәрен әнисе белән үткәрә торган Иске Фәйзулла авылына барып, Гакыйльнең үзе, хөрмәтле Хәбибҗамал апа белән күрешеп, озак кына сөйләштем. Шуннан бирле безнең арада элемтә өзелгәне юк. Алар гаиләбезнең кадерле кунаклары. Гакыйль - искиткеч мәгънәле, оста әңгәмәдәш!*

*Аның рәсемнәр күргәзмәсен оештыру турында сүз чыккач, Гакыйль башта ышанмады. Шулай да, аңа хәзерлекне ул үзенә максат итеп куйды һәм элек ясалган рәсемнәре янына кыенлыкларны җиңеп, яңадан-яңаларын өсти барды. Бүген без Гакыйльнең иҗат җимешләре - аның искиткеч рәсемнәре белән соклана алабыз.*

*Мин Гакыйль исеменнән шушы күргәзмәне оештыруда беренчеләрдән булган Атлас Төхбәтовка, "Бердәмлек" газетасы редакциясе коллективына рәхмәт җиткерәм.*

*Бу күргәзмә талантлы якташыбыз йөрәгенә бәлзәм булып ятсын һәм озак еллар иҗат ләззәтенә чумып яшәргә көч бирсен.*

**Фәния ШӘФИГУЛЛИНА.**
"Бердәмлек", №24, 9-15 июнь 1998 ел.




**Күргәзмәне ачканнан соң. Самараның журналистлар йорты алдында** (сулдан уңга) **Мидхәт ШАКИРОВ, Нурхатим БИКУЛОВ, Азат НАДИРОВ, Фәрхәт МӘХМҮТОВ, Фәния ШӘФИГУЛЛИНА, Мәрьям МОСТАФИНА, Разия МӘРДИЕВА, Атлас ТӨХБӘТОВ, Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

# Самара өлкә Сабан туенда - рәсемнәр күргәзмәсе



Самара төбәгенең мәшһүр татары Гакыйль СӘГЫЙРОВ.

1998 елның февралендә талантлы якташыбыз, гомеренең зур өлешен Кошки районының Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылында үткәргән танылган татар шагыйре һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровка 60 яшь тулды. Бу олы юбилейны татар җәмәгатьчелеге зур бәйрәм буларак билгеләп үтеп, 1998 елны Гакыйль Сәгыйров елы дип игълан итте. Баштан татарлар күпләп яшәгән Камышлы районы үзәгендә, аннан соң Самараның өлкә Журналистлар йортында рәссамның каләмен тешләре белән кысып ясаган кырыктан артык рәсемнәре күргәзмәсе үткәрелгән иде. Ә менә хәзер «Бердәмлек» газетасы коллективы һәм «Азатлык» татар-башкорт яшьләре берлеге инициативасы буенча шушы күргәзмә Самараның Юрий Гагарин паркына өлкә Сабан туена җыелучыларга да тәкъдим ителде. Рәссамнең рәсемнәре, осталыгы белән сокланмаган кеше булмагандыр, мөгаен. Күпләр үзләренең фикерләрен махсус кенәгәгә теркәп калдырдылар.

Сабан туенда Гакыйль Сәгыйров үзе дә катнашты. Чөнки аңа күптәнге традиция буенча өлкә «Туган тел» җәмгыяте карары нигезендә «Самара төбәгенең 1998 елгы мәшһүр татары» дигән мактаулы исем бирелде. «Туган тел» җәмгыяте исеменнән махсус диплом һәм мең сумлык акчалата приз тапшырганда, өлкәбезнең милли хәрәкәт әгъзалары Гакыйль Сәгыйровның яшь буынны тәрбияләүгә, мәдәниятебезне, телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне саклауга керткән зур өлешен билгеләп үттеләр.

Самара төбәгенең 1998 елгы мәшһүр татары Гакыйль Сәгыйров үзенең җавап сүзендә, иҗатына һәм эшчәнлегенә

шундый олы бәя биргәннәре өчен, рәхмәтен белдерде. Аның авызыннан яңгыраган шигъри юллар да бик тә урынлы һәм мәгънәле иделәр.

*«Мин татар да, син татар,*
*Икебез дә татарлар.*
*Ике татар бергә килсә,*
*Сөйләшер сүз табарлар...*
*Менә ничек матур итеп*
*Әйткән безнең бабайлар.*
*Яшәгәннәр бабайларым*
*Яшерми татарлыгын.*
*Кирәк икән, җыр сузганнар,*
*Яңгыратып татар моңын.*
*Бәйгеләрдә аклаганнар*
*Халкымның батырлыгын.*
*Башка милләт халкы белән*
*Бутамасыннар безне.*
*Әйтеп торсын исемебез*
*Татар икәнебезне.*
*Өйрәник, белик, яратыйк*
*Без туган телебезне*
*Һәм изге динебезне...»*

Самара төбәгенең мәшһүр татары Гакыйль Сәгыйров әйткән бу теләкләр тулысынча тормышка ашачагына шигебез юк.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**



**1998 елның июнендә Самара өлкә Сабан туенда Гакыйль СӘГЫЙРОВны хөрмәтләү тантанасы.**

# Алты лауреат арасында

## «Вөҗданлылык» бүләгенә лаек булган Гакыйль СӘГЫЙРОВ та бар



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ - «Вөҗданлылык» бүләге иясе.**

Самараның Актерлар йортында беренче тапкыр "Вөҗданлылык" ("Благородство") бүләкләрен тапшыру тантанасы булып узды. Бирегә күпсанлы самаралылар җыелган иде. Аларга «Хәерле эш» акциясе советы әгъзасы, өлкә губернаторы урынбасары Владимир Мокрый котлау сүзләре белән мөрәҗәгать итеп, чын күңеленнән шушы зур бәйрәмнең сәбәпчесе булган «Ностальжи» радиосының генераль директоры Елена Хегайга үзенең олы рәхмәтен белдерде.

— Россия халкы, — диде ул, — һәрвакытта да үзенең рухы, намуслылыгы, вөҗданлылыгы һәм батырлыгы белән аерылып торды. Ә бүгенге кыен вакытларда җәмәгатьчелеккә вөҗданлылык күрсәтүче кешеләргә бигрәк тә игътибарлы булырга кирәк.

Совет әгъзалары төрле оешмалар тарафыннан тәкъдим ителгән 16 кандидат арасыннан «Вөҗданлылык» бүләгенә лаек дип табылган алты лауреатны сайлап алганнар.

**Олег Моцарь**, **Александр Богачев, Дмитрий Раков** — эзләү- коткару хезмәте күрсәтү хезмәткәрләре. Алар һәркайчан кешеләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклап калу сагында торучылар. Шулай ук фехтование буенча Олимпиада уеннары, Дөнья һәм Европа чемпионы, атказанган спорт мастеры **Валерий Захарченко** да бүләккә лаек булды. Ул дөнья чемпионатында көндәшенең кылычы сынгач, аңа үзенекен сузып, зур намуслылык күрсәткән кеше.

Хәрби госпиталь врачы **Михаил Федосеев**, ятим балаларны

тәрбиягә алган укытучы **Юрий Устинов** күрсәткән вөҗданлылык үрнәкләре турында да күп яхшы нәрсәләр әйтелде.

Ә инде ике лауреат турында аерым сөйлисе килә. **Наталья Осколкова**ның бөтен тормышы инвалид коляскасында уза. Ләкин шулай да ул язмыштан мәрхәмәтлелек көтеп яшәми, үзе шундый башка гарипләргә ярдәм итәргә тырыша. Наталья Владимировна – инвалидларның «Равный» исемле регионара җәмгыять рәисе урынбасары. Ул инвалидларның ялын оештыруда, көнкүрешләрен яхшыртуда көчен кызганмый.

Ә милләттәшебез Кошки районының Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылында яшәүче, быел үзенең 60 еллыгын билгеләп үткән, күпләргә яхшы таныш булган танылган татар шагыйре һәм рәссам **Гакыйль Сәгыйров**ка шушы зур бүләкне тапшырганда Самара драма академия театры артисткасы, СССРның халык артисткасы Вера Ершова каһарман якташыбыз алдына тезләнеп, башын иде. Аның лауреат турында сөйләгән сүзләрен тыңлаганда, залда утыручыларның күбесенең күзләре яшь бөртекләре белән чыланган иде.

Милләттәшебезнең кешеләргә күрсәткән яхшылыгын, вөҗданлылыгын сүзләр белән генә әйтеп бетерерлек түгел.



**Бүләкне Гакыйльгә СССРның халык артисткасы Вера ЕРШОВА тапшыра.**

Биредә оештырылган аның рәсемнәр күргәзмәсен беренче тапкыр күрүчеләр Гакыйль Сәгыйровның батырлыгы алдында шулай башларын иеп, аңа рәхмәтләрен белдерделәр.

«Вөҗданлылык» бүләген тапшыру киләчәктә һәр елны оештырылачак дигән ышаныч бар. Шулай була күрсен инде.

Ә без тагын бер кат барлык лауреатларны, бигрәк тә милләттәшебез Гакыйль Сәгыйровны шушы зур уңышлары белән тәбриклибез.

**Рәфыйк НӘБИУЛЛИН.**
"Бердәмлек", №41, 6 - 12 октябрь 1998 ел.



**Россия Журналистлары берлегенең Самара өлкә оешмасы җитәкчесе Ирина ЦВЕТКОВА Гакыйль СӘГЫЙРОВны зур бүләге белән тәбрикли.**

# Сизгер зиһенле Гакыйль



Нурхатим БИКУЛОВ.

**Ниһаять, «Самара матбугат йорты» нәшриятында Гакыйль Сәгыйровның инде күптәннән көтелгән «Кабатланмас моң» дип аталган шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Бу - төрле яктан уникаль китап. Ул ике телдә бастырылган: авторның туган татар телендә һәм рус теле тәрҗемәсендә. Шигырьләр белән беррәттән китапта авторның рәсемнәре дә урын алган. Һәм шунда ук Фәния Шәфигуллинаның Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы, якташыбыз, рәссам Нурхатим Зарип улы БИКУЛОВ белән әңгәмәсе дә урнаштырылган. Без аны сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәбез.**

*Самараның күренекле рәссамы, Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы Нурхатим Бикуловның иҗат мастерскоена мин бер генә максат белән килдем: Гакыйль Сәгыйровның рәсемнәрен берәмтекләп карый-карый, профессиональ рәссам ярдәмендә аның графикасының аклы-каралы тылсым серенә төшенергә телим.*

**- Гакыйль белән очрашырга туры килсә, аңа иң беренче нинди сорау бирер идегез?**

- Ә мин аның белән очраштым инде. Быелгы Самара өлкә Сабан туенда, аның күргәзмәсе янында. Мин аңардан: «Рәсемнәрең шигырьләреңә иллюстрацияме?»—дип сорадым. Ә ул: «Юк, шигырьләр дә, рәсемнәр дә мөстәкыйль рәвештә туалар»,—дип җавап бирде.

**- Аларны нәрсә якынлаштыра... икән соң?**

- ...шигърият. Аның һәр рәсеменнән шигърият бәреп тора. Гакыйльнең рәсемнәреннән шигырь язып, ә шигырьләреннән рәсем ясап була. Карагыз әле: ул нәрсә генә эшләмәсен: шигырь язсынмы, рәсем ясасынмы—бу бит җан сыкравы. Мондыйны һич кенә дә натурадан язып булмый...

**- Әйтик, профессионал буларак, сезгә аның бер рәсемен сайлап алырга тәкъдим итеелде, ди...**

- Бу җиңел булмас иде. Миңа аның күп рәсемнәре ошый.

Гакыйль техникада, композициядә үзен профессиональ итеп күрсәтә, аның пластик культурасы да югары.

**- Шулай да...?**

- Мөгаен, мин «Салкын иртә»не сайлар идем. Сызыклар ярдәме белән рәссам кышкы күк йөзен шундый итеп тасвирлаган... бер чиртсәң, һава вак боз кисәкләренә ватылыр сыман.

**- Сез аңа бу турыда әйттегезме?**

- Ничек бу рәсемен ясаганын сорадым. Анда бит әле сызгыч та кирәк. Ул болай аңлатты: «Мин рәсемнең нинди буласын сиздем генә. Һәм сызгыч тоткан ярдәмчемә «якынрак», «ераграк» дип әйтеп тордым. Соңыннан үзем ясап бетердем».

**- Гакыйль узган җәйдә үзләренең Иске Фәйзулладагы өйләрендә очраклы рәвештә кайчандыр карандаш белән өстән-өстән генә ясалган беренче рәсемнәре табылуын (ул аларны әле үз кулы белән ясаган булган) сөйләгән иде.**

- Мин моны белмәдем...Дөрес, ничек башлаганы, кемдә укыганы турында сораштым. Бу сорауны икебезгә дә бирсәләр, җавабы бертөсле булыр иде: «Огонек» журналы буенча. Ул вакытта анда искиткеч репродукцияләр, шедеврлар бастырыла иде. Мин дә, Гакыйль кебек, авыл малае шул журнал аркасында Кустодиев, Репин, Суриков һәм башка рәссамнар белән таныштым. Соңрак миңа училище, аннан Харьковта сәнгать институтын тәмамларга насыйп булды. Ә Гакыйль «үзен-үзе» укыткан. Хәзер дә әле ул бик яхшы иҗади формада.

**- Аның соңгы рәсемнәренең берсе аңа хас булмаган, яңа манерада ясалган. Хәтта ул тема бөтенләй аныкы да түгел, күбрәк сезнеке дип әйтергә була.**

- Әйе, «Лилияләр» - Сәгыйровның иң гүзәл рәсемнәренең берсе. Ассоциация: елга чәчәкләре - матур кызчыклар - су кызлары. Искиткеч! Мәңгелек тема. Минем үземнең дә «Русалка»м бар. Ләкин Сәгыйровта ул - бөтенләй башка дөнья. Гоголь, Крамской яки башка берәрсенеке төсле түгел. Ул үзенчә образны үзләштерә: Гакыйль рәсемендә яшь һәм шат, авырлыклар күрмәгән кызлар. Гүя алар тере су белән юынганнар, яңа гына шаярып, су сибешеп уйнаганнар. Бу - табигатьнең сафлыгын сурәтләү, теманы бөтенләй яңача хәл итү. Тик, миңа калса, композиция төгәлләнмәгән. Арткы планда сурәтләнгән караңгы төстәге агач кәүсәләре урынына бөдрә таллар, офыкны сурәтлисе килә. Шигъриятлелек темасын шундый кырыс рамкага чикләргә ярамый. Исегездәме аның «Яз» дигән рәсемендә нинди иксез-чиксез киңлекләр? Нинди матур!

**- Лэкин «Лилиялэр» - экият сюжеты бит...**

- Ә «Яз» экиятнеке түгелме? Табигатьтә бик күп нәрсәләр экияттәгедәй. Гакыйль моны бик яхшы күрә дә, сизә дә. Менә композиция буенча сизгерлек белән җиренә җиткереп төзелгән. Алдагы планда (имән булса кирәк) - калын, кәкре, кара агач. Ә сул якта яшь каен. Нәфис, ап-ак, кар кебек пакь... Шул экият түгелмени? Шагыйрь әйтмешли «...шулай ук ялгыз гына биек имән басып тора...» Тик моң гына башка. Ә бит бу рәсем моннан 30 ел элек ясалган.

**- Минемчә, Гакыйль күбрәк кышны ярата.**

- Минем фикеремчә, кышкы сериядә бөтен рәсемнәр дә берберенә тиң түгел. Чын мәгънәсендә төгәлләнгән дип «Кышкы кич» рәсемен әйтеп була. Төн, кар, ай, тәрәзәдәге ут - барысы да балачак образы, кайтара алмаслык күңел халәте. «Кичкә таба салкын көчәя, ә мин әле һаман чана өстерәп тауга менәм, караңгы күктәге айдан, айдагы көянтә күтәргән кыздан күзне алалмыйм».

Әгәр дә рәссам үзенең балачак хисләрен сакламаган икән - ул иң яхшы, иң камил рәсемнәре белән дә кеше күңелен кузгата алмаячак. Гакыйль - бик сизгер зиһенле рәссам.

**- Ә миңа аның башка рәсеме күбрәк ошый: буранда ат чана тартып бара... «Буран»!**

- Нәкъ шул рәсемгә пластик төзү ягыннан минем дәгъвам бар. Ул рәсемдә атны бераз күчереп сурәтләсәң, яхшырак булыр иде. Фонарь янындагы спиральгә дә артык басым ясарга кирәкмәгәндер.

**- Лэкин ниндидер күтәренке рух бар!**

- Әлбәттә, бар! Рух...Гакыйль башкалардан шуның белән аерыла да инде. Буран, фонарь җемелди, ялгыз юлчы... Күренеп тора- ул каядыр китә,, саубуллаша, иң кадерле әйберен калдыра... Рәсемдә саф, керсез күңел оста күрсәтелгән. Гакыйль нәрсә эшләсә дә, бик нык борчылып, кайгыртып эшли - аның талантының сере нәкъ шунда. Аның болай гына, күңел бирмичә генә ясаган рәсемнәрен минем күргәнем юк.

**- Рәссамның аклы-каралы рәсемнәренә карыйсың, ә нәрсәдәндер бөтенесен төсле итеп күрәсең кебек тоела.**

- Тормышта күргәнегезне искә төшерү бу. Тәэсирле итеп, «төгәл» сүзе биредә туры килми. Ә менә сиземләү...Әйләнәтирәне ул бөтен йөрәге белән сиземли. Табигатьне ишетә белә. Шуңа күрә бөтенләй таныш булмаган шагыйрьнең дә Гакыйльнең рәсемнәре буенча шигырь язасы килә башлый. Ә

рәссамның аның шигырьләренә рәсем ясыйсы килә. Мин менә рәхәтләнеп аның графикасы буенча төсле рәсемнәр ясар идем.

**- Үзенчәлелек тәэсире? Аның бит үз стиле, теле, образлылыгы...**

- Ул, һичшиксез, үзенчәлекле рәссам.

Шигырьләре буенча аның Һади Такташны, Габдулла Тукайны яратканын аңлап була.

**- Ә рәсемнәреннән?**

- Бу рус реализмы мәктәбе. Аның тарафдарлары рәсем ясаганда кулланылган ысуллары белән бер-берсеннән бик аерылмыйлар. Шулай да аларны һәрберсе үзендә генә саклап килгән шәхси башлангыч аера. Шуның өчен психологлар иҗади эшләренә карап авторның нинди кеше икәнлеген сөйләп бирә алалар. Хәтта мин дә, ясаган рәсемнәренә карап, кеше турында үз фикеремне әйтә алам.

**- Рәсемнәренә карап, Гакыйль турында нәрсә әйтә аласыз?**

- Ул киң күңелле, туганнарына, якыннарына, гомумән, кешегә изгелек, мәрхәмәтлелек теләүче кеше. Башкаларның шатлыклы, кайгылы кичерешләрен аңлый, ярдәм итә, кичерә белә. Ныклы, шул ук вакытта миһербанлы.

**- Бөтен яктан башкаларга буйсынган хәлдә дә ул үз-үзенә ышаныч һәм ихтирам, икенче төрле әйткәндә, рухи азатлыкны, мөстәкыйльлекне саклап калган. Мондый сыйфатка бик азлар гына ия була. Янәшәдә үз-үзләренә ышанычын югалткан, якыннары белән дә, танышлары белән генә дә уртак тел таба алмаган кешеләр әз түгел. Ә тәкәбберлек, истерика белән абруен төшергәннәре тагын да күбрәк...**

- Гакыйль Сәгыйров - нык ихтыярлы, чын кеше. Үзенең дәрәҗәсен беркайчан да төшермәс. Миңа калса, ул яшь, көчле, сау-сәламәт кешеләргә дә терәк булып торырлык. Рухи яктан какшамас, чыдам һәм акыллы шәхес ул.

**- Нурхатим, сез Гакыйльне рәссам буларак кына түгел, гомумән, кеше буларак якын күрәсез төсле...?**

- Кызганыч, мин аны бик соң белдем, танышуым да күптән түгел генә булды. Ә шулай да үземне аның белән бергә үскән кебек хис итәм. Безне яшьтәшләр дисәң дә була. Яшәгән урыныбыз да берберебездән ерак булмаган: ул - Кошки, мин - Похвистнево районында. Хыялыбыз да бер булган. Язмышыбыз да бертөсле булырга тиеш иде...

Балачакта мин дә каты авырдым. 17 операция кичердем, ике ел селкенмичә түшәктә яттым. Китаплардан бөтен рәсемнәрне күчереп ясавымны күреп, кемдер Сталинга хат язып җибәрергә кушты, «каты авырыйм, бик тереләсем килә»,— дип. Мин шулай дип яздым да, аның портретын да ясап җибәрдем.

**- Җавап бирдеме соң?**

- Бервакыт авылга хат килеп төште. «Москва-Кремль. Ваша просьба рассмотрена ЦК ВКП (б). Подпись: Ворошилов». Бу хат артыннан ук икенчесе: «Облздрав. Приезжайте в областную больницу». Хастаханәгә мине әтием ат белән илтә китте, ә анда мине инде көтәләр иде. Иң яхшы врачлар, дарулар... Шулай итеп, мине аякка бастырдылар.

**- Язмышларыгыз туры килүенә гаҗәпләнерлек. Сынаулар да, аларны җиңеп чыгу да. Һәм икегез дә бернәрсәгә карамыйча, балачак хыялыгызны тормышка ашыргансыз, рәссамнар булгансыз.**

- Кыенлыкларга, сынауларга килгәндә, ул вакыттагы авыл балаларының тормышы күпләргә билгеле инде. Сугыш һәм сугыштан соңгы еллар: ачлык, ялангачлык, авыр эш. Якында табиблар да, дарулар да юк. Район хастаханәсенә аяктан егылгач кына баралар иде.

**- Самарада үткәрелгән «Кабатланмас моң» китабының презентациясендә бер татар язучысы болай диде: «Гакыйльнең җырын аның энисе саклап калган. Чөнки Хәбибҗамал апа - күңеле белән үзе дә шагыйрь һәм рәссам».**

- Бу шулай да. Улының хыялын йөрәгең белән аңлау, аңа ышану һәм аны сүндермәү - ананың иң зур батырлыгы, минемчә.

**- Нурхатим, иҗат кешесе өчен күргәзмәме, презентация булсынмы, аның талантына баш иючеләр белән очрашу - зур вакыйга. Менә Самарада татар һәм рус телендә нәшер ителгән үзенең дүртенче китабын Сәгыйров та гомер буе көтте бит...**

- Гакыйльнең илһамы беркайчан да сүнмәсен, энисе Хәбибҗамал апа да озак яшәсен, аңа улының уңышларын, яңа рәсемнәрен, китапларын күреп шатланырга язсын Ходай. Минем теләгем шул!

**-Шулай була күрсен!**

**Әңгәмәне Фәния ШӘФИГУЛЛИНА үткәрде.**

## ***Гакыйльнең әле исән чагында, 1951-54 елларда куллары белән ясаган рәсемнәре***



«Яшь гвардия» романының герое Олег КОШЕВОЙ



Гражданнар сугышы полководецы Василий ЧАПАЕВ



Без - яшь диңгезчеләр...



Әнисенең әтисе - Гакыйльнең бабасы Шәфәгыйтдин абзый

# Рәссамның аяк-куллары хәрәкәтсез калгач, каләмне тешләре арасына кабып ясаган рәсемнәре (1962-1991 еллар)


Яз башы


Ташу


Кояш һәм торналар


Айлы кич



Кызлар һәм төнбоеклар



Яңа юл



Топольләр



Инеш ярында



Көз

Буранлы
көн





Карт имән



Чишмә



Хыял



Язгы көй



Аждаһалар илендә



Кышкы тынлык

Зәмһәрир
суык иртә





Боз китү

# Ике кояш бар дөньяда...

*“Ике кояш бар дөньяда — күктә берсе,*
*Йөрәкләрдә икенчесе, иң көчлесе”*



**Шагыйрь Фәнис ЯРУЛЛИН.**

**Гакыйль кебек үк яшьләй фаҗигагә очрап, гомергә аяклары йөрмәс калган авыр язмышлы икенче олы шәхес - Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм Муса Җәлил исемендәге яшьләр оешмасы бүләге лауреаты Фәнис ЯРУЛЛИНның каләмдәшенә карата язылган бәяләмәсе зур игътибарга лаек.**

**Гакыйль Сәгыйровның иҗат юлына багышлаган күләмле язманы укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.**

- Гакыйль Сәгыйровны шагыйрь буларак иң беренче Илдар Юзеев ачты. Самара өлкәсенең Кошки районындагы Иске Фәйзулла авылында әнисе белән генә яшәп ятучы, аягы-кулы хәрәкәтләнмәгәнгә күрә күңелендә канат ярган шигырьләрен кәгазь битләренә каләмен авызына кабып төшерүче, хыял кошларын ерак офыкларга җибәреп, аларга карашы белән юнәлеш биреп ятучы билгесез шагыйрьне кем белер иде әле? Илдар Юзеевка рәхмәт. Ул аның янына барып, шигырьләрен алып кайтып, редакцияләргә таратты, ә соңрак туплап, китапларын чыгарырга булышты. Кайчандыр шушындый игелекле эшне миңа карата Марс Шабаев эшләгән иде.

Җирдә алтын-көмешләр күп булган кебек, шагыйрьләр дә күп, ләкин алтынны җир астыннан казып, комнардан аралап аласы булса, шагыйрьләрнең шагыйрьлеген ачасы бар. Беренче карашка бу бик табигый кебек: шигыреңне яздың, җибәрдең. Бастылар-чыгардылар. Һәм син икенче көнне танылган шагыйрь булып уяндың.

Теоретик яктан шулай күренсә дә, тормышта алай булмый шул. Бигрәк тә шәһәр цивилизациясеннән еракта, авыруы белән күзгә-күз калган һәм шушы «бил алышта» җиңелергә дә мөмкин булган бер шагыйрьнең «чүп-чарлары» арасыннан саф

бөртекләрне җыеп алу, менә синең шагыйрьлегең кайда, дип күрсәтеп бирү - бик саваплы эш.

Гакыйль менә шулай ачылып китте. Китапларының саны буенча әллә ни мактанырлыгы булмаса да, шигъри тирәнлектә, үзенчә фикерле белүдә, күңелне тетрәндерерлек образлар табуда ул беребездән дә калышмый. Шигырьләрен һәр күренгән җирдә укыйм, ә менә бу «Кабатланмас моң» китабы (2000 елда Самарада татар һәм рус телләрендә дөнья күрде) Гакыйльне тулырак ача. Хикмәт китапның калын булып чыгуында гына түгел. Мин һәрвакыт авыр язмыш кысаларына кысылып яшәргә мәҗбүр булган шагыйрь, әдипләрнең иҗатын аеруча җентекләп күзәтәм. Шагыйрь үз язмышына кереп бикләнмәгәнме? Авыруы салган тышауны өзеп, дөньяда, яшәештә барган вакыйгаларга фәлсәфи карый аламы?

*Ачты яз серле сандыгын,*
*Өләште бүләкләрен:*
*Кояшка-нур,*
*Инешкә- җыр,*
*Җиргә - гөл-чәчәкләрен,* - дип яза ул «Бүләкле яз» шигырендә. Образлар якты, язның нәкъ үзеннән алынган.

*Тормыш агай кысып күкрәкне*
*Бирсә бирде миңа кирәкне:*
*Һаман саен һәрбер матурлыкка*
*Сизгеррәк итте йөрәкне,* - ди ул икенче шигырендә. Килешмичә мөмкин түгел. Матурлыкны күрер өчен йөрәкне сандалга салып очкыннар чәчрәтә-чәчрәтә төяргә, хисләрне хәнҗәр итеп чарларга, җан чишмәңне туктаусыз авыр ташлардан чистартырга кирәк. Әле алай да шигырең шигырь булып җитмәскә мөмкин, чөнки син чын тормышның үзен түгел, чагылышын гына күрәсең. Кояш синең өеңә тәрәзә аша гына керә, төннәрен йолдыз яңгыры яуганда, учларыңны сузып, йолдызлар тота алмыйсың. Кичләрен яшьләр арткы урамга җыелып биегәндә җан ачысы белән караватыңнан сикереп төшмәкче, шул яшьләргә кушылмакчы буласың да, тауга ябышып каткан таштай хәрәкәтсез аякларыңа карап, тешләреңне кысасың.

*Ә мин ятам - яраланган бөркет,*
*Яшәвемнән хәтта оялам.*
*Була кайчак, яшен кебек ярсып,*
*Атылырга уйлыйм кыядан,* -
кебек шигырьләр шундый чакта туадыр. Моның өчен

шагыйрьне гаепләргә ашыкмыйк. Шигырь бит ул - күңел халәте. Ул халәтне ясалма рәвештә тудырып булмый. Табигать күренешләре никадәр бай төсмерле, никадәр тиз үзгәрүчән булса, шагыйрьнең дә төсләр гаммасы шулай тиз алмашынып тора. Кайбер шигырьләр шагыйрь дәфтәренә кояш нурларыннан саркып төшсә, кайберләре авыр таш астыннан сытылып чыккан тамчылар кебек дөньяга авыр һәм газаплы юллар аша килә. Тәнкыйтьчеләр төшенкерәк тонда язылган шигырьләргә икенче сортлы шигырь итебрәк карый. Әгәр шигырьдә чын образ бар һәм шагыйрьнең җан ачысы белән язылган әсәре башкаларны да тетрәндерә ала икән, пессимистик шигырьләргә ирония белән карау урынсыз.

Тормыш күренешләреннән тирән фәлсәфә чыгара белү, үзеңне чиксез зур дөньяның бер «акыллы материясе» итеп тою һәрбер шагыйрьгә дә җиңел килми. Сәламәт кешеләр биек-биек тауларга менеп, югары үрмәләүнең рәхәтен, михнәтен үз күзәнәкләрендә тойса, агымсуларда тыннарың беткәнче коенуның ләззәтен җаны-тәне белән кичерсә, иң-иң биек агач башларына менеп кочагына керергә торган Айга үрелсә— Гакыйльгә болар балачактан алган ассоциация аша, анда да акыл казанында кабат-кабат кайнатылып, хәтер күгендә яктыртылып, хисләр кайнарлыгында эшкәртү нәтиҗәсендә бирелә.

*Кирәк түгел андый-мондый бәхет,*
*Мин тормышка карыйм тирәннән.*
*Кайгысы да, шатлыгы да аның*
*Биегрәк булсын түбәмнән.*

Гадәттә, үз түбәңнән биек сикерә алмыйсың, дисәләр дә, мин Гакыйльне үз түбәсеннән биегрәк сикерүчеләр рәтенә кертәм. Спортчылар үз планкаларын миллиметрлап күтәрә бара. Йөзләрчә-меңнәрчә кат сикерә-сикерә генә рекорд куялар, максатларына ирешәләр. Шагыйрьләр дә шулай. Бүген бу биеклекне алдың икән, иртәгесен планкаңны күтәрергә кирәк.

Бер биеклектә калган спортчының тамашачы өчен кызыгы бетә, аны карамыйлар, аңа сокланмыйлар. Спортчыдан аермалы буларак, шагыйрьнең бер өстенлеге бар: спортчы физик көчкә, ә шагыйрь акылга таяна. Акылның мөмкинлекләре иксез-чиксез. Ул әле океаннар тирәнлегенә төшә, әле йолдызлар биеклегенә күтәрелә. Хыял менә алмаган күкләр, зиһен ача алмаган ишекләр юк.

*Син нәфис күбәләк сыман,*
*Җиңел, җиңел.*

*Әйтерсең лә, бассаң менеп,*
*Пәрәвез дә түзәр.*
*Әмма хәйран калам:*
*Каян табасың син*
*Шундый авыр сүзләр?*
*Эчем пошып китап киштәләрен*
*Актарганда чыкты бу рәсем.*
*Айкаганда язмыш дулкыннары*
*Яшеренеп калган, күрәсең.*
(«Бер рәсем»).

Гакыйль Сәгыйровның шигырьләрен мисалга китерүдән туктап, уйга калдым: укучыга нәрсәсе белән кадерле соң алар? Иң беренчесе — ихласлыгы беләндер, мөгаен. Әлбәттә, ихлас язучы шагыйрьләр күп, ә Гакыйльнең ихласлыгы нидә? Аның ихласлыгы — хакыйкатькә туры карый белүдә. Аның шигырьләрендә Язмыш бар. Кайсы гына шигырен укысаң да, күренмичә генә, үз фикерен көчләп такмыйча гына сине әнә шул Язмыш күзәтә. Сизмәстән, уйларың автор уйлары белән үрелеп китә дә йөрәк тибешеңә кушыла. Әллә автор йөрәге тибә, әллә синеке. Шагыйрьнең фикерләре, образлары хисләреңә шулкадәр нык килеп чорналган ки, ул йомгакны сүтә башласаң, җаның шәрәләнеп калачак.

Китапның тагын бер үзенчәлекле ягын әйтми кала алмыйм: бирегә Гакыйль Сәгыйровның рәсемнәре дә тупланган. Гадәттә күп кенә шагыйрьләр рәссам да була. Бу, мөгаен, шигърият белән рәсем сәнгатенең игезәк булуыннан киләдер. Тегесендә дә, бусында да образлар белән эш итәсең. Дөньяга карашыңны рәсем яки шигырьләреңә салган образлар аша сурәтлисең. Тик сурәтләү чаралары гына башка.

Күңелендә Ходай Тәгалә салган иҗат орлыклары булса, тәне сау-сәламәт кеше өчен рәсем ясау бик кыен эш кебек түгел. Ләкин бу үзе эшләмәгән кешегә генә шулай тоелырга мөмкин. Һәр эшнең үз нечкәлекләре, үз авырлыклары бар. Ә менә Гакыйль кебек шигырьне дә тешләренә каләм кыстырып язган кешенең рәсемнәр ясавын күзаллау кыен. Аның китабына тупланган рәсемнәрне карасаң, һич кенә дә кулсыз кеше ясаган димәссең. Аларда табигать матурлыгы, җир һәм күк, ут һәм су гармониясе искиткеч табигый чагыла. Сәламәт кешегә бер сызык сызар өчен бер селтәнү җитә, ә Гакыйльгә чыршылардагы һәр ылысны, урман арасыннан саркып кергән һәр нурны ясау өчен күпме көч кирәк булгандыр!

Тырышыбрак эшләгән эшнең кыйммәте сөендерә, зуррак була. Чөнки син аңа җан җылыңны саласың. Шуңа, ахры, Гакыйльнең иҗаты күпләрне сөендерә, сокландыра. Аның рәсемнәрен күргән кешеләр һич тә битараф кала алмый. «Любовь к людям, любовь к природе, любовь к земле своей этим пронизаны его работы»,–дип яза Сызран шәһәреннән Т. Володькина. «Теплота, доброта, которые исходят от Ваших, Гакыйль, картин придают силу нам, здоровым, для творческого поиска»,–дип яза Дмитриева һәм Самара шәһәре китап сөючеләре. Ә Одесса шәһәрендә яшәүче Әлфия Шәфигуллина аның сәнгать әсәрләренә карата мондый фикер белдерә: «Твои прекрасные рисунки дают эстетическое наслаждение, очищают душу, твои работы учат нас быть достойными нашего Творца, помогают жить, храня в сердце созданную им красоту, гармонию. Такие люди, как ты, являются духовными интеллектуальными настройщиками своего народа».

Татарстаннан читтә яшәп иҗат итүче талантлы бу шәхескә китабын һәм рәсемнәрен дөньяга чыгарырга, киң катлам укучы күңеленә җиткерергә мәрхәмәтле, олы җанлы кешеләр табылган. Шундый игелекле эшләр эшләүчеләр арасында башка милләт вәкилләренең дә күп булуы мине аеруча сөендерде. Китапка Самара өлкәсенең губернатор урынбасары Владимир Мокрыйның (хәзерге вакытта Дәүләт Думасы депутаты) сүз башы язуы да олы мәгънәгә ия. Димәк, Гакыйль Сәгыйровны халык кына түгел, җитәкчеләр дә белә һәм аның белән санлаша. Ничек кенә: «Безне халык ярата – шул җиткән», – дип йөрсәк тә, җитәкчеләр күрмәмешкә салышып, иҗатыңны күтәрешмәсә, иҗат кешесенең күңеле китек була. Иҗатны аңлар өчен акыллы укучылар, аны югары күтәрер өчен зирәк җитәкчеләр кирәк. Владимир Мокрый сүзләрен тулысынча китереп үтсәм урынсыз булмас, шәт: «Сезнең кулыгызда, укучым, төрле яктан да уникаль булган китап. Ул ике телдә бастырылган: авторның туган татар телендә һәм рус теле тәрҗемәсендә. Ике телле әдәби җыентыкның бастырылуы – бүгенге көндә бик мөһим вакыйга. Ул безнең өлкәләрдәге милли мәдәниятләрнең үзара тулы рухи баюына шаһит булып тора. Бу күрше мәдәниятләрнең дустанә диалогы гадәти көнкүрешнең моңарчы сизелмәгән яңалыкларын да күрергә булыша, чөнки шагыйрь һәм рәссам чынбарлыкны күчереп кенә калмый, аңа карата тирән фәлсәфи һәм рухи мөнәсәбәттә тора. Гакыйль Сәгыйров та әнә шундыйлардан. Уйларының сафлыгы, ата-бабаларының изге теленә карата

булган тирән ихтирамы, шәфкатьлелеге, бәрәкәтлелеге һәм җан җылылыгы белән тәңгәл килә һәм бу анының тормышында да, иҗатында да киң чагыла».

Гакыйль Сәгыйровның иҗаты хуплауга лаек. Бу шагыйрьнең иҗатын республикабызда зуррак итеп күрсәтергә вакыт җитте. Башкалар танып та, үзебез аны һаман күрмәмешкә салышсак, оятын кая куярбыз? Гакыйльнең яше дә бара, аңа «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исем бирергә дә вакыт. Бүгенге эшне иртәгегә калдырырга ярамый. Иҗатын күрү, аны лаеклы бәяләү шагыйрь һәм рәссамны, бәлки яңа биеклекләргә күтәрер. Иҗат кешесенә ихтирам күрсәтү, вакытында әйтелгән җылы сүз анының өчен яңа ачышлар, яңа табышлар китерә. Ә шагыйрьләр — кошлар нәселеннән, алар бары тик очышта гына яши ала һәм җир белән күк арасына ак канаты белән ак шигырьләр яза.

**Фәнис ЯРУЛЛИН,**
**Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм Муса Җәлил исемендәге яшьләр оешмасы бүләге лауреаты.**

(“Бердәмлек”, № 7, 13 февраль 2001 ел).

# Изгелек һәм игелек бергә йөри

**Каһарман якташыбыз - күренекле татар шагыйре һәм рәссам Гакыйль Сәгыйров каләмен тешләре арасына кабып ясаган рәсемнәре өчен халыкара «Филантроп» бүләгенә лаек булды. Мәскәүгә шушы тантанага китәр алдыннан аның Ульяновск өлкәсендә нәшер ителүче «Өмет» газетасы хәбәрчесенә биргән әңгәмәсен укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәргә булдык.**

## Язмыш киртәләрен ватып, юллар сала белик...

**- Гакыйль абый, ерак юлга нинди уй-фикерләр белән чыгасыз?**

- Әлбәттә, чиксез дулкынланам. Ни дисәң дә, башкалага беренче мәртәбә баруым. Шул ук вакытта горурлык хисе дә күңелне биләп алган кебек. Юрий Соломин җитәкчелегендәге комиссия минем иҗат җимешләремә шундый югары бәя бирә икән, димәк, рәсемнәремдә кешене җәлеп итәрлек нindидер мәгънә бар. Бертуганымның улы Ринатка рәхмәтем чиксез. Ул талантлы инвалидлар арасында конкурс үткәрелүе турындагы белдерүне телевизордан күреп алган. Шуннан соң кирәкле документларны Мәскәүгә жюри карамагына юлладык. Кызганыч, рус һәм татар телләрендә «Кабатланмас моң» китабым чыгып өлгермәде. Югыйсә, «Шигъри сәнгать» номинациясендә дә катнашырга мөмкин иде.

**- Сезнең өчен фани дөньяда иң кадерлесе ни?**

- Иҗатым белән кызыксынган, мине белгән кешеләрнең миңа карата ихтирамлы мөнәсәбәте, дуслыгы. Җир йөзендә башка төрле яшәүне күз алдына да китерә алмыйм. Шуңа күрә дуслыкны сакларга, ныгытырга, кадерләргә тырышам. Минемчә, бер-береңә ярдәм кулы сузып, тирә-юньдәгеләр белән уртак тел табып, аңлашып гомер сөрү бар нәрсәдән дә өстен булырга хаклы. Әмма дуслыкның да төрлесе бар. Әйе, кешеләр бик күп, тик безне кешегә санаучылар гына аз. Аяныч ки, әхлакый сыйфатлар, кешелеклелек юкка чыга бара. Менә шуңа йөрәк әрни, җан сыкрый.

**- Сезнеңчә, нәрсә ул тормыш яме?**

- Әлегә сөальгә өлешчә җавап бирдем кебек - шул ук дуслыкта күрәм мин аны. Башкаларга, ягъни якын дусларга, фикердәшләргә, гомумән, дөньяга карата йөрәктә туган мәхәббәт кенә адәм баласына яшәү көче бирергә сәләтле. Әгәр кеше күңелендә шул булмаса, ул үзен үги итеп санаячак. Әйе, халык арасында яшәп тә, үзләрен ялгыз яки үги итеп исәпләүчеләр еш очрый. Андыйларны рухи фәкыйрьлек кичерүчеләр, дип тә атыйлар.

**- Сезнең өчен иң куркынычы ни?**

- Бер бүлмәдә ялгыз ятудан курыкмыйм мин. Чөнки ул вакытлы күренеш - яныма кеше килеп йөри. Ә менә рухи ялгызлык, бер үзем генә калу, чынлап та, өркетә. Газиз әнием, якын туганнарым, дусларым, фикердәшләрем бар, шуңа сөенәм, ихлас күңелдән шатланам, куанам. Менә алардан аерылырга Ходай язмасын. Алар барында яшим әле, иҗат итәм, уңышларымны күреп канатланам да сыман.

**- Гомерегездә төрле мизгелләр булгандыр. Араларында иң гүзәлен, иң истәлекле хатирәне искә төшерә алмассызмы икән?**

- Дөрес әйттегез - бихисап алар. Әмма 70нче елларда Татарстан китап нәшриятында икенче китабым - “Айбагарлар”



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ Мәскәүгә китәр алдыннан.**

басылып чыгу мине, һичшиксез, үзгәртте, дөньяга башка күзлектән карый башларга мәҗбүр итте. Хикмәт шунда - шагыйрь Илдар Юзеев тәкъдиме буенча, миңа Шәйхи Маннур исемендәге премия бирелде. Шунысы аеруча игътибарга лаек: 12 кеше арасыннан нәкъ мине сайлап алдылар. Шатлыгым берничек тә аңлатып бирерлек түгел иде: шигырьләремне хәтта Казан әдипләре таный, бәялиләр. Үз-үземә ышаныч уянды. Аңа кадәр бер дә ышанмый идем. Дөресен генә әйткәндә, хәзер дә ышанмыйм. Башкалар миннән күпкә яхшырак яза шикелле...

**- Гакыйль абый, шигырьләрегездә сөю темасына күбрәк игътибар бирәсез кебек. Үзегез саф мәхәббәтне ничек күзаллыйсыз?**

- Әлеге сөальгә шигырьләрем үзләре үк җавап бирәдер, дип уйлыйм. Прозаның монда катнашы юк.

**- Язмыш төшенчәсенә дә тукталып үтми мөмкин түгел. Сезнеңчә, бармы ул?**

- Язмыш, язмыш... Кем ничек аңлый бит аны. Адәм баласының алдан язылган нindидер бер юлы бар, аны тәкъдир дип тә атыйлар. Бу фикер белән килешеп бетә алмыйм. Чөнки һәрбер кеше яшәеш чорында үз язмышын үзгәртә ала һәм, минемчә, шулай эшләргә тиештер дә. Әгәр начар юлдан киткән икән, димәк, сәбәбе бар. Мәсәлән, тирән уйлый белмәве аркасында, кемгәдер ияргән. Бәлки, аңлы рәвештә шушы адымга баргандыр... Ә теләсә, тырышлык куйса - яхшы юлны да табар иде. Кызганыч, бу тормыш дәрьясында без күбрәк җиңел юлны эзлибез шул. Акылыбызны, ихтыяр көчен эшкә җигәргә ашыкмыйбыз. Бөтен ялгышлыклар, абыну-сөртенүләр шуннан башлана түгелме соң?! Әгәр тәкъдиргә сылтап, бернәрсә белән дә шөгыльләнмичә, елап-сыкранып караватта яткан булсам, минем дөньяда барлыгымны кем ишетеп белгән булыр иде. Шуңа буйсынып яшәсәм, тормышым нәрсә белән тәмамланыр иде... Ә мин кешеләргә шатлык өләшүне, дөньяга ямь өстәүне, рухи халәтебезне баетуны өстенрәк күрдем, ягъни кешелек җәмгыятендә үз урынымны таптым, кыскасы, язмышымны үзгәрттем.

**- Чын Кеше! Кем ул?!**

- Совет халкының мәшһүр язучылары - Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты» һәм Борис Полевойның «Чын кеше турында повесть» китаплары үрнәгендә тәрбияләндек без. Шушы әсәрләрнең төп геройлары - безнең буын вәкилләренең

кумирлары. Тормышта үз урынын тапкан, язмышын үзгәртә алган, көч-куәтен файдалы эшкә сарыф итә белүче,ниндидер шөгыле булган затны гына чын кешеләр сафына кертә алам. Мисаллар кирәк, дисезме? Күптән түгел миңа бер «яңа татар» белән күрешеп сөйләшергә насыйп булды. Мактаныпмымактана: бер төн эчендә өч кыз алмаштырып, 2 мең сумнан артык акча туздырган! Бу хакта горурланып сөйли бит, малай. Гаҗәпләндергәне шул: үзен чын кеше, ягъни бүгенге көннең каһарманы итеп исәпли. Шул ук вакытта аның тирә-күршесендә дистәләгән кеше мохтаҗлык кичерә, көчкә очын-очка ялгап яши...

**- Гакыйль абый, кабат иҗатыгызга әйләнеп кайтыйк әле. Рәсемнәрегездә болытлар еш тасвирлана, Гомумән, Сез болыт төшенчәсен кеше тормышында ничек аңлыйсыз?**

- Минем фикеремчә, болыт ул кешенең җаны, күңеле кебек - тиз үзгәрүчән. Балачактан ук аларны күзәтергә яратам. Күкрәүле яңгырларны, яшен яшьнәвен карап, тыңлап ятуы үзе бер рәхәт. Әнә, туган авылым Иске Фәйзуллада (Җүрәй) тәрәзәне махсус зуррак ясаттырган идем. Аннан соң, болытлар җиргә шифа алып киләләр, халык аларны зарыгып көтеп ала. Бәлки, игътибар биргәнегез бардыр, алар төрле - бер-берсенә охшамаганнар.

**- Тормышыгызның, гомумән, күпкырлы иҗатыгызның иң югары ноктасы дип аталган вакыт күләме бармы?**

- Шөкер, «Филантроп» халыкара премиясен алу бәхетенә ирештем. Ә ул бүләкне, белүегезчә, әсәрләрнең сәнгати дәрәҗәсе ифрат та югары булуын һәм физик кимчелекләрне сәнгать чаралары белән җиңеп чыгу осталыгын исәпкә алып бирәләр. Самара шәһәрендә шигырьләр җыентыгым басылып чыкты. Димитровград типографиясе «Ике кояш» дип аталган китабымны нәшер итәргә җыена. Мэрия тиешле сумманы бүлеп бирергә ышандыра. Халкыбызның талантлы җырчысы Салават та җыентыгымны чыгарырга вәгъдә итә. Тагын 500дән артык шигырем язган килеш ята - аларны да дөньяга чыгарасы иде. Шуңа күрә иҗатымның иң югары ноктасына җиттем, дип әйтә алмыйм. Үземдә канәгатьләнү хисе сизмим.

**- Ә шигырьләрегез өчен яңа темаларны каян табасыз?**

- Әлбәттә, бармактан суырып чыгарып язып булмый. Төп чыганак - тормыш үзе. Яшәешебез темаларны кызыклырак, эчтәлекле итә. Минемчә, иҗат өчен очкын кирәк. Ә ул, сер түгел,

янып, дөрләп тә китәргә мөмкин. Иң мөһиме - битараф булмау, вакыйгаларны, тирә-юньдәгеләрнең шатлык-хәсрәтләрен, җәмгыятьнең моң-зарын, кем әйтмешли, йөрәк аша кичерү. Менә шунда гына иҗат әһеленең әсәрләрендә тормышыбызның асылы чагылыш табар.

**- Сез «Өмет»нең даими авторы гына түгел, якын дусты да. Газета турында фикерләрегезне ишетәсе килә...**

- Ульяновск өлкәсенең «Өмет»е, Самараның «Бердәмлеге» - милләтебезнең көзгесе, йөзек кашы. Татарны борчыган мәсьәләләрне оста куясыз, аның хокукларын яклыйсыз. Теләгем шул: җил-давылларга бирешмичә, кыйблагызны саклагыз! Ә «Өмет»не укучыларга, иҗатым белән кызыксынган өчен, рәхмәтемне җиткерәсем килә. Бергә булыйк, бердәм булыйк, дуслар!

**- Ә Сезне, Гакыйль абый, халыкара премия алуыгыз белән ихлас күңелдән тәбрикләп, иҗади уңышлар, ихтыяр кече һәм хәерле сәфәр телибез.**

**Әңгәмәдәш - Исхак ХӘЛИМОВ.**
(“Бердәмлек”, № 29, 11 июль 2000 ел).

# Гакыйль СӘГЫЙРОВ: “Мәскәүдә яхшы, ә өйдә - әйбәтрәк”

**Премия белән лауреат дипломын рәссамга Мәскәүдә, “Яңа опера” театрында тапшырдылар. Бүген Гакыйль Шәрифулла улы үзе башкалада алган тәэсирләре белән уртаклаша.**

- “Филантроп” халыкара оешмасы инде озак вакыт эшләп килә. Әмма мөмкинлекләре чикле булган талантлы кешеләрнең иҗат бәйгесен беренче мәртәбә үткәрергә ниятләгән. Бу хакта кечкенә генә хәбәр 1999 елның җәй башында Ульян өлкәсенең бер газетасында басылып чыкты. Бу турыда миңа Яңа Малыклы районы Урта Исәнтимер авылыннан дусларым - Гакыйль һәм Рәисә Шәкүровлар әйттеләр. Тик анда адресы да, конкурс шартлары да күрсәтелмәгән иде.

Бервакыт, инде ноябрь башында, бертуганымның улы Ринат очраклы рәвештә телевизордан шул “Филантроп” оешмасының белдерүен ишеткән һәм адресын язып алган. Ә заявкалар кабул итү вакыты тәмамланырга бик аз калган иде инде. Документлар җыюны тизләтергә кирәк булды. Эшнең бу өлешен Димитровград шәһәре татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе Роза Шаһимәрдан кызы Әхмәтҗанова үз өстенә алды.

Мәскәүдә эшләүче танышыбыз полковник Сәфәргалиев Роберт Вазыйх улы конкурсның оештыру комитетына рәсемнәрне һәм документларны вакытында илтеп тапшырырга ярдәм итте. Бәйге нәтиҗәсен көтәсе генә калды.

2000 елның май башында шатлыклы хәбәр алдым: Юрий Соломин, Михаил Жванецкий, Зураб Соткилава, Игорь Маменко, Зураб Церетели, Геннадий Гладковлар кебек сәнгать эшлеклеләре кергән абруйлы жюри карамагына эшләре тапшырылган Россиянең 62 төбәгеннән, шулай ук Австрия, Израиль, Венгрия, Белоруссия, Украина, Молдова, Казахстан илләреннән меңләгән дәгъвачы арасыннан 12 лауреатны сайлап алганнар, алар арасында мин дә бар. Бүләкләү 27 майга билгеләнгән иде. Мин, озата баручылар белән бергәләп, 25 майда Мәскәүгә, “Россия” кунакханәсенә барып җитәргә тиеш идем.

Хатны Роза Шаһимәрдан кызына күрсәттем. Мәскәүгә машинада бик тә озак барасы, андый ерак юлга түземлегем

җитү икеле, дип шик белдерүемә, ул болай диде: “Барысы да әйбәт булачак, спонсорлар да табылыр”. Һәм аңа гына хас үҗәтлек белән юлга чыгуны оештыру эшенә кереште.

Мәскәү бездән бик еракта булса да, исән-сау барып җитеп булырмы икән дип, шикләнеп кенә юлга чыксак та, бер ният кылгач, озын юлның да очына чыгыла икән. Наил энемнең «Жигули» машинасына аның олы улы Ринатны руль артына утыртып, Мәскәү тарафларына юнәлдек. Безнең сәяхәткә энемнең кече улы Марат та кушылды. Сәфәребез кичке сәгать бишләр тирәсендә башланып китте. Әгәр иртәнге якта юлга чыккан булсак, икенче көнне нәкъ кич белән Мәскәүгә килеп җитәсе булган икән. Ә болай без төштән соң, сәгать өчләр тирәсендә үк Мәскәү уртасында - «Россия» кунакханәсе янында идек инде.

Безне көтеп торганнар, әйбәт итеп каршы алдылар. 25 майда кичен программада Третьяковка галереясына бару каралган булган икән. Мине, чакырсалар да, баш тартырга туры килде, чөнки юлда бик арылган иде. Безгә аерым бүлмә бирделәр, һәм мин тизрәк кереп ятып ял итү ягын карадым.



Гакыйль СӘГЫЙРОВ Роза ханым ӘХМӘТҖАНОВА һәм Наил энесенең улы Марат белән катерда Мәскәү елгасы буйлап сәяхәт вакытында.

26 майда төшкә кадәр без ял иттек, ә кичен катерда Мәскәү елгасы буйлап сәяхәткә алып чыктылар. Без килгәнче Мәскәү өстендә кара болытлар йөзгән, без баргач, биредә бөтенләй аязып китте һәм без Мәскәү елгасы өстендә искиткеч матур шәфәкъне күрү бәхетенә ирештек. Күз алдында гаҗәеп манзара пәйда булды: офык әйтерсең эреп юкка чыккан. Су өсте һәм күк йөзе бердәм ялкын булып дөрлиләр. Ә инде бераздан караңгы төшкәч,

һавада да, суда да йолдызлар кабынды. Елгада кояш баюы бигрәк матур күренә икән. Әгәр дә болытлы көн булса, мондый матурлыкны күреп булыр идеме? Катерда барганда диктор гел сөйләп, аңлатып барды. Залда музыка уйнады, хәтта биючеләр дә табылды. Мин, тавыштан качып, борт кырыена чыктым да шуннан матур яр буйларын, йолдызлар тулы күкне күзәтеп бардым. Төн уртасында гына кунакханәгә кайтардылар.

## Мәскәү елгасында кич

*...Урам-ярлар арасында калды*
*Шаулы машиналар ташкыны.*
*Тирбәләбез йошмак дулкыннарда,*
*Хыял оча алга ашкынып.*
*Кояш баеп бара - ялкыннары*
*Елга өстен бердән дөрләткән.*
*Серле гүзәллеккә хәйран калып,*
*Җыр түгелә минем йөрәктән.*
*Диктор сөйли... һәр борылыш саен*
*Ачылып китә яңа күренеш.*
*Рекламалар күзне камаштыра:*
*Һәр хәрефе алтын, я көмеш.*
*Яктыртылган өйләр һәм күперләр...*
*Яр буйлары җем-җем нур тулы...*
*Кем йөрәге сыйдыра алыр икән*
*Шушы гүзәллекне берьюлы...*
*Әтием исемә төште: бу якларда*
*Ул хәбәрсез-эзсез югалды;*
*Ул саклаган фашист-илбасардан*
*Башкалага илткән юлларны.*
*Балачактан җаныма уелып үскән*
*Кайгы бетмәс инде - гел сызлар.*
*Җир белән күк бүген тоташ кебек —*
*Күктә-җирдә-суда йолдызлар.*
*Ялкын яллы йөгерек дулкыннарга*
*Күңелемнән түгелеп моң калсын.*
*Беренче һәм бәлки соңгы тапкыр*
*Күрүемдер Мәскәү елгасын...*



**Мәскәүдә «Филантроп» бүләген алганнан соң тамашачылар арасында.**

27 май кичендә "Яңа опера" театры бинасында лауреатлар белән дипломантларны тантаналы бүләкләү булды. Зал чакырылган кунаклар белән шыгрым тулы иде. Сәхнәгә мине җиденче кеше итеп чакырдылар.

Алып баручы минем турыда кыскача гына сөйләп бирде. Лауреат дипломын һәм чәчәкләр тапшырдылар. Моңа җавап итеп: "Жюриның минем хезмәтләремә шундый югары бәя бирүенә мин бик шатмын. Әлеге башлангыч - бик тә яхшы, кирәкле һәм аны киләчәктә дә дәвам иттерү мәслихәт. Мөмкинлекләре чикле булган башка кешеләр дә иҗатларын күрсеннәр, куансыннар. Безгә карата шундый мөнәсәбәт, һичшиксез, әйбәт, күңелле һәм гүзәл күренеш. Шундый бәйрәм оештырган өчен рәхмәт", - дидем.

ОРТ минем турында махсус документаль фильм да төшергән иде һәм аның фрагментлары «Филантроп» премиясен тапшыру тантанасы вакытыңда да, телевидение программасында да күрсәтелде.

Лауреатлар арасында Ульяновск шәһәреннән Елена Токарчук та бар иде. Ул гаҗәеп дәрәҗәдә талантлы кыз. "Поэзия" номинациясендә җиңү яулады. Тантаналы кичәне алып баручы аның сүзләренә музыка язган һәм әлеге җырны үзе үк башкар-

ды, Еленаның коляскасы янында тезләнеп, аның кулын үпте. Бу тетрәндергеч мизгел иде. Зал озак алкышлады.

Ә урамда безне сюрприз көтә иде: театр каршындагы мәйданчыкта чын фейерверк оештырганнар. Шундый гүзәл тамашаны миңа тәүге мәртәбә күзәтергә туры килде.

28 майда безне Кремль территориясендә йөрттеләр. “Царь-колокол», «Царь-пушка»ларны күрдек. Президент Путинның эш бүлмәсенең тәрәзәсенә карап уздык. Ул көнне Кремль территориясенә ирекле керү көне булган икән. Шуңа күрә дә халык бик күп иде.

## Кремль йортында

*...Хыялымның ерак бер йолдызы*
*Идең эле кичә син, Мәскәү.*
*Йөрим менә шаулы урамыңда —*
*Күрештек бит бүген без икәү.*
*Уйламаган-юрамаган жирдән*
*Тәкъдир бире тартып китерде,*
*Һәр урамың миңа таныш кебек,*
*Һәр йортыңны беләм шикелле.*
*Тезелеп үскән зәңгәр чыршыларың,*
*Чәчәк аткан биек каштаннар,*
*Кремльнең ныклы диварлары*
*Чал тарихка кереп басканнар.*
*Яшәешнең юллар чатында мин.*
*Туры килсә - син дә - күреп чык:*
*Моториннар кыңгыравын, Тупны —*
*Гасырлардан калган уенчык.*
*Чәчәк аткан сирин һәм яшь каен*
*Карт имәнне бирелеп тыңлыйлар,-*
*Вакыйгалар, еллар тезелеп үтә...*
*Кыңгыраулар тынмый чынлыйлар...*
*Бу йөрәге - кайнар кан тибеше*
*Башланган җир бөек дәү илнең.*
*Эш бүлмәсе тәрәзәсен күрдем*
*Яңа башлык - яңа хакимнең.*
*Көн аяза - болыт арасыннан*
*Кояш чәчә җылы нурларын;*
*Яктырт, Кояш, көчең аямыйча,*
*Чын тормышка бару юлларын.*

16 сәгатьтән соң безне картиналарыбыз эленгән «Рәссамнәр йорты» бинасына алып бардылар. Күргәзмәдә рәсемнәр бик күп булып, зур форматтагы картиналар арасында минем рәсемнәремә дә урын бирелгән иде. Үз рәсемнәремне карап торганда “Сезнең рәсемнәр безгә бигрәк тә ошый”, - дип килеп әйтүчеләр бихисап күп булды. Хәтта Палестинадан килгән Нәһа исемле ханым да үзенең соклануын әйтте. «Бу юлы мин үзем белән ике кызымны һәм улымны да алып килдем», - дип аларны минем белән таныштырды.

Ханым русча бик әйбәт сөйли. «Кайдан болай өйрәндегез?» - дип сораган идем; «14 яшемнән бирле мин монда яшим инде», - дип сөйләп китте. Журналистика институтын тәмамлаганнан соң, бер Пакистан егетенә кияүгә чыгып, хәзергесе көндә Пакистанның бер журналыңда эшли, Мәскәүдә яши икән.

Мәскәүне карап йөргәндә, иң зур мәчетләрнең берсенә кереп, аларга үземнең «Кабатланмас моң» китабымны бүләк итеп калдырдым. «Мөфти Равил Гайнетдинның үзенә бирербез», - дип әйтеп калдылар.

29 май төнендә без Мәскәү белән хушлашып, өйгә кайту юлына чыктык.

Элек капиталистик илләрнең башкалалары турында язганча, Мәскәү дә миңа контрастлар, ягъни капма-каршылыклар шәһәре булып күренде. Үзәк урамнарда шау-шу хөкем сөрә,




**Гакыйль Палестина журналисты Нәһа ханым һәм аның өч баласы белән.**

машиналарның исәбе-хисабы юк. Күпчелеге иномаркалар, безнең «Жигули»ларны сирәк очратасың. Тукталышларда, светофорлар янында машина янына кулларын сузган карчыклар, хатын-кызлар, яшүсмерләр йөгереп килеп җитәләр. Әлеге күренеш һәр светофор янында кабатлана.

Ашау-эчү бик тә кыйбат: бер стакан чәйнең бәясе 10-12 сум, бер чәшкә кофеның хакы 14-16 сум тәшкил итә. Ә пәрәмәчне 15-17 сумга сатып утыралар. «Изге чыганак» этикеткасы ябыштырган гади су 20-30 сум тора.

Чынлап та, Мәскәү күз яшьләренә ышанмый, зур акчалар кирәк анда. Әйтәсе килгән сүзем шул: «Мәскәүне макта, әмма үзеңнең тыйнак шәһәреңдә яши бир, әлбәттә, башыңа артык, кирәкмәгән борчылулар аласың килмәсә. Безнең ише гади халык өчен шуннан да яхшырагы, акыллырагы булмас».

Мәскәүгә барып кайту чыгымнарын Димитровград шәһәре администрациясе үз өстенә алса, «Булгар» фирмасы мөдире Хәйдәр Ярулла улы Галиуллин һәм «Био-Тон» фирмасының генераль директоры Геннадий Сәхип улы Шәрифгалиев та зур ярдәмнәрен күрсәттеләр. Анарның барысына да чын күңелдән рәхмәтемне белдерәсем килә.

Роза ханым да оештыру эшләрен үз өстенә алып, барысын да төгәл башкарып чыкты. Ул тырышлык күрсәтмәсә, мин, бәлки, бу озын сәфәргә бара да алмас идем. Мин аңа да чын күңелдән рәхмәтлемен.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
(“Бердәмлек”, № 29, 11 июль 2000 ел).

# Шагыйрьнең йөрәк авазы

*Ике кояш бар дөньяга - күктә берсе,*
*Йөрәкләрдә икенчесе, иң көчлесе.*
*Тормыш йөзен яктыртучы иң яктысы,*
*Кыш көненә яз китерә бер чаткысы.*
*...Мәхәббәт ул... нинди татлы әрни күңел,*
*Әгәр сүнсә—күктәгесе берни түгел.*




Яшәешнең тирән фәлсәфәсен, мәгънәсен ачып салучы бу шигъри юллар каһарман якташыбыз, шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның йөрәк авазы булып яңгырыйлар. Аларны Димитровград (Мәләкәс) шәһәренең мәһабәт «Восход» Мәдәният сарае сәхнәсеннән Димитровград шәһәре администрациясе тарафыннан нәшер ителгән шагыйрьнең «Ике кояш» дип аталган яңа китабын тәкъдир итү кичәсендә кайчандыр Татарстан радиосының дикторы булып эшләгән, бүгенге Татарстан Язучылар берлеген җитәкләүче, филология фәннәре докторы, профессор, Казан Дәүләт педагогия университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы депутаты, язучы Фоат Галимуллин укыганда, залда утыручыларның күңелләре, мөгаен, тетрәнгәндер. Чыннан да ачы язмышка—унҗиде яшеннән түшәктә генә, бер хәрәкәтсез ятарга дучар ителгән, тормышта шундый гади, ягымлы сүзле, басынкы, ләкин шундый батыр йөрәкле Гакыйль Сәгыйровның, каләмен тешләре арасына кысып, күңелләрне тетрәндергеч шигырьләр, рәсемнәр иҗат итүе (аның шушы «Ике кояш» шигыре генә үзе ни тора) хөрмәтләү, соклану тойгысын уята. Җыр-моңлы шигырьләре аша үзен таныткан, яраттыра алган шагыйрь ул - Гакыйль Сәгыйров.

*- Без бу кичәгә чакыру алгач, бик күп эшләребезне калдырып, юлга чыктык, - диде Фоат Галимуллин. - Чөнки чыкмый кала алмадык. Гакыйль Сәгыйров дигән каһарман шагыйрь бар бит дөньяда - Татарстан Язучылар берлегенең олы хокуклы әгъзасы...*

*Яшь вакытта, 60нчы еллар ахырында, Татарстан радиосында диктор булып эшләгән чагымда, миңа Гакыйль Сәгыйров әсәрләреннән төзелгән әдәби-музыкаль композицияне алып барырга туры килгән иде. Шул вакыттан алып мин аның шигъриятенә гашыйкмын. Ә менә бүген шагыйрьнең «Ике кояш» китабында басылган шигырьләре белән танышкач, тагын бер кат хәйран калдым. Ике ягында ике фәрештә дигән кебек, Гакыйль - ике яклап гаҗәеп олы талантка ия кеше. Сүз сәнгате, шагыйрьлек, шул ук вакытта рәсем сәнгате, шуларны бит аерым ике кеше иҗат итсә дә, аларга бик зур ихтыяр көчен җигәргә туры килер иде. Менә шушы ике талант Ходай Тәгалә тарафыннан бары бер кешегә — безнең Гакыйлебезгә бирелгән.*

*Мин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе буларак, 280 татар язучыларының берсе булган, иң көчле, иң талантлы шагыйрь һәм шәхес Гакыйль Сәгыйров алдында башымны иям.*

*Тәрәзәдән генә дөньяны аңлап, тоеп, аның сулышын сизеп яткан бу олы шагыйребезнең бөтен дөнья турында уйландырган һәр шигыре күңел аша узып, йөрәккә барып җитә. Мондый шагыйрьне, мондый талантны ничек бәяләмисең инде?* — дип тәмамлады Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин үзенең чыгышын.

Мондый сүз-фикерләрне аның белән килгән каләмдәшюлдашлары да хуппладылар. Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт, татар яшьләренең Муса Җәлил исемендәге, Башкортостанның Фатыйх Кәрим исемендәге бүләкләр лауреаты Ренат Харис, мәсәлән, Мәләкәстә үткәрелә торган шушы китап бәйрәмен җәмгыять тормышында зур вакыйга дип атады. Чөнки китапта аның фикеренчә, бер кешенең зиһене генә түгел, милләтнең, аның үткәненең һәм бүгенгесенең зиһене дә тупланган. Һәр китапта кеше күңеленең гүзәллеге чагыла. Гакыйль Сәгыйровның «Ике кояш» китабы нәкъ шундыйлардан. Аның матурлыгы туп-туры кеше йөрәгенә килеп бәрелә.

- *Бу китапны укып чыккан кеше,* - диде Ренат Харис, - *һичшиксез, үзен мәрхәмәтлерәк, күпкә чистарак һәм сафрак итеп сизә башлаячак. Моңарчы әти-әниләренә хат язарга онытк ан яшь кызлар һәм егетләр кулларына каләм алырлар да, әти-әниләренә генә түгел, шунда ук ярат каннарына да хат язып салырлар.*

Күптән түгел генә өч телдә — татар, рус, инглиз телләрендә,

шигырьләре белән беррәттән үзе ясаган рәсемнәрен дә туплап китап чыгарган Ренат Харис, рәссам буларак та, Гакыйль Сәгыйровның рәсемнәренә шулай ук югары бәя бирде.

Тагын бер Казан кунагы — танылган язучы һәм журналист Шаһинур Мостафин чыгышында, сугышка беренче көненнән китеп һәм шунда мәңгелеккә ятып калган Гакыйльнең әтисен - Шәрифулла абыйны да искә алып, аның улына дөньяның ике кояшын бүләк итәргә өлгерүен әйтеп үтте.

- *Гакыйль - әтисе Шәрифулла абзыйның дәвамы*, - диде ул, - *әнә ничек бүген сәхнә түрендә балкып утыра. Шундый батыр егет, чын мәгънәсендә ир-егет үстергәне өчен Хәбибҗамал апа алдында да башыбызны иясебез килә.*

Бу кичәдә кем генә чыгыш ясамасын, ә алар байтак иде, Ульян өлкәсенең Законнар чыгару җыелышы рәисе урынбасары Татьяна Владимировна Сергеева, Ульян өлкәсенең милли-мәдәни автономиясе рәисе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы, профессор Азат Курчаков, Димитровград шәһәренең милли-мәдәни автономиясе рәисе Роза Әхмәтҗанова, Ульян өлкәсенең “Өмет” татар газетасы мөхәррире Исхак Хәлимов, Татарстанның Нурлат районы хакимияте вәкиле, журналист Сәкинә Хәйруллина, Самара татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы Равил Яһудин, Самараның «Бердәмлек» татар газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин һәм башкалар Гакыйль Сәгыйровның яңа «Ике кояш» китабына, аның шигырьләренә һәм рәсемнәренә югары бәя биреп, шушы гүзәллекне халыкка җиткерүдә зур өлеш керткән Димитровград шәһәре һәм Мәләкәс районы башлыклары Владимир Алексеевич Паршинга, Владимир Ильич Чигановка һәм Ульян өлкәсе губернаторы Юрий Фролович Горячевка үзләренең рәхмәтләрен белдерделәр, шагыйрьгә күпсанлы бүләкләр тапшырдылар.

Ульян өлкәсе вәкилләре аңа телефон-факс, нурлатлылар 10 мең сум акча бүләк иттеләр. Димитровград шәһәре башлыгы Владимир Паршин Гакыйль Сәгыйровның автомашинасының моторына капиталь ремонт ясатачагы турында әйтте.

Шул ук вакытта кайбер чыгышларда берникадәр борчылулы фикерләр дә ишетелде. «Бердәмлек» газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин каһарман якташыбыз, шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровның тормыш-көнкүреш хәленә тукталып, аның кечкенә пенсия алып яшәве турында әйтеп узды.

- *Без бүген барыбыз да бик матур итеп сөйләдек,* — *диде*

*ул. — Минемчә, моннан ике еллар элек, шагыйрьнең 60 еллык юбилеенда нәкъ менә шушы мәһабәт залда тагын да матуррак сөйләүчеләр дә булган иде бит. Татарстан Язучылар берлегенең элеккеге рәисе, язучы Ринат Мөхәммәдиев Гакыйль Сәгыйровка өстәмә пенсия бирергә, аны Гаяз Исхакый премиясе белән бүләкләргә булышачагы турында әйткән иде. Тик болар әлегә буш сүзләр генә булып кала бирәләр. Ә Гакыйль Сәгыйров иҗат итү өчен уңай шартларга да, югары премияләргә дә, гомумән, яхшы тормышка да лаек. Аңа, кичектермәстән, булышырга кирәк.*

Гакыйль Сәгыйров үзенең йомгаклау чыгышында “Ике кояш” китабын чыгаруда, бүгенге бәйрәмне оештыруда зур көч куйган бөтен кешеләргә олы рәхмәтен белдереп, үзенең иң бәхетле мизгелләр кичерүе турында әйтте.

*- Быел минем тормышымда өч зур вакыйга булды,* — диде ул, *- беренчесе Самарада рус-татар телләрендә «Кабатланмас моң» китабым чыгуы, икенчесе - Мәскәүдә, халыкара «Филантроп» премиясе белән бүләкләнүем, һәм менә, ниһаять, өченчесе, иң соңгы сөенечем — «Ике кояш» китабым... Юкка гына мин аны шулай дип атамадым. Бер кояшыбыз безгә күктән нурын сибеп торса, икенчесе - ул мәхәббәт, иң гүзәл, иң саф хисләрнең берсе. Мәхәббәт - безнең бөтен тормышыбызның нигезе ул. Шушы ике кояш безгә юлдаш булып, нур сибеп торсын, беркайчан да сүнмәсен иде.*

Шагыйрьнең күңел түреннән бәреп чыккан, йөрәк авазы булып яңгыраучы сүзләре иде болар.

Ә «Ике кояш» китабын тәкъдир итү кичәсе әле озак дәвам итте. Гакыйль Сәгыйровның күпсанлы шигырьләре сәхнәдән яңгырады, шигырьләренә туганнан туганы Ринат Сәгыйров, ике туган баласы Гакыйль Шәкүров һәм башка үзешчән композиторлар иҗат иткән матур моңлы җырлар җырланды. Аларны Мәләкәс шәһәреннән «Сүнмәс йолдызлар» ансамбле җырчылары Кадрия Сүнчәләева, Фәния Хәлиуллова, Венера Шәрапова, Ульяннан килгән Җәмилә Мифтахова, балалар җыр ансамбле һәм башкалар башкардылар. Тамашачылар һәвәскәрләрне сәхнәдән озак чыгармый торып, алкышларга күмделәр. Гомумән, Гакыйль Сәгыйровның шигъриятен сөюче һәркем бу бәйрәмнән илһам, яшәргә рухи көч алып киткәндер.

**Рөстәм НӘБИУЛЛИН.**

“Бердәмлек”, № 50, 5 декабрь 2000 ел.

# Әдипләр салган дуслык күпере

Ульяновск өлкәсе милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе Азат Гайнулла улы Курчаковның зур көч куюы, фидакарь тырышлыгы аркасында Казан белән рухи һәм мәдәни бәйләнешләребез соңгы елларда сизелерлек дәрәҗәдә ныгый бара. Үзгәртеп кору чорында борынгы Сембер җиренә аяк басарга да җөрьәт итмәгән Татарстан язучыларының хәзер даими рәвештә, төгәлрәге, ел саен безгә килеп йөрүләре әнә шул хакта ачык сөйли. Бу юлы да әдипләребез китап укучылар белән күрешеп, сөйләшү, кыйблаларын барлау максатыннан сәфәргә чыкканнар.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин Ульяновск якларына сәфәрләренең максатын бәян итеп, ике төбәк—Ульяновск өлкәсе белән Татарстан Республикасы арасындагы хезмәттәшлек җепләренең яңа эчтәлек белән тулылануына өметләр баглавын яшермәде.

— *Борынгы Сембер туфрагында татар халкының шактый өлеше гомер кичерә, без аларның язмышына, кардәшләребезне борчыган проблемаларга битараф кала алмыйбыз,* — дип белдерде Фоат әфәнде.

- *Ульяновск өлкәсенә бүген без - танылган җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрь якташыбыз Ренат Харис һәм Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, шагыйрь Харис Әюп, истәлекле, мөһим вакыйга уңаеннан килдек. Татарстан җирендә туып-үскән, бүген Димитровград шәһәрендә яшәп иҗат итүче каһарман шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровка татар әдәбияты өлкәсендәге иң олуг бүләк — Гаяз Исхакый исемендәге премияне тапшырасыбыз бар. Элегрәк елларда ошбу бүләккә Рабит Батулла, Әхмәт Рәшит, Аяз Гыйлаҗев, Гариф Ахунов, якташыгыз Ибраһим Нуруллин кебек шәхесләрнең лаек булулары күп нәрсә турында сөйли. Быел исә премия тагын да көчлерәк рухлы милләттәшләребезгә—Фәүзия Бәйрәмова белән Гакыйль Сәгыйровка бирелде.*

*Дөресен әйтим, былтыр Мәләкәс шәһәрендә дөнья күргән «Ике кояш» дип аталган шигырьләр һәм рәсемнәр җыентыгы авторы Гакыйль Шәрифулла улына Гаяз Исхакый премиясен бирү турындагы хәбәрне каләм ияләре дә, киң җәмәгатьчелек тә хуплап каршылады, чөнки аның иҗаты— фидакарьлек,*

*тормыш көзгесе, бик күпләрдән аермалы буларак, ул кешенең җанын айкый, рухын, тойгы-кичерешләрен бөтен барлыгы белән аңларга тырыша,* — диде Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин.

«Филантроп» халыкара премия һәм Гаяз Исхакый исемендәге бүләк лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, каһарман шагыйрь һәм рәссам Гакыйль ага Сәгыйровның җавап чыгышы шулай ук ифрат та үзенчәлекле яңгырады:

— *Белүегезчә, иҗат белән шөгыльләнү минем өчен җиңел түгел, әмма бүген шатлыгым чиксез. 6-7 сыйныфларда укыганда, әнием миңа, нәрсәгә язасың, синең шигырьләрең кемгә кирәк, дип әйтә торган иде. Шөкер, Ходайның ярдәме белән, алар иясенә, ягъни укучыга барып ирештеләр. Ә беренче шигырьләрем Татарстанның Октябрь районының (бүгенге Нурлат районы) «Дуслык» газетасында дөнья күрделәр. Язмыш танылган әдипләр Илдар Юзеев һәм Шәүкәт Галиев белән очраштыргач, Казан матбугат мәйданына да юл ачылды. «Тормыш җиле» — мәркәзебез китап нәшриятында басылып чыккан тәүге җыентыгым. Ә «Айбагарлар» дип аталганы Шәйхи Маннур исемендәге әдәби премиягә лаек дип табылган иде. Ә хәзер Татарстан Язучылар берлегенең минем иҗатыма шундый югары бәя бирүе, һичшиксез, куандыра һәм яңа үрләр яуларга дәртләндерә,* - диде Гакыйль ага Сәгыйров үзенең чыгышында.

**Исхак ХӘЛИМОВ.**
Ульяновск шәһәре.
“Бердәмлек”, № 50, 11 декабрь 2001 ел.



**Фоат ГАЛИМУЛЛИН Гакыйль СӘГЫЙРОВка бүләк тапшырганда.**

# Ул яшәгән йорт таралмасын иде

Авылга кайтып килсәм, ничектер күңел гаҗәеп баеп киткәндәй була. Әйтерсең, авыл әллә нинди тылсымлы көчкә ия. Кылт итеп шунда безнең хөрмәтле шигъри йолдызыбыз Гакыйль абый Сәгыйровның шигъри юллары искә төшә:

*Бормалы юлларыңны сагынам,*
*Үрмәле гөлләреңне сагынам,*
*Сөрмәле күзләреңне сагынам,*
*Мин әллә кемнәреңне сагынам,*
*Җүрәем, син минем Җүрәем,*
*Күңелне сихерли һәр җәең,*
*Сер тулы зәңгәрсу кичләрең,*
*Уята иң кайнар хисләрне.*

Безнең Иске Җүрәй авылын белмәгән кеше бик аздыр. Авылыбыз үзенең матурлыгы белән тирә-юньдә дан тота. Ул Кармалка исемле инеш буенда урнашкан. Җәйнең ямьле көннәрендә халык инештә су керә, балык тота. Безнең һәрберебез шул инештә су чәчрәтеп, уйнап үскән.

Авыл уртасында әле тагын дүрт күл бар. Халкыбыз аларның суын яшелчәләр үстерү, ә җирле хуҗалык чәчү кырларын, печән болыннарын сугару өчен файдалана.

Авылыбызда яңа мәчет төзелү халкыбыз өчен бик зур шатлык булды. Хәзер җомга көннәрендә бабайлар һәм абыйлар бизәкле түбәтәйләрен киеп, намазга ашыгалар.

Әле менә җәй көннәрендә генә иске китапханә урынында яңа Мәдәният йорты төзи башладылар. Киләсе елга, бәлки, төзелеп тә бетәр әле, дигән өмет бар.

Иске мәктәп урынында Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтырга насыйп булмаган авылдашларыбыз хөрмәтенә куелган һәйкәл дә дәһшәтле елларны онытырга ярамаганлыкны, бүген тынычлыкны бергәләп сакларга кирәклекне искә төшереп тора. Шушында ук яшел агачлар, куаклар, төрле чәчәкләр утыртылган парк та булса, нинди сокланып туя алмаслык матур урын булыр иде!

Бүгенге көндә авылыбызның һәр торак йортына газ кергән. Бу - халыкның күптәннән көтеп алган шатлыкларының берсе.

Шундый уңайлыклар булса да, барыбер күп авылдашларым авылны ташлап китә бит. Шәһәрнең тарту көче нидән гыйбарәт соң? Шунысы бар: авыл кешесе җиргә нык басып йөрергә өйрәнгән. Элегрәк моны шәһәрдә яшәүчеләрнең кайберләре аңларга теләмәсәләр, менә хәзер, телиләрме-юкмы, моның белән килешергә мәҗбүр булалар. Әлбәттә, моңа азык-төлеккә бәяләрнең котырынып үсүе зур этәргеч ясады. Шәһәрчә үк киенергә мөмкинлеге булмаса да, рухи яктан авыл кешесе күпкә матуррак. Ул үзенең кунакчыллыгы, инсафлыгы белән аерылып тора.

Хәзерге заманда дөньяда яшәргә җиңел түгел. Эш табуы да зур проблемага әйләнде. Шуңа күрә яшьләрнең күбесе нәрсә өчен яшәүләрен дә аңламыйдыр, мөгаен. Кайберәүләре хәтта начар юлга да басканнар. Шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да күпме наркоман бар инде бүген. Ялкауланып, эчеп, эшләмичә, үзләренең Ходай биргән гомерләрен кыскартучылар, үзләрен кеше итеп хис итәргә теләмәүчеләр артып китте.

Минемчә, әгәр кешенең теләге булса, ул ничек тә дөньяда үз урынын таба ала, яраткан эшен табып карьера ясый. Ялкауланып утырмый икән, һәркем теләгенә ирешә ала.

Соңгы елларда авылыбызда яшь гаиләләр саны азая, туйлар сирәгәя башлады. Нәтиҗә буларак, балалар да бик аз туа. Хәзер мәктәпләрдә шуңа күрә укучылар саны бармак белән генә



**Иске Фәйзуллада (Иске Җүрәйдә) Гакыйль СӘГЫЙРОВ яшәгән йорт.**

санарлык. Менә безнең яңа ике катлы мәктәбебез төзелгәнгә дә унбер ел булды инде. Быел беренче сыйныфта алты бала белем алып маташа, ә мәктәптә җыенысы - утыз дүрт укучы гына. Элек заманнарда бер сыйныфта утыздан артык кеше укыса, хәзер бөтен мәктәптә шулкадәр укучы юк.

Мин укыганда сыйныфыбызда барлыгы алты укучы идек. Беренче ике елны әле иске мәктәптә укыган булсак, аннан соң инде яңа мәктәпкә күчтек.

Хәзер мәктәбебез ак каеннар белән уратып алынган. Шул унбер ел эчендә яшь каеннар гөрләп үсеп җиткәннәр. Ул беренче агачларны минем Эльмира апамның сыйныфында укучы өч кыз утыртканы әле дә исемдә.

Мәктәпне тәмамлаганыма әле биш ел гына булып килә. Шулай да ул күңелле чаклар һаман хәтердә. Ул вакытлар бик тә сагындырып, һәрвакыт искә төшеп торалар.

Мәктәптән без туп-туры өйгә кайтырга ашыкмый идек. Язларын, җәйләрен һәм көзләрен Гакыйль абый һәм Хәбибҗамал әби Сәгыйровлар шәһәрдән кайтып авылда торалар иде. Без мәктәптән кайтканда аларга сугылып чыкмый калмыйбыз. Сәгыйровлар өе безнең икенче өебез булды, дисәм дә, ялгышмам. Гакыйль абый безгә дәресләребезне әзерләргә ярдәм итеп, кызыклы хикәяләр, мәзәкләр сөйләп, күңелебезне күтәрә иде.

Чибәр, күтәренке күңелле Хәбибҗамал әбине дә мәңге онытмабыз. Аның хуш исле мәтрүшкәле чәйләре, озак-озын итеп кызыклы, тормышта булган хәлләр турында сөйләве, гомумән, шул күңелле кичләр һаман бик сагындыралар шул.

Кичләрен алар өендә бик күп кеше җыела торган иде. Кемдер Гакыйль абый янында утырып, көнбагыш чиертә-чиертә, телевизор карый, ә кемдер әби белән көлешеп, тәмле иттереп чәй эчеп утыра.

Ә без, укучылар, фотокарточкалар ясау белән шөгыльләнәбез. Бу турыда Гакыйль абый белән алдан сөйләшеп куябыз да, кичен бергә җыелышып, аның янына киләбез. Эшебез беткәч тә, сөйләшә-сөйләшә таң атканы да сизелми кала иде. Кайсы көннәрне Гакыйль абыйларда куна калганыбыз да булгалады.

Ә хәзер Гакыйль абый белән Хәбибҗамал әби авылга бик сирәк кайталар. Әбинең исәнлеге дә начарлана бара икән. Картлык үзенекен итә бит ул. Өйләренә газ да һаман кертелмәгән. Алар булмаганга урамның яме югалган, урам

йоклаган сыман. Элеккеге нәфислек юк инде хәзер... Өйләренең ялангач тәрәзәләре үткән-барган кешеләргә моңаеп карап утыра.

Ә кышкы бураннарда ул тәрәзәләрне дә кар күмеп китә. Шуларны күрәсең дә, йөрәк әрни башлый.

Мин «Бердәмлек» газетасында Мордовия Республикасының Сыркыды авылында туып үскән, күренекле татар шагыйре Һади Такташның йөз еллык юбилеена баручылар ул яшәгән йортны таба алмаулары турында укыган идем. Ул йортның урыны гына сакланып калган. Соңрак бу урында Һади Такташның йорт музее булдырылуы турында ишетеп шатланган идем. Ә нигә безгә дә шулай эшләмәскә?

Гакыйль абый Сәгыйровны бүген авылыбызда һәм районыбызда һәрбер кеше белә, ярата, хөрмәтли. Ул безнең өчен игелеклек, түземлек үрнәге булып тора. Дөньяда кеше гомере һәм яшәү мәгънәсе турында язылган күпсанлы шигырьләре һәм рәсемнәре үзләренең тирәнлекләре белән безне шаккаттыралар. Аның көчле һәм сынмас рухы гаҗәпләнмәслек түгел шул. Ул гаҗәеп якты, игелекле җан. Аның шигырьләрен укыгач, үзеннән-үзе яшәү дәрте көчәеп китә, иртәнге кояш нуры төсле бәгырьгә җылылык бөркеп керә.

Гакыйль абый кебек тормышны өзелеп яратучы, үзенә бирелгән гомернең кадерен белүче, башка кеше дөньяда бармы икән?

Безнең Кошки районы музеенда шушы күренекле татар шагыйре, якташыбыз иҗатына һәм тормышына багышланган күп шигырь китаплары, мәгълүматлар җыелган, күргәзмәгә аның рәсемнәре куелган.

Минемчә, Иске Җүрәй авылында шундый батыр, каһарман авылдашыбызның нигезе тузылып ятарга тиеш түгел. Ул өйдәге һәрнәрсәнең кадере булырга тиеш. Шагыйребезнең яткан урынын, өстәлләрен, урындыкларын һәм башка әйберләрен җыеп, ул яшәгән чаклардагы кебек ясап куярга кирәк. Халык килеп карагач, сокланып китәрлек булсын. Анда аның рәсемнәренең күргәзмәсен дә оештырырга мөмкин.

Бирегә үзебезнең мәктәп укучылары гына түгел, ә күрше төбәкләрдән дә килеп, Гакыйль абый Сәгыйровның тормышы, иҗаты турында сөйләнсә, аның шигырьләре, җырлары яңгыраса, начар булыр идемени? Андый кичәләргә Гакыйль абый үзе дә кайтыр иде.

Бәлки минем уйларымны һәм идеяләремне аңларга

теләмәүчеләр дә булыр. Ләкин кешенең кадерен үзе исән чагында белергә кирәк. Халыкта шундый әйтем бар бит: "Үлгәннәрнең каберен, исәннәрнең кадерен бел".

Бу өй безнең авылыбызның горурлыгына әйләнеп, аны күрергә әллә кайлардан халык җыелыр иде, минемчә.

Әйдәгез әле, авылдашлар, бергәләшеп бу фикерне чынбарлыкка ирештерик.

Гакыйль абый һәм Хәбибҗамал әби! Сезгә чын күңелдән исәнлек-саулык, корычтай нык сәламәтлек, иҗатыгызда һәм тормышыгызда зур уңышлар, хәерле, озын гомер телибез.

Туган авыл - һәркайсыбыз өчен бер изге җир ул. Күбебез шунда дөньяга килгән. Шунда күзебез ачылган.

Их, син, туган авыл - милләтебезнең нигезе, хәтфәдәй болыннарың, гаҗәеп матур тугайларың, уңдырышлы басуларың ят булып калмасын. Синдәге яшәү чыганагы гел бәреп торсын иде.

Ә синең күгеңдә безгә үрнәк булып, сүнмәс йолдызыбыз - шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровның исеме балкый.

**Руфия НИЗАМЕТДИНОВА.**
*Иске Җүрәй (Иске Фәйзулла) авылы,*
*Кошки районы.*

("Бердәмлек", № 2, 5 январь 2002 ел).

# Табигатьнең нурлы җырчысы

## (Гакыйль Сәгыйровның лирик портретына штрихлар)

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар—гаян ит,*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар—*
*сөйлә безгә!* **(Дәрдмәнд)**



**Мансур САФИН.**

Татар халкыбызның асыл улы Гакыйль әфәнде Сәгыйров турында безнең матбугатта инде шактый күп язылды вә әйтелде. Тормыш кыенлыкларын җиңә барып, батырларча яши бирүе турында да дистәләрчә очерклар вә репортажлар басылды. Әйе, һичшиксез, бу үзенчәлекле талант иясе шундый олуг хөрмәткә лаеклы. Мин исә, әдәбиятчы вә фәнни тикшеренүче буларак, үз игътибарымны аның иҗади мохитен өйрәнүгә юнәлттем. Чыннан да, күренекле әдибебез Роберт Миңнуллин әйткәнчә, бүгенге көндә Гакыйль Сәгыйровның шигырьләре дә, рәсемнәре дә гаҗәп дәрәҗәдә камил, җитлеккән. Ул ясаган рәсемнәрнең композицион бөтенлегенә, җылылыгына сокланмый мөмкин түгел. Аның шигырьләрендә, рәсемнәрендә—яшәү матурлыгы, тормышның ургылып, ташып торуы күзгә ташлана. Бу—Гакыйльнең эчке халәте, аның табигый хисләре. Монда бернинди дә ялган, нәрсәгәдер көчләп ышандырырга тырышулар юк. Ул тойган, күрергә теләгән хисләрне, күренешләрне табигатьнең үзеннән эзли башлыйсың.

Әйе, бу каһарман чордашыбыз, күренекле язучы һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровны татар дөньясында белмәгән, аның гаҗәеп тормыш һәм иҗат юлы белән кызыксынмаган кеше сирәктер, әлбәттә. Ул үз уңышлары өчен юкка гына халыкара «Филантроп» премиясе, Татарстан Язучылары берлегенең Шәйхи Маннур һәм Гаяз Исхакый бүләкләрен алмагандыр.

Гакыйль әфәнденең иҗаты бай һәм тәвәккәл. Кырыклап еллар элек Кошки районының «Ильич Маягы» һәм Нурлаттагы «Дуслык» газеталарында дөнья күргән беренче шигырьләреннән үк күренекле әдипләребез Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов,

Шәүкәт Галиев, Гөлшат Зәйнашева, Атилла Расихлар игътибарына лаек булды, ә хәзерге көндә инде дүрт поэтик китап авторы. «Ике кояш» исемле соңгы шигырьләр һәм хикәяләр китабы әле 2000 елның җәендә генә Димитровград шәһәренең «Симбирская книга» китап нәшриятында басылып чыкты. Күләме—20 басма табак тирәсе.

Мин үзем шәхсән Гакыйль чордашымның иҗаты белән Казан дәүләт университетында укып йөргән вакытларымда, 1970 елда чыккан «Тормыш җиле» китабы аша таныштым. Ул елларда аның шигырьләре еш кына «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә дә күренәләр иде. Илдар абый Юзеев та яшь язучыларның бер семинарында аның яшәү батырлыгы, чиксез оптимизмы турында сокланып сөйләгән иде. Аннары кулыма «Айбагарлар» һәм «Кабатланмас моң» җыентыклары да эләкте. Кай ягы белән «сихерли» соң аның әсәрләре? Миңа Гакыйль әфәнденең иҗаты тирән образлылыгы белән ошый, күңелемне үзенә тарта. Әлбәттә, монда аның әле талантлы рәссам булуы да зур роль уйный. Ул, минем фикеремчә, бигрәк тә матур итеп традицион пейзаж образларын күрсәтә белә. Аның һәрбер табигать сурәте-образы үзенчәлекле энергетик көчкә ия һәм шагыйрьнең йөрәге аша узган шатлыклар вә сагышлар белән уралып бара. Каеннар, имәннәр, миләшләр... Ел фасыллары, табигать манзаралары, һава күренешләре...

*Чирмешән буенда имәннәр,*
*Башлары кояшка тигәннәр.*
*Чирмешән буенда болыннар,*
*Баһадир имәннәр як-ягы,* — дип горурлана ул «Чирмешән буенда имәннәр» исемле шигырендә туган як гүзәллеге белән. Гадәттә көч, батырлык, мәңгелек, түземлек символы булган имән агачын Гакыйль дә күбрәк гашыйк егет итеп гәүдәләндерә һәм бу бик тә отышлы укыла. Менә аның «Күл буенда имән белән каен» исемле шигырендә имән белән каен парлашып, мәхәббәттән исереп, ике гашыйк булып йөриләр:

*Хәйран калып айга текәлгәннәр*
*Дулкыннарда чумып йөзгәнгә.*
*Назлы каен, чиксез якын күреп,*
*Бөдрә башын куйган имәнгә...*

Соңгы китабына кергән «Имәннәр» дигән шигырендә ул имәннәрне инде Таһир—Зөһрәләр белән чагыштыра, аларны үзенең сердәшләре итеп таный һәм әсәрен шундый юллар белән идиллияләп тәмамлый:

*Имәннәрем-имәннәрем*
*Берсен-берсе сөйгәннәр;*
*Безнең кебек, сагынышып,*
*Күл буена килгәннәр.*

Каеннар, мөгаен, иң яраткан агачлардыр Гакыйль Сәгыйрь күңелендә. Алар аңа илһам көче өстәп тора, поэтик дөньясына яшь сирпи: ул үзе дә аларга мәхәббәтен ачыктан-ачык әйтә:

*Матурлыгын эчтем, каеным, —*
*Ул бетмәслек чишмә бит синдә,*
*Хисләремдә сөеп йөрттем дә,*
*Җырларыма күчтең, каеным...* **(«Каеным»)**.

Шагыйрь ихлас күңелдән ярата каен дустын һәм аның белән бергәләшеп сөенеп яши белә:

*Якты нурлар кочты ак каенны,*
*Уяттылар татлы йокыдан:*
*Әй, гүзәлкәй, язлар килеп җитте,*
*Котылдык бит кышкы зыкыдан!*

Әмма каеннар мәхәббәти хисләр уятмый шагыйрь уйларында. Менә аңа сөйкемле булган кызый Хәдичәне ул каен сердәше, ахирәте итеп күрсәтә:

*Һәр көнне кич шәфкать кабынганда*
*Алсулыкка манып дөньяны,*
*Турларында ак каенга сыенып,*
*Уйланганын күрәм мин аның.*

Шулай ук каен-кайгы символы буларак та тәсмерләнгән Гакыйльнең «Моңлы каен» шигырендә. Анда лирик герой, яшьлек хатирәләре, гашыйк истәлекләрен барлап, зиратка килеп чыга:

*Мин тезләндем — куйдым*
*Яңакларым —*
*Нинди җылы кабер туфрагың!..*
*... Чәчләрен кабер өсләренә*
*Моңсу каен коя яфрагын.*

Каеннар язмышына карата миһербансызлык, битарафлык шагыйрь күңелен көйсезләндерә, көйдереп ала:

*... Яраткан каеннарымны*
*Мин кочып-үбеп китәм.*
*Нигә берсе корып кипкән,*
*Ни-нәрсә булды икән?*
*Зур кадак— сылу тәнендә,*
*Утыра зәһәр көлеп,*

*Хыянәтсез йөрәгемә*
*Кадалган хәнҗәр кебек...* **(«Яраткан каеннарымны...»)**

Халык иҗатында тал образы дистәләгән вариантларда йөргәнлеге бүгенге укучыга яхшы мәгълүм, әлбәттә. Кол Гали поэмасында Йосыфның бармакларын яшь тал чыбыгы белән чагыштырудан башлап, Нәҗип Мәдиярда таллыкны яшел могҗизалы дәстәрхан итеп тасвирлауга кадәр. Гакыйль да бу образга еш игътибар итеп кенә калмый, ә аны үзенчә күрсәтергә омтыла:

*Бөгелә-сыгыла тал, диләр,*
*Талда өмет бар, диләр.*
*Бер күреп сөйләшәләр дә:*
*«Гомерлеккә яр!» — диләр.* **(«Гомерлек яр»).**

Гакыйль Сәгыйровның тополь образына игътибары зур. Төз, матур гәүдәле, гүзәл ябалдашлы агач аңа имән кебек баһадир вә каен кебек сылу булып күренә: «Түбәсе белән болытны тоткан мәһабәт тополь йортның каршында», — ди ул «Тополь» шигырендә. Яз көннәрендә бу агач аеруча гүзәллеккә китеп, хәтта тирә-юнь манзарасын да тылсымлы үзгәртергә сәләтле:

*Нурларда коена-коена,*
*Топольләр көн саен яшәрде,*
*Уралды ямь-яшел томанга*
*Шау-шулы каргалар шәһәре.* **(«Топольләр»).**

Шагыйрь үзенең әсәрләрендә фәлсәфи уйлануларын башка төрле агач сурәтләре аша да башкара, чөнки, һичшиксез, табигать һәм кеше проблемалары бер-берсе белән тыгыз бәйләнгәннәр: Гакыйль лирикасында иң зур урын алган каен, имән, тал һәм топольләр белән беррәттән чыршы, өрәңге, миләш, шомырт, сирень образ-символлары да очрый.

Гакыйль Сәгыйровның иҗатына багышланган бу кечкенә язмамда мин автор кулланган, үз шигырьләренә тәфсилләп үргән барлык пейзаж образларны да күзаллый алмыйм, әлбәттә. Тик шулай да, шуны әйтеп китми булдыра алмыйм: Гакыйль Сәгыйров та, күренекле әдипләребез Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Зөлфәтләр кебек, үзенең иң кадерле хисләрен гөл-чәчәкләр образлары аша сурәтли. Бу алым — аның шигъриятенең отышлы якларыннан берсе. Тәлгать абый Галиуллин әйткәнчә: «Чәчәк — табигатьтәге гармония билгесе». Шул изге хакыйкатькә таянып, ул үзенең чордашы — укучысы белән бөек Табигать арасында «арадашчы-толмачы» булырга тырыша:

*Юл буенда гөлләр арасында*
*Иркәләнеп үсә миләшләр,*
*— Ни турында икән таң нурында*
*Сердәшләре белән сөйләшә.* **(«Миләүшә»)**.

Тик ул үзе бу мөкатдәс вазифаның никадәрле катлаулы икәнлеген аңлый булса кирәк, әмма югалып калмаска, үзенекен итәргә омтыла:

*Айбагарлар айга гашыйк мәллә,*
*Алалмыйлар айдан күзләрен, —*
*Айбагарлар сыман тып-тын калдым,*
*Әйтә алмыйм әйтер сүзләрем.* **(«Айбагарлар»)**.

Бәлки шуңа күрәдер, Гакыйль әфәнде кеше вә табигать арасындагы гармониягә инана, чәчәкләр моңында оптимизм чагылышын күрә белә:

*Ерганак җырын ишетеп,*
*Шомыртлар күзен ачкан:*
*Ап-ак чәчәккә күмелер*
*Көнебез якынлашкан!* **(«Шомыртлар күзен ачкан»)**.

Замандашым Гакыйль Сәгыйров үз лирикасында кешенең рухи халәтенә табигать сурәтләре аша үтеп керү максаты белән, шулай ук кошлар (сандугач, тургай, торна, күгәрчен, козгын, бөркет, карга), хайваннар (ат вә бүре), астрологик (кояш, ай, йолдызлар), гидронимик (чишмә, елга, диңгез), метеорологик (җил, давыл, яңгыр, томан, кар) һәм башка табигать образларын мул куллана. Әлбәттә, авторның армый-талмый эшләве аның иҗатына яңа үзенчәлекләр өсти, аның әсәрләрен яңа милли бизәкләр белән баета, патриотик төсмерләвен арттыра бара.

Шулай итеп, үзенең туган ягына чиксез мәхәббәтен пейзаж образлары-символлары аша тасвирлап яза Гакыйль Сәгыйров, һәм бу аспекттан караганда, аның иҗаты иң югары бәягә лаеклы булып тора.

**Мансур САФИН,**
**әдәбият белгече.**
*Яр Чаллы шәһәре,*
*Татарстан.*

(“Бердәмлек”, № 45, 5 ноябрь 2002 ел).

# Елавык көннәр хатирәсе

Хикәя язу минем өчен бик кыенга төшә башлады. Әбиебез исән чагында, миңа кирәк вакытта, төнлә татлы йокысыннан уянып та сукрана-сукрана булсынмы, яныма килә, кәгазь һәм карандашымны җайлап бирә иде. Кәгазем язып тулса, кабаттан килә, алмаштырып куя. Әбиебезнең кинәт кенә сәламәтлеге начарланып китүенә менә өч ел тула инде: кан басымы югары булганлыктан, миенә зарар килгән икән. Хәзер аның үзенә ярдәм кирәк—ятагыннан өстәл янына дә көчкә-көчкә генә урындыгын төртеп килә. Шул хәлендә дә әле мине кайгырткан була: ыңгырашканымны ишетеп алса, әллә авырыйсыңмы, чәй кирәкме әллә, дип сорый, өстемә ябынганны төзәткәләп уза. Урынында гына утырса, бөтенләй хәрәкәтсез калыр дип куркабыз, шуңа күрә, «үзең тор, үзең тотып эч, үзең өстәл янына кил», дип юри кымшандырырга тырышабыз. Минем эшчәнлек тә әни белән бик нык бәйләнгән иде шул.

Хикәя язганда җөмләләрне озын-озак төзергә, еш кына кайтып-кайтып эшкәртергә туры килә. Язучының бу мәшәкате аның үзен бик борчымый. Ә менә әйтеп яздырганда, синең сүзләреңне көтеп алып кәгазьгә теркәп баручыны нык ялыктыра, эчен пошыра, теңкәсенә тиядер, мөгаен...

Күп еллар элек Самарада хастаханәдә ятканда, урта яшьләрендәге бер ир-атның һәр көн кулына авторучка һәм калын дәфтәрен тоткан көе йөргәне, кая җитсә, шунда туктап дәфтәренә нидер язгалап куйганы исемдә. Язучы булган икән ул: китабын укыгач, китабындагы рәсемен күргәч кенә белдем. Башыңа килгән фикерне вакытында язып куярга кирәк икән шул.

Шигырьләр хикәя түгел— аларны язмыйча да эшләп бетерергә мөмкин. Шунысы кызганыч: соңгы вакытта шигырьләр язу, алардагы гүзәллектән күңел канатланып, илһамланып янып китү миңа тәтеми башлады. Озакламый шәһәребездә Халыклар дуслыгы йорты ачылачак. Шул уңай белән бер шигырь башлаган идем, һаман шуны дәвам итә алмыйм. Менә тәүге юллары:

*...Бихисап гасырлар элек,*
*Ачыклау мөмкин түгел,*
*Очрашып кушылган бергә*
*Чирмешен белән Идел.*
*Сөйләмиләр - өсләреннән*
*Нинди давыллар үткән...*

*Ярларында -төз наратлар,*
*Зифа каеннар үскән.*

Чирмешән буендагы куе урманнар эчендә тамыр җәйгән төбәкләрдә безнең бабайлар гомер кичергәннәр. Хәзерге асфальт һәм тимер юлларны элек елгалар алыштырган. Алар төбәкләр арасында аралашу өчен бик җайлы булган.

Татарлар, чувашлар һәм башка төр халыклар бер-берсе белән дус-тату яшәгәннәр. Кайбер авыллар арасында дин үзгәлеге дә зур роль уйнамаган. Татарлар русча, чувашча яхшы белгән кебек, чувашлар да татарча чатнатып сөйләшә белгәннәр. Әле хәзер дә күрше чуваш авылларындагы өлкәнрәк яшьтәгеләр исеңне китереп, татарча сөйләшәләр. Халыклар арасындагы күптәнге дуслык дәвам итә. Халыклар дуслыгы йорты ачылуга мин бик шат: мондый мөһим үзәк әллә кайчан булдырылырга тиеш иде инде.

Үткән елның октябрь башында чирләп китеп хастаханәгә эләктем. Шунда «общий» наркоз бирделәр. Мин ул хәлне тоймый калдым. Шигырьләрне яза алмый башлавымның төп сәбәбе — шул наркозның шаукымыдыр дип уйлыйм: шуннан бирле читләштем бит шигырьләрдән...

Форсат кына көткәннәр шикелле — берсе арты берсе чәчәк атарга ашыккан гөлләргә охшап, күптән язарга уйлап куйган хикәяләрем хәтсез генә чиратка тезелешкән. Кайсыннан башлап язарга?.. Кинәт телефон шалтырамаса, бәлки башкача килеп чыккан булыр иде. Телефонда шәһәрнең үзәк хастаханәсендә хирург булып эшләүче туганыбыз Тәлгать тавышы ишетелде: минем һәм әниемнең хәлләрен сорашты, нинди дарулар кирәк, дип белеште. Узган ел хастаханәдә ятканда үткән күренешләр аерым ачык булып күз алдына килеп бастылар...

Бишенче октябрь... Кичке сәгать сигезләр тирәсе. «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртырга туры килде: бәвел чыкмый, эчем авыртып, өрелеп китте. Фельдшер ханым алып килгән сеңер көпшәләрне күргәч, алар белән булдыра алмыйсыз, яралап кына бетерерсез, дигән идем, җыена ук башлады: «*Минем вакытым юк сезнең белән сатулашырга. Риза булмады, дип язам да китәм*», ди. Нишлим, каршылык күрсәтүнең файдасы юк. Гадәти юлдан бәвел түгел, ә көпшә артыннан кан бәреп чыккач, үзе дә аңлады булса кирәк: «Җыендырыгыз, алып китәм», ди. Шулай итеп, мин, үзем дә сизмәстән, хастаханәгә эләктем.

Җанымны алырлык итеп берничә мәртәбә казынганнан соң, корсагымны тишеп, көпшә тыгып, шешә асып куйдылар.

Кечкенә генә җылы, якты бүлмәдә без бишәү ятабыз: бишебез дә бәвел белән бәйләнгән чирләр. Ишектән керүгә — уң якта минем карават; аргы башта, тәрәзә кырында — авыл карты: катлаулы операциядән шүрләп, һәр көн үлем дәрәҗәсенә җитә-җитә дүрт ай буе өйдә ятканнан соң, уллары үгетләвенә көчкә күнеп, бирегә килеп эләккән. Операциядән соңгы авыр көннәре үткән инде, бәвеле үз юлыннан килә, берничә көннән өенә кайтарып җибәрерләр дип тора. Ике ел элек бандитлар кулыннан килене вафат булган: милициядә эшләүче ире һәм ике улы калган. Бабайлары янына оныклары килгән иде, бабай-бабай, дип кенә эндәшәләр, ягымлы, бик күндәм балалар. Икенче улы хатыны белән килгән: мине телевизордан күргән булганнар, танып, китабымны сорап алдылар.

Миңа каршы яктагы утыз яшьләрендәге Сергейга икенче көнне операция ясадылар. Ул наркоздан айнымаган иде әле, эшеннән соралып, озынча зифа буйлы, яшь кенә тормыш иптәше килеп җитте. Бүлмәдәгеләр көлешеп: «*Иреңне мулла ясадылар, сезгә хәзер мулла белән яшәргә туры киләчәк*», —диештеләр. Ханым, матур зур күзләрен елмайтып: «*Кем булса да ярый, исән генә булсын*», — дип сөйләнә-сөйләнә ире янына килеп утырды.

Тышта сөмсере коелган көзге көн: мин хастаханәгә эләккәннән бирле көне-төне вак яңгыр сибәли, әйтерсең лә, зәңгәр күк йөзен кырып-кырып юып та бетмәслек итеп, берничә кат сыек сары буяуга чумырганнар. Мине бирегә алып килгәндә машинага салкын яңгыр бәреләә, хастаханә тирәсендәге агачларга кунган ала каргаларның, бу хәлгә канәгатьсезлек белдереп, ара-тирә кыркылдавы яңгырый, чыпчыкларның чыркылдавы, песнәкләрнең күңелсез генә сызгырганы ишетелә иде. Агачлар бөрешеп, каралып киткәннәр. Мин савыгып чыкмыйча, күк йөзендә кояш күренмәс, ахрысы. Бүген иртән, кабат тикшергәннән соң: «Операциясез котыла алмассыз, өйдә унбиш көнләп ял иткәннән соң — икенче этап», — дип мине «шатландырып» куйды дәвалаучы уролог Ойкин.

Хастаханәгә «Ашыгыч ярдәм» алып килсә дә, өйгә кайтырга машина бирелми икән. Әллә инде үземнең бәләкәй машинамда утырып кайту килешмәде, кичен үк корсакка куелган көпшәдән чыкмыйча, тирәсеннән сыекча саркый башлады. Табибка шалтыраткан идек, була ул, ансыз котылып булмый инде, дип җавап бирде. Бу хәл ике-өч көнгә сузылгач, температура күтәрелеп, утыз сигезне узып киткәч, яңадан

урологка мөрәҗәгать иттек. Аны өйгә алып килергә ул көнне машинабыз җимерек иде. «Ашыгыч ярдәм»дә килүчеләр: *«Хастаханәдән урологны эзләп йөрмәдек, вакытыбыз чикле. Бездә дә оста табиблар эшли, кирәгенчә ярдәм итәрләр»,* — диделәр һәм мине якындагы стационарга алып киттеләр. Биредә чирлеләр бик күп: палаталар шыгрым тулы, хәтта кайберләре, чират көтеп, өйләрендә яталар икән. Мине коридордагы бер бүлемтеккә урнаштырдылар. Биредә тагын ике чирле ята икән: берсе - олыгаеп килүче рус кешесе, ә икенчесе - безгә килеп йөрүче таныш егет Рәфис булып чыкты. Ул мине күрүгә: «И, абый! Нишләп бирегә эләктегез?» — дип елмаеп, аксый-туксый минем яныма килеп утырды. Үзе, аягы шешеп, миннән ике генә көн элек кергән икән. Хәзер хастаханәләрдә минем кебек хәрәкәтсез ятучы чирлеләргә дәвалануы бик кыен - андыйларны даими тәрбияләүче кеше булуы зарури: шәфкать туташларының болай да эшләре күп, санитаркалар штаты аз, арттырсаң - хезмәт хаклары түбән булачак. Рәфисне күрүгә, аның белән бер урында ятуыма бик шатландым: киң күңелле, һәрвакыт ярдәмгә әзер торучы күндәм егет ул - мине игелегеннән мәхрүм итмәс дип уйлыйм. Төзелештә ташчы булып эшли, апасында фатирда яши. Урта белем алганнан соң, һөнәр мәктәбендә ташчыга укып чыккан. Бераз тотлыгып куйгалый, әмма аз гына шәйләнгән бу кимчелеге аны бозып күрсәтми. Матурлыгы өстенә уңганлыгын кушып, эчке дөньясының киңлеген, гүзәллеген ачып әллә ниткән бәхет эзләп интеккән чибәрләргә күрсәтсәң икән! Юк шул, яннарында әйләнеп йөргән бәхетне күрмиләр алар.

Авылдагы күрше малае Гомәр, бермәлне, миннән болай дип сораган иде: *«Гакыйль абый, өйләнеп кайткач, яшь килен турында ник һәрвакыт, «матурмы», дип сорыйлар? Кем дә «уңганмы, акыллымы» дип сораганы юк».*

Кызганычка каршы, кешенең ул сыйфатлары яши башлагач кына беленә, ә матурлык күзгә бәрелеп тора шул. «Матурмы», дип төпченүнең төп сәбәбе шундадыр: матур кешедән начарлык көтелми, ни өчендер ул уңган да, чибәр дә, ягымлы да, мәрхәмәтле дә булырга тиеш кебек безгә. Чөнки матурлык, дөньядагы бөтен яхшылыкны, гүзәллекне, чибәрлекне үзенә сыйдырган шикелле тоела. Тагын бер кат, кызганычка каршы, кешенең эчке матурлыгы тиз генә ачылмый, күңел гүзәллеге, рухи байлыгы соңрак беленә шул.

Рәфисне анда очратмасам, хастаханәдә егерме көн ятуларым минем өчен бик кыенга туры килгән булыр иде. Сәламәт кеше,

үзе дә белмәстән, һәр көнне үзенең меңнән артык вак-төяк хаҗәтләрен үти бит, ә син шуларга мохтаҗлык кичерәсең. Бүтән чирлеләр дә үзләре теләп ярдәмгә киләләр. Һичкайчан үтенечне кире какканнары юк. Ә Рәфис алдан ук кисәтеп куйды: «*Нәрсә кирәк булса да әйтегез, тартынып тормагыз, төнлә дә уятыгыз*».

Шәфкать туташлары якында гына утыралар, яктыртылган өстәлләре, ни эшләгәннәре күренеп тора. Аларның күбесе ягымлы, мәрхәмәтле булсалар, араларында ул тойгыны кичермәүчеләре дә табыла икән.

Өченче төн иде бугай. Бөкләнеп озак торудан тезләрем оешкан. Җайсызлык тоеп, аягымны сузып җибәргән идем, караваттан янга төшеп асылынып калды. Бу хәлдә озак ятып булмас. Ике иптәшем дә тирән йокыга талганнар. Рәфисне уятырга кызгандым. Шактый шулай ятканнан соң, яңа гына укол ясап килеп утырган шәфкать туташына мөрәҗәгать иттем. Дөрес, килгәндә сүз әйтмәде. Әмма аягымны күтәреп куйгач: «Бу эшне мин эшләргә тиешме соң? - дип теш арасыннан ачулы мыгырданып китеп барды. Кешеләрнең җаны күптөрле була шул...

«Яныгызда берәр туганыгыз торырга иде», - дип әйтүчеләр дә табылыр, мөгаен. Өйдә әни чирләп ята, биредә—мин... Нәкъ шушы көннәрдә энемнең улы өйләнде, туйлап йөрделәр. Бу арада аларның вакытлары тыгыз иде. Җыен кунак минем яныма кереп чыктылар, күчтәнәчләр, чәчәк бәйләмнәре калдырдылар. Иптәшләрем белән яшьләргә тыныч тормыш, бәхетле озын гомер теләп калдык. Күчтәнәчләре белән рәхәтләнеп чәй эчтек. Безнең белән бергә ятучы Андрей, үзенең эчке хисләренә бирелеп, сагышлы гына елмаеп куйды: «*Яңа гына тормышка кергәндә барысы да ал да гөл була шул. Яши-яши генә бергә кушылган йөрәкләрнең кайсы нинди икәнлеге ачыклана икән. Без дә болар кебек бик матур пар идек. Мин төзелештә балта остасы булып эшлим, ә Валя—штукатур-маляр. Бергә еш булабыз, танышып киттек. Озатышып йөрүебезне озакка сузмадык, өйләнештек. Беренче улыбыз туганчы бер бүлмәдә яшәп алдык. Аннан соң, икебез дә чиратта торуны исәпләп, ике бүлмәле фатир бирделәр. Күп тә үтмәде, икенче улыбыз дөньяга килде. Әгәр илдәге бу башбаштаклык килеп чыкмаган булса, өч бүлмәлесе дә эләккән булыр иде, бәлки, минем тормышым да бу кадәр челпәрәмә килмәгән булыр иде...*»

Андрейны уколга чакырдылар. Ул, авырткан аягын сөйрәп, акрын гына процедурныйга барып кайтканчы шактый вакыт үтсә дә, хикәясен сөйләп бетермичә бездән котыла алмады. Сүлпән көн, томанлы вак яңгыры белән әңгер-меңгергә ялганып, кичкә әверелде. Ала каргалар төнге урын-җирләренә кайтып уздылар. Караңгыланып килгән тәрәзә тирәсендә пырылдаган чыпчыклар да тынычланып калдылар. Өйләрдә утларның яктырагы кабынды... Ул арада Андрей янына эштән кайтып баручы өлкән улы кереп чыкты. Киенгән-ясанган чибәр генә ханым ниндидер кәгазьләргә кул куйдырып китте.

— *Бу минем «асылкошым» инде, аерылышу документлары ясап йөри. Үземә тиешле бүлмәне кече малайга калдырдым... Өченче ел инде бергә тормыйбыз бит. Илне җимереп, йөз меңнәрчә халыкны бөлгенлеккә төшергәне өчен Ельцинны күрә алмыйм мин, исемен дә ишетәсем килми. Башкаларны, бәлки, бер гаепсезгәдер, көн дә рәнҗетәләр, моңа һаман халыкның каргышы төшми.*

Ул, тешләрен шыгырдатып, төн караңгысы тулган тәрәзәгә озак кына карап утырды. Кинәт, күңелсез уйларыннан бүленеп, көрсенеп куйды да, сүзен дәвам итте:

- *Төзелешләр тукталды... без дә эшсез калдык. Көн саен иртән торып эшкә йөгерергә өйрәнгән җаннарга шабашкы эзләп интегү бик кыен бит ул. Башыңа төшкәч, башмакчы да буласың икән. Кем акыл биргәндер, Валя бухгалтерлар курсына укырга керде. Бераз җыелган акчабыз бар иде... элек алган киемнәр... шулар исәбенә көн үткәреп килдек.*

Вак-төяк эшләрен алдан тәмамлап, иң кыенына керешергә җөрьәт итә алмыйча аптыраган кеше шикелле, Андрей да банкадан су салып эчте, мендәрен рәтләп салды.

Ә тормыш драмасы менә болай дәвам иткән. Валя бер офиста бухгалтер булып эшли башлаган. Күп тә үтми, еш кына кичләрен өйгә соңгарып кайткан, төрле сәбәпләр табып аклана икән. Бер төнне, инде таң беленеп килгәндә, эче пошып яткан Андрей тәмәке көйрәтергә балконга чыккан. Кинәт подъезд төбенә машина килеп туктаган. Машинадан көлә-көлә чыккан Валясының озатып килүче ир-ат белән кочаклашып үбешә башлаганын күргән Андрей, башы әйләнеп, чак егылып төшмәгән, Өйдә олы гауга купкан. Унсигез ел бергә гомер итү дәверендә бармак очы тимәгән хатынга иренең йодрыгын татырга туры килгән. Чыгып китеп, атна буе кайтып кермәгән. Антлар биреп, тәүбә итсә, гафу үтенсә дә, аяк астында тапталган чәчәк шикелле,

бергә яшәүнең яме-тәме калмаган, Якын кешесенең хыянәте ирне егып-бөкләп ташлаган, өметсезлеккә чумган җан иясенә әйләндергән. Гаражда, элмәккә эленгән җиреннән, куркыныч тавышлар ишетеп кергән күршесе, җепне кисеп, коткарып калган. Ул хәерсез көннәр билгесе -сөйләшкәндә Андрейның тавышы ысылдап-кысылып кына чыга хәзер. Соңгы вакытта бер складта каравылчы булып эшләгән, шул ук бүлмәсендә яши дә икән, *«Тезләремнең шеше озакка китте, бетәргә уйламый дә... Эшемнән куып чыгармасалар ярар иде»*, - дип хафалана, Ул көннең күңелсезлеге Андрей бәян иткәннәр белән генә бетмәгән икән.

Күз бәйләнер алдыннан гына Рәфиснең апасы килеп китте, *«Иртәгә килеп булмый: Ольганы алыштырырга кирәк, апаларына барып кайтырга җыена*, - дип сөйләнде яшь кенә чибәр хатын. - *Күр әле, ишек читенә эләгеп, колготкием умырылып төште, әллә чүплектән җыеп, үтүкләп сатарга чыгаралар инде безгә, Ходаем...»* Ярты сәгатьләп энесе янында көлешә-көлешә сөйләшеп утырды: якынлашып килүче олы хәсрәтнең - афәтнең бер генә билгесе дә сизелми иде әле.

Кичке ашны ашагач, Андрей күрше бүлмәгә телевизор карарга юнәлде. Рәфис, китабын алып, караватына сузылып ятты: иртәгә чыгарга, башлаган китапны укып бетерәсе бар...

Мин коридорда йөренүче авыруларның кызык-мәзәк сүзләренә колак салып ятам: *«Син дә бәвел белән ятасыңмы?» «Юк, мин тешләрем белән...»* Кайвакыт яңа берәр чирлене арбада тартып узалар: коридор поезд үткәндәге шикелле яңгырап тора...

Кизүчеләр өстәлендә кинәт телефон шалтырап җибәрде: кемдер Хайрутдиновны чакыруларын үтенде. Үз фамилиясен ишетүгә, Рәфис сикереп торды, өстәл янына ашыкты. Рәфискә килеп ирешкән хәбәр бик тә күңелсез булып чыкты: кичен генә алты яшьлек малае белән килгән апасын, автобустан төшкәч, узып баручы машина бәреп үткән, икесе дә хастаханәдә: апасының аяк-кулы зарарланган, улы бөтенләй аңсыз килеш реанимациядә ята икән. Нинди генә көчле булсаң да, мондый хәсрәт кешене аягыннан ега, миңгерәтеп ташлый, бу минутта ни эшләргә кирәклеген дә онытырып җибәрә икән. Шәфкать туташлары Рәфисне, дарулар биреп, тынычландырырга тырыштылар. Минем яныма килеп утыргач та, Рәфиснең яшьләре туктамады: *«Әнинең хәле бик яхшыдан түгел, йөрәге авырта, урын өстенә егылмаса ярар иде»*, - дип кайгыртты.

Иртәгә без икебез дә биредә булмаячакбыз: Рәфис төшке ашка кадәр чыгачак, мине кичкә таба килеп алачаклар. Көпшәләргә уралып, әле минем күпме ятачагым, күпме газаплар чигәчәгем бардыр, Алла белсен. Рәфисне дә хастаханәдән чыкканын олы хәсрәтләр кочак җәеп көтеп торалар ич. Яшәү барышында очраган төрле кыенлыкларны җиңү, башка төшкән кайгы-хәсрәтләрне кичү, алардан өстен чыгарга омтылу күпне таләп итә. Авырлыкларга килеп терәлгәч тә, аларны сикереп, күзләрне йомып, йоклап кына үтү һич мөмкин түгелдер, барын да үзең өзелеп әрнеп, бәгырең аша, йөрәгең аша үткәрергә кирәктер. Кеше гомере бөтенләе белән диярлек шуннан гыйбарәт.

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
Димитровград шәһәре.

(“Бердәмлек”, № 37, 9 сентябрь, 2003 ел).

# Иртәгәме ? Нигә – иртәгә ?

Ир-ат кешегә бу үткән тормышны яңадан барлап, эшләнгән эшләргә, кылган гамәлләргә ниндидер йомгак ясау чоры. Күпләр өчен инде барсы да хәл ителгән, ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән, һәм алар пенсиядә тынычлап кына, исән-имин булып картлыкларын уздырырга җыеналар.

Ә ул андыйлардан түгел. Аңа тыныч тормыш төшендә дә тәтемидер, мөгаен. Чөнки Гакыйль Сәгыйровның бөтен гомере көрәштә үтә. Иң егәрле чагында—егет булып өлгереп килгәндә, гәүдәсе, кул-аяклары бөтенләйгә хәрәкәтсез калгач, ул өр-яңадан яшәргә өйрәнә башлый. Чыдый алмаслык тән сызлауларына, икеләтә, өчләтә тапкыр (алай гынамы икән әле) күңел сыкраулары да өстәлеп, кайчакларда тормышның, яшәешнең мәгънәсе югалгандай тоела аңа. Тик ул һәрвакыт үзендә яңа көч табып, мондый күңел төшенкелекләрен җиңеп чыга. Тормыш юлында беренче терәге, әлбәттә, әнисе Хәбибҗамал апа була. Тешләре арасына каләм кабып, озын кышкы төннәрдә Гакыйльнең күңел түрендә туган тәүге шигъри юллары да иң беренче тапкыр ак кәгазьгә әнисе ярдәме белән төшерелә. Ә тора-бара ул шул ук ысулны кулланып, рәсемнәр дә ясый башлый. Рәссам булу теләге аңарда әле балачактан ук хыялына кереп урнашып, операциядән соң хәрәкәтсез калганчыга кадәр егет укырга керер өчен сәнгать училищесына гариза да биргән була инде. Тик язмыш бу хыялларны челпәрәмә китерә.

Шул чаклардан бирле ярты гасыр гомер үтеп тә киткән. Бүген Гакыйль Сәгыйров үзенең 65 яшьлек юбилеен күренекле татар шагыйре, танылган рәссам, төрле елларда дөнья күргән биш шигырьләр китабы авторы («Тормыш җиле», «Айбагарлар», «Кабатланмас моң», «Неповторимая мелодия», «Ике кояш», «Шатлыклы иртә»), Шәйхи Маннур, Гаяз Исхакый, Сахаб Урайский исемендәге әдәби премияләр, рәсемнәре өчен бирелгән халыкара «Филантроп» бүләге лауреаты, Самара һәм Ульян төбәкләренең мөхтәрәм татары исемен йөртүче буларак каршылый. Мондый дәрәҗәләргә ирешү өчен аңа күпме көч куярга, түшәктә хәрәкәтсез яткан килеш, чын мәгънәсендә, йокысыз караңгы төннәрне үткәрергә туры килгәндер, боларны ул үзе генә белә.

Соңгы вакытларда үткән елны 85 яшен тутырган Хәбибҗамал апаның исәнлеге дә начараеп китте, Гакыйль үзе дә больницага

эләгеп, катлаулы операция кичерде. Ләкин ул да, аның якыннары да төшенкелеккә бирелергә һич кенә дә тырышмыйлар. Туган энесе Наилнең уллары Ринат белән Марат алмаш-тилмәш гел әбиләре һәм абыйлары янында. Алар Гакыйльнең яңа шигырьләрен кәгазьгә күчереп язарга, компьютерда басарга, редакцияләргә җибәрергә булышалар. Ә йорт эшләре, әлбәттә, тулысынча Наилнең хатыны Халидә ханым җилкәсендә хәзер. Тик ничек кенә булмасын, бу гаиләдә бөтенесе дә Гакыйль Сәгыйровка яшәү өчен тиешле мөмкинлекләр тудыруга юнәлдерелгән. Чөнки биредә Гакыйльнең нинди зур, талантлы шәхес икәнлеген бик тә яхшы аңлыйлар.

Мин бу кешеләргә карап-карап торам да, аларның күңел сафлыгына, миһербанлыкларына, батырлыкларына сокланып туя алмыйм. Әйе, бар бит әле дөньяда шундый кешеләр!

Ә менә безнең кайберләребез арабызда нинди талант иясе яшәгәнен аңлап бетерәбезме икән? Моннан биш ел элек Мәләкәстә каһарман шагыйрьнең 60 яшьлеген билгеләп үткәндә, аның кечкенә пенсиясенә өстәп, берникадәр матди ярдәм күрсәтү кирәклеге турында сүз чыккач, ул чакта Татарстан Язучылары берлеге рәисе булган Ринат Мөхәммәдиев бу эшне тиз көндә эшләячәге турында белдергән иде. Тик ул сүзендә тормады, хәзер Казаннан Мәскәүгә үк китеп барган икән инде. Бүгенге көндә Язучылар берлегендә яңа җитәкчеләр эшли, тик һаман да шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның тормыш хәлен бераз җиңеләйтү өчен бернәрсә дә диярлек эшләнгәне юк.

Бу турыда Татарстан хөкүмәтенең бер җаваплы түрәсе белән сөйләшкәндә, аның авызыннан: “Гакыйль Сәгыйров Татарстан өчен нинди зур гамәл майтарган соң?” — кебегрәк сүзләр ишетергә туры килгән иде. Күрәсең, әле күпләр шагыйрьнең эшчәнлегенә тиешле бәяне бирә белә алмыйлардыр. Бу шуның белән генә аңлатыладыр, мөгаен. Төптән уйлап карасаң, татар халкы, аның киләчәге өчен Гакыйль Сәгыйров эшләгән изге гамәлләрне санап та, үлчәп тә бетерерлек түгел, минемчә.

Бәлки, туган көннәрдә, юбилейларда бу хакта сөйләп тору килешмидәдер. Тик Гакыйль Сәгыйров кебек шәхесләр турында сүз барганда, боларны әйтми калу мөмкин түгел. Мине гафу итәрләр дип уйлыйм.

Татарстан матбугатында язучыларның, җырчыларның, башка сәнгать хезмәткәрләренең, гомумән, күренекле кешеләрнең туган көннәре турында мәгълүматлар басылып барыла. Тик бу юлы февраль ае исемлегендә мин нигәдер Гакыйль Сәгыйров исемен

генә таба алмадым. Бәлки, Татарстанда кайберәүләр аның татар шагыйре икәнлеген дә онытканнардыр?

Гакыйль Сәгыйров берьюлы өч төбәкнең — Татарстанның, Самара, Ульян өлкәләренең якташы булып тора. Ул Нурлат районының Әхмәт авылында туган, гомеренең иң күп елларын Кошки районының Иске Җүрәй авылында үткәргән, ә бүгенге көндә Мәләкәстә яшәп ята.

Тик ул кайда гына яшәсә дә, без аның турында онытмасак иде дә бит.

Соңгы елларда сәламәтлекләре нык какшау сәбәпле, Гакыйль әнисе Хәбибҗамал апа белән Иске Җүрәйдәге туган йортларына кайта алмыйлар инде. Шуңа күрә бу өй бүген ташландык хәлдә. Ә аны ничек тә саклап каласы иде.

Менә шундый төрле бимазалы уйлар килеп йөдәтә якташыбыз, каһарман шагыйрь Гакыйль Сәгыйровка 65 яшь тулган көннәрдә. Мондый шәхесләрне исән чакларында яхшы итеп, җиренә җиткереп хөрмәтли, бәяли беләбезме икән соң?

Шагыйрь үзенең «Иртәгә мин, бәлки...» шигырендә болай дип язган иде:

*Усал жилләр соңгы яфрагын*
*Тарткалыйлар ялгыз каенның.*
*Шул каендай басып торам менә*
*Уртасында дәһшәт кайгының.*
*Ярдәм кирәк миңа бүгенгә,*
*Ышаныгыз әйткән сүземә.*
*Иртәгәме?*
*Нигә иртәгә?*
*Иртәгә мин, бәлки үзем дә...*

65 яшьлек юбилей көннәрендә, аңа: «Гакыйль, син ялгыз түгел, без синең белән», — дип әйтәсе килә. Тик сүзебездә тора алырбызмы?

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 7, 11 февраль 2003 ел).

# Кыядагы көчле бөркет кебек

Тамашачы белән тулы зал өстендә җыр яңгырый:

*... Әй, Мәләкәс, әй, гүзәл калам...*

Мәләкәс турында бу җырны Гакыйль Сәгыйров шигыренә аның энесенең улы Ринат Сәгыйров иҗат иткән, ә шагыйрьнең 65 еллык юбилей кичәсендә аны Фәния Хәлиуллова җитәкчелегендәге «Карлыгачлар» балалар һәм яшүсмерләр ансамбле башкарды. Бәйрәмдә бу талантлы яшь коллектив шагыйрьнең әле тагын бик күп җырларын тамашачыга бүләк итте.

Менә сәхнәгә көчле кул чабулар һәм алкышларга күмелеп, инвалид арбасына утырган килеш бүгенге тантананың «гаеплесе» - Гакыйль Сәгыйров үзе килеп чыкты.

Кичәне алып баручы Равил Шәфигуллин (ул үзе дә шагыйрь) юбилярга багышлап язган шигырь юлларын укый:

*Салмак кына яуган чакта җиргә тәңкә кар*
*Илгә бәхет өстәп шагыйрь туган...*
*Андый шагыйрь тагын кайда бар?*
*Шигъри сүзе көчле күтәрелә -*
*Энисенең гүя камыры.*
*Тумышы да аның изге яктан,*
*Нык шулай ук Җүрәй тамыры.*
*Йөзе ачык аның, күңеле киң,*
*Сүзен әйтә, гүя фәрештә.*
*Бәхет теләп җырлый сандугачтай*
*Барыбызга иртә дә, кич тә.*

Татарстанның Нурлат районындагы Әхмәт авылында туып-үскән, аннан соң гомеренең зур өлешен Самараның Кошки районындагы Иске Җүрәй авылында үткәргән, ә бүгенге көндә Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә яшәүче Гакыйль Сәгыйров үзенең бөтен якташларын да ярата, үз итә. Тик шулай да, ул аеруча мәләкәслеләргә, семберлеләргә рәхмәтле. Чөнки бредә менә өченче тапкыр инде аның хөрмәтенә зур кичәләр уздырыла. Беренчесе шагыйрьнең 60 еллыгына багышланган булса, икенчесе «Ике кояш» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрү уңаеннан үткәрелгән иде. Һәм менә, ниһаять, аның 65 яшьлек юбилее билгеләп үтелә.

Шуңа күрә дә тәбрикләү өчен беренче булып сүз

мәләкәслеләргә бирелде. Юбилярга Димитровград шәһәре администрациясенең бүләге — зур төсле телевизор тапшырылды.

Аннан соң сәхнәгә Ульян шәһәре делегациясе күтәрелде. Өлкә администрациясе һәм аның башлыгы Владимир Анатольевич Шаманов исеменнән өлкә Мәдәният идарәсе җитәкчесе урынбасары Евгений Александрович Данилин Гакыйль Сәгыйровка котлау адресы һәм акчалата бүләк тапшырды. Ульян өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Азат Курчаков өлкә администрациясе тарафыннан юбилярга «Ока» автомобиле биреләчәге турында шатлыклы хәбәр җиткерде. «Өмет» газетасының баш редакторы Исхак Хәлимов каһарман якташыбызга күренекле шагыйрь Сахаб Урайский исемендәге бүләк бирелүе турында таныклык алып килгән иде.

Тәбрикләүләр котлаулар җырлар, биюләр белән бизәлеп алып барылдылар. Гакыйль Сәгыйров шигырьләренә иҗат ителгән күп җырлар яңгырады.

Шагыйрьне котларга туган төбәгеннән — Нурлаттан шәһәр администрациясе башлыгы киңәшчесе Фатыйх ага Галимов килгән иде. Ул үзенең Гакыйль Сәгыйров белән Биккол авылы мәктәбендә 6— 7нче классларда бергә укыганын һәм аның ул чакта ук рәсем ясарга хирыс булуын, нинди шәп дус икәнлеген тәфсилләп исенә төшерде.

— *Шуннан соң без аның белән 1969 елда, «Комсомольская правда» газетасында «Корчагиннар нәселеннән» дигән күләмле язма дөнья күргәч кенә яңадан очраштык. Мин мәктәптә укытучы булып эшли идем. Укучыларымны алып, шагыйрь янына очрашуга баруыбыз хәтердә уелып калган,* - дип сөйләде ул. Ниһаять, сүз юбилярның Самарадан килгән якташларына бирелде. Кошки районы администрациясе башлыгы урынбасарь Нәкетдин Халитов, Степное Шенталы волосте башлыгы Равил Минебаев, Иске Фәйзулла (Җүрәй) авылының «Рабочий» крестьян хуҗалыгы рәисе Әнвәр Алиев, Самараның «Идел» ансамбле җитәкчесе, төбәгебезнең танылган гармунчысы Мидхәт Әминев сәхнәгә менгәч, бәйрәмне алып баручы аларның исемнәрен атауга, зал алкышларга күмелде. Чөнки бу кешеләрнең барсы да Гакыйль Сәгыйров белән дистә еллар бергә, бер авылда тормышларында аның уңай йогынтысын тоеп яшәгән. Авыл яшьләренең гармунда уйнарга өйрәнергә теләкләрен күреп, Гакыйль аларга почта аша ундүрт тальян гармуны кайтарта һәм яшь гармунчылар түгәрәге оештыра. Нәкъ шунда ундүрт яшүсмернең барсы да диярлек гармунда

уйнарга өйрәнеп, дүртесе танылган гармунчы булып киткән. Менә шуларның икесе - Мидхәт белән Равил бүген остазларын юбилее белән котларга килгәннәр дә инде.

Тәбрик сүзләре әйтелеп, бүләкләр дә (265 еллык юбилеен билгеләп үткән Кошки районы тормышы турында телефильм, җирле рус шагыйре Иван Акулиничевның автографы белән «Сенокос» исемле шигырьләр китабы, шушы төбәк шагыйрьләренең «Кондурчинское раздолье» дигән җыентыгы (анда Гакыйль Сәгыйровның русчага тәрҗемә ителгән шигырьләре дә урын алган) һәм җирле рәссамның туган як табигатен сурәтләгән матур зур картинасы) тапшырылганнан соң, Мидхәт үзенең гармунында «Авыл көен» уйнап җибәрүгә, күпләрнең күзләренә яшьләр килде. Әйе, туган як моңнары беркемне дә, беркайчан да битараф калдырмый шул.

Ә без, Самара төбәгеннән килүчеләр— мин, «Бердәмлек» газетасының баш мөхәррире, Самара шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе әгъзасы Рәфгать Әһлиуллин, танылган җәмәгать эшлеклесе, җырчы Идеал Галәүтдинов, Тольятти шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары Рафаэль Хәсәнов, «Азан» мөселман газетасы мөхәррире Шамил Галимов, Камышлы районының «Камышлы хәбәрләре» газетасы редакторы Резеда Төхбәтшина, Самараның «Яшь зыялылар клубы» җитәкчесе Фәрхад Мәхмүтов, иң беренче нәүбәттә юбилярга «Татар кухнясы» хуҗабикәсе Разия Әюпова пешергән чәкчәкне тапшырдык. Нурлатлылар бүләк иткән бавырсак янында ул сәхнәгә тагын да ямь өстәп җибәрде кебек. Ә инде Идеал әфәнде юбиляр хөрмәтенә борынгы татар җырын «Шәм-Шәриф»не сузып җибәргәч, күңелләребез нечкәреп киткәндәй булды.

Татар дөньясына Зыя Ярмәки, Халикъ Садри, Әнвәр Давыдов, Рөстәм Мингалимов кебек олуг шагыйрьләрне һәм язучыларны биргән Камышлы ягыннан бүләккә шигырь язып җибәргәннәр.

*Гомер тауга менеп төшү -*
*Тау түбәсе кыядыр.*
*Кыя бик кыю кошларга -*
*Бөркетләргә оядыр.*
*Алтмыш биш ел — син кыяда,*
*Күзеңнең очлы чагы,*
*Болытларга омтылырга*
*Канатың көчле чагы.*

*Бәйрәмең торсын җим булып,*
*Бер алтын бөртек булып...*
*Ходай бирсен озак еллар*
*Яшәргә бөркет булып.*

Димәк, Камышлы якларында шигърият чишмәләре бүген дә саекмаган икән әле.

Бу күләмле язмамның ахырында Казан кунагы — Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты исеменнән рәхмәт хатын тапшырган Фәрит Уразаев чыгышына аерым тукталып үтәргә кирәктер.

*- Милләттебез алдында олы хезмәтегезне искә алып, татар халкының туган телен, мәдәниятен үстерүдә, гореф-гадәтләрен саклап калуда башкарган зур гамәлләрегез өчен Бөтендөнья конгрессы башкарма комитеты сезгә зур рәхмәтен белдерә һәм киләчәктә дә зур уңышлар тели, - диде ул. — Сезнең шигырьләрегез, сезнең рәсемнәрегез һәрвакыт татар дөньясын берләштерүче көч булып тора. Быел җәен Димитровград шәһәрендә үткәреләчәк татарларның Федераль Сабан туеның да сез төп батыры булачаксыз дип шикләнмичә әйтәм.*

Бу сүзләр Гакыйль Сәгыйровның тормышына, иҗатына иң югары бәяләрнең берсе иде, әлбәттә.

Әгәр бу юбилей кичәсен үткәрүгә ярдәм кулын сузучыларның исемнәрен атамасак, дөрес булмас иде кебек.

Менә алар: Димитровград шәһәре, Ульян өлкәсе администрацияләре, эшкуарлар - Фәрит Хәлиуллин, Геннадий Шәрифгалиев, Ривал Идрисов, Шамил Идрисов, (Димитровград), Җәмил Вәлиуллин, Марат Мөхәммәтшин (Самара).

Кичә ахырында сүз юбилярның үзенә — Гакыйль Сәгыйровка бирелде.

Ул шушы зур бәйрәмне оештыручыларның һәркайсына үзенең рәхмәтен белдерде, яңа шигырьләрен укыды.

Сәхнә түрендә — яңадан "Карлыгачлар" ансамбле кызлары һәм егетләре. Алар башкаруында Гакыйль Сәгыйров шигыренә иҗат ителгән "Зәңгәр күзләр" җыры яңгырый.

Күңелгә ничектер рәхәт булып китә. Бу шушындый чын кеше, олуг шәхес һәм шулай ук милли моң, сәнгать, әдәбият белән очрашудан соң туган халәттер, мөгаен.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**
Самара-Димитровград-Самара.
("Бердәмлек", № 11, 12 март 2003 ел).

# Чын кеше булу өчен нәрсә кирәк?



Нурзидә
ФӘЙЗУЛЛИНА.

Мәшһүр якташыбыз, шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровның 65 еллык юбилеена без ныклап әзерләндек. Һәр уку елында уздырыла торган татар теле һәм әдәбияты декадасын да нәкъ шушы вакытка туры китерергә тырыштык.

Уку елы башында һәр сыйныфта әдәбияттан календарь-тематик укыту планында «Гакыйль Сәгыйровның иҗаты белән танышу һәм шигырьләрен уку» дигән класстан тыш уку дәресен расладык. «Шигърият сөючеләр» түгәрәгенең эш планына да бу теманы керттек.

Мин үзем, шәхсән, шигърият дөньясына һәм Гакыйль абый Сәгыйров иҗатына битараф түгелмен. Шуңа да аның турында булган барлык материалны, шул исәптән «Бердәмлек» газетасы битләрендә урын алган мәкаләләрне, шигырьләрне тагын бер тапкыр укып чыктым. «Шагыйрь Гакыйль Сәгыйров иҗаты» дип исемләнгән папкага бөтен мәгълүматларны тупладым.

Ункөнлек кысасында үткәрелгән ачык дәреснең һәм кичәнең темасы итеп шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның балалар поэзиясен һәм аның иҗатындагы хәрби-патриотик юнәлешне алдым. «Шигърият сөючеләр» түгәрәгенә йөрүче укучылар белән якташыбызга багышлап, «Шигырьдә – рәссам, рәсемдә - шагыйрь» дип аталган Гакыйль абыйның рәсемнәреннән торган стенд әзерләдек һәм аның шигъри иҗатына багышланган әдәби газета чыгардык. Мин 5нче сыйныфта әдәбияттан «Шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның балалар поэзиясе» дигән темага класстан тыш уку дәресен үткәрдем. Дәрескә әзерләнү чорында яшь укучылар шагыйрьнең «Кабатланмас моң», «Неповторимая мелодия», «Ике кояш» китапларындагы, «Бердәмлек» газетасы битләрендәге балалар өчен язылган әкиятләрен, хикәяләрен укыдылар, шигырьләрен ятладылар, биографиясен һәм иҗатын өйрәнделәр. Шулай ук алар видеотасмада шагыйрьнең үзен

күрделәр, аның балалар өчен язган шигырьләрен автор башкаруында тыңладылар. Бу дәрес һәм якташыбызның иҗаты укучыларның күңел түрендә озак сакланыр, дип уйлыйсы килә.

Ә менә 14 февральдә без, «Яктылык» мәктәбенең укытучылар коллективы һәм укучылары, мәшһүр якташыбызны 65 еллык юбилее белән котлап, аңа телеграммалар да җибәрдек әле!

Быел без шагыйрь Гакыйль Сәгыйровка багышланган әдәбимузыкаль кичәне һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары белән Ватанны саклаучылар көненә багышланган очрашу кичәсен берләштерергә булдык. Кичәне үткәрү сценариен югары сыйныф укучылары белән бергәләп әзерләдек, шигырьләрне дә бергә сайладык.

Шагыйрьнең шигырьләренә язылган җырларны өйрәндек. Бу берләштерелгән кичә булганга, Гакыйль Сәгыйровның мәхәббәт, әхлак, яшәү философиясен (фәлсәфәсен) чагылдырган, сугыш, хәрби-патриотик темаларга караган шигырьләренә күбрәк урын бирелде.

Әйтергә кирәк, кичәгә килүче ветераннар татар милләтеннән генә булмыйча, рус милләтеннән дә булганга, якташыбызның иҗаты белән таныштыруны рус телендә дә алып барырга туры килде. Ә җырчыларыбыз Гакыйль Сәгыйров шигырьләренә язылган җырларны дәртләнеп башкарганда, аларны тамашачылар алкышларга күмделәр.

**Нурзидә ФӘЙЗУЛЛИНА,**
**«Яктылык» мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Шигърият сөючеләр» түгәрәге җитәкчесе.**
Самара шәһәре.

(“Бердәмлек”, № 11, 12 март 2003 ел).

# “Бердәмлек” безнең ярдәмгә мохтаҗ

Соңгы вакытларда озак елларым үткән Иске Җүрәй авылына еш кайта алмый башладым. Анда миннән башка булган хәлләрне тулысы белән бик беләсем килсә дә, якын кешеләр сагынылса да, тормыш үзенекен итә шул. Үткән елда хәзер мин яшәп яткан Мәләкәс шәһәрендә әниебез вафат булды. Аны да биредә генә җирләргә туры килде.

Җаныма якын авылымдагы, Кошки районындагы, Самара өлкәсендәге үзгәрешләр мине нык кызыксындыра. Әлеге вакытта анда булып үткән вакыйгаларның күбесен «Бердәмлек» аша гына белеп торам. Өлкәдәге күләмле шул басманың өебезгә килүен сабырсызлык белән көтеп алам.

Туган телебезне, мәдәниятебезне, динебезне халкыбыз арасында тарату, саклап калу өчен тырышучы Самара төбәгендәге төп басма бит ул -«Бердәмлек». Укучыларыбызның тормыш-көнкүреше турында язылган йөзләгән хатлары, иҗади җимешләре - зәвыклы хикәяләр, повестьлар аның битләрендә басылып тора.

«Бердәмлек»не күбесенчә авылларда яздырып алалар бит. Әле беренче чыга башлаган елларда Иске Җүрәй авылында почтальонка булып Халисә Гыймалетдинова эшли иде. Авылдашлар Татарстанның үзеннән дә, башка милли басмаларны да өйләренә алдыралар, русча чыккан район һәм өлкә газеталарына да күпләп язылалар иде ул чагында. «Бердәмлек»не генә дә авылыбызда алтмышлап кеше ала иде.

«Күтәреп кайтырга, таратып йөрергә бигрәк авыр, җилкәләрем талып төшә», - дип зарлана иде Халисә.

Аның каравы, хәзерге көндә хат ташучының сумкасы бик кысыр күренә. Билгеле инде, тормышның кыенлашып китүе монда төп сәбәпләрнең берсе булып тора. Яшьләрнең, укучы балаларның татар телендә чыккан басмалар белән кызыксынмый башлавы да моңа аяк чала.

Иске Җүрәй авылындагы тугызъеллык мәктәпне башлангыч итеп кенә калдырырга тырышучылар күп икән. Болай да яртылаш русча сөйләүче балалар, рус мәктәбенә китеп укый башлагач, туган телләрендә уку-язуны бөтенләй онытачаклар бит. Мәктәптә балалар азлыгына сылтау ясыйлар. Ә моңа авыл-

да яшьләрнең төпләнеп калмавы гаепле. Ә төпләнеп калмауның сәбәбе -авылларның экономик яктан какшавы китереп чыгарган күренеш.

Үткән елда авылда колхозның соңгы сыерларын да суеп бетергәннәр. Моны «Терлекләр асрау рентабельле түгел» дип нигезләгәннәр. Шушы тармакта эшләүче типсә тимер өзәрлек ир-атлар, хезмәт сөючән хатын-кызлар эшсез калган. Хәзер кыш көнендә башка җирләргә китеп, эш эзләп йөрергә мәҗбүрләр. Таштан әйбәт итеп салынган биналар караучысыз калган. Хәзер аларны сүтәләр, җимерәләр.

«Ата-баба ясаганны җимерү, юкка чыгару бик җиңел», диләр бездә. Моның өчен зур акыл да, күп көч тә кирәкми. Бүлеп бирелгән пай җирләрен аерып алып, эшкәртә башласалар, күпләрнең хәленнән килмәячәк. Андыйлар җирләрен сатып, башкаларга батрак булып керәчәкләр. Хезмәт куя алмаганнар, акчалары беткәнче яшәгәннән соң, хәерчеләр рәтенә басачаклар. Пенсия алып торучылары булмаган гаиләләр бүген дә акчага нык тилмерәләр. Шуңа күрә кешеләргә, ник газетага язылмыйсыз, дип тел тидерергә дә күңел бармый.

Мәктәпләрдә туган телне укыту ягы Самара һәм Ульян өлкәләрендә әйбәт бара, дип билгеләргә мөмкин әле. Үткән елда, җае чыгып, Наил энемнең өлкән улы Рафаэль янына баргач, Әстерхан өлкәсе мәктәпләрендә туган телне укыту белән кызыксындым һәм без шәһәрдән утыз чакрымдагы Катузан урта мәктәбенә юл тоттык. Тулысы белән татар авылы, мәктәптә - 78 бала. Унбиш ел инде биредә татар теле укытылмый. Элек туган телне укытучы олы яшьтәге Бану ханым бу хакта ачынып сөйләде. Дүрт ел инде мәктәп мөдире дә рус кешесе икән.

Аннан без Ташлы дигән авылга киттек. Ул ике мәчетле бик зур татар авылы булып чыкты. Мәктәптә 215 бала укый. Ә татар теле белән шундый ук аянычлы хәл. Мин укытучылардан «нишләп татар теле укытылмый соң?» дип сораган идем, «сәгатьләр бирмиләр», дигән җавап алдым.

Очрашуга утыздан артык укытучы һәм өлкән сыйныф укучылары җыелган иде. Алар алдында берничә сүз әйтеп, үземнең ике китабымны бүләк итеп бирдем. Элекке елларда туган телне укыткан Зәйтүнә ханымга: «Балаларга берничә шигыремне укып күрсәтегез!» - дип мөрәҗәгать иттем. Әллә шушы үткән унбиш ел эчендә апабызга бер дә татарча укырга туры килмәгәнме инде? Тотлыга-тотлыга, ике шигыремне көчкә укып чыкты. Аның өчен мин оялып, «Ник укырга соралдым

икән?" - дип утырдым. Телебезнең бөтенләй матурлыгын алып ташлады бит укытучы апабыз.

Ә инде мәктәп ишек алдында яртылаш русча, яртылаш татарча сөйләшеп йөрүче укучыларны күргәч: «Бу мескен балалар хәзердән үк туган телләреннән аерылган, татарча укый да, яза да белмиләр бит», - дигән шомлы уйларга баттым.

Казан якларындагы зур абзыйлар хәзерге хәрефләрне латин графикасына күчерергә баш ватып йөриләр. Әлегә кадәр бөтен ихтыяҗларыбызны үтәгән хәрефләр кайсы яклары белән аларга ошамады икән?

Эш юктан эш чыгарып, йөз меңнәрчә акча туздырып, шундый мәсьәләне күтәреп йөргәнче, әлеге мәктәпләрдә туган телебезне укытуны яңадан торгызу хакында кайгыртсыннар иде дә бит.

Туган телне белүчеләр, туган телендә язылган китап-журналларны укучылар юкка чыкса, әллә нинди графика белән язсаң да, сине укучылар булмаячак, романың да, повестең да, газетаң да кирәкмәячәк. Чөнки халык тагын берничә елдан тәмам руслашып бетәчәк, газета-журналларны, китапларны миллионлаган тираж белән бастырып чыгарсаң да, аларны укучы булмаячак.

Әнә шушы хәлләр турында алданрак уйланырга, хәл кылырга кирәк, дип саныйм. «Бердәмлек» укучыларына миннән күп сәлам. Яраткан басмабызның тиражын арттыру турында барыбыз да кайгыртсак иде. Чөнки мактап сөйләрлек, кызыктырырлык, өлкәбездә татар телендә дөнья күрүче бердәнбер газетабыз бит ул - «Бердәмлек»!

**Гакыйль СӘГЫЙРОВ.**
*Димитровград шәһәре,*
*Ульян өлкәсе.*

("Бердәмлек", № 8, 15 февраль 2005 ел).

# Гакыйль дустыбыз - бездә кунакта

Шушы көннәрдә генә «Бердәмлек» газетасы редакциясендә кадерле кунак — иң актив хәбәрчеләребезнең берсе, Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләк лауреаты, шагыйрь һәм рәссам, озак еллар Кошки районының Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылында гомер иткән, ә хәзер Ульяновск өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә яшәүче каһарман якташыбыз Гакыйль Сәгыйров булып китте. Шагыйрь безгә үзенең соңгы вакытларда иҗат иткән бер кочак өр-яңа шигырьләрен алып килгән иде.

Самарага килер алдыннан гына аның күзенә катарактадан Мәләкәс хастаханәсендә операция ясаганнар. «*Аллаһыга шөкер, барсы да уңышлы булды кебек. Күзем яхшы ук күрә*», — дип шатлыгы белән уртаклашты шагыйрь якташыбыз. Операцияне ясаган күз врачы Валерий Петрович Библаевка һәм хастаханәнең бөтен хезмәткәрләренә рәхмәте зур аның.

*- Күзләрем дә күрмәсә, миңа бик тә кыен булыр иде,* — ди ул.

Хәзер шагыйрь яңа иҗат планнары белән янып яши. Аңа быелгы язны Иске Җүрәйгә кайтып, анда айдан артык яшәве дә илһам биргәндер, мөгаен.

*- Әнинең бертуган энесенең улы Руслан (Гакыйльнең ике туганы була) һәм аның хатыны Гөлсинә ханым Абдулганиевлар гаиләсендә яшәдем,* — дип сөйләде шагыйрь, — *урамда бик пычрак булганлыктан үзем йөри алмасам да, мине искә төшерүчеләр яныма еш килделәр. Шуңа күрә ай буе Иске Җүрәйнең бөтен проблемаларын ишетеп, белеп яшәргә туры килде. Мин авылда чакта хуҗалык рәисен дә алыштырдылар бит әле. Районда эшләүче авылдашыбыз Нәкетдин Халитовны чакырып алып, сайлап куйдылар. Зур өмет белән язгы чәчүне дә уңышлы гына үткәргәннәр икән авылдашларым. Көзгә табарак, уңыш җыеп алынганнан соң, бу хакта «Бердәмлек»кә дә бәйнә-бәйнә язып җибәрермен әле, Аллаһы теләсә.*

Әнисе Хәбибҗамал апа турында да бер кыйсса кебек нәрсә язмакчы әле ул. Аның исеме дә бар икән инде. «Мәрхәмәтле куллар иясе» дип аталачак ул.

*— Быел 30 апрельдә әнинең вафат булуына ике ел тулды бит инде,* — дип сөйли Гакыйль. — *Ә ул әле бүген дә исән, менә ишек ачылып китәр дә, кояш кебек елмаеп, әнием килеп керер кебек. Төшемә еш кермәсә дә, кайчак өстәл тирәсендә чәй ясап, елмаеп утырганын күргәлим. Әнием турында уйлаганымны язып төгәлләсәм, аңа бу дога булып, барып ирешер иде. Әниемнең бертуган энесе, мәрхүм Сиражетдин абзыйның сөйләп калдырган армиядәге мажаралары турында да язмакчы булам. Моңа вакыт һәм дәрт-дәрман гына кирәк.*

Иске Фәйзуллада булганда, Нурлат телевидениесеннән килеп, аның турында бер кыска гына тапшыру да ясап киткәннәр икән. Күптән түгел генә шалтыратып, бу телевизион фильмның Казанда үткәрелгән телетапшырулар бәйгесендә беренче урынны яулавын хәбәр иткәннәр.

Озак сөйләшеп утырып, аның яңа шигырьләре белән танышканнан соң, каһарман якташыбыз белән саубуллашабыз. Әле тагын шулай күп тапкырлар очрашырга язсын иде, Ходай. Ә син безне һәм «Бердәмлек» укучыларын яңа шигырьләрең, язмаларың белән гел шатландырып тор, Гакыйль дустыбыз!

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 28, 11 июль 2006 ел).

# Йөрәк серен ачканда

Бу көнне Татар мәдәнияте кичәсенә җыелган тамашачыны Димитровград каласының «Восход» Мәдәният сарае киң күңелле кеше сыман каршылады.

Шәһәр хакимияте һәм татар милли-мәдәни автономиясе тырышлыгы белән зурдан кубып уздырылган әлеге чара шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның «Йөрәк сере» китабын укучыларга тәкъдир итүгә багышланган иде.

Гакыйль Сәгыйров - татар халкының күренекле шагыйре, танылган рәссам, «Тормыш җиле», «Айбагарлар», «Кабатланмас моң», «Ике кояш», «Шатлыклы иртә» китаплары һәм яңа гына мәркәзебез Казанда басылып чыккан «Йөрәк сере» дип исемләнгән җыентыкның авторы. Якташыбыз - Гаяз Исхакый, Шәйхи Маннур, Сахаб Урайский исемендәге әдәби бүләкләр иясе, рәсем сәнгатендәге уңышлары өчен Халыкара «Филантроп» премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, Ульяновск һәм Самара өлкәләренең мәшһүр татар исемен йөртүче шәхес.

Ул - ярты гасырдан артык гомерен урын өстендә ятып, шигырьләрен һәм рәсемнәрен тешләренә каләмен кысып язучы рәссам. Аның «Йөрәк сере» җыентыгына да шул рәвешле иҗат ителгән әсәрләре һәм рәсемнәре тупланган. Китапны ачып кайсы гына шигырен укыма, ул - шиңмәс гөл. Нинди генә рәсеменә юлыкма, ул - хыял юлы, зәңгәр офыклар...

Сәхнәгә бер-бер артлы күренекле милләтпәрвәрләребез Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Рамис Сафин, төбәгебездә чыгып килүче бердәнбер «Өмет» татар газетасының баш редакторы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Исхак Хәлимов һәм танылган шагыйрә, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы Лена Садыйкова-Иделбикә күтәрелде. Аларның барсы да өлкә татар-милли мәдәни автономиясе әгъзасы, Россия Федерациясенең атказанган укытучысы Роза Әхмәтҗанова кебек үзләренең дәртле чыгышларында тирән хисле котлау сүзләрен ирештерделәр.

Өлкә Законнар чыгару җыелышы депутаты Александр Чурсин Гакыйль Сәгыйровны өлкә парламентының Мактау

грамотасы белән бүләкләде, ә Ульяновск өлкәсе губернаторы ярдәмчесе Валентина Сергеева Сергей Иванович Морозовның кайнар котлау сүзләрен җиткерде.

Кичәне оештыру буенча барлык мәшәкатьләрне үз җилкәсенә алган, ару-талуны белмәгән, милләтебез язмышын йөрәгенә сеңдергән шәхесебез - Димитровград шәһәре татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Риваль Идрисов әдипне кайнар тәбрик итеп, аңа милли-мәдәни автономиясе президиумы әгъзаларының бүләкләрен, чәчәк бәйләмнәрен тапшырды.

Котлаулар, тәбрикләү сүзләре җыр-моңнарыбыз һәм шигъри сүзләр белән бергә үрелеп барды. Сәхнәдән шагыйрьнең тирән мәгънәле шигырьләре, Гакыйль Сәгыйров сүзләренә язылган җырлар, халкыбызның онытылмас көйләре яңгырады.

Гакыйль абыйның сагышлы җырларының күпчелек өлешен бертуган энесенең улы Ринат Сәгыйров иҗат иткән. «Төнге яңгыр», «Соңгы сәлам», «Аппагым», «Назла, әнием» дип исемләнгән җырлар нәкъ әнә шундыйлардан.

Залны шыгрым тутырып килгән тамашачыларның берсе дә кичәдән буш китмәде шикелле. Аларның йөзләренә бәхет, милли горурлык хисе тулып китте, шатлык өстәлде.

*«Бер-береңә шатлык китереп,*
*Эзләп торсаң иде җай гына.*
*Һәрбер йөздә бәхет балкыр һәм*
*Урын калмас иде кайгыга»,* - дип яза бит әнә шагыйребез Гакыйль Сәгыйров та.

**Равил ШӘФИГУЛЛИН.**
Димитровград шәһәре.

(“Бердәмлек” № 12, 20 март, 2007 ел)

# Аның тормышы һәм иҗаты - безгә үрнәк

Самараның Халыклар дуслыгы йортында өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте каршында оештырылган әдәби түгәрәк әгъзалары үзләренең чираттагы җыелышларын танылган якташыбыз, күренекле татар шагыйре Гакыйль Сәгыйровның яңа гына дөнья күргән «Йөрәк сере» дип исемләнгән яңа китабын тәкъдир итүгә багышлаганнар иде. Әдәби түгәрәкнең җитәкчесе Фәрит Шириязданов үзе дә күптәннән шигырь язу белән шөгыльләнә. Шуңа да аңа яхшы шигырь җан азыгы булып тоеладыр, күрәсең. Гакыйль Сәгыйровның һәр яңа шигырен укыганда, аның ничек нык дулкынлануы әллә кайдан күренеп, сизелеп тора.

- *Шагыйрьнең шигырьләре, кайсын гына алма, көчле мәхәббәт хисе белән сугарылганнар,* - диде ул үзенең кереш сүзендә. - *Ничек дүрт стена артында бикләнеп ятып, ә Гакыйль Сәгыйровка күпчелек вакытын шушы халәттә үткәрергә туры килә, кешелек дөньясына шулай яратып карап була икән соң?*

«Яктылык» мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нурзидә Фәйзуллина да сүзен әле 1970 елларда ук шагыйрьнең беренче шигырьләре белән ничек танышуы турында башлап җибәрде.

- *Бу шигырьләрне укыганда, әгәр белмәсәң, шагыйрьнең гел хәрәкәтсез түшәк өстендә генә ятып торырга дучар ителгәнен күз алдына китерүе дә мөмкин түгел. Шигырьләрнең барсы да оптимистик рухта язылганнар.*

Нурзидә ханым үзе генә түгел, аның тормыш иптәше Мәгъруф әфәнде Гыйльмияров та Гакыйльнең иҗатына мөкиббән кешеләр.

— *Соңгы вакытларда без еш кына Гакыйль Сәгыйровның шигырьләрен кабат-кабат укыйбыз, һәм алардан яңа фикерләр, төсмерләр табабыз,* — диделәр алар.

Нурзидә ханым кичәгә үзе белән укучыларын да алып килгән иде. Ринат Альмушев белән Равил Насыйров бик зәвыклы итеп шагыйрьнең берничә шигырен бәйрәмгә килүчеләргә дә укып бирделәр.

Гомумән, бу көнне биредә Гакыйль Сәгыйровның яңа ши-

гырьләре бик күп яңгырады, аның шигыренә язылган җырлар да башкарылды. Аларны бик оста итеп, Гакыйль Сәгыйровның иҗатын пропагандалаучыларның берсе булган, Самара төбәгенең танылган җыр остасы, озак еллар «Ялкынлы яшьлек» ансамблендә җырлап йөргән Галия Мостафина җиткерде.

Ә бу кичәне иң кызыклы җире шагыйрьнең авылдашы, үзенең балачак елларын Иске Җүрәйдә Гакыйль Сәгыйровтан, үзе әйтмешли, аның яткан «сәкесен»дә аунап тәрбия алган, озак еллар Дәүләт куркынычсызлыгы органнарында җаваплы урыннарда хезмәт иткән Ирек Мустаев белән очрашу булгандыр. Ирек әфәнде бик тә кызыклы итеп Гакыйль Сәгыйров белән бергә Иске Җүрәйдә яшәгән шул еллар турында үзенең балачак һәм яшүсмер хатирәләрен яңартты. Үзенең чыгышы ахырында ул Иске Җүрәйдә шагыйрь яшәгән йортны саклап калып, анда әдәби музей ачарга кирәклеген тагын бер тапкыр барыбызның да исенә төшерде. Киләсе 2008 елда күренекле якташыбызның туувына 70 яшь тулачак. Бу вакыйганы өлкәбездә истә калырлык итеп үткәрергә кирәктер, мөгаен. Гакыйль Сәгыйров кебек шагыйрьләребезнең тормышын һәм иҗатын без һәрвакыт яшь буынга үрнәк итеп куярга бурычлыбыз.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 12, 20 март 2007 ел).

# Бер көрәшү - үзе бер гомер

Ул гади кеше түгел. Ә кем, нинди кеше соң, ул Гакыйль абый Сәгыйров? Аның иҗаты белән таныш булган һәр кешенең җаны шушы табышмак сорауга җавап эзлидер, мөгаен. Гакыйль абыйның күңел җылысы белән язылган шигырьләрен китапларыннан, районыбызда чыгып килә торган "Дуслык" газетасыннан укып, даими танышып торсак та, үзе белән дә очрашу күптәнге хыялыбыз иде. Аның «Йөрәк сере» дип аталган яңа җиденче җыентыгы дөнья күргәч, бу хыялыбызга чынга ашарга мөмкинлек туды.

Шагыйрьнең «Тормыш җиле», «Айбагарлар», «Кабатланмас моң» һәм башка китаплары буенча аның иҗаты белән таныш укучылар, «Йөрәк сере» районыбызга килеп ирешү белән, тиз арада китапны сатып алып та бетерделәр. Нурлат мәгариф бүлегенең баш белгече, тынгысыз җанлы Разия Идрис кызы Садретдинова, күпсанлы укучыларның теләген искә алып, Гакыйль абый белән бәйләнешкә керде һәм аны Нурлат якларына кунакка чакырды. Кайсы шагыйрь үз укучылары белән очрашудан баш тартыр икән?! Гакыйль абый да бу чакыруны бик теләп кабул итте.

Югары Нурлат авылы урта мәктәбендә үткәрелгән очрашуда укучылар белән ул бик тиз уртак тел тапты, кечкенә сыйныф укучылары үзенә бүләк итеп хәзерләгән җыр-биюләрне бик яратып кабул итте. Аның шигырь җыентыкларының берсе - «Шатлыклы иртә» нәкъ менә нәни дусларына багышланган бит. Балаларның үзләре өчен язылган шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләп кенә калмыйча, шул шигырьләргә карата ясаган рәсемнәрен дә бүләк итүләре шагыйрь күңеленә бик хуш килде. Җыр-бию башкарган нәни дусларының исемнәре белән кызыксынып, аларга төрле сораулар биреп, күптәнге танышлары белән очрашкандай сөйләште Гакыйль абый.

Бу очрашуны аеруча дулкынланып көткән югары сыйныф укучыларын да Гакыйль абый үз итте. Очрашу аның тормыш юлы белен таныштыру, шигырьләрен сәнгатьле уку, аңа бүләккә җырлар башкару белән бергә үрелеп барды. Үзенең шигырьләрен башкаручыларга бик таләпчән булган Гакыйль абый Илсинә Әһлиуллинаның сәнгатьле укуын аеруча яратып тыңлады.

16 яшендә хәрәкәтләнүдән мәхрүм калып, бөтен тормышы коляскага бәйле булган Гакыйль абый, язмышның кырыс,

мәрхәмәтсез сынауларын кичеп тә, яшьлек хыялларын югалтмый, аларга тугры кала. Җанның иң нечкә кылларын тибрәндерерлек шигырьләр иҗат итүче, туган ягы табигатен сокланырлык рәсемнәрендә мәңгеләштерүче кеше ул. Ә ул шигырьләрнең, рәсемнәрнең нинди шартларда язылуын белгәч, Гакыйль Сәгыйров иҗатының батырлыкка тиң икәнен аңлыйсың.

Әгәр балаларына язмышны аналар яза торган булса, ачы язмышлар булмас, язмышлар гел бәхетле һәм ак кына булыр иде. Ләкин балаларның язмышы күкләр кулында шул. Олы җанлы Хәбибҗамал апа да улын үзенә таяныч булыр дип үстергәндер. Чыннан да алар гомер буе бер-берсенә терәк-таяныч булып яшәделәр бит.

Нинди генә авыр вакытларында да аның янындагы әнисе Хәбибҗамал апага - улының ирешкән уңышларына иң, нык куанучы, изге җанлы, сабыр холыклы анага, чиксез рәхмәтлебез. Шуңа күрә Гакыйль абыйның әниләргә багышлаган шигырьләре бу очрашуда аеруча бер ярату белән башкарылды.

*Әни, әнкәй, син бит дөнья яме,*

*Син булмасаң, мин юк, беләмсең,* - дигән юлларны ничек дулкынланмыйча тыңлап була?!

Руфина Мөхәммәтованың әниләргә багышлаган җыры да, улын язмышларга буйсынмаслык көчле итеп тәрбияләгән изге ананың рухына якты нур булып иңсен иде, дигән теләктә башкарылды.

Күбебезгә битараф чире йоккан, кеше язмышларына күзебез сукырайган, дөньяның кырыслыгыннан йөрәк бәгырьләренә салкын үткән бу заманда Гакыйль абыйның:

*«Аяк-кулын бәйләп куйган*
*язмышының чылбырларын өзеп,*
*читкә атты микән?*
*Морҗасыннан нинди кара төтен чыга,*
*Әллә соң ул кайгыларын якты микән?»* - дигән шигырен тыңлау, мөгаен, иң битараф җаннарны да сискәндерер.

Гакыйль абыйның шигырьләрен тыңлагач, дөньяда кылган эшләребез, гамәлләребез турында тагын бер кат уйлап куябыз. Без кешеләргә, бигрәк тә зәгыйфьләргә, ятимнәргә, ярлыларга карата игътибарлымы?

Бәлки бу ыгы-зыгылы заманда кайберләребезгә нәкъ менә шул сыйфат җитмәгәнгә күрә, ата-аналары исән килеш сабыйлары балалар йортындадыр да. Күз карасыдай кадерләп үстергән йөрәк җимешләре җир җимертеп дөнья көткәндә, аларның

ата-аналары картлар йортында гомер сәгатьләрен саныйлар. Гакыйль абыйның «Тәкъдир» шигырен тыңлау уйландырырлык. Кешегә яшәү өчен якты кояш, сулар һава, эчәр су гына түгел, ә якыннарының игътибары, исән чакта кадерләре дә кирәк шул.

Очрашуда Гакыйль абый үзенең балачагының, тормыш юлының яңа сәхифәләрен ачып, аны юмор аша сөйләвен бөтен зал тын алмый тыңлады. Бу сөйләгәннәре аның тормышы, иҗаты белән яхшы таныш булганнар өчен дә яңалык булды.

Шагыйрь белән бергә очрашуга Димитровград шәһәреннән килгән һәм аның җырларын башкарган укытучы, җыр-моң чишмәсе Фәния Хәлиуллованың чыгышы да нур өстенә нур булды. Бөтен зал аның тәэсирле моңында тирбәлде. Талантлы, нечкә зәвыклы шагыйрь янында талантлылар гына була ала шул.

Фәния ханым башкарган җырларның күбесенә көйне Гакыйль абыйның энесе Наилнең уртанчы улы Ринат язган икән. Бүгенге очрашуга абыйларын безгә алып килгән Ринат белән Маратка да безнең күңелләрдә рәхмәт хисе чиксез иде. Ә абыйсының җырларына көй язуын ишеткәч, Ринатка хөрмәтебез тагын да артты. Җыр-моңга бай, нечкә күңелле, миһербанлы, туган җанлы егетләр бар икән әле бездә. Гакыйль абыйларының һәр теләген, күз карашыннан ук аңлап, аны канәгатьләндерергә әзер торган бу егетләр бик изге гамәл үтиләр. Әйе, без, адәм балалары, яратылышыбыз белән бертөрле булсак та, килеш-килбәтебез, холык-фигыльләребездән тыш, тагын күп сыйфатлар аерып тора безне. Шуларның иң әһәмиятлесе - кешеләргә кылган изге гамәлләребездер, мөгаен.

Өч сәгатькә якын барган очрашу бер мизгел кебек үтте дә китте. Гакыйль абыйны ялыктырганбыз инде дип борчылсак, әле ул тагын да укучыларыбызның үзләре язган шигырьләрен тыңларга теләге барлыгын белдерде. Мәктәбебезнең каләм тибрәтүче егет-кызлары чын шагыйрь алдында бик теләп шигырьләрен укыдылар.

*Шундый сизгер күңел биргәнсең,*
*Һәркайсының хәлен аңлый беләм,*
*Һәркайсының җанын саклый беләм,*
*Шул яшәтә мине, күрәсең,* - дигән шигъри юллар Гакыйль абыйның рухына туры килә. Беркемгә дә ярарга тырышмый, җаны кушканча яши бирә ул.

Шагыйрь үзе дә, укучылар һәм укытучылар да, Гакыйль абый белән очрашу буласын белеп килгән авылдашлар да тиз генә аерылыша алмадылар. Алып килгән бүләк-күчтәнәчләрен

тапшыргач, сөйләшү, нәкъ татар халкындагы кунакчыл гадәт буенча, чәй табыны янында дәвам итте. Гакыйль абый үзе дә буш кул белән килмәгән. «Йөрәк сере» җыентыгын очрашуга килүчеләр бик тиз алып бетерделәр. Кайберәүләргә җитми дә калды.

*«Әгәр дә адәм баласы бу дөньяда башка бер кешегә үзенең кирәклеген белмәсә, яшәүнең мәгънәсе булмас иде».* Бу сүзләр - карандашны авызына кабып, тешләре белән кысып язган шигырьләрен - күңел җимешләрен безгә бүләк иткән Гакыйль абый сүзләре. *«Кеше көчле булырга тиеш, Кеше батыр булырга тиеш! Халкыбызның асыл улы Гакыйль Сәгыйров кебек!»* - дигән иде үзенең бер шигырендә күренекле шагыйрь Роберт Миңнуллин. Тормышның терәге - көчле кешеләр. Мәйданнарда бил алышырдай көч-куәт юк аларда, әмма алардагы ихтыяр көче, башкаларны әйдәп, яшәргә көч бирә, сынган күңелләргә канат куя.

Нурлы Нурлат якларына, туган авылыбыз Югары Нурлатка чакырулы кунак булып килде Гакыйль абый, җаныбызга якты, җылы нур салып китте. Тик бу очрашу соңгысы гына булмасын иде. Гөлия һәм Лилия башкарган «Куллар биреп саубуллашмыйк» җыры шагыйрь күңелендә шушы теләгебез булып калсын иде.

**Нәфисә ТӨХВӘТУЛЛИНА,**
**Югары Нурлат урта**
**мәктәбенең татар теле һәм**
**әдәбияты укытучысы.**
Нурлат районы,
Татарстан.

(“Бердәмлек”, № 20, 15 май, 2007 ел).

# Халкыбызның асыл улы

2007 елның 4 апреле безнең күңелләрдә гомергә уелып калыр, мөгаен. Ник дигәндә, әлегә кадәр китаплары аша гына элемтә тоткан булсак, бүген зур аудиториядә шагыйрь-рәссамның үзе белән очрашу бәхетенә ирештек.

Озак - ике елдан артык әзерләндек без әлеге очрашу-кичәгә. Гакыйль абый турында шактый гына материал җыйдык, аны якыннан күреп белгән кешеләрдән кыйммәтле мәгълүматлар тупладык, шигырьләрен, җырларын өйрәндек.

Һәм менә көтеп алган көн килеп тә җитте. Чәршәмбе иртәсе. Кәрәзле телефон аша Гакыйль абыйның энесенең уртанчы улы Ринат абый белән элемтәгә керәбез. Юлга чыкканнар. Хәерле сәгатьтә!

Ике сәгать ярым дигәндә, аларның «Ока» машинасы безнең мәктәп ишек алдында иде инде. Без шагыйрьне, аның белән килгән кунакларны җылы итеп каршы алдык. Ринат абый белән Марат абый Гакыйль Сәгыйровны коляскасына утырттылар. Менә ул актлар залы аша коридор буйлап безнең кабинетка килде. Без, укучылар, аны басып сәламләдек.

Аннары кунакларга татарга хас кунакчыллык белән токмачлы аш, чәй тәкъдим иттек. Нур өстенә нур булып, Гакыйль абый янына Казаннан аның чордаш дусты, үзен һәм иҗатын беренче тапкыр дөньяга чыгаручы танылган журналист һәм язучы Рәшит Карип улы Зәкиев килеп керде. Ике дус рәхәтләнеп сөйләштеләр.

Актлар залы. Бүген ул укучылар, укытучылар, әти-әниләр, чакырылган кунаклар белән шыгрым тулы иде. Менә Гакыйль абыйны сәхнәгә күтәреп менгерделәр. Залдагы һәммә кеше, аягүрә басып, көчле алкышлар белән аңа булган ихтирамын белдерде.

Кичә башланып китте. Алып баручы - минем әнием Гөлнирә Наил кызы Садретдинова, Гакыйль абый турында горурланып һәм яратып сөйләде. Укытучыбыз Фирдәүсә апа безнең класс укучысы Илүзә Кәлимуллинаның әнисе Земфира апа бүләккә әзерләгән түбәтәйне Гакыйль абыйның башына кидерде. Зәңгәр күзле шагыйребез бу мизгелләрдә бизәкләп эшләнгән яшел хәтфә түбәтәйдән безнең алда сәхнәбез күрке булып утыра иде. Ә аның янәшәсендә - Мәләкәстәге татар мәктәбенең музыка укытучысы, “Карлыгач” ансамбле җитәкчесе Фәния апа Хәлиуллова.




**Илүсә КӘЛИМУЛЛИНА белән Фаил САДРЕТДИНОВ Гакыйль СӘГЫЙРОВка үзләре язган шигырьләрен укыганда.**

Менә сәхнәгә бер-бер артлы укучылар күтәрелә башлады. Алар, шагыйрьнең күзләренә карап, чын күңелдән хисләнеп, алдан өйрәнгән шигырьләрен яттан сөйләделәр. Илүсә белән мин дә сәхнәгә мендек һәм, яшь иҗатчылар буларак, үзебезнең шигырьләребезне сөйләп күрсәттек.

Кичәнең иң дулкынландыргыч минутлары — ул “Назла, әнием!..” җырының премьерасы булгандыр, минемчә. Гакыйль Сәгыйров шигыренә безнең музыка укытучыбыз Наталья Абутьева язган бу җырны автор үзе һәм математика укытучысы Наилә Хәйбуллина ике тавышка башкардылар. Шунысын да әйтим: фонограмманы да Наталья Александровна үзе язган иде. Җырны башкарганда бөтен тамашачы диярлек күз яшьләренә тыгылды. Гакыйль абыйның да күңеле нечкәреп китте ахыры. Ул күпмедер вакыт залдан чыгып торды һәм бераздан гына кире сәхнәдә үз урынын алды.

Шагыйрь турында күп нәрсә белдек без ул көнне. Зур экраннан аның хакында төшерелгән фильм да күрсәтелде. Чыннан да, «Таш астыннан үсеп чыккан ак чәчәк” бит ул безнең Гакыйль абыебыз!

Менә сүз шагыйрьнең үзенә бирелде. 70 яшенә якынлашып килүче аксакалның һәр сүзен без йотлыгып тыңладык. Хәер, кичә барганда залда чебен очкан тавыш та ишетелмәгәндер. Ул үзе турында күп сөйләде, телендә тормыш мәгънәсе,

яшәеш, яшәү мәне иде. Аның белән килгән җырчы Фәния апа шагыйрьнең сүзләренә язылган җырларны башкарды. Берсенең көен Ринат Сәгыйров язган иде.

Кичә ахырында Рәшит Зәкиев сүз алып: "*Гакыйль Сәгыйров әдәбиятта бер сенсация булып тора*", - диде һәм һәр әйтелгән сүзләрнең кадере, шагыйрьнең нинди шартларда иҗат итүе турында җентекләп сөйләп бирде.

Кичә тәмамлангач та Гакыйль абыйның якташларыннан тиз генә аерыласы килмәде әле. Очрашу безнең класста - сый-нигъмәттән сыгылып торган өстәлләр артында - әңгәмә рәвешендә, бүгенге көндә "Чаян" журналының баш редакторы булып эшләүче Рәшит Зәкиев, Нурлат районының "Дуслык" газетасы баш редакторы Сәкинә Хәйруллина һәм мәктәбебезнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында дәвам итте. Без, укучылар да, тере шагыйрь-легенданың үзе янына басып, карточкага төшү бәхетенә ирештек.

Минем "Язмышына буйсынмас җан" дип аталган фәнни-тикшеренү эшемне Гакыйль абый да ошаткан икән, класста ясалган күргәзмә-стендлардан да канәгать калган.

Әлеге очрашудан мин үземә бик күп нәрсә алдым. Шагыйрь Роберт Миңнуллин сүзләре белән: "*Кеше көчле булырга тиеш! Кеше батыр булырга тиеш! Халкыбызның асыл улы Гакыйль Сәгыйров кебек!*" - дип тагын бер кат кабатлыйсым килә. Чыннан да:

"*Һәр шигырем - уйларымның чыны*
*Тормыш көзгесенең кыйпылчыгы*", - дип яза бит ул үзе дә үзенең иҗат җимешләре турында һәм шушы сүзләре белән безне дә көчле, ихтыярлы, рухи яктан бай булырга чакыра.

Дөрестән дә, тормыш бит ул - шундый матур нәрсә. Нәкъ әнә шул матурлыкка таба бүген тагын бер зур адым ясалды. Аны без Гакыйль Сәгыйров белән бергәләп ясадык.

**Фаил САДРЕТДИНОВ,**
**Татарстанның Нурлат шәһәрендәге**
**1 санлы урта мәктәп укучысы.**

# Илле елдан соң кабат очрашу

«Бердәмлек» газетасы редакциясендә дустыбыз, киңәшчебез, фикердәшчебез, күренекле татар шагыйре һәм рәссам, каһарман якташыбыз Гакыйль Сәгыйров булып китте. Ул безне, “бердәмлек”леләрне, чын күңелдән газетабызның туган көне - 17 яшь тулу уңаеннан котлап, эшебездә иҗади уңышлар теләде. Без дә аның бүгенге тормышы, иҗаты, уй-фикерләре, киләчәккә планнары белән кызыксындык. Шагыйрь гадәттәгечә «Бердәмлек»кә үзенең күп яңа шигырьләрен дә алып килгән иде.

Киләсе елның февралендә үзенең 70 яшен тутырачак күренекле шагыйрь соңгы вакытларда сәламәтлеге бераз какшабрак торганга, көн дә элеккечә иҗат белән шөгыльләнә алмаса да, кайчак та яңа шигъри юллар үзеннән-үзе туып кына торалар икән, ак кәгазьгә төшереп кенә өлгер.

Ике ел элек сөекле әнисе Хәбибҗамал апаның вафатыннан соң, аның булышчылары булып Наил энесенең ике улы Ринат белән Марат калганнар. Ә яшьләрнең шигырьләрне язып алырга вакытлары җитешеп бетми шул. Шуңа да кайбер шигъри юллар




**Нурлат шәһәренең 1 санлы урта мәктәбендә очрашу вакытында. Гөлнирә САДРЕТДИНОВА һәм Фәния ХӘЛИУЛЛОВА** (сулдан уңга).



**Рәшит ЗӘКИЕВ һәм Гакыйль СӘГЫЙРОВ. Илле елдан соң очрашу.**

язылмыйча кала баралар. Шулай да Гакыйль күңелсезлеккә бирешергә тырышмый. Еш кына туган якларына - Нурлатка, Иске Җүрәйгә барып, анда мәктәпләрдә булып, укучылар белән очрашуларда катнаша. Менә ул безгә Нурлат шәһәренең 1 санлы мәктәбендә шундый очрашуларның берсеннән фотосурәтләр алып килгән иде. Анда шушы очрашу мизгелләре тасвирланган. Бусында мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлнирә ханым Садретдинова шагыйрьнең яңа гына Казанда дөнья күргән «Йөрәк сере» китабыннан өр-яңа шигырьләре белән укучыларны таныштыра. Ә менә монысында Гакыйль Сәгыйров Димитровград «сандугачы» Фәния Хәлиуллова каршында утыра. Җырчының репертуарында талантлы шагыйрьнең шигырьләренә язылган күпсанлы җырлар бар. Ул аларның күбесен очрашу вакытында Нурлат мәктәбендә укучыларны да таныштырды.

Ә менә бу рәсем Гакыйль Сәгыйров өчен аеруча кадерле. Ул анда Казаннан очрашуга махсус чакырылган танылган татар язучысы һәм журналисты, бүгенге көндә «Чаян» журналында баш мөхәррир булып эшләүче Рәшит Зәкиев һәм «Дуслык» дип аталган Нурлат район һәм шәһәр газетасы мөхәррире Гөлсинә Хәйруллина белән бергә төшерелгән.

Рәшит Зәкиев - Гакыйль Сәгыйровны шагыйрь буларак

беренчеләрдән күргән, таныткан, тапкан кешеләрнең берсе. «Дуслык»та, тора-бара Татарстан Республикасының «Социалистик Татарстан» газетасында хәбәрче булып эшләгәндә ул Гакыйль янына Иске Җүрәйгә барып, аның шигырьләрен газета битләрендә бастырып чыгарып, укучыларына ирештерә. Бераздан Рәшит Зәкиев бу сәләтле егетнең язмышы турында республика газетасында үзенең күләмле очеркын да урнаштыра. Шуннан соң фаҗигале язмышка дучар ителгән яшь шагыйрьнең һәм рәссамның иҗаты белән китап укучылар да, Татарстан язучылары да ныграк кызыксына башлыйлар. Бер-бер артлы Иске Җүрәйдә Гакыйль янында күренекле язучылар, шагыйрьләр Атилла Расих, Гөлшат Зәйнашева, Роберт Әхмәтҗанов, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеевлар булып, фаҗигале язмышлы талант иясенең шигырьләрен һәм рәсемнәрен үзләре белән Казанга алып китеп, көндәлек матбугатта, журналларда бастырып, дөньяга тараталар.

Менә, ниһаять, илле елдан соң Гакыйль Сәгыйровның «иҗат чишмәсен» беренчеләрдән булып ачкан эчкерсез шәхес Рәшит Зәкиев белән яңадан очрашу булды. Әлбәттә, бу мизгелләрне сөйләп тә, аңлатып та бетерерлек түгел. Моның өчен аларны үз күзләрең белән күрергә кирәктер.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 21, 22 май, 2007 ел).

# Җүрәйләрдә йөреп гыйбрәт ал

**Кошки районындагы Иске Җүрәй (Иске Фәйзулла) - Самара өлкәсендә генә түгел, бөтен татар төбәгендә иң борынгы авылларның берсе. Степан Разин явы кузгалган елларда ук телгә кергән авыл ул.**

## Авылның алтын баганасы

Соңгы дәвердә атаклы шагыйрь, рәссам Гакыйль Сәгыйровның туган-үскән бишеге буларак та танылды Иске Җүрәй. Хаста түшәгендә бер хәрәкәтсез яткан килеш, тешләренә карандаш кабып иҗат итүче, искиткеч нык ихтыярлы бу кешене ишетмәгән, белмәгән берәр татар баласы калдымы икән хәзер?! Николай Островскийлар, Фәнис Яруллиннардай могҗизалы каләмгә ия булган көчле рухлы бу шәхесне тагын бер мәртәбә күреп сөйләшү нияте белән дә килдем бирегә. Димитровград шәһәрендәге фатирында кыш чыкканнан соң язын беренче тургайлар белән ашкынып-сагынып Иске Җүрәенә кайта торган гадәте бар аның. Гомерлек юлдашы - газиз энисе Хәбибҗамал әби белән, әлбәттә. Юк икән, насыйп булмаган икән бу юлы авылда күрешергә, бәләкәй өйнең ишеге биктә.

- *Кайталмады шул әле Гакыйлебез,* — дип уфтана кардәше Наҗия түти. — *Энисе дә үлеп киткәч... Апрельдә елы була бит Хәбибҗамал апабызның. Озакламый кайтыр Гакыйль, Алла теләсә. Йортын карап торабыз... Сыңар кадагына да тигәннәре юк аның.*

Аннары, мине тәмам үз итеп өлгергәнгәме, бик «яшерен» серләрен дә чишеп салды:

- *Музей итәргә йөри бит әле халык аның ызбасын. Сәгыйров музее ясарга. Нигә, үзе рөхсәт бирсә, күркәм эш булыр иде кана.*

Шагыйрьнең өе, үзе авылда яшәгәндә, клубтан ким түгел иде, диләр. Юк, клуб кына түгел, яктылык, сафлык үзәге булган ул. Техника җене кагылган, шахмат-шашка уйнарга маһир, китап укырга яраткан яшүсмер, егет-җилән җыела аның янына.

Ятагына кадаклангандай сеңгән, аяк-куллары бөтенләй хәрәкәтсез кешенең радиоалгыч, автомобиль ише нәрсәләрне төзәтеп, «җан өргәнен» күргәнегез бармы? Минем бар. Менә ипләп кенә китереп куялар да алдына тиешле схема-сурәтне, шулар-

га карап табып бирә, күрсәтә әйбернең ватык җирен Гакыйль абзагыз. Тәүге тапкыр очрашканда, анда-санда таралып, өелеп яткан транзистор-радио детальләрен күреп, үзем дә сәерсенгән идем. Шул хәлдә күрше-тирәнең күпме техникасын, аппаратын көйләгән, рәткә керткән ул.

Әдип кешенең шәкертләре дә булырга тиештер инде.

Күршесендәге сыер савучы пенсионер Оркыя апа Камалетдинова әнә, Тукай әйтмешли, авылда «аз гына бернәрсә «шылт» иттеме, шул турында бәет чыгарырга остарып беткән. Ә менә хәзер яшьрәкләр арасында каләм тибрәтүчеләр күренәме икән?

Бу соравым кыен хәлдә калдырды ахры. «Карале, ахирәт, синең кыз шигырь чыгара иде түгелме соң? Хәзер туктадымыни?», «Фәләннең малае языштыргалый. Тик менә урысча гына маташтыра шул», - диештеләр, уңайсызланып кына. Ни хәл итәсең, Оркыя апалары төсле ана телендә укулар тәтемәде шул бүгенге буынга. Авыл мәктәбендә белем алу урысча гына бара.

## Җырлап-биеп кенә эш бетми

Тулы булмаган урта мәктәпнең ике катлы таш бинасы әллә кайдан күренеп тора. Шул тарафка ашыгып барыш иде, татарча җыр аһәңнәре ишетеп, туктап калдым. Янәшәдәге агач йорттан килә җанга якын, ягымлы музыка. Ике-өч ел элек кенә шыгырдап торган нараттан салынган клублары шушы икән. Иркен, җайлы фойе, зур гына залы. Газета-журналлар куелган, өстәл уеннары белән шөгыльләнә торган почмакта төрле төстәге, эреле-ваклы гөл чүлмәкләре күзгә ташланды. Күзләрне иркәләп, матур гына чәчәк атып утыралар. Мөдир Дамир Шәрипов тырышлыгы, диделәр.

Ә моң һаман күңелләрне иркәли. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлсинә Әбделганиева өлкән сыйныф укучылары белән тиздән Самарада өлкә «Туган тел» җәмгыяте үткәрәсе татар фестиваленә әзерләнә икән. Дулкынланудан янып торган күзләренә, шат балкыган йөзләренә караганда, рәхәтләнеп шөгыльләнүләре хак. Халык көйләрен дә әйбәт беләләр. Гакыйль абыйларының сүзләренә язылган «Җүрәем», «Этием» җырларын да шәп сиптерәләр. Мәктәп үзешчән сәнгать коллективының туган телне, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерүдәге уңышлары өчен бәйгеләрдән ел саен рәхмәт хатлары, мактау кәгазьләре белән кайтуы тикмәгә түгелдер.

Әле генә репетициядә татарча иттереп җырлаган бала-чага, ул да түгел, шау-гөр килеп, урысча гына сөйләшә-сөйләшә кайтып китте. Нишлисең, җырлап-биеп кенә туган телне саклап калып булмый икән шул.

## Ни ылтара, ни пылтара

Мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укыту торышы белән кызыксынырга өлгермәдем, башлангыч сыйныфлар укытучысы Фәния Әбделганиева авызны тиз япты:

— *Бер дә мактанырлыгыбыз юк. Мөселман балалары барлыгын искәртер дәрәҗәдә генә дәрес бүленгән ана телебезгә. Болай да атнасына 4 сәгатьтән артмый иде аны фән буларак укыту, инде мәктәпләрне дә кушкач, ул 0,5 шәр сәгатькә (!) генә кала. Ни ылтара, ни пылтара инде бу! Моның белән нарасыйларга ничек юньле-башлы белем бирмәк кирәк.*

Дөрестән дә, бик хаклы тәҗрибәле педагог. Әле болары гына җитмәгән, зур афәт алдында тора 30лап укучыны, 8 педагогны берләштергән коллектив. Гомуми белем бирү учреждениеләренә реструктуризация дигән зәхмәт яный икән. Шул бездәге оптимальләштерү сыман инде. Биредә нәниләрне генә калдырып, өлкән сыйныфларны җиде-сигез чакрымда урнашкан Яңа Кармала дигән авыл мәктәбенә күчерәләр. Төньяк-көнбатыш округының мәгариф бүлегендә бернинди дә авырлыгы юк моның, автобусы бар, фәлән-фәсмәтән, дип тынычландырырга маташалар да бит. Теге чуаш авылында да татар дәресләре керәчәк, имеш.

- *Күзгә төтен җибәрәләр!* — ди, кырт кисеп, мәктәп директоры Валентина Яковлевна. — *Кармаладагы коллегам: «Көтмәгез дә, нитмәгез дә, татар теле дәресләре булмаячак», -дип алдан кисәтеп куйды инде.*

Ә мондагылар исә кыскарту мәрәкәсенә үзенчә карыша, көрәшә. *«Бу төбәктәге бердәнбер татар авылы мәктәбен саклыйк, зинһар, киләсе уку елына балаларның артуы да күзәтелә»,* - дип югарыга хат та юллаганнар. Кыскарту шаукымы Кошки районындагы тагын бер татар авылы - Яңа Җүрәйне дә читләтеп үтми.

...Сабакка чакырып кыңгырау чыңлаттылар. Тавышы шәп яңгырый үзенең. Инде хәзер ул да тынып калса? Милләткә куркыныч яный дип алагаем селтәнеп чаң кагар вакыт җитте түгелме?

## «Бәетен чыгарасы гына кала»

Туган якны өйрәнү музеенда андый тарихи истәлекләр бихисап. Бай эчтәлекле елъязма белән математика укытучысы Рөстәм Әбделганиев таныштырды. Борынгы документларны нинди сакчыл кадер белән кулларына алуыннан ук татар җанлы кеше булуын чамаларга мөмкин. Гакыйль Сәгыйровның туганнан туган энесе икән әле үзе.

XVII гасыр азагында Сембер төбәгендәге Татар Колмаеры авылыннан килеп төпләнгәннәр бирегә. Иң әүвәл Фәйзулла бай күчеп утырган. Авылның исеме дә шуннан. Халкы шактый ук үрчи төшкәч, 1880 елда бер өлеше Яңа Җүрәйгә аерылып чыккан. Менә бит нинди экәмәт: XX йөз башында 1200 кеше яшәгән авылда бүген аларның саны 350гә дә тулмый. Аның да күбесе - пенсионер, карт-коры. Эшкә сәләтлеләре 57 дән артмый.

— *Авыл бетеп бара, олан* - дип турыдан ярып салды элекке механизатор 80 яшьлек Хәбибулла бабай. - *Менә минем күршедә генә 6-7 йорт буш тора. Яшьләр читкә китеп бетте. Техника бар, йөртүчесе юк.*

Бүтәннәр дә, көрсенеп, аның сүзен җөпли. Хуҗалык мең төрлегә үзгәрә торгач, «Рабочий» дигән авыл хуҗалыгы кооперативына әйләнгән бүген. Эшчәнлеген иң элек терлектуарны сугымга алу белән башлаган яңа хуҗалык. Мәшәкате муеннан, асрар кеше юк, янәсе. Игенчелек белән генә шөгыльләнергә исәпләре. Һәр ихата саен ике-өч сыер асрыйлар югыйсә. Уңган халык, тик тормый. Эшмәкәрлеккә генә кызыгучы юк икән: нибары бер шәхси кибет очрады. Итен-сөтен читтән килүче шома эшкуарларга очсызга сатып җибәрәләр. Киләчәккә ышаныч сүрелгән сыман авылда. Ниндидер битарафлык хөкем сөрә димме...

- *Оркыя апага әйтеп, бәетен чыгарасы гына калды инде авылыбызның*, - дип моңсу гына шаяртуларын ишетүе бер дә күңелле түгел шул.

**Илдус ДИНДАРОВ.**

(“Бердәмлек”, № 29, 12 июль, 2005 ел).

# Тегермәнле авыл егете

**Безнең Бикколдан район үзәге Нурлат шәһәренә барышлый алты-җиде чакрымнан соң Әхмәт исемле авыл очрый. Хәзер генә ул машиналар шома асфальт юлдан аның аркылы җилдереп кенә уза: кечкенә авыл күзгә-башка чалынырга өлгерми дә кала. Ә без үскәндә ымсындырып торган район тарафына күбесенчә җәяү йөреш иде. Сабантуй дип, тагын ниндидер бәйрәм, базар-мазар дип, байтак еллар тәпиләргә туры килде әле бу егерме чакрым араны.**

Бүгенгедәй хәтеремдә, күчтәнәч-төенчекләр күтәреп, олау-олау кызык сәфәр тәэссораты «төягән» килеш шау-гөр килеп авылыбызга кайтканда шактый арыла да, телләр кибеп аңкауга ябыша башлый. Өмет-ышаныч белән, тилмереп гел Әхмәт ягына карый-карый атлаган көнебез... Бер мәлне офыктагы үр башында сихерләп торган җил тегермәне караеп күренүгә, күңелләр күтәрелеп китә дә көч-дәрман арта, ару-талчыгулар онытылган төсле була иде. Тирмән исә (безнең якта тегермәнне шулай атыйлар) канатларын салмак кына изәп, һаман үзенә чакыра, дәшә. Кайсы яктан юлга кузгалсаң да, ерактан ук иң әүвәле ул шәйләнә, иң элек ул сәламли. Юлчы өчен үзенә күрә маяк хезмәтен үтәгән биек корылма. Әхмәт кешеләренең горурлыгы, даны-җаны иде ул. Тегермән борынгыдан муллык, иминлек, бәрәкәт билгесе ич халыкта. Аннары авылда уңган оста-куллар яшәвенә дә ишарә. Заманында Кама аръягында җил көче белән он тарттыручы бердәнбер тегермән булган, диләр аны. Серле табигать манзарасы рәвешендә, тирә-юньне ямьләп утырган атаклы тирмән күңелләрдә иң якты хисләр генә уята.

...«Тегермәнле авыл» итенгәләп тел чарлавымның хикмәте бар: ваемсыз балачагым белән бер чорда күрше авылда гына булачак күренекле шагыйрь һәм рәссам яшәгән икән бит! Бүген инде Сәгыйров авылы буларак танылды Әхмәт, һәм бу миңа үсә төшкәч кенә билгеле булды. Хәер, кем белде икән дә кем чамалады икән ул вакытта Гакыйль атлы гади генә малайның шундый зур шәхескә, олы талант иясенә әвереләсен. Унике-унөч яшенә хәтле бүтән бала-чагадан һичнинди артык җире булмаган юкса үзенең. Биккол авылындагы җидееллык мәктәпкә сабакка килеп йөргән. Юк, холкы-фигыле белән барыбер шул чакта ук бүтән «ташбаш»лардан ничектер аерылыбрак торган ул. Аны укыткан мәрхүм әниемнең: «Тырыш, зиһенле бала иде. Кая ул

стена гәҗитен, плакат-лозунгны аңардан да остарак бизәүче! Такмак-шигырьләрне дә бик тиз чыгара торган иде», - дип сокланып сөйләгәне хәтердә.

Гакыйль абыйның авызына каләм алып рәсем ясау сәләтенә һич кенә дә тыныч, битараф карый алмыйм, мәсәлән, мин үзем. Башка да сыйдыру мөмкин түгел сыман бит моны бер уйлаганда! Искиткеч, гайре гадәти хәл ич ул сау-сәламәт адәмнәр кул белән дә башкара алмаган мондый илаһилыкка ирешү! Могҗиза! Кулына төсле буяулар, пумала тотып мольберт алдында эшләү бәхетенә дә ирешкән булса... Классик язучыбыз, Тукай бүләге лауреаты Илдар ага Юзеевның «Гакыйль шигырьдә - рәссам, рәсемдә - шагыйрь» дигән бәһасе искә төшә. Шуннан да тулы, төгәл, җиренә җиткереп әйтеп булмастыр. Ярый ла, Илдар ага кебек игелекле җаннар җырлы-моңлы шигъриятен вакытында күреп алып, китапларын азмы-күпме бастырып чыгаруда хәерһаклык күрсәткәннәр.

Ә менә рәсем сәнгате киң катлау тамашачылар күзеннән читтә кала килә әлегә. Әледән-әле шәхси күргәзмәләрен оештыру фарыз да бит... Аның кебек каләмен -карандашын теш арасына кыстырып, шулкадәрле тәэсирле күренешләр, асыл сыннар иҗат итүче кем бар икән тагы бу якты дөньяда?! Профессиональ рәссам дәрәҗәсендә эшли ул, дип саный белгечләр. Башка халыкларда андый уникаль, сирәк талант иясе булсамы? Кадерен белмибез, игътибар җитми, мәнсезлек, гамьсезлек баштан ашкан. Бөтен гомерен Татарстаннан читтә үткәрүе дә әдәбият, сәнгать әһелләре белән аралашып, киңәшләшеп эшләү җәһәтеннән уңайга түгел, әлбәттә. Нишлисең бит, тәкъдирендә шулай язылгач... Башта озак еллар әнисе Хәбибҗамал апаның туган җирендә - Самара өлкәсенең Иске Җүрәй авылында яшәде. Хәзер исә - Ульян өлкәсенең Димитровград шәһәрендә энесе гаиләсендә.

Туган җире, туган авылы белән дә аралары өзелгәне юк, шөкер. Ифрат җирсеп, сагынып язуы да хак мөкатдәс, газиз, изге нәрсәләр турында. Рәсемнәрен карый башлагач, таныш йөзләргә, җанга якын урман-суга, йорт-җиргә юлыгам да: «Гакыйль абый, болар Әхмәт авылыннан түгелме?» - дип сорамыйча түзә алмыйм. Автор дәшми, хәйләкәр генә көлемсерәп куя. Шул инде шул, безнең күрше авыл күренешләре! Шунысы да миңа яхшы мәгълүм: күбесен хәтеренә төшереп кенә ясамый, язмый. Яткызырсың аны түшәктә генә көннәр әйбәт торганда. Президентыбыз бүләк иткән «Ока»сын иярли дә килеп җитә

безнең якларга! «Әйдәле, - ди ул, ике сөйләп тормаслык итеп, — бераз җилләнеп, кырларны әйләнеп кайтыйк, авылларга да кереп чыгарбыз!» Әхмәт авылы калмый, Зиреклесе, Кизләве, Бикколы. Самараның Кошки районындагы татар авылларын да гизеп чыккан бар тынгысыз мосафир белән. Үзе тирә-ягын тамаша кылыр, үзе тегесен-монысын сораштырыр. Аннан соң мине шунысы сокландыра: гел хаста-фәләнгә салынып, мескенләнүнең әсәре дә юк аңарда. Үз дәрәҗәсен, үз кадерен яхшы белә диюем. Тәҗел йомышын, гозерен боргаламый-сыргаламый гына төгәл, ачык итеп әйтер. Энесе, туганнары белән мөнәсәбәте җылы, эчкерсез. Әмма кирәк чакта үз сүзен катгый төстә, нык итеп әйтә, хата-ялгышларны төзәттермичә тынычланмый. Кыскасы, зур гаиләнең тулы хокуклы әгъзасы. Шул хәлендә дә кырыкмаса-кырык төрле йорт мәшәкатьләрен кайгыртып ята. Хуҗалыкка матди өлешен кертергә тырышуын гына күр син аның. Ә инде халкыбыз, милләтебез язмышы бәгырен тагын да катырак борчый, сызландыра булыр. Анысын әсәрләреннән укып иланабыз. Җиһанга оптимистик караш, яшәүгә омтылыш мөлдерәп тулган аларда. Каһарманнар ихтыяры, Алыплар олпатлыгы, Титаннар сабырлыгы бар минем күрше авылы егетендә!

**Илдус ДИНДАРОВ.**

*("Ватаным Татарстан" газетасы)*

# “Мин үземне бүген бәхетле кеше дип саныйм”



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ - бәйрәм сәхнәсендә.**

Без Мәләкәскә (Димитровградка) каһарман якташыбыз, күренекле татар шагыйре, рәссам Гакыйль Сәгыйровның 70 яшьлек юбилее уңаеннан үткәреләчәк тантаналы кичәгә Самарадан дүртәү - мин, «Бердәмлек» газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин, хатыным Фатыйма ханым (без Сәгыйровлар гаиләсе белән үзара күптән бәйләнештә торабыз инде), «Азан» газетасы редакторы Шамил Галимов һәм Самараның атаклы эшкуары, төбәгебезнең мәшһүр татары Вазыйх Мөхәммәтшин җитәкләгән, күпләребезгә яхшы таныш «Прогресс» төзү-ремонт фирмасы вәкиле Раушания Ситдыйкова (ул да «Бердәмлек»тә шактый еллар журналист булып эшләп киткән иде) бардык.

Самара өлкә татар җәмәгатьчелегенә юбилей кичәсендә катнашырга оештыручылардан чакыру алынгач, Вазыйх әфәнде эшкуарларыбыздан һәм милли оешмалар җитәкчеләреннән ярдәм кулын сузарга әзерлеген белдергән бердәнбер кеше булгандыр, мөгаен. Безгә Мәләкәскә юбилей тантанасына барырга берсүзсез автомашинасын да, җәлләмичә мул бүләген дә бирде ул. Мондый мәрхәмәтле, изге бәндәгә рәхмәттән башка нәрсә әйтәсең инде. Милли проблемаларыбызны төптән аңлаучы шундый җитәкчеләребез күбрәк булсыннар иде дә бит. Хәер, болар барсы да сүз уңаеннан гына әйтелделәр.

Бу турыда укыгач, бәлки башкаларда да шәфкатьлелек чаткысы кабыныр, бәлки талантлы якташыбыз янына барып хәлен белүчеләр саны артыр, ярдәм кулын сузучылар табылыр, дигән өметебез дә юк түгел.

Сәгыйровлар гаиләсенең элеккеге фатирларын яңа аерым зур йортка алмаштыруларына ике еллар вакыт үтеп киткән инде. Искесендә еш кына булгаласам да, яңа урыннарында булырга туры килмәгән иде әле. Форсаттан файдаланып, аларның ничек яшәүләрен үз күзләребез белән күреп чыгарга булдык. Озак эзләп йөрмәдек, Гакыйль Сәгыйровны Мәләкәстә яхшы беләләр икән, урамын да, йортын да шактый тиз таптык.

Бүген ул биредә үзенең чиксез якыннары арасында - энесе Наил гаиләсендә көн күрә. Гомер буе газиз улын үзенең җылы сулышыннан аермаган сөекле әнисе Хәбибҗамал апаның якты дөнья белән хушлашып, җирдә зур хәрефле Ана исемен калдырып китүенә дә дүрт еллар вакыт үтеп киткән. Шулай да Гакыйль ялгыз түгел. Энесе Наил, аның тормыш иптәше Халидә ханым, аларның уллары Ринат белән Марат, киленнәре Эльвира Гакыйль абыйлары янында бөтерелеп, абый дип, һәр сүзен, һәр йомышын үтәргә әзер торалар. Кеше күңелендәге изгелек хисләрен, миһербанлыкны нәкъ менә Сәгыйровлар гаиләсе мисалында күрергә мөмкин. Кешелеклелекнең иң яхшы, иң кыйммәтле сыйфатларын үзенә туплаган гаилә бу.

Хәл-әхвәл сорашып, юбилярга бүләкләребезне тапшыргач, хуҗалар белән бергәләп кичә булачак урынга - Димитровградның «Восход» мәдәни күңел ачу үзәгенә юнәлдек. Соңгы айларда




**Шагыйрьне 70 яшьлек юбилее белән сәхнәдән Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей МОРОЗОВ тәбрикли.**

авырып торуы сәбәпле, Гакыйль абыебызның көздән бирле урамга чыкканы булмаган икән. Шәһәр урамнарындагы карның күплеген күреп, аның исе-акылы китте. Юбилей кичәсе алдыннан ничектер савыгып китүенә, үзендә ниндидер илаһи көч сизә башлавына шатланып бетә алмый иде ул.

Ә «Восход»та аны көтәләр иде инде. Ишектән керүгә ике якка рәт белән баскан, милли киемнәргә киенгән яшь кызлар һәм егетләр шагыйрьне җырлап, кулларына чәкчәк һәм чәчкә бәйләмнәре тотып каршы алдылар. Фойеда рәссамның картиналары, төрле елларда төшерелгән фотосурәтләре, кыйммәтле һәм истәлекле бүләкләре күргәзмәгә куелган. Без дә шулар яныннан тукталмыйча үтеп китә алмадык. Аның искиткеч талантлы рәсемнәрен күргән саен хисләр өермәсенә чолганасың, әйтерсең лә, сихерләнәсең. Рәсемнәрдәге күренешләр хыял белән бергә үреләләр. Рәссамның һәр рәсемен «Яшәү белән үлем чиге» дип исемләнгәне булсынмы, «Яңа юл», «Чишмә», «Кичке моң», «Хыял», «Тулган ай», «Буран», «Төнге яшен» дип аталганнары булсынмы, караган саен яңадан карыйсы килә башлый. Алар үзләре белән яңа фәлсәфә алып киләләр сыман.

Без тамаша залына үтәбез. Эш көне, җомга көн булуга да карамастан, ул халык белән шыгрым тулы иде инде. Мәләкәслеләр арасында Казаннан, Ульяннан, Нурлаттан килүчеләрне күреп, шәйләп алабыз. Юбиляр якын туганнары белән сәхнә түренә күтәрелгәндә, тантанага җыелган халык аларны аягүрә басып, көчле алкышлар, кул чабулар белән каршылый. Сәхнә рәссамның рәсемнәренең берсе сурәтләнгән, шигъри юллары язылган панно һәм 70 саны белән бизәлгән.

Юбилей кичәсен алып баручылар - Ләйсән Хәмитшина һәм Равил Шәфигуллин, күренекле татар шагыйре һәм рәссам, Гаяз Исхакый, Шәйхи Маннур, Сәхаб Урайский, Габделҗәббар Кандалый исемендәге әдәби премияләргә, рәсем сәнгатендәге казанышлары өчен Халыкара «Филантроп» премиясенә лаек булган, Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы, Самара һәм Ульян өлкәләренең «мәшһүр татары» исемен йөртүче Гакыйль Сәгыйровның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырып үткәннән соң, сәхнәгә бәйрәмгә килгән кунакларны бер-бер артлы чакыра башладылар.

Беренче булып сәхнә түренә Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей Морозов һәм аның фикердәшләре - моңа кадәр Димитровград шәһәре мэры булып эшләгән, хәзерге көндә

Ульян өлкәсенең Законнар чыгару җыелышына депутатлыкка кандидатлар итеп теркәлгән Александр Молочков һәм Анатолий Голубков күтәрелделәр. Тантанага өлкә губернаторының үзе килүе бу вакыйганың мөһимлеген күрсәтүче дәлил булып тора түгелме? Ул шагыйрьгә чиксез рәхмәт сүзләрен белдереп, аңа өлкәнең иң югары бүләген - «Ышаныч һәм яхшылык өчен» дип аталган Мактау билгесен тапшырды, шулай ук Гакыйль Сәгыйровның исеме Ульян өлкәсенең Почет тактасына кертеләчәге һәм аңа өлкәнең Мактаулы гражданины исеме биреләчәге турында да хәбәр итте.

Ә сәхнә бер генә минутка да буш тормады. Губернатор артыннан тәбрик сүзләре һәм бүләкләре белән Димитровград шәһәре Советы депутатлары да, өлкәнең күрше районнарыннан һәм авылларыннан килгән җитәкчеләр дә, татар милли-мәдәни автономияләре рәисләре һәм әгъзалары да сәхнәгә күтәрелделәр. Ульян өлкәсенең татар җәмәгатьчелеге исеменнән юбилярны өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисенең беренче урынбасары Рифкать Әхмәдуллов, автономиянең элеккеге, бүгенге көндә аның почетлы рәисе, Ульян өлкәсенең мактаулы гражданины Азат Курчаков, «Өмет» газетасының баш редакторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Исхак Хәлимов һәм җирле шагыйрә Лена Садыйкова (Иделбикә) тәбрикләделәр.

Казаннан килгән бер төркем кунаклар - Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары Рамис Сафин (ул Ульян өлкәсендә озак еллар эшләп киткән кеше) шагыйрьгә конгрессның «Татар халкы алдындагы хезмәтләре өчен» медален, ә аны караучы туганнарына - энесе Наилгә һәм аның тормыш иптәше Халидә ханымга Рәхмәт хатларын тапшырды.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев һәм язучы Лерон Хәмидуллин берлек исеменнән һәм Татарстан Республикасының премьер-министры урынбасары - мәдәният министры Зилә Вәлиеваның котлау сүзләрен җиткерделәр. Юбилярга бүләкләр дә алып килгәннәр иде алар.

Шагыйрьнең туган җире Нурлат шәһәреннән дә кунаклар - муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Фәнис Нәбиуллин, район мәгариф идарәсенең милли мәгариф буенча белгече Разия Садретдинова, «Ватаным Татарстан» газетасының Нурлаттагы үз хәбәрчесе Илдус Диндаров шагыйрьне туган көне белән

котлап, район һәм шәһәр хакимиятләре исеменнән 20 мең сум акчалата бүләк һәм чәчәк бәйләмнәре тапшырдылар.

Аннан соң сүз безгә, Самара өлкәсе делегациясенә, бирелде. Раушания Ситдыйкова «Прогресс» төзү-ремонт фирмасы җитәкчесе исеменнән Гакыйль Сәгыйровка 10 мең сум акча бирде. «Бердәмлек», «Азан» газеталары коллективлары да юбилярны бүләксез калдырмады. Самаралыларның тәбрикләве Мәләкәс тамашачысы тарафыннан бигрәк тә җылы каршыланды.

Димитровград шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе вәкилләре Равил Идрисов, Хәйдәр Галиуллов, Роза Шәймәрданова, Әнәс Гобәйдуллин, Мөнирә Жумаева, Фәрит Хәлиуллин да үзләренең тәбрикләүләрендә яраткан шагыйрьләре өчен матур сүзләр таба алдылар.

Кичәдә тәбрикләүләр шагыйрьнең шигырьләре, җирле үзешчән җырчылар башкаруында аның сүзләренә язылган моңлы җырлар белән үрелеп барды. Җырларның көйләренең күбесе шулай ук җирле үзешчән композиторлар - Гакыйльнең туганнан туган энесе Ринат Сәгыйров, Гакыйль Шәкүров һәм башкалар тарафыннан язылганнар иде. Алар үзешчән җырчылар Алия Шәрәфетдинова, Венера Нуруллина, Суфия Зәйнуллова, Фәния



**Гакыйль СӘГЫЙРОВ энесе Наил әфәнде һәм җиңгәсе Халидә ханым белән.**

Хәлиуллова, Разия Билданова, Гакыйль Шәкүров һәм башкалар башкаруында бик тә матур яңгырадылар. 25 баладан торган күп конкурсларда лауреат исемен яулаган Димитровград шәһәренең балалар сәнгать мәктәбенең «Сандугачлар» ансамбле дә Гакыйль абыйларына үзләренең моңлы җырларын бүләк иттеләр.

Ә юбиляр үзе кичә ахырында чыгыш ясаганда бик матур, бик гыйбрәтле сүзләр әйтте. *"Миңа бүген 70 яшь тулган дип әйтәсез, уйлап карасаң, әгәр мин кичергән авырлыкларны искә алсаң, бу 140 елга торырлык гомердер, мөгаен. Ә мин күңелем белән үземне бары 35тә генә кебек хис итәм"*, - дип шаяртып алырга да өлгерде.

*- Билгеле, шигырь язу - үзенә күрә бик яхшы әйбер ул. Әгәр синең язганнарың халыкка ошаса, бигрәк тә үзеңне дә кинәндерерлек итеп, барысын да әйтеп бирә алсаң. Шулай бервакыт мин Рәисә һәм Гакыйль Шәкүровларга кунакка барып (Гакыйль Шәкүров шагыйрьгә ике туган тиешле), алар да кунарга калдым. Хуҗалар кичен үз эшләре буенча клубка киткәч, без Гакыйль Шәкүровның этисе 80 яшьлек Хәсәнҗан абзый белән берүзебез калып, озак дөнья хәлләре турында сөйләшеп утырган идек.*

*Сугыш вакытында Хәсәнҗан абзый - авыр фронт юллары аша үткән, орден, медальләр белән бүләкләнгән карт ветеран, Полесье сазлыкларын саклап, сугышта йөргән вакытлары турында сөйләде. Шунда күрсәткән батырлыклары өчен Хәсәнҗан абзыйны командование өенә 10 көнлек ялга да җибәрергә дигән карар кылган булган. Тик кая инде ул сугыш барганда ял итүләр!*

*Шул Хәсәнҗан абзыйдан ишеткән истәлекләрне хәтер сандыгына җыеп куеп, җаен китереп бу турыда язармын дип уйлаган идем. Тик менә бер ел узды, ике, өч ел. Шигырьне яза гына алмыйм бит. Ә язасы килә. Кышкы озын төннәрдә үз алдыма уйланып, сөйләнеп ятам, мәйтәм, Гакыйль, син язмасаң, кем язар соң? Син белгәнне башка кем дә белми бит. Белсәләр дә син белгәнчә, кем дә язмаячак! Син үзеңчә язасың, һәм син аны язарга тиеш, -дим.*

*Һәм, бөтен авыруларымны онытып, бар көчемне туплап, тәки яздым бит бу шигырьне. Менә соңгы 2006 елда Казанда басылып чыккан «Йөрәк сере» китабында да ул урын алган. «Буран» дип атала.*

*Хәсәнҗан абзый хәзер мәрхүм инде. 86 яшендә бакыйлыкка күчте. Ә мин язган шигырь яши, аның белән сугыш ветераны*

*Хәсәнҗан абзый Шәкүров та яши, әле һаман исән кебек әле ул.*

*Тик миңа үзем язган күп шигырьләрем ошап бетми, алардан гел гаеп табып торам, тагын да яхшырак, камилләштерергә тырышып язам да яңадан үзгәртәм.*

*Атаклы татар шагыйре Илдар Юзеевның (ул беренчеләрдән булып тапкан, шагыйрь булуын ачкан кеше) бер китабында кечкенә генә шигыре бар иде.*

**Исемем дә матур минем,**
**Үзем дә атказанган.**
**Булмаса иде шигърем дә**
**Халыктан отказ алган.**

*Мин дә, атказанган исемем булмаса да, шигырьләремне халык өчен язам. Әгәр ул аларны кабул итә икән, шагыйрь өчен шуннан да зуррак шатлык бармы икән?*

Менә шулай сөйләгән иде мөхтәрәм Гакыйль Сәгыйров үзе турында һәм шигырьләре геройлары турында.

Кичәдә мин чыгыш ясаганда, шулай ук Димитровградның Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Фәнис хәзрәт Сәмигуллов шагыйрьнең мәрхүм әнисе Хәбибҗамал апаны олылап искә алганда, күпләр сәхнә өстендә канатларын җилпеп, очып йөрүче ак күбәләкне күрүләре турында әйттеләр. Моны кайберәүләр шунда ук Ана рухына китереп бәйләделәр. Бу, бәлки, чыннан да мәрхүмә Хәбибҗамал апаның рухы шулай итеп улын хөрмәтләгәннәре өчен шатлангандыр.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 9, 27 февраль, 2008 ел).

# Васыятеңне һичшиксез үтәячәкбез!

«Бердәмлек»кә кайгылы хәбәр килеп ирештe: 2009 елның 29 июлендә иртәнге унбер сәгатьтә Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә күренекле татар шагыйре һәм каһарман якташыбыз, рәссам Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйров вафат булган.

Без аның белән әле күптән түгел, «Бердәмлек» газетасының 1000нче юбилей санын әзерләп йөргәндә телефон аша озак кына сөйләшкән идек. Аннан соң ул безгә үзенең «Бердәмлек» - халкым чишмәсе син!» дип аталган тәбрикләү сүзләрен язып җибәргән иде. Без аларны 18 июльдә дөнья күргән 1000нче санызда бастырып та чыгардык. Бу якташыбызның безгә, «Бердәмлек» газетасы укучыларына, гомумән бөтен татар халкына әйтелгән соңгы васыяте булган икән, ләбаса.

*«Милләт! - диеп яныл яшибез без,*
*Шундый инде безнең холкыбыз.*
*Гомер буе уртак ярыбыз бар,*
*Ул - халкыбыз безнең, халкыбыз!»*

Моннан да аңлаешлырак, йөрәкләргә, күңелләргә үтеп кереpлек итеп халкыбызга карата мәхәббәтне белдереп буламы икән?

Безнең «Бердәмлек» газетасының якын дусты, фикердәше иде ул. Үзенең шигырьләрен, публицистик язмаларын беренче булып Гакыйль Сәгыйров туган ягында нәшер ителүче «Бердәмлек» редакциясенә җибәрә иде, һәм алар аның битләрендә даими басылып килделәр.

Өч төбәк -Татарстанның Нурлат районындагы Әхмәт авылы (ул анда туган), Самара өлкәсенең Кошки районындагы Иске Җүрәй (Иске Фәйзулла) авылы (биредә аның балачагы, яшүсмер еллары үткән, биредә ул чын шагыйрь, ир-ат булып җитешкән) һәм, ниһаять, гомеренең соңгы елларын уздырган Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәре - һәрберсе Гакыйль Сәгыйровны үзенең якташы дип саный, хөрмәт итә иде.

Биредә шаулатып-гөрләтеп аның 60,65,70 яшьлек юбилей тантаналары, яңа китапларын тәкъдир итү кичәләре уздырылып килде. Әнисе Хәбибҗамал апа исән чакта, без бергәләшеп аның

юбилейларын да билгеләп үтә, шундый олуг шәхесне үстергән ана батырлыгына сокланып баш ия идек.

Менә үлем якын дустыбызның да гомерен чикләде. Тик без аның каһарманлыгын беркайчан да онытмабыз, киләчәк буыннарга да түкми-чәчми җиткерербез.

Гакыйль Сәгыйровның ачы язмышы татар халкының гариплэнгән, тик бернигә дә бирешмәгән ачы язмышына тиң. Без якташыбызның тормышын үзебезгә үрнәк, өлге итеп алып, милләтебезне торгызу, аякка бастыру өчен бөтен көчебезне, тырышлыгыбызны куярга тиешбез.

Шагыйрьнең "Бердәмлек"кә багышлап язылган соңгы шигырендә әле тагын мондый юллар да бар:

"...*Бергә булсак кына без үтәрбез*
*Алга илткән кыен юлларны...*"

Без синең бу васыятеңә тугры калып, аны үтәргә тырышырбыз. Бу - безнең уртак бурычыбыз!

Ә синең урының оҗмахның иң түрендә булсын, син моңа лаеклы, Гакыйль дустыбыз!

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН,**
**Самара өлкә «Бердәмлек»**
**татар газетасының баш мөхәррире.**

("Бердәмлек", № 31, 1 август 2009 ел).

# Ятим өйнең бакчасындагы алмагачта биш алма

Татарстанның Нурлат районындагы Әхмәт авылында 1938 елда дөньяга килгән Гакыйльнең гаиләсе (әнисе, энесе), әтиләре Шәрифулла абый сугышта хәбәрсез югалганнан соң, Хәбибҗамал апаның туган авылына - хәзерге Самара өлкәсенең Кошки районындагы Иске Фәйзуллага (Иске Җүрәйгә) күченеп кайта. Булачак шагыйрь үзенең балачак, яшүсмер елларын гүзәл табигать кочагына сыенып утырган шушы авылда үткәрә. Шулай ук биредә ул язмыш тарафыннан зур сынау кичереп, унбиш яшеннән хәрәкәтсез килеш түшәктә генә ятып торырга дучар ителгәннән соң, үзендә яңа көч табып, каләмне тешләренә кыстырып, кабат язарга, рәсем ясарга өйрәнә, ир-ат булып җитлегә, шагыйрь-рәссам буларак формалаша. Әнисе Хәбибҗамал картаеп, якты дөньядан китеп баргач, ул соңгы ун еллар чамасы гомерен Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә энесе Наил, аның хәләл җефете Халидә, аларның балалары Рафаэль, Ринат, Марат янында үткәрә.

Димәк, бу өч төбәкнең һәркайсысын үзенең туган ягы, Кече Ватаны дип санарга хакы бар аның. Тик шулай да артык зур да, кечкенә дә булмаган шушы бер гади татар авылы Иске Җүрәй аның күңеленә якынрак булгандыр, күрәсең. Бер дә юкка гына үзенең күп шигырьләрендә аңа мәдхияләр җырламагандыр, биредәге гаҗәеп табигать күренешләрен рәсемнәренә төшермәгәндер шул ул.

*Җүрәем, Җүрәем, хәлемне беләсең,*
*Җаныма шифаңны бирәсең,*
*Сагынып-сагынып үлмәсен тагын, дип,*
*Юатып төшемә керәсең.*

Тормыш өчен күп уңайлыклары булса да, күңелгә ят шәһәрдә төшләренә кереп йөдәтүче Җүрәен юксынып яшәгән шагыйрь (авылдашлары сөйләвенчә, ул бирегә вафатына ике-ике атна ярым калгач, соңгы тапкыр килеп, барысын да күреп, карап, һәрберсе белән сөйләшеп киткән) көтмәгәндә генә нык авырый башлагач, үзенең соңгы васыяте итеп, гәүдәсен туган авылы туфрагына илтеп күмәргә сораган да инде.

Менә ул Гакыйль Сәгыйровның шигырьләрендә, җыр-

ларында җырланган, рәсемнәрендә тасвирланган гүзәл Иске Җүрәй авылы. Менә ул шагыйрьне назлап, кадерләп үстергән, тәрбияләгән зур иҗатка рухландырган туган нигезе. Инде шактый нык искергән йортта барысы да элеккегечә: зур, киң тәрәзә каршындагы Гакыйль яткан сәке янында күпсанлы китаплар, энисе Хәбибҗамал апаның самовары. Ә яшел чирәм белән уратып алынган өй алдында

*Нурларда коена-коена*
*Топольләр әле дә яшәрә...*
*Уралган ямь-яшел томанга*
*Шау-шулы каргалар шәһәре...*

Шагыйрьнең җәсәден Димитровградтан Иске Җүрәйдәге туган нигезенә алып кайтканда, кайчандыр ул

*Топольләрем, уйчан топольләрем,*
*Кошларымның яшел бишеге.*
*Топольләрем җирне ямьләндереп,*
*Мәңге аумый яшәр шикелле,* - дип язган, шул топольләр өстендә утыручы йөзләрчә кара каргалар бүген дә аны каршы алдылар. Гакыйльнең йөзләгән авылдашлары, Нурлаттан, Казаннан, Мәләкәстән, Ульяннан, Кошкидан, Самарадан килгән якташлары кебек үк, каргалар да, әйтерсең лә, бу олуг шәхесне соңгы юлга озатырга җыелган иде бүген.

Әстерханнан ике мең чакрым араны автомашинада 17 сәгать эчендә кош кебек очып кайтып җиткән Наил энесенең олы улы Рафаэль өйгә кереп, иң соңгылардан булып абыйсы белән саубуллашып чыкканнан соң, авыл мәчете имамы Габделхәй хәзрәт Халитов җитәкчелегендәге дин әһелләре, догалар укып, мәетне соңгы юлга әзерләү, пакьләндерү, ак кәфенгә төрү гамәленә керештеләр.

Менә, ниһаять, шагыйрьнең гәүдәсе өй алдындагы яшел чирәмгә китереп куелгач, кыска гына матәм тантанасы үткәрелде.

Беренче сүзне Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, язучы Вакыйф Нуриев әйтте.

*- Без күренекле шагыйрь, рәссам, тормышта зур батырлык, фидакарьлек күрсәткән бөек шәхесебезне - Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровны югалттык,* - дип башлады ул үзенең сүзен. *- Гомеренең таңында ук урын-җирдә хәрәкәтсез ятып, тормыш рәхимсезлегенә бирешмичә, күңел көрлеген, рухи ныклыкны саклап калып, Гакыйль ага гомере буе шигърияткә тугрылыклы булды. Ул үзенең иҗаты белән халкыбызга хезмәт итте, анын рухын баетты.*

*Аның «Тормыш җиле», «Айбагарлар», «Кабатланмас моң», «Неповторимая мелодия», «Ике кояш», «Шатлыклы иртә», «Йөрәк сере» кебек шигырьләр һәм рәсемнәр җыентыклары татар һәм әдәбият дөньясында мирасыбызны баеткан кадерле әйберләргә әйләнделәр.*

*Бүген мин Татарстан Язучылары берлеге исеменнән Гакыйль аганың соңгы сулышына кадәр тиешле тәрбия күрсәткән Халидә ханымга, Наил әфәндегә һәм аларның уллары Рафаэль, Ринат, Маратка, аны озатырга килгән авылдашларына, якташларына үземнең рәхмәтемне әйтәсем килә.*

*Хуш, Гакыйль ага, авыр туфрагың җиңел булсын!*

Кошки муниципаль районы башлыгы Анатолий Струков һәм Иске Фәйзулла авылында яшәүчеләр исеменнән сүз алган район администрациясе вәкиле Марат Шәкүров Гакыйль Сәгыйровның зур гражданлык батырлыгы үрнәкләрен, үзенең әсәрләрендә туган якка, туган авылына булган мәхәббәтен күрсәтә алуын һәм аның яшь буынга якты истәлек калдыруын билгеләп үтте.

Ульян өлкәсенең Димитровград шәһәре татарларының милли-мәдәни автономиясе әгъзасы, хатын-кызларның «Сөембикә» милли оешмасы җитәкчесе, вакытында Гакыйль Сәгыйровны Мәскәүгә, Халыкара «Филантроп» бүләген алырга илткән якын дусларының берсе - Роза ханым Әхмәтҗанова да аның кешелеклелеге, һәркем - олысы һәм кечесе белән сөйләшә, һәркемнең хәленә керә белүе турында сөйләде.

- *Әгәр дә синең өчен берәр нәрсәне эшли алмаган, тиешле ярдәмнәребезне күрсәтеп өлгермәгән булсак, гафу ит безне, Гакыйль абый!* - дип тәмамлады ул сүзен.



**Шагыйрьнең дуслары Мәләкәстән Роза ӘХМӘТҖАНОВА һәм Самарадан Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

Күпсанлы Самара өлкәсе делегациясе исеменнән Самара шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе, өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте, Самара Җәмигъ мәчете мәхәлләсе әгъзасы, танылган эшкуар

Рифкать Хуҗин, Самараның «Ялкынлы яшьлек» ансамбле җитәкчесе Илгиз Колючев, Татарстанның Нурлат муниципаль районы башлыгы исеменнән Биккол авылы мәктәбендә Гакыйль белән бер класста, бер парта артында утырып белем алган Фатыйх әфәнде Галимов самаралыларның да, ульянлыларның да, татарстанлыларның да, нурлатлыларның да, мәләкәслеләрнең дә, кошкилыларның да шагыйрьне зур ихтирам белән үз якташлары дип атарга хаклы булуларын билгеләп үттеләр. Шушы фикерне Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы, күренекле татар язучысы Шаһинур Мостафин да куәтләде.

*- Гакыйль ага үзе дә безгә якташларым дип,хөрмәтләп дәшә иде,* - диде ул һәм үзенең бер шигырен укып бирде:

*Кай туфрактан шытып чыккан булсак,*
*Шул туфракка кабат кайтасы...*
*Гөлләр булып калкыр, балкыр өчен,*
*Туган җирдә киләә ятасы...*

*- Үзенең шушы хыялына ирешкән бәхетле кеше ул - Гакыйль Сәгыйров. Туган туфрагы тарткан, изге җиргә тарткан аны. Биредә, шагыйрьнең туган нигезендә, киләчәктә музеен ясасак шәп булыр иде. Дөньякүләм билгеле шәхесебез Гакыйль Сәгыйров моңа лаеклы. Әгәр без бу эшне эшләсәк, ул безнең барыбызны да тагын да якынайтыр, үз янына берләштерер иде.*

Бу фикергә Нурлат төбәге буенча «Ватаным Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе, Гакыйль Сәгыйровның тормыш һәм иҗат юлы турында күп очерклар язган Илдус Диндаров һәм башкалар да кушылдылар.

Мәләкәс шәһәрендә яшәүче шагыйрь, Ульян өлкәсе «Өмет» газетасының үз хәбәрчесе Равил Шәфигуллин үзенең инде күптәннән Гакыйль Сәгыйровның авылы Иске Җүрәйнең яшел чирәмле урамнарын, топольләрен, кара каргаларын күрәсе килгәнлеген, шушы бәхетне аңа менә шушы кайгылы мизгелләрдә кичерергә туры килүен, шагыйрьнең үз янына башкаларны да җыеп китерүен үзенең бер шигырендә өзгәләнеп:

*Әй, кошлар, аккошлар, мин булыйм берегез,*
*Алыгыз мине дә еракка.*
*Язмышлар язганын күрербез бергәләп,*
*Яз җиткәч, кайтырбыз бу якка,* - дип язуын искә алып узды. *- Ул үз гомерендә бер генә шигырь, бер генә рәсем иҗат итсә дә, Гакыйль Сәгыйров булып калачак иде!* - диде.

Шагыйрьнең авылдашы Разия Сәнәгатова да Гакыйль ага-

ның Иске Җүрәй авылының чын горурлыгы булуын билгеләп үтеп, аның бирегә моннан ике атна - ике атна ярым элек кенә кайтып, авылдашлары белән соңгы мәртәбә очрашып, күрешеп йөрүе, аңа әнисенең яңа гына мичтән чыгарган тәмле икмәген авыз иттерүе турында да сөйләде.

Менә шулай һәр чыгышта күренекле якташыбызның искиткеч тормышы һәм иҗат юлы, кылган изге гамәлләре яхшы сүзләр белән искә алынды, барысы да бөек шәхескә *«урының оҗмахта булсын иде»* дигән теләкләрен әйттеләр.

Менә җеназа намазын укыр вакыт та килеп җитте. Иске Җүрәй авылы мәчете имамы Габделхәй хәзрәт Халитов артыннан тигез сафларга тезелешеп баскан дин кардәшләребез тарафыннан Гакыйль Сәгыйровка багышлап догалар, Коръән аятьләре укылды.

Җеназа намазы вакытында моңа кадәр шактый нык кыздырган кояш та әллә кайдан гына килеп чыккан болытлар арасына кереп яшеренде, өй каршындагы топольләрне, талларны назлап җиләс җил исә башлады, моңа кадәр нәрсәдер әйтергә теләгәндәй кычкырышкан кара каргалар да каядыр очып китеп, тирә-юньдә бер мизгелгә тынлык урнашты.



**Гакыйль СӘГЫЙРОВны соңгы юлга озатырга килгән шагыйрьләр һәм язучылар Шаһинур МОСТАФИН, Равил ШӘФИГУЛЛИН һәм Вакыйф НУРИЕВ.**

Ә берничә минуттан без бөек шагыйребезне шәп-шәп атлап, еракта түгел урнашкан Иске Җүрәй авылы зиратына илтеп, яңа гына казылган кабергә - туган җир куенына иңдердек.

Гакыйль Сәгыйровның «Кайттым» дигән бер шигырендә мондый сүзләр дә бар. Ул анда үзенең туган ягына, туган авылына мәңгелеккә, бөтенләйгә кайтачагы турында әйткән диярсең.

*Таныш-белеш сәлам биреп уза,*
*Туган итеп, якын үз итеп.*
*Рәхәтләнә җаным туган илдә,*
*Туган авазларны ишетеп.*
*Гаҗәпсенгән эткәй кулын суза.*
*- Кичер, эткәй, булма бик кырыс.*
*Кайттым менә, бөтенләйгә кайттым,*
*Туган якларыма - бул тыныч.*

Ә шагыйрьнең әлегә ятим булып калган ташландык йорты янындагы бакчада кайдандыр, җил беләндер инде, килеп төшкән орлыктан үсеп чыккан алмагачта беренче тапкыр алсуланып биш алма өлгергән иде.

Бу нигездә шагыйрьнең музееn ачу турындагы хыял тизрәк тормышка ашырылсын да, үксез алмагачлы йортның хуҗалары шигъри юллар, җырлар, хатирәләр булып, Иске Җүрәйгә мәңгелеккә әйләнеп кайтсыннар иде.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 32, 8 август 2009 ел).

# Бу дөнья бит минсез торган кайчандыр,
# Бу дөнья бит минсез калыр кайчандыр...

Озак еллар Кошки районының Иске Җүрәй (Иске Фәйзулла) авылында яшәп иҗат иткән бөек татар шагыйре (юк, аны шулай атаудан һич кенә дә тартынмыйк) һәм талантлы рәссам, каһарман якташыбыз Гакыйль СӘГЫЙРОВның якты дөньядан китеп, үзенең туган авылы (гәрчә биредә тумаса да, ул Иске Җүрәйне туган авылы дип саный иде) зиратында җирләнүенә 7 сентябрьдә кырык көн тула. Үзенең бер шигырендә ул:

*Бу дөнья бит минсез торган кайчандыр,*
*Бу дөнья бит минсез калыр кайчандыр.*
*Аңлый алмыйм һаман шуны, дивана:*
*Нигә кирәк булдым икән дөньяга?...* - дип язган булган. Аның соңгы «Йөрәк сере» дип аталган китабында басылып чыккан бу шигырьгә без, аның укучылары, үз вакытында игътибар да итмәгән булганбыздыр. Ә менә хәзер ансыз калгач, аның нигә дөньяга кирәк булганлыгын ныгытып аңлый башладык кебек. Бу дөнья, чыннан да, безнең һәркайсыбыздан башка да торган һәм торачак та, тик аның бер кыйпылчыгы Гакыйль Сәгыйров булмагач, ул ничектер ятим, кителеп калгандай тоела.

Шагыйрьнең китапларын кулга алып, аның һәрберсендә ниндидер бер тирән фәлсәфәле фикер яткан ялкынлы, тирәюньдәге кешеләргә, туган телебезгә, ата-аналарыбызга, туган якка, табигатькә карата мәхәббәт хисе тулы шигырьләрен укып, тагын бер кат сокланасың, горурланасың. Бу кешегә: «Нигә кирәк булдым икән дөньяга?» - дип ут йотарга кирәккәнме икән. Тик нишлисең бит, ул үзенә дә, башкаларга да нык таләпчән һәм шул ук вакытта риясыз бер бәндә иде. Дөнья Гакыйльгә кирәк, ә ул, һичшиксез, дөньяга кирәк булгандыр.

Шушы каһарман якташыбызны, бөек шагыйребезне һәм талантлы рәссамыбызны искә алган шушы көннәрдә без аның шигырьләрен укып, рәсемнәрен карап ләззәтләник, гыйбрәтләр алып, уйланыйк! Ә Гакыйль дустыбызга белгән догаларыбызны укып, аңа тагын бер тапкыр урының оҗмахта булсын дигән теләкләребезне әйтик. Аңа хәзер бездән дә, бу фани дөньядан да башка берни дә кирәкми инде. Ул безгә, дөньяга кирәк, киләчәк буынга яшәешебезнең бер якты үрнәк өлгесе буларак кирәк.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**
(“Бердәмлек”, № 36, 5 сентябрь, 2009 ел).

# “Яхшылыклар белән искә алып, сагынсалар иде безне дә...”

*Гасырларга житәр гыйбрәтле җыр*
*Һәр буынның йөрәк түрендә.*
*«Якташыбыз!» - диеп куанабыз*
*Һәр ел саен туган көнендә*, дип язган иде Гакыйль абый Сәгыйров турында күпләргә таныш булган милләттәшебез, «Яктылык» мәктәбенең элеккеге укытучысы, җырчы, шагыйрә Фәридә Зиннәтуллина. Үткән елның җәендә каһарман якташыбыз бакыйлыкка күчкәч, хәзер аның туган көннәре үзеннән башка гына узачак инде. Менә Самараның «Яктылык» татар мәктәбендә шундыйларның беренчесе булып үтте.

Мөселманнарда һәр хәерле эш «Бисмилләдән», изге догадан башланырга тиеш. Бу кичәдә дә беренче булып мөфтиебез Вагыйз хәзрәт Яруллин чыгыш ясап, Гакыйль Сәгыйров, аның тормышы, иҗаты турында бик җылы сүзләр әйтте.

- *Ул безнең өчен - зур вәгазь*, - дип тәмамлады ул үзенең чыгышын һәм мәрхүмнең рухына багышлап, Коръән аятьләре укып, дога кылды.



Искә алу кичәсендә Самара өлкәсе мөфтие Вагыйз хәзрәт **ЯРУЛЛИН** чыгыш ясый.

Әйе, 54 ел дәвамында урын өстендә ятарга мәҗбүр булган, искиткеч шигырьләр иҗат иткән, куллары эшләмәгәнгә, каләмне авызына кыстырып, гаҗәеп матур рәсемнәр ясаган кешегә сокланмыйча мөмкин түгел, әлбәттә. Үзе ул «Ә мин ятам, яраланган бөркет, яшәвемнән хәтта оялам», дип язса да, шушындый ачы тәкъдиргә карамастан, сынмаган, сыгылмаган. Яшәү мәгънәсен тапкан, тормышны оптимистларча кабул иткән бу олуг шәхесне батырларга тиңләсәк тә, ялгышмабыз.

Кичә барышында алып баручылар Линар Абсатта-

ров белән Инзилә Гарәфетдинова салмак кына уйнап торган музыка астында тамашачыларга шагыйрьнең нәкъ шундый батырларча тормышы, аның иҗаты турында сөйләп тордылар.



Фаил ГАЙНЕТДИНОВ.

Гакыйль Сәгыйровның шигырьләренең һәрберсендә ниндидер бер тирән фәлсәфәле фикер ята. «Яктылык» мәктәбе укучылары Фаил Гайнетдинов, Наил Җаббаров, Раилә Айбулатова, Ринат Хөснетдинов, Эльвира Йосыпова кичәдә шагыйрьнең шундый шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйләделәр. Ана телебезгә, ата-аналарыбызга, туган якка, табигатькә, мәхәббәткә багышланган шигъри юлларның тамашачыларның йөрәгенә үтеп кереп, тирән тәэсирләр калдырганын аларның уйчан карашларыннан күреп аңларга булды.

Чарага Гакыйль абыйның якын дуслары, туганнары да килгән иде. Алар арасында Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәрләре, Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районындагы Урта Исәнтимер авылыннан ирле-хатынлы Шәкүровларның чыгышы аяз күктә яшьнәгән яшенгә охшады. Шагыйрьнең адашы, якын дусты Гакыйль әфәнде моңлы тавышы белән Сәгыйров



Линар АБСАТТАРОВ һәм Галия МОСТАФИНА.

сүзләренә үзе иҗат иткән бик күп җырларны башкарды. Ә Рәисә ханым профессионалларча оста итеп Гакыйль абыйның шигырьләрен укыды.

Элек күп еллар Самараның «Ялкынлы яшьлек», «Идел» ансамбльләрендә җырлап, тамашачы мәхәббәтен казанган, Гакыйль Сәгыйров иҗатын яратучыларның, пропагандалаучыларның берсе — Галия Мостафина да үзенең моңлы чыгышы белән кичәне тагы да бизәп җибәрде. Ул тамашачыларга Гакыйль Сәгыйров сүзләренә якташыбыз Али Губанов, танылган Татарстан композиторы Фирзәр Мортазин, Нурлат егете Равил Мифтахов язган җырларны бүләк итте.


Гакыйль ШӘКҮРОВ.

Йомшак күңелле, кешелекле, мәрхәмәтле кеше булarak, мәрхүм Гакыйль абый күп кешенең күңелендә, йөрәгендә тирән эз калдырган. Шундыйлар арасыннан аның бертуган энесе Наил әфәнде, авылдашы Ирек Мостаев, Димитровград шәһәреннән Фәния Хәлиуллова, «Яктылык»ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нурзидә Фәйзуллина, «Ялкынлы яшьлек» ансамбле җитәкчесе Илгиз Колючев кичәдә үз истәлекләре белән уртаклаштылар.

Ә Фәния ханым Хәлиуллованың:

*- Без Гакыйль абый белән янәшәдә генә яши идек. Аның хәлен белергә килгәч, ул, киресенчә, үзе синең хәл-әхвәлләреңне сорашып, эчеңне бушаттырып, акыллы киңәшен биреп, озатып кала иде. Үтә дә нечкә күңелле иде Гакыйль абый, без аны бик яратабыз һәм сагынабыз. Ул барысын да берсүзсез, күзеңнән күреп аңлый торган иде,* — дигән сүзләре бигрәк тә йөрәккә үтеп керделәр.

Шагыйрьнең энесе Наил Сәгыйровның улы Ринат та Гакыйль абыйсының шигырьләренә бик күп матур җырлар иҗат иткән. Чарада Фәния ханым Хәлиуллова моңлы тавышы белән шуларның берничәсен - «Төнге яңгыр», «Көнбагышлар» җырларын тамашачыларга да җиткерде.

Гомумән, искә алу кичәсендә җыр-моңга сәләтле күп кешеләр чыгыш ясады. Әйтик, шундыйларның берсе - «Яктылык» мәктәбе укытучысы Линар Абсаттаров халыкка Гакыйль Сәгыйров сүзләренә башка композиторлар иҗат иткән җырларны гына башкарып калмыйча, шагыйрьнең «Тыңла мине, аппагым» дигән шигыренә үзе язган бик матур җырны да тәкъдир итте.

Кичә ахырында чараны оештыручыларның берсе — «Бердәмлек» газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллинның ялкынлы чыгышы халыкны изге гамәлләргә өндәү булып яңгырады:

*- Без киләчәктә дә Гакыйль Сәгыйровның шигырьләре яңгырар, татар теле онытылмас, дигән өмет белән кичәне тәмамлыйбыз.*

*Бүген авылларда мәктәпләр ябыла, җирләр сөрелмичә, чүп үләне белән капланган, терлек фермалары тузып ята. Америка тавыклары ботларын ашап яшибез, үзебезнең итебез дә, сөтебез дә юк диярлек. Авыл җирендә укырга бала юк. Иске Җүрәйдә Гакыйль Сәгыйров белем алган ике катлы мәктәп тә ябылды инде.*



**Искә алу кичәсе күмәкләшеп «Туган тел» җырын җырлау белән тәмамланды.**

*Шундый хәлләр хөкем сөргәч, безнең киләчәгебез бармы? Бүгенге көндәге кебек киләчәктә дә шушы мәктәпкә җыелып, татар телендә шундый матур чаралар үткәрербезме? Әнә, хәзер Сабантуй, Нәүрүз бәйрәмнәренә дә халык аз җыела. Безне, татар халкы яшәрме, дигән мәсьәлә борчырга тиеш.*

*Быел Россиядәге татар авыллары арасында Федераль Сабан туе Похвистнево районының Гали авылында үтәчәк. Шул гөрләп торган Гали авылы үрнәгендә Гакыйль Сәгыйровның туган авылы Иске Җүрәйне дә яңадан торгызасы иде. Безгә бергәләшеп ничек булса да татар телен, халкыбызны саклап калу өчен, балаларыбызны ана телебездә, Тукай, Җәлил, Такташ, Сәгыйров телендә тәрбияләргә тырышырга кирәк. Шул эшләребезне җайлап җибәрүдә әлеге кичә бер этәргеч булсын иде.*

*Тагын бер хыялым белән уртаклашмасам, бүгенге кичәнең уңышлы булуы өчен бернәрсә дә эшләмәдем, дип санарга була. Иске Фәйзулла авылында Гакыйль Сәгыйровның йорты ташландык хәлдә. Бөтен көчебезне туплап, бергәләшеп шунда аның музеен ачсак, бу каһарман якташыбыз истәлеген мәңгеләштерү бер изге гамәл булыр иде.*

Гакыйль Сәгыйров “Васыять” исемле шигырендә:

“*Яхшылыклар белән искә алып,*

*Сагынсалар иде безне дә*”, - дип язып калдырган. Кичәдә Нурзидә апа Фәйзуллина, Рәфгать абый Әһлиуллин әйткәнчә, һәр буынның йөрәк түрендә Гакыйль Сәгыйровның шигырьләре гыйбрәтле җыр булып яшәсә, “Яктылык” татар мәктәбендә, Иске Җүрәйдә каһарман якташыбыз, бөек шагыйребез һәм талантлы рәссамыбыз музейларын булдырсак, без үзебезне аның васыятен үтәгән бәхетле кешеләр итеп санар идек.

Ә кичәнең татар халкының гимнына әйләнгән сөекле шагыйребез Габдулла Тукай сүзләренә “Туган тел” җырын бөтен тамашачылар бергәләп башкаруы белән тәмамлануы үзе генә дә киләчәккә өметләр уята.

**Миләүшә ГАЗИМОВА.**

(“Бердәмлек”, № 8, 20 февраль 2010 ел).

# Васыять

Бу үтә дә чиксез кызу җәйге челлә көннәрендә миңа каһарман якташыбыз, күренекле шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровның вафат булуына бер ел тулуга багышланган Коръән мәҗлесләренең берничәсендә катнашырга насыйп булды. Шагыйрь дөньяда яшәгән 71 яшенең күбесен үткәргән, туган авылына әйләнгән Кошки районының Иске Фәйзуллада (Иске Җүрәйдә) якын туганнары тарафыннан оештырылган мәҗлестә катнашмасам да, элеккеге күршесе, бүген Самарада яшәүче авылдашы Ирек Мостаевның сөйләве буенча үземне дә анда булгандай хис иттем.

Мәҗлес башланыр алдыннан мәрхүмнең якыннары һәм туганнары авыл зиратына барып, аның каберен дә зиярәт иткәннәр, Иске Җүрәй мәчетендә дә якташлары рухына дога кылынган.

Бу көннәрдә шагыйрьнең кабере өстенә һәйкәл кую хәстәрлеге дә алып барыла икән. Әгәр барысы да уйланылганча барса, рамазан ае тәмамланып, Ураза гаете үткәч, һәйкәлне тантаналы төстә ачу да күз алдында тотыла. Туганнарның теләге буенча анда шагыйрьнең түбәндәге дүрт юллык шигыре уелып язылырга тиеш.

*«Җырлар язам, хатлар язам, китап язам,*
*Ак кәгазьне сүзләр белән сырлап салам;*
*Күпме көрәш китә аның һәр юлына!*
*Шатланам мин җырлар булып калуыма».*

Иншалла, уйланылган бу изге гамәлләр тормышка ашсыннар иде инде.

*- Тик шагыйрьнең ятим калган өе яныннан үткәндә генә никтер күңелне моңсулык хисе биләп алды,* - дип сөйләде миңа авылдашы (ул Гакыйль Сәгыйровны үзенең остазы дип атый) Ирек әфәнде Мостаев.

Әле 1954 елда төзелгән бу өйдә, Гакыйль Сәгыйров әнисе Хәбибҗамал апа белән үткән гасырның 90нчы елларында Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәренә энесе Наил гаиләсе янына күчеп киткәнче, миңа берничә тапкыр булырга туры килгән иде. Хәбибҗамал апаның егәрлеге, исәнлеге бар чакта алар җәй көннәрендә дә кайтып биредә яши торган иделәр. Ә инде әни кеше тәмам картаеп, йөрергә көче калмагач, ә аннан бөтенләй бакыйлыкка күчкәч, туган нигезгә

кайтулар тәмам тукталды. Шул чакта ук без «Бердәмлек»тә шагыйрьнең ятим калган өен саклап калу турында, үзе исән вакытта бирелдә аның музеен ачу турында мәсьәләне күтәреп чыккан идек. Тәкъдимне хуплаучылар табылса да, бу изге эшне башлап, артыннан йөрергә теләүчеләр генә күренмәде, һәм бу эш хәл ителмичә, гел артка күчерелеп килә торды. Бу турыда шагыйрьнең 60, 65, 70 еллык юбилейларын үткәргәндә дә күп сөйләнде, эшлекле тәкъдимнәр дә әйтелде. Нурлаттан атаклы «Зюзеев-нефть» ширкәтенең генераль директоры Шамил әфәнде Яһудин (аның әтисе Габделхәй ага тумышы буенча шушы Иске Фәйзулла авылыннан) берничә тапкыр очрашып сөйләшү вакытында мәсьәләнең зур әһәмияткә ия булуын аңлап, кирәкле матди ярдәм күрсәтергә дә вәгъдә иткән иде. Бәлки, ул сүзендә торган да булыр иде. Тик без үзебез ваемсызлык күрсәтеп, эшләнәсе эшләрнең күләмен билгеләүне, кирәкле документларны рәсмиләштерүне, смета-проект кәгазьләрен әзерләүне гел артка чигерә килдек. Хәер, акчасыз, файдасы булмаган эшкә кем алынсын инде? Андыйлар хәзер акчага табынган заманда бик сирәк шул.

Менә Гакыйль Сәгыйровсыз бер ел үтеп тә киткән инде. Ә аның йортын торгызу эше әле һаман урыныннан кузгалганы юк.

Бу турыда Димитровградта шагыйрьнең энесе Наил әфәнде һәм аның тормыш иптәше Халидә ханым яшәгән йортта дин әһелләрен, җирле татар җәмәгатьчелек вәкилләрен чакырып үткәрелгән искә алу кичәсендә дә, Самараның Җәмигъ мәчетендә Коръән мәҗлесендә дә сүз бик җитди төстә алып барылды.

Димитровградта җирле Җәмигъ мәчетенең яшь имамы Рамис хәзрәт Рамазанов, ә Самарада Самара мөселманнарының региональ Диния нәзарәте рәисе, мөфти Вагыйз хәзрәт Яруллин үзе, мәрхүмнең рухына багышлап, Коръән аятьләре укып, догалар кылганнан соң, татар җәмәгатьчелеге вәкилләре Димитровградтан - Риваль Идрисов, Равил Шәфигуллин, Роза Әхмәтҗанова, Самарадан – Нурзидә Фәйзуллина, Фәния Шәфигуллина, Рифкать Хуҗин, Камышлыдан – Атлас Төхвәтов һәм башкалар каһарман якташыбызны бары яхшы сүзләр белән генә искә алып, аның исемен мәңгеләштерү буенча әйтелгән фикерләрне хуплауларын белдерделәр.

Әнә Мордовиянең Сыркыды авылына танылган татар шагыйре Һади Такташның 100 еллыгына баргач, кунаклар аның кычыткан үсеп утырган ташландык нигезе урынында кар өстенә

тезләнеп намаз укыганнан соң, шагыйрьнең йортын торгызуны хакимият алдына кабыргасы белән куеп, кыска вакыт эчендә мәсьәләне уңай хәл итүгә ирешә алганнар иде. Татарстан Язучылары берлеге рәисе Илфат әфәнде Ибраһимовның әйтүенчә, Татарстан һәм Мордовия республикаларының мәдәният министрлыклары үзара килешеп, Һади Такташның йорт-музеен Сыркыдыда сафка бастырды. Ә безнең Самара өлкәсе хакимияте кемнән ким, безнең татар җәмәгатьчелеге җитәкчеләре теләсәләр, моны эшли алачаклар, әлбәттә. Мәҗлесләр вакытында чыгыш ясаучылар мәсьәләне хакимиятләр алдында күтәрүне һәм бу эшкә үзебезнең җиң сызганып алынырга кирәклегенә басым ясадылар. Бу эшне бигрәк тә шагыйрьнең Иске Фәйзулла авылы урнашкан Самара өлкәсе вәкилләре җитәкчелеге әйдәп барырга тиеш. Моның өчен якын көннәрдә, озакка сузмыйча, каһарман якташыбыз Гакыйль Сәгыйровның Иске Фәйзулла авылындагы йортын торгызу һәм шагыйрьнең музеен булдыру өчен махсус фонд оештыру һәм аның исәп-хисабын ачу зарури. Ә акча булса, барысын да уңай хәл итеп булачак.

Бу фикерләрне Самарада каһарман якташыбызны искә алу мәҗлесен оештыруда актив катнашкан укучыларның барсы да




**Самараның Җәмигъ мәчетендә шагыйрьне искә алу мәҗлесендә.**

аларны тормышка ашыру өчен бөтен көчләрен куячакларын белдерделәр. Димитровград шәһәренең татар җәмәгатьчелеге дә бу изге эштән читтә калмаячак. Татарстан Республикасында да бу башлангычны яклаучылар табылачагына ышаныч зур. Самара өлкәсе мөфтие Вагыйз хәзрәт Яруллин да үзенең мәҗлестә ясаган йомгаклау сүзендә бу изге эшкә хәер-фатыйхасын бирде.

Ә Гакыйль Сәгыйров үзенең яшәгән йорты-музеен ачарга бик тә лаеклы. Мин искә алу мәҗлесләренә барыр алдыннан аның китапларын актарып шигырьләрен кабат укып чыктым. Аларның һәр юлында тирән мәгънә, зур фәлсәфә ята, барысы да туып-үскән җиребезгә мәхәббәт хисе белән сугарылган, һәрберсендә туган телебезне, татарлыгыбызны, авылларыбызны, мәдәниятебезне, тарихыбызны, динебезне торгызу һәм саклап калу турында бара.

Минемчә, Гакыйль Сәгыйровның балалар өчен язылган кайбер шигырьләре татар әлифбасына, ә күп шигырьләре татар әдәбияты дәреслекләренә дә кертелергә хокуклары бар. Бу кайчан да булса бер эшләнергә, хәл ителергә тиеш. Ә инде әлегә тормышка ашырылмаган икән, татар теле укытучыларына аның иҗатын, өстәмә дәресләр үткәреп, балаларыбызга җиткерү өстендә эшләргә тәкъдим итәсем килә.

Кайберәүләр Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылы таралачак, аның киләчәге юк дип куркыталар. Юк, бу авыл үләргә тиеш түгел. Кайчан да булса бу афәтле вакытлар үтеп, авыл күтәреләчәк, кысыр калган җирләр эшкәртелеп, уңыш бирә башлаячак, авыл таркалырга тотынганда ябылган мәктәп тә яңадан ачылачак. Моңа ышанырга гына кирәк. Ә моңа ышаныч тудырып, авыл уртасында торгызылган, ачы язмыш тарафыннан гарипләнеп тә җиңелмәгән бөек, каһарман шагыйрь турында сөйләүче Гакыйль Сәгыйровның йорт-музее басып торырга тиеш. Каһарман шагыйрьнең тормышы, иҗаты белән танышырга район, өлкә, илебез мәктәпләреннән бирегә укучы балалар да, өлкәннәр дә килер, тормыш дәвам итәр.

Шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның «Васыять» дип аталган бик тә гыйбрәтле бер шигыре бар. Аны Димитровградта үткәрелгән искә алу мәҗлесендә аның шигырьләрен пропагандалаучыларның берсе — Ульян өлкәсе Яңа Малыклы районының Исәнтимер авылында яшәүче - «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» исемен йөртүче Рәисә Шәкүрова да безгә тагын бер кат искә төшерде.

*«Җылы җәйме, язгы ташулармы,*
*Көзге яңгыр яки кыш-кармы,*
*Үлгәч, мин үземне атка салып,*
*Авыл әйләнергә кушармын».*
*Сәер, мәзәк, серле мәгънәсезлек?*
*Кемнәргәдер яшерен ишарә?*
*Теләгем гади: уем белән*
*Күңелләрдә озак яшәргә?..*
*... Без киткәч тә,*
*Берни булмаган күк,*
*Язлар килер,*
*Кошлар кайтырлар.*
*Туар, үсәр,*
*Назлы җилләр исәр,*
*Яшьнәп-күкрәп*
*Явыр яңгырлар.*
*Тормыш дәвам итәр*
*Янып, балкып.*
*Йә көлдерер,*
*Алыр елатып.*
*...Ни сөйләрләр икән безнең хакта?*
*Сөйләрләрме әле, әй, чынлап та,*
*Их, тыңлыйсы иде бер кайтып.*

Менә шундый якты уй-фикерләр килде каһарман якташыбызны искә алу мәҗлесләрендә булып, Коръән сүзләрен, аның турында яхшы фикерләр ишеткәннән соң. Юк, без сине, шагыйрь, онытырга тиеш түгелбез. Син безгә үрнәк күрсәтеп, арабызда һәм күңелләребездә мәңге яшәргә хаклы.

Самара өлкәсе мөфтие Вагыйз хәзрәт Яруллин әйткәнчә, барыбызга да ихласлы булып яшәргә язсын! Шул чакта без беркайчан да халык буларак югалмабыз.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 33, 14 августа 2010 ел)

# Шагыйрьнең борчулы уйлары...

Исән булса, быел аңа 73 яшь тулган булыр иде. Тик мәрхәмәтсез үлем 2009 елның 29 июлендә татарның бөек шагыйрен (аны шулай дип бернинди шик-шөбһәсез әйтергә мөмкин, минемчә) арабыздан алып китте. Без аның дуслары, күпсанлы укучылары менә икенче ел инде туган көнен үзеннән башка билгеләп үтәбез.

Үлем бер кешене дә аямый, яшен дә, картын да, авыруны да, аттай тап-тазаны да. Ә ачы язмыш тарафыннан илле елдан артык гомерен бер хәрәкәтсез түшәк өстендә ятып торырга дучар ителгән Гакыйль Сәгыйровның үлеменә һаман ничек тә ышанасы килми. Ул чираттагы туган көне алдыннан Татарстан хөкүмәте биргән "Ока" машинасына утырып, редакциябезгә үзе килеп керер, йә булмаса телефоннан шалтыратып, хәл-әхвәлләребезне сораша башлар кебек.

Менә мин хәзер шагыйрьнең якташы, Татарстанның Нурлат районындагы Биккол авылында туып үскән егет (Гакыйль дә биредәге күрше Әхмәт авылында дөньяга килгән бит), "Ватаным Татарстан" газетасының үз хәбәрчесе, танылган журналист һәм язучы Илдус Диндаров язган "Гомер фасыллары" дип аталган китапны актарып утырам. Анда "Гакыйльнең офыклары" исемле каһарман шагыйрьнең тормышына һәм иҗатына кагылышлы язма да бар. Шуннан түбәндәге юлларны укыйм:

*«Кайдандыр басу капкасы ягыннан, ындыр артларыннан кузгалып, авыл урамына йөгереп кергәч, күңелле генә челтер-челтер акканнан соң, пәйда булган кебек үк, кинәт кенә гаип булган язгы гөрләвекне күз алдына китереп карагыз әле. Табигать уянып килгән иртәләрдә ул китергән куанычны берни белән дә алыштырырлык, чагыштырырлык түгел. Дөрес, икенче көнне аның тыйнак кына, сабыр агымына күнегә төшәбез. Әмма ул үтеп киткәч, нидер җитешмәвен тоябыз һәм аны һәр яз саен сагынып, көтеп алуыбыз хак.*

*Алтмышынчы еллар ахырында татар әдәбиятына шагыйрь Гакыйль Сәгыйров та нәкъ әнә шулай — үзенчә җырлап, үз моңы белән килеп кергән иде. Хаста түшәгендә бер хәрәкәтсез яткан килеш, тешләренә карандаш кабып иҗат итүче, искиткеч ник ихтыярлы бу кеше турында*

*ишетмәгән, белмәгән берәр татар баласы калдымы икән хәзер!? Рәхимсез язмышка баш бирмичә, уч итеп, каләмен теш арасына кыстырып, ярсу, тынгысыз хисләрен кәгазьгә төшерә ул. Эч пошканнан түгел - язмыйча түзә алмаганга, күңелендә тормышны, кешеләрне чиксез ярату тойгылары ташып торганга иҗат итә. Шуңа күрә шигырьләре бик тә самими, садә, җылы, рәсемнәре һәркемне сокландырырлык нәфис, гүзәл.*

*...Сөекле әнисе Хәбибҗамал апа исән булганда, җәйләрен Самара өлкәсендәге Иске Җүрәй авылына кайтып яши торган иде алар. Ә ул йортта караваты янындагы тәрәзәдән яшел чирәмле, тузанлы урам, инеш, тирәкләр күренеп тора. Бары шулар гына ләбаса. Әмма чын шагыйрь йөрәге тар тәрәзә өлгесеннән дә дөнья матурлыгын, олылыгын күрә белә, яшәү шавын, саф җилләрнең куәтле агышын бөтен җаны-тәне белән тоя. Ул, үзе язганча, «таныш түгел юлларны» да, «пәрәвез шарына тотынып» ерак сәяхәткә кузгалган «бәләкәй үрмәкүч баласы»н да күзәтеп тора, яңгырга тилмергән басуларга карап, бәгыре бәргәләнгән игенченең борчу-кайгыларын үз йөрәге аша үткәрә. Ифрат каты тән газапларын, җан әрнүен җиңеп, бөтен күңеле белән туган халкына игелек кылырга, фанилыкта үз урынын яуларга омтылган олы җанлы кеше генә шулай яза ала. Аның күңел офыкларын һични белән үлчәп булмый. Бу иҗатында, шигырьләрендә чагыла. Аларда - керсез тойгылары, якты өметләре, ышанычы, яшәү мәгънәсе..."*

Гакыйль Сәгыйровның нәкъ туган көнендә Димитровград шәһәренең «Восход» Мәдәният йортында үткәрелгән аның 70 яшьлек юбилеенда автор үзенең бу китабын миңа да бүләк иткән иде.

Шагыйрь турында бик күп язылды һәм бик күпләр язды инде. Ә менә Илдус Диндаров кебек, аның иҗатын төптән аңлап бәя бирүчеләр артык күп түгел.

Мин үзем дә күңелем тынычлык табалмаган чакларда Гакыйль Сәгыйровның шигырь китапларын кулыма алам һәм аның шигырьләрен укыганнан соң ниндидер илаһи көч тоя башлыйм кебек, чөнки ул язган һәр юлда диярлек ниндидер фәлсәфәле фикер салынган.

Менә мисал өчен шагыйрьнең 2006 елда Казанда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Йөрәк сере» исемле җыентыгыннан «Уйларым» дигән шигырен генә алыйк:

## Уйларым...

*...берсе-әрем,*
*берсе - борыч, -*
*әйтеп тора йөзкәйләрем,*
*яшькә тулы күзкәйләрем...*
*Үзәннәргә төтен җәелгәнме, -*
*Офыкларым төссез, томанлы;*
*Тойгыларга сизгер йөрәгемдә*
*Илем дигән тойгы югалды.*
*Өстем-астым, алдым-артларымда*
*Тулы төсле төрле хәшәрәт:*
*Чага, тешли, суя, аса, ата, -*
*Белмим ничек кирәк яшәмәк.*
*Бабам китте илне бүлешкәнче,*
*Имин чакта үлем әләкте...*
*Туктатырга кыргый вәхшилекне*
*Ходайның да җитмәс кодрәте.*
*Тракторлар, буразналар ярып,*
*Буйдан-буйга гөрләп барырмы;*
*Иксез-чиксез яткан басуларым*
*Үкенечкә генә калырмы?..*
*Эчем пошып карыйм киләчәккә:*
*Җимерәбез һаман, ватабыз;*
*Тиздән-тиздән җыен килмешәккә*
*Газиз җиребезне сатарбыз?..*
*...Мин яратмыйм көзне: сагыш... сары...*
*Черек исе... көчкә тын алдым.*
*Алмагачның кызыл яфракларын*
*Алмалары диеп алдандым.*

Әйе, сиземләү хисе шундый көчле булган шагыйрь үзенең туган Иске Җүрәй (Иске Фәйзулла) авылының киләчәк ачы язмышын бик яхшы күргән. Биредәге күмәк хуҗалыкның таркалуына, җирләрнең эшкәртелмичә, чәчелмичә калуына, яшьләрнең эшсезлектән иза чигеп авылдан китүләренә, сабый балалар юклыктан мәктәпнең ябылуына бөтен тәне-җаны белән әрнеп язып калдырган ул бу юлларны. Менә икенче ел инде татар дөньясы үзенең бөек шагыйрьләренең берсеннән - Гакыйль Сәгыйровтан башка яши. Без аның якташлары, авылдашлары, фикердәшләре, гомумән, үзебезне татар кешеләре дип санаучылар шигырьләре аша шагыйрь васыять итеп калдырган әманәтләрне тормышка ашыра алырбызмы икән? Иске Җүрәй-Фәйзулла

кырлары, басуларындагы шаулы уҗымнар өстендә язлар килгәч, яңадан тургайлар сайравын тыңлап хозурланырбызмы? Туган авылларына әйләнеп кайткан яшь игенчеләрнең балалары, сабыйларының кулга-кул тотынышып, яңадан ишекләрен ачкан мәктәпкә баруларын күрербезме? Моңа бик тә ышанасы килә.

Әйдәгез, бөек якташыбызның туган көненә багышлап үткәрелүче кичәләрдә аның шигырьләрен укып (ә аларның татарлар яшәгән күп урыннарда үткәреләчәгенә шик юк), нәкъ шушы турыда сөйләшсәк, уйлансак иде.

Ә язын, Татарстан хөкүмәтенең Мәдәният министрлыгы ярдәме белән, бөек шагыйрьнең Иске Җүрәй авылындагы зираты өстенә мәрмәрдән эшләнгән истәлек ташы куелачак, Аллаһы боерса. Тора-бара, бәлки, уртак тырышлыгыбыз белән шагыйрь яшәгән йортта аның музеен ачып җибәрүгә дә ирешербез әле.

*“Әйткән иде: бүген алып кайтып*
*Кинәндерсен әле бабасын,*
*Кабат-кабат шушы башакларны*
*Кулларына тотып карасын,*
*Бер суласын әле*
*Гомер сөргән*
*Кырларының иркен һавасын».*

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

(“Бердәмлек”, № 7, 12 февраль 2011 ел)

# Шагыйрьнең өметләре тормышка ашарга тиеш...

**2011 елның 29 июлендә, шагыйрь һәм рәссам Гакыйль СӘГЫЙРОВның вафатына ике ел тулган көнне, аның каберенә истәлек ташы кую чарасы уздырылды.**

*«Күзгә-күз багып бирәмсең сәламең?*
*Туганым, дип өзеләме камәлең?*
*Нәсел-ру, ил-йорт йөгендә*
*Нык булдымы билеңдәге камәрең?*
*Дога, бәддога, вәгазь таләбең?*
*Вәгъдәңә, тәнгә ятышмы гамәлең?*
*Яктыртмакчы күңел күген күпләрнең -*
*Кояш, ай, йолдызлымы үз галәмең?*
*Искәндә дулап җаһилек җилләре.*
*Имангамы чакыра бу әләмең?*
*Уңмас, уелмас илаһың нурына*
*И, шагыйрь, манып язамсың каләмең?*

*Үзенең каләмен илаһының нурына манып язган шагыйрьнең истәлек көне бүген. Аның бөтен гомере фәкать илаһыдан килгән мөмкинлекләрдән чыгып, аның энергиясе, тәкъдире белән каләмгә, каләм аша кәгазьгә, кәгазьдән безнең җаннарыбызга күчте. Җаһилек җилләре искәндә, динебез дә, денебез дә онытылып торганда, иманыбыздан йөз чөергән заманда шагыйрьнең сүзе халыкка бик кирәк иде. Һәм аның сүзе халыкка барып җитте дә"*...




**Шагыйрьнең каберенә куелган истәлек ташы.**

...Якташыбыз Гакыйль Сәгыйровның каберенә истәлек ташы кую чарасында шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Илфак Мирза улы Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза) бөек шагыйребез турында менә шундый бөек сүзләр әйтте. Бу

мизгелләрдә җыелган һәр кешенең күңелендә авылдашы, якташы белән горурлану хисе күтәрелгәндер, әлбәттә. Шигырьдәге һәр сорауга Гакыйль уңай җавап бирә алыр иде бит. Кечкенә генә татар авылының гади бер өендә иҗат итеп хәрәкәтсез яткан бу кешенең башында татар теле, халкы, туган җире турында тиңсез шигырьләр туган һәм вакыт үтү белән аларның онытылмавын, ә бәлки, классикага әверелә баруын күрәбез.

Егерменче гасыр башларында төзелгән өй, инде җиргә сеңеп бара. Шифер белән ябылган түбәсе тәмам каралып беткән, аның сырты сыгылып ук төшкән. Ә менә өй эченә керсәң, яшьлегеңә кайткан сыман буласың: ап-ак итеп акшарланган мич артында “почмак”. Бу мичтә Хәбибҗамал апа яраткан улына тәмле-тәмле кабартмалар, коймаклар пешергәндер. Тәрәзә төбендә керосин лампасы. Мич каршында Гакыйльнең киң агач караваты — ятып торган кешегә җылы булсын өчен шунда куелгандыр ул. Караватт башлары кырылып, агарып беткән булса да, ул әле нык, тагын бер гасыр торырлык итеп ясалган. Каршыда - өстәл, диварда - чаршау белән каплап куелган киштә. Анда да, өстәлдә дә, алгы бүлмәдәге чаршау артындагы киштәләрдә дә китаплар, китаплар, китаплар... Алар яңа түгел, еш укудан да, вакыт үтүдән дә инде таушалып беткәннәр.

Гакыйль аларны үзе шулай еш укыдымы икән, шуннан яшәү көче, гайрәт алып яшәдеме икән, әллә авылдашларына биреп, алар белән дә белем уртаклаштымы икән? Билләһи, бу өйнең ниндидер тарту көче бар, аннан чыгасы килми, күңелең белән биредә изге кешеләр, изге ниятләр яшәгәнлеген тоясың.

Ике ел элек, Гакыйль Сәгыйров вафат булган көннәрдә үк, “Бердәмлек” газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин бу өйдә музей ачу турында сүз кузгаткан иде. Өй хәзер үк музей булырлык, тик аны сипләп, яңадан күтәрергә генә кирәк. Бу турыда истәлек ташы кую чарасында да сүз барды, Татарстан Республикасы, Самара һәм Ульян өлкәләре башлыкларына бу эштә ярдәм сорап мөрәҗәгать тә кабул ителде. Хәер, мәкаләмне истәлекле таш куюдан башларга кирәк иде бит әле...

...Без Иске Җүрәйгә килеп җиткәндә авыл гөж килә иде инде. Авыл уртасындагы клуб янында халык җыелып, төркем-төркем булып сөйләшеп тора, анда-монда телевидение операторлары, корреспондентлар йөгерешәләр, берәрсен тотып камера алдына китереп бастыралар да Гакыйль турында сөйләтәләр. Әйе, бүген Гакыйль тормышы, Гакыйль иҗаты,

Гакыйль мирасы турында мөмкин кадәр күбрәк халык белергә тиеш, бүген бит аның мәрәсиме...



**Рифкать ХУҖИН чыгыш ясый.**

Кошки муниципаль район башлыгы урынбасары Юрий Макаров, Степная Шентала авыл җирлеге (аңа Иске Җүрәй авылы да керә) башлыгы Равил Миннебаев, Ульяновск өлкәсе губернаторының милли мәсьәләләр буенча киңәшчесе, өлкә татар милли-мәдәни автономиясе башкарма комитеты рәисе Рамис Сафин, Ульяновск татар язучылары оешмасы җитәкчесе Равил Шәфигуллин, Россия Язучылар берлегенең Самара өлкәсе оешмасы җитәкчесе Александр Громов, Ульяновск өлкәсе Димитровград шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе башкарма комитеты рәисе урынбасары Мөнирә Жумаева, Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе, шагыйрь, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза), Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Гәрәй Рәхим, “Мәдәни җомга” газетасы мөхәррире урынбасары, шагыйрь, Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты Газинур Морат, “Ватаным Татарстан” газетасының үз хәбәрчесе, язучы Илдус Диндаров, Россия Журналистлары берлегенең Самара өлкәсе оешмасы идарәсе әгъзасы Виктор Садовский, Самара өлкәсенең “Туган тел” татар җәмгыяте президенты Илгиз Колючев, Самара шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рифкать Хуҗин, Самара өлкәсе Дикия нәзарәтенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге җитәкчесе, Самара өлкә “Дуслык” татар иҗади-иҗтимагый җәмгыяте әгъзасы Идеал Галәүтдинов, шагыйрьнең туганнары һәм авылдашлары җыелышып, авыл зиратына килделәр.

Бу чараны оештыруда башлап йөрүче “Бердәмлек” газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин шагыйрьнең кабере янында берничә сүз әйткәннән соң, Александр Громов һәм Илфак Ибраһимов кабер ташы өстендәге япманы төшерделәр. Бу вакытта барыбыз да дин әһелләренә кушылып тәкъбир



**Самараның «Болгар яңарышы» мәчете имамы Гомәр хәзрәт ВАККАЗОВ һәм Иске Фәйзулла авылы мәчете имамы Габделхак ХАЛИТОВ.**

әйтеп тордык. Ташта шагыйрьнең рәсеме уелып ясалган һәм "Шатланам мин җырлар булып калуыма", - дигән шигъри юллары язылган. Самара мөселманнарының региональ Диния нәзарәте вәкиле, Камышлы һәм Кләүле районнары мөхтәсибе Габдулла хәзрәт Мөхәммәткәрим һәм Иске Фәйзулла авылы мәчете имамы Габделхак хәзрәт Халитов ислам кануннары буенча Коръән сүрәләре укып, дога кылганнан соң, барыбыз да шагыйрьнең өе янына юнәлдек.

Өй каршына куелган чатыр астында трибуна. Беренче булып халыкка Кошки муниципаль район башлыгы урынбасары Юрий Макаров мөрәҗәгать итеп: "Без истәлек ташы кую инициативасы белән чыккан милли оешмаларга бик рәхмәтле. Өч төбәк — Татарстан Республикасы, Самара һәм Ульян өлкәләре өчен якын булган Гакыйль Сәгыйровның музее ачылса, без аны карап-төзәтеп торырга алыначакбыз", - дип белдерде.

Степная Шентала авыл җирлеге башлыгы Равил Миннебаев Гакыйль янында уйнап, аның шигырьләрен тыңлап үскән малай булып чыкты. Ул да, музей була калса, көченнән килгәнчә булышырга вәгъдә итте.

Ульян өлкәсе губернаторының милли эшләр буенча киңәшчесе Рамис Сафин, телевидение журналисты буларак, Гакыйль турында үз вакытында берничә телевизион тапшыру әзерләгән булган. Унбиш еллар чамасы элек ясалган бу сюжетны әле дә сорап килүчеләр бар икән. Бәлага тарган, аяксыз-кулсыз калган кешеләр хәзер дә Гакыйльдән көч, үрнәк алалар, дип сөйләде ул.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов Гакыйль Сәгыйров иҗатын Габдулла Тукайныкына тиңләде: "*Тукай безгә ничек кирәк булса, Гакыйль дә безгә шулай кирәк. Ту-*

*кай халыкны бер идея — ана телебезне, милли гаиләләребезне саклап калу, авылларыбыз туфрагын ятим итмәү идеясе тирәсендә туплый алган булса, Гакыйль Сәгыйров та шулай бүген безне берләштерә. Аның иҗатының әһәмиятен Татарстанда да яхшы аңлыйлар. Менә мәдәният министры Айрат Сибагатуллин да музей концепциясен эшләп чыгаруда Татарстан хөкүмәте ярдәм итәчәген белдерде. Ә инде Гакыйль Сәгыйровның 75 еллыгына аның шигырьләренең тулы җыентыгын без һичшиксез чыгарачакбыз*", - диде.

Бу чарада чыгыш ясаган һәр шәхеснең Гакыйль белән бәйле хатирәләре бар. Димитровград шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары Мөнирә Жумаева егерме елга якын Гакыйль белән көн саен диярлек аралашып, аңардан рухи ярдәм алып торган, Бөтендөнья татар конгрессының Нурлат бүлеге җитәкчесе Фәридә Мөхлисова аның иҗатын балалар тәрбияләүдә куллана икән. Ә Илгиз Колючев "Ялкынлы яшьлек" ансамбле белән Иске Җүрәйгә килеп, Гакыйль Сәгыйровның өендә концерт куюлары турында сөйләде.

Александр Громов һәм Виктор Садовский да шагыйрьнең батырлыгын Николай Островский герое Павел Корчагин батырлыгы белән тиңләп, Ялтада аның музее булган кебек, Иске Җүрәйдә дә шундый ук музей ачарга кирәклеге турында әйттеләр.

Шулай итеп, чарага җыелган абруйлы шәхесләр бертавыштан авылда Сәгыйровның музеен ачу кирәклеген расладылар



**Халык, дин әһелләренә кушылып, тәкъбир әйтеп тора.**

һәм Татарстан Республикасы, Самара һәм Ульян өлкәләре хөкүмәтләренә ярдәм сорап, мөрәҗәгать кабул иттеләр.

Халык шунда ук музей ачу өчен акча да җыя башлады. Кем күпме булдыра ала, кесәсендә күпме акчасы бар — барысын да әзерләнгән тартмага салып киттеләр. Ә беренче булып садаканы Яңа Җүрәй мулласы Хәмзә хәзрәт Ибәтуллин китереп бирде. *"Безнең мәчеткә йөрүче картлар, шул исәптән мин дә, Гакыйльне бик яхшы беләбез. Туганнары аны Яңа Җүрәй клубына еш кына алып киләләр, һәм ул безгә үзенең яңа шигырьләрен укый, халык белән аралаша торган иде"*, - дип юксынды ул шагыйрьне. Кулы җиңел булды Хәмзә хәзрәтнең. Ул көнне халыктан уникe мең сумнан артык акча җыелды. Аллаһы бирсә, киләчәктә бу изге гамәлне башкарудан түрәләр дә, укучыларыбыз да читтә калмаслар, дип ышанабыз.

Кызганыч, әмма газета бите кысалары чарада катнашкан кешеләрнең фикерләре, авыл клубында уздырылган шигърият кичәсе, шагыйрьнең туганнары Наил һәм Халидә Сәгыйровларның, Руслан һәм Гөлсинә Абдулганиевларның шушы хәтле күп халык өчен әзерләгән искә алу мәҗлесе турында тәфсилләп язарга мөмкинлек бирми.

Ә менә Самара шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе башкарма комитеты рәисе Рифкать Хуҗинга, район һәм авыл җирлеге җитәкчелегенең оештыру эшләрендә ярдәм итүе өчен аерым рәхмәтебезне җиткерәбез. Рифкать Туктаргали улы берничә көн алдан Кошки районына барып, җитәкчеләр белән күрешеп, сөйләшеп, барлык эшләрне дә оештырып кайткан иде.

Чараны алып баручы ирле-хатынлы Гакыйль һәм Рәйсә Шәкүровлар да рәхмәткә лаеклы. Алар икесе дә Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районы, Иске Исәнтимер авылы Мәдәният йортында эшләп, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәрләре дигән исемгә лаек булдылар. Алар гомер буе Гакыйль Сәгыйровның иҗатын пропагандалау белән шөгыльләнәләр. Һәвәскәр автор-башкаручы Гакыйль Шәкүровның репертуарындагы унбишләп җыр аның тарафыннан Гакыйль Сәгыйров сүзләренә язылган. Аларны еш кына татар радиосы һәм телевидениесендә популяр җырчылар башкаруында да ишетеп була. Менә бу чараны да җырчы һәм композитор "Җүрәем" җыры белән башлап җибәрде һәм үзенең башка җырларын да башкарды. Ә Рәйсә ханым Гакыйль Сәгыйровның шигырьләрен укыды. Ул аларның байтагын яттан белә. Шагыйрь исән чакта да аның тирәсендә булдылар алар

һәм хәзер дә аның истәлеген мәңгеләштерү буенча зур эшләр башкаралар.

Ульян өлкәсенең “Өмет” татар газетасы редакторы Исхак Хәлимов үзенең чыгышында: “*Бүген без изге җомга көнендә изге сүзләребез, изге догаларыбыз белән изге кешене искә алабыз. Ул олуг хөрмәткә лаеклы шәхесләребезнең берсе һәм халык күңелендә лаеклы урынга лаек.*

*Шулай ук мин остазыма — Рәфгать абый Әһлиуллинга, сокланиуымны белдерәм. Ул һәм Гакыйль Сәгыйров бүген өч өлкә вәкилләрен бирегә җыйдылар. Нәкъ Рәфгать абый безнең барыбызны да шагыйрьнең каберенә истәлек ташын куюга, аның истәлеген мәңгеләштерү эшенә алынуга этәрде. Аның гайрәте шушы йортны торгызып, музей ачарга да җитәр, дип ышанам. Ә без аңа булышырбыз*”, - дип сөйләде.

Язмамны Рәфгать Әһлиуллинның йомгаклап әйткән сүзләре белән тәмамлыйсым килә. Ул истәлек ташын куюга матди ярдәм күрсәтүчеләргә, чараны оештыручыларга, катнашучыларга, Казаннан, Самарадан, Ульяннан, Димитровградтан, Нурлаттан һәм башка төбәкләрдән килгән кунакларга, шагыйрьнең авылдашларына, туганнарына, якыннарына, йорт-музей булдыру турындагы башлангычны яклаучыларга рәхмәтләрен белдерде.

- *Гакыйль Сәгыйровның йорт-музее да ачылыр, авылларыбызда ябылган мәктәпләр дә яңадан торгызылып, анда татар теле дә укытылыр, җирләр мул уңыш бирер. Моңа ышанасы, өметләнәсе килә. Талантлы якташыбызның гүзәл иҗаты, яшәеше безгә үрнәк булып, юл күрсәтеп торырга тиеш*, - диде Рәфгать Нәбиулла улы.

Бу сүзләрне куәтләгәндәй шагыйрьнең йорты янындагы мәйданда мәрхүмнең рухына багышлап Коръән сүрәләре, ә Иске Җүрәй мәчете манарасыннан җомга намазына чакырып, моңлы азан яңгырады.

**Эльмира ШӘВӘЛИЕВА.**

(“Бердәмлек”, № 32, 06 август 2011 ел)

## ОБРАЩЕНИЕ

### Губернатору Самарской области Артякову Владимиру Владимировичу, Президенту Республики Татарстан Миннеханову Рустаму Нургалиевичу, губернатору Ульяновской области Морозову Сергею Ивановичу, членам правительств Республики Татарстан, Самарской и Ульяновской областей

*Сегодня, спустя два года после смерти известного татарского поэта и художника Гакиля Шарифулловича Сагирова, мы, члены Самарской областной, Самарской городской национально-культурных автономий татар, областного татарского общества “Туган тел”, региональной общественной творческой организации “Дуслык”, редакций областных газет “Бердэмлек” и “Азан”, все участники церемонии открытия памятного камня на могиле поэта обращаемся к вам с просьбой помочь в организации Дома-музея Гакиля Сагирова в селе Старое Фейзуллово Кошкинского района, где он прожил большую часть своей жизни.*

*Сын фронтовика, погибшего на войне, волею судьбы оставшийся без движения, он нашел в себе силы и научился писать и рисовать, зажав карандаш зубами. Благодаря упорству и таланту он стал настоящим поэтом и художником.*

*У члена Союза писателей Республики Татарстан, поэта, художника и журналиста Гакиля Сагирова восемь сборников стихов и рисунков, выпущенных в книжных издательствах Казани, Самары, Димитровграда и Ульяновска.*

*На разных языках разные люди, по сути, в один голос оценивают феномен Сагирова - его жизнеутверждающее творчество, пример человеческой стойкости и мужества как общенациональное наше богатство, как бесценное достояние разноязычного российского народа.*

*Подтверждают такую оценку и давно заслуженные художником награды. На Самарском Сабантуе он удостоен*

*звания Человек Года - за большой вклад в развитие национальной культуры, языка и за духовное объединение. Он лауреат Самарской областной общественно значимой Акции «Благородство», международной премии «Филантроп», премии имени Гаяза Исхаки Республики Татарстан и многих других литературных премий.*

*29 июля 2009 года, не стало этого сильного человека - творца и гения современности Гакиля Сагирова. Но еще так мало сделано для увековечивания его памяти, для сохранения его уникального творчества для наших потомков.*

*Оргкомитет по увековечиванию памяти поэта и художника Гакиля Сагирова призывает правительства Самарской, Ульяновской областей и Республики Татарстана и всех, кто неравнодушен к его творчеству, откликнуться сердцем на это обращение и оказать содействие в открытии Дома-музея поэта, выделить средства на реставрацию дома в селе Старое Фейзуллово Кошкинского района Самарской области.*

*Имя Гакиля Сагирова будет хорошим примером для воспитания молодежи в духе патриотизма, дружбы между народами и покажет, как надо преодолевать жизненные трудности и невзгоды.*

**Обращение обсуждено и принято на церемонии открытия памятного камня на могиле поэта Гакиля Сагирова 29 июля 2011 года в селе Старое Фейзуллово Кошкинского района Самарской области.**

# “Каурый каләм эзеннән”

## (Гакыйль Сәгыйровны искә алып)

Ульяновск шәһәренең татар мәдәнияте үзәгендә өлкә татар язучыларының «Каурый каләм эзеннән» дип исемләнгән I форумы булып узды. Өлкә татар милли-мәдәни автономиясе, «Өмет» газетасы редакциясе һәм татар мәдәнияте үзәге тырышлыгы белән оештырылган әлеге очрашуда мөхтәрәм кунаклар - Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей Морозов, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе вәкилләре - Данил Салихов, Эльмира Шәрифуллина да катнаштылар.

Форум кунакларын иң әүвәл легендар шәхес - каһарман шагыйрь һәм рәссам, «Филантроп» халыкара премиясе лауреаты Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровның иҗат җимешләре - каләмне тешләре арасына кыстырып ясаган рәсемнәре күргәзмәсен ачу тантанасы көтә иде. Иҗат әһеленең 75 еллык юбилеена багышланган әлеге күргәзмәдә ике дистәдән артык рәсем урын алган. Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Рамилә Сафина беренче булып каһарман милләттәшебезнең тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырып үтте. Аннары тантанада катнашучыларны Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей Морозов сәламләде.

*- Геройлары, нык ихтыяр көченә ия шәхесләре булган милләтләрнең генә тарих сәхифәләрендә үз урыны бар. Татар халкы бу яктан бик тә бәхетле - ул Тукай, Җәлил, Гакыйль Сәгыйров кебек каһарманнары белән чиксез горурланып яши. Димитровград шәһәре мэры булып эшләү дәверендә миңа да Гакыйль Шәрифулла улы белән якыннан аралашырга, аның иҗат кичәләрендә, юбилей бәйрәмнәрендә катнашырга насыйп булды. Һәрвакытта да аның батырлыгына, актив тормыш позициясенә, иҗади осталыгына соклана һәм таң кала идем,* - диде губернатор.

Өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рамис Сафин исә төбәгебез татарлары турында һәрдаим кайгыртучанлык күрсәтүе өчен губернаторга рәхмәт сүзләрен ирештереп, күргәзмәдә урын алган рәсемнәрнең мәдәният үзәге фондында сакланачагы хакында хәбәр итте.

Гакыйль ага Сәгыйровның бертуган энесе Наил абыйның чыгышы да күпләрнең игътибарын җәлеп итте.

*- Абыем илле елдан артык урын өстендә ятты. Ул шигырьләр язу, рәсемнәр ясау белән генә чикләнмичә, телевизорлар һәм радиоалгычлар да ремонтлый, авыл балаларын фоторәсемгә төшерергә һәм гармунда уйнарга да өйрәтә иде. Рәсемнәрен гади карандаш белән генә түгел, ә каләмне тушька манып та ясый иде. Бүген аның иҗат җимешләренең төп нөсхәләре гаиләбез архивында саклана. Әгәр туган авылыбыз Иске Җүрәйдә шагыйрьнең музей-йорты ачылса, һичшиксез, аларны шунда тапшырачакбыз,* - диде Наил абый.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Данил Салихов та төбәгебез башлыгы Сергей Морозовка рәхмәт сүзләрен җиткерергә ашыкты.

*- Милләтебез каһарманы Гакыйль Сәгыйровның иҗаты белән кызыксынуыгыз, татарларга карата уңай, җылы мөнәсәбәттә булуыгыз, менә шушы мәһабәт бинаны - мәдәният үзәген автономия карамагына тапшыруыгыз өчен олы рәхмәтебезне кабул итеп алсагыз иде. Сез Россиянең бик күп төбәкләре җитәкчеләре өчен үрнәк булып торасыз,* - диде мәркәзебез Казан кунагы губернаторга мөрәҗәгать итеп.



**Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей МОРОЗОВ** (уңда) **Гакыйль СӘГЫЙРОВның рәсемнәр күргәзмәсен ачканда татар җәмәгатьчелеге вәкилләре белән.**

Ә Сембер шагыйрәсе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Иделбикә каләмдәше Гакыйль Сәгыйровның китапларын бастырып чыгаруга һәм аңа «Ока» машинасы бүлеп бирүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен вакытында үзенең бик күп түрәләрнең ишекләрен шакуы турында сөйләде.

Тантананың ахырында милләтпәрвәр Розалия Матросова һәм мәдәният үзәгенең «Хыял тамчылары» ансамбле солистлары Айгөл Альметова белән Алсу Сәлахетдинова Гакыйль Сәгыйровның гаҗәеп дәрәҗәдә тирән эчтәлекле шигырьләрен яңгыраттылар. Ә Сембер татар сәхнәсе йолдызы Алсу Альметова Гакыйль Сәгыйров сүзләренә иҗат ителгән җырлар белән сөендерде.

Зәвыклы итеп әзерләнгән күргәзмә белән танышканнан соң, Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей Морозов, Татарстан вәкилләре һәм язучылар форумында катнашучылар мәшһүр әдип һәм мәгърифәтче Кол Гали һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

**Исхак ХӘЛИМОВ.**

(Бердәмлек, №12, 16 март 2013 ел).

# Без татарлар бит әле!...

Шундый шигарь астында Ульян өлкәсе Димитровград шәһәренең “Восход” Мәдәният сараенда каһарман якташыбыз Гакыйль Шәрифулла улы СӘГЫЙРОВның 75 яшьлек юбилеена багышланган кичә уздырылды. Мондый чаралар инде гадәткә кереп һәр биш ел саен даими үткәрелеп килделәр. Тик каһарман якташыбызның 70 еллык юбилее аның исән чагында соңгысы булган икән. Ә бу юлы чараны юбилярның үзеннән башка гына үткәрергә туры килде. Кичәне оештыручылар, аның җомга, эш көнендә үткәрелүе сәбәпле, халык җыелырмы икән, дип бераз борчылганнар да иде. Шагыйрьнең үзен күреп белүчеләр саны да ел саен артмый, кими бара бит.

Юк, борчыласы булмаган икән, билгеләнгән вакытка Мәдәният сарае фойесында басарга да урын калмаган иде инде. Кичәгә килүчеләр Гакыйль Сәгыйровның иҗатына багышланган күргәзмәләр белән таныштылар. Анда аның китаплары, рәсемнәре куелган иде.

Шушында ук якташыбызның иҗаты турында фикер алышулар башланып китте. Кайберәүләр аларны Татарстанның “Яңа гасыр” телевидениесе журналистларына да белдерделәр.



**Фойеда** (сулдан уңга) **Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН, Наил СӘГЫЙРОВ, Риваль ИДРИСОВ шагыйрьнең рәсемнәре күргәзмәсе янында.**

Шагыйрьнең шигыреннән алынган “Без татарлар бит әле...” юллары белән исемләнгән кичә Гакыйль Сәгыйров озак еллар яшәгән Иске Фәйзулла авылының матур табигать күренешләре һәм аның үзе төшерелгән видеоязманы карау белән башланып китте. Алып баручылар - Гакыйль Сәгыйровның иҗатын даими пропагандалаучы Равил Шәфигуллин һәм Фәния Хәлиуллова тагын бер кат аның тормыш һәм иҗат юлын тамашачыларның исенә төшерделәр, шигырьләрен укыдылар.

Беренче сүз Димитровград татарларының җирле милли-мәдәни автономиясе рәисе Фәрит Хәлиуллинга бирелде. Ул каһарман якташыбызның таланты, батырлыгы белән горурлануы, соклануы турында белдерде, шагыйрьнең киң кырлы иҗатын халык арасында тагын да ныграк пропагандалау кирәклеге турында әйтте.

Тәбрикләү сүзләре белән шулай ук Димитровград шәһәре администрациясе башлыгы урынбасары Ирина Баканова, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының мәгълүмат бүлеге җитәкчесе Гөлназ Шәйхи, Ульяновск өлкәсе татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе Рамис Сафин, “Өмет” татар газетасы мөхәррире Исхак Хәлимов, Димитровград шәһәренең 22 санлы татар мәктәбе директоры Мөнирә



**Шагыйрьнең җиңгәсе Халидә ханымга Димитровград шәһәр татар милли-мәдәни автономиясенең бүләген тапшырганда.**

Җумаева, Димитровград шәһәре татар милли-мәдәни автономиясенең почетлы рәисе Риваль Идрисов чыгыш ясадылар һәм бүләкләрен тапшырдылар.

Димитровград шәһәре татар милли-мәдәни автономиясе исеменнән бүләкләнүчеләр арасында шагыйрьне исән вакытында карап-тәрбияләп торган туганнары — энесе Наил һәм җиңгәсе Халидә дә бар иде. Алар сәхнәгә күтәрелгәндә зал көчле алкышларга күмелде.



**Данияр СӘЙФИЕВ бүләккә Самара Җәмигъ мәчете сурәте төшерелгән келәм тапшыра.**

Самарадан бу кичәгә без өчәү — өлкә "Туган тел" татар җәмгыяте директоры Данияр Сәйфиев, мин — "Бердәмлек"нең баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин һәм "Дуслар клубы" дип аталган татар яшьләре оешмасы җитәкчесе Рамил Фәрзетдинов бардык. Данияр Сәйфиев өлкә "Туган тел" татар оешмасы исеменнән шагыйрьнең иҗатын актив пропагандалаулары өчен Димитровград шәһәре татар мәктәбе коллективына (директоры Мөнирә Җумаева) Самараның Җәмигъ мәчете рәсеме төшерелгән келәм, ә "Сүнмәс йолдызлар" ансамбленең сәнгать җитәкчесе, җырчы Фәния Хәлиуллловага чәй чынаяклары бүләк итте. Без үзебезнең чыгышларыбызда якташыбызны, аның иҗатын онытмаулары өчен шәһәрнең татар милли-мәдәни автономиясе җитәкчелегенә, гомумән, бөтен Димитровград халкына рәхмәт сүзләребезне белдердек. Гакыйль Сәгыйровка хәзер артык зур тантаналар да, мактау да кирәк түгел инде. Бу безнең үзебезгә, бүген дөньяда яшәүчеләргә, бигрәк тә яшьләребезгә кирәк.

Үткән елны Самара эшкуарлары ярдәме белән шагыйрьнең зиратына истәлек ташы куйган идек. Хәзерге вакытта аның ачы язмышлы сикәлтәле тормыш һәм иҗат юлы турында документаль китап язып дөньяга чыгарырга планлаштырабыз. Шагыйрьнең Иске Фәйзулладагы өендә аның музеен оештыру

да көн үзәгендәге мәсьәләләрнең берсе булып тора. Каһарман якташыбызның исемен мәңгеләштерүне һәрберебезнең изге бурычы итеп санарга кирәктер. Әлегә без аның алдында зур бурычлы булып кала бирәбез. Бу фикер күпчелек чыгыш ясаучыларның фикерләренә дә тәңгәл килә иде.

Ә менә алдан ук юбилей кичәсенә чакыру алган, 300ләп әгъзасы булган Татарстан Язучылары берлеге җитәкчелеге үзенең бер генә вәкилен дә кичәгә җибәрмәгән, бары котлау хаты белән генә чикләнгән. Ә Гакыйль Сәгыйровның иҗаты бу мәртәбәле оешма тарафыннан тиешле бәя алырга бик тә хаклы.

Бәйрәм (кичә чын бәйрәмгә әверелде, дисәң дә ярыйдыр) шагыйрьнең шигырьләрен укып, аның сүзләренә язылган җырларны башкару белән үрелеп барды. Шигырьләрне мәктәп укучылары да, өлкән яшьтәгеләр дә укыдылар. Җитмеш яшьлек Роза апа Гайнуллина Гакыйль Сәгыйровка багышлап үзе язган шигырен сөйләп биргәннән соң, зал тагын бер кат көчле алкышларга күмелде. “Сүнмәс йолдызлар”, “Карлыгачлар”, “Сандугачлар”, “Сөембикә” җыр, “Ясмин” бию ансамбльләре башкарган халык җырларын да, биюләрне дә, юбиляр иҗат иткән шигырьләргә композиторлар язган җырларны да тамашачы яратып каршы алды.

Мондый халкыбыз булганда каһарман якташыбызның шигырьләре дә онытылмас, туган телебез дә яшәр. Шагыйрьнең үзеннән башка әле беренче тапкыр гына үткәрелгән бу юбилей кичәсе нәкъ менә шушы хакыйкатьне раслады түгелме? Әйе, бу шулай булырга тиеш тә, чөнки шагыйрьнең үзе әйткәнчә, “Без татарлар бит әле...”

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

# Тик нигәдер вәгъдәләр бирешәбез дә, онытабыз...

Әле кайчан гына Иске Җүрәйнең яшел хәтфәдәй үлән белән капланган урамнары буйлап Хәбибҗамал апа белән аның каһарман улы шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сәгыйров яшәгән бу йортка беренче очрашуга барган идем. Вакыт үтмәгән дә кебек.

Ә аннан соң күренекле якташыбыз белән әле күпме очрашулар, күрешүләр булды, шагыйрьнең иҗатына багышланган кичәләрне, аның юбилейларын Самарада да, Димитровградта да үткәрергә насыйп итте Ходай. Ә моннан нәкъ биш ел элек, 2009 елның 30 июлендә, без аны 71нче яшь белән барганда Иске Җүрәй авылы зиратында җир куенына куйдык.

Татарстанның Нурлат районындагы кечкенә генә Әхмәт авылында туып, анда балачак еллары үткән булса да, ул нигәдер озак еллар гомер кичергән әнисе Хәбибҗамал апаның туган авылы Иске Җүрәй авылын якын күрә иде. Соңгы елларын Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә үткәрсә дә, ул үзен Иске Җүрәйдә күмәргә васыять әйтеп калдырды.

Вафатына ике ел узгач, каберенә Самара, Ульян өлкәләре, Димитровград шәһәре, Нурлат районы татар җәмәгатьчелеге вәкилләре, Татарстан Язучылары берлеге әгъзалары катнашында истәлек ташы куелды. Ә менә хәзер, биш елдан соң, без яңадан аны искә алу, каберен зиярәт итү өчен бирегә җыелдык.

Самарадан да, Димитровградтан да, Нурлаттан да шагыйрьне якын итүчеләр, аның иҗатын чын-чынлап аңлаучылар, яратучылар килгән иде. Казаннан язучылар, Кошки районыннан администрация вәкилләре, чакырылган булсалар да, күренмәделәр. Хәер, татар язучылары Гакыйль Сәгыйровның вафатыннан соң Димитровградта үзеннән башка беренче тапкыр уздырылган 75 яшьлек юбилеена да килмәгәннәр иде бит. Бу юлы да, вафатына биш ел тулу уңаеннан искә алуга чакыргач, артык зур теләкләре барлыгы сизелмәде. Югыйсә, 300ләп әгъзасы саналган Татарстан Язучылар берлегеннән бирегә килергә бер-ике кешене табарга мөмкин булгандыр бит.

Дөньяда чагында язмыш тарафыннан рәнҗетелеп, шундый авыр тормышта яшәүче шагыйрьгә тиешле хөрмәт, ярдәм күрсәтелмәгәч, хәзер бакыйлыкка күчкәч, ул кемгә кирәк?

Мәрхүмнең сайланма әсәрләрен туплап, Татарстан нәшриятында берничә китабын бастырып чыгарырга мәдәният министрлыгы тарафыннан вәгъдә ителсә дә, бу да һаман эшләнмәгән. Вафатына ике ел чамасы калгач, шагыйрь Татарстан Язучылар берлегенә үзе илтеп тапшырган балалар өчен язылган ике китабы кульъязмаларының да язмышы билгесез. Югыйсә, икесен дә бастырырга вәгъдә ителгән булган, бу турыда төрле басмаларда хәбәрләр дә урнаштырылган иде бит. Бәлки, Язучылар берлегенең күпсанлы шүрлекләрендә бүген дә алар тузан җыеп ята торгандыр яисә (кем белә) куллары туры түгел бәндәләр үз максатларында файдаланганнардыр, дип тә уйлап куясың. Башка шундый күңелсез уйлар да килде Иске Җүрәйгә баргач.

Кошки районы администрациясе һәм мәдәният идарәсе вәкилләренең бу чарада катнашмауларын да аңлавы кыен. Мөһим эшләр килеп чыгу сәбәпле, соңрак булса да искә алу чарасына барыбер киләчәкләрен белдергәннәр иде бит. Самара төбәгендәге милли оешмаларның кайсыбер зур җитәкчеләренең дә шагыйрьне искә алуга, аның исемен мәңгеләштерү мәсьәләләренә битарафлык күрсәтүләре сизелде.

Ни генә булмасын, каһарман шагыйрьне искә алу чарасы югары дәрәҗәдә узды. Башта авыл халкы, килгән кунаклар




**Нурлатлылар шагыйрьнең каберенә чәчәкләр куйганда.**

шагыйрьнең җимерелеп баручы ятим калган йорты янына җыелып сөйләштеләр, аннан авыл зиратына каберен зиярәт кылырга юнәлделәр.

Нурлатлылар - район мәдәният идарәсе хезмәткәре Әлфия Галәүтдинова һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының район бүлеге җитәкчесе Фәридә Сәгыйрова шагыйрьнең кабере өстенә кәрзин белән ак чәчәкләр бәйләмен куйдылар. Самара өлкәсе мөселманнарының региональ Диния нәзарәте президиумы әгъзасы, “Болгар яңарышы” мәчете имам-хатыйбы Расих хәзрәт Вакказов һәм Иске Җүрәй авылы мәчете имамы Габделхәй хәзрәт Халитов шагыйрьнең рухына багышлап Коръән сурәләре укып, дога кылдылар.

Шагыйрьнең Димитровградта яшәүче Наил энесе һәм Халидә җиңгәсе уллары Рафаэль, Ринат, Марат белән бергәләп (Әстерхан шәһәрендә гомер итүче Рафаэль Гакыйль абыйсын искә алу өчен махсус кайткан) якын туганнары Руслан һәм Гөлсинә Абдулганиевлар өендә аларның ярдәме белән зур Коръән мәҗлесе әзерләгән иделәр. Ул да бик тә матур үтте. Расих хәзрәт бөтен кешегә аңлаешлы итеп вәгазь сөйләде, догалар укыды.

Ә инде Иске Җүрәй мәчетендә көндезге намаз укылганнан соң, барысы да авыл клубына җыелдылар. Аның хезмәткәрләре (клуб мөдире Рәфисә Минебаева) Гакыйль Сәгыйровның иҗатына һәм тормышына багышланган стенд әзерләгәннәр, китапларын күргәзмәгә куйганнар иде.

Очрашу барышында күп истәлекләр сөйләнде, шагыйрьнең иҗатын озак еллар дәвамында пропагандалаучы якын дуслары һәм фикердәшләре - Ульян өлкәсе Яңа Малыклы районының Урта Исәнтимер авылы Мәдәният йортында эшләүче, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәрләре ирлехатынлы Гакыйль һәм Рәйсә Шәкүровлар башкаруында Гакыйль Сәгыйровның шигырьләре һәм аның сүзләренә язылган җырлары яңгырады. Аларның репертуарында шагыйрьнең төрле темаларга багышланган шигырьләре, Гакыйль Шәкүров иҗат иткән унбиштән артык җыр бар. Очрашуга җыелган авыл халкы һәм кунаклар аларның һәрберсен тын да алмыйча тыңлады, көчле алкышларга күмде.

Ә истәлекләр бер-бер артлы агылдылар да агылдылар гына. Самараның “Яктылык” татар мәктәбендә күп еллар татар теле укытучысы булып эшләүче Нурзидә Фәйзуллина үзенең әле үткән гасырның җитмешенче елларында Арча педагогия учи-

лицесында укыганда беренче тапкыр Гакыйль Сәгыйровның “Тормыш җиле” китабындагы шигырьләрен укуын хәтеренә төшерде, соңрак курсташы Нина Андрееваның Иске Җүрәй авылы мәктәбендә укытучы булып эшләве һәм аның очрашканда гаҗәеп шәхес — Гакыйль Сәгыйров турында сөйләвен искә алды. Нинага шагыйрь үзенең бер шигырен дә багышлаган булган. Шуннан бирле Нурзидә ханым Гакыйль Сәгыйровның иҗатына мөккибән, аның батырлыгы белән горурланып, шагыйрьнең иҗатын “Яктылык” мәктәбендә укучы балаларга пропагандалауны үзенең төп бурычларының берсе итеп саный, мәктәптә аның музеен ачу турында хыяллана.

Ә менә Нурлат районының Гакыйль Сәгыйров бишенче-алтынчы сыйныфларда белем алган Әхмәт авылыннан биш чакрым арада урнашкан Бикколда мондый музей бар икән инде. Бу хакта җирле авыл советы рәисе Рәйсә Әхмәтшина, күрше Фомка мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Бикколда шагыйрьнең музеен һәм шәхси сайтын оештыручыларның берсе - Гөлүсә Әһлиуллина сөйләделәр. Очрашудан кайткач ук, шушы сайтка кереп карадым. Чыннан да бик шәп музей һәм сайт оештырганнар нурлатлылар. Безгә дә алардан калышмаска иде.



**Рәйсә һәм Гакыйль ШӘКҮРОВЛАР башкаруында шагыйрьнең шигырьләре, җырлары яңгырады.**



**Нурзидә ФӘЙЗУЛЛИНА һәм Разия ӘЮПОВА шагыйрьнең ятим калган өе алдында.**

Очрашуда кем генә сүз алып сөйләмәсен, барысы да Иске Җүрәйдә (Иске Фәйзуллада) Гакыйль Сәгыйровнның йортын торгызып, анда аның шәхси музеен ачу проблемасына тукталды, үзләренең уй-фикерләре белән уртаклашты.

Димитровград шәһәре вәкилләре - җирле татар милли-мәдәни автономиясенең мактаулы җитәкчесе Риваль Идрисов, шагыйрь, Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы, берничә шигырьләр җыентыгы авторы Равил Шәфигуллин яшь буынны тәрбияләүдә Гакыйль Сәгыйровнның иҗаты һәм тормышы зур әһәмияткә ия булуын билгеләп үттеләр. Әгәр Иске Җүрәйдә аның йорт-музее ачылса, бу эшнең яңа баскычка күтәреләчәгенә басым ясадылар, шулай ук аның музейларын Самарада да, Димитровградта да, Ульяновскида да татар мәктәпләрендә булдыру кирәклеге турында да әйттеләр. Димитровград татарлары, әгәр ярдәм кирәк булса, бу эштән читтә калмаячакларын белдерделәр.

Самара өлкәсе хатын-кызларының “Ак калфак” оешмасы җитәкчесе, “Розалина” татар кафесы хуҗабикәсе Разия Әюпова бу оешманың филиалы Иске Җүрәйдә дә оештырылуы турында әйтте. “Хатын-кызлар оешмасы бик зур әһәмияткә ия һәм аңа без зур өметләр баглыйбыз”, - диде ул. Гакыйль Сәгыйровнның

музеен ачу өчен ярдәм сорап губернаторыбыз Николай Иванович Меркушкинга тагын мөрәҗәгать итәргә чакырды.

- *Ул, һичшиксез, булышачак. Ә калганы барысы да үзебездән - татарларыбыздан тора. Бу йортны халыктан, байларыбыздан ярдәм сорап, өмәләр үткәреп тә торгыза алабыз*, - дип белдерде Разия ханым.

Самара өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясенең башкарма директоры Шамил Галимовның да фикерләре әйтелгәннәр белән тәңгәл яңгырады. Чыннан да бу шулай ич. Теләк булса, барысы да үз кулыбызда, моның өчен бары теләк кенә, татарларыбызга бердәм булу гына кирәк.

Җир биләмәсен йортны шәхси милектән авыл җирлеге милегенә күчерү озакка сузылу сәбәпле, эш һаман арткы планда кала бирде. Хәзер барысы да эшләнгән, тик менә тиешле карар чыгару гына һаман сузыла. Бу эшне ничек тә тизләтәсе иде.

Дөрес, авыл җирлеге башлыгы Равил Минебаев үзенең чыгышында, хәзерге вакытта район мәдәният идарәсе шагыйрьнең йортын төзекләндерү һәм анда музей ачу өлкәнең "Авыл туризмы" проекты программасына кертеләчәге һәм моның мәдәният министрлыгында да хуплау табуы турында белдерде. Әгәр бу шулай булса, бик шәп, әлбәттә.

Тик нигәдер очрашкан саен вәгъдәләр бирешәбез дә, аннан онытабыз. Бу юлы да шулай гына булып калмаса ярар иде.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН.**

("Бердәмлек", август 2014 ел).

# Гакыйль Сәгыйров турында китап, ниһаять, дөнья күрәчәк

Өлкә губернаторы Николай Иванович Меркушкин бер төркем мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә губерна бүләкләрен һәм грантларын тапшырды. Бу бүләкләр өлкәбездә 2003 елдан бирле бирелеп килә инде. Ә 2014 елда губернатор карары буенча аларның саны икеләтә арттырылган һәм бу юлы егерме кешегә бирелде.

Барлыгы 29 кеше бүләкләнеп, беренче булып премия Алла Шелест мәктәбенең классик балет традицияләрен үстергән өчен Россиянең атказанган артисты Ольга Бараховскаяга тапшырылды. Ул Куйбышев шәһәренә (хәзерге Самарага) моннан 44 ел элек Ленинградтан күчеп килгән һәм үзенең моңа беркайчан да үкенмәвен белдерде, иң яхшылардан саналган опера һәм балет театрында эшләве белән горурлануын әйтте. Губерна бүләгенең тагын бер лауреаты Жигулевск шәһәренең мәдәният бүлеге хезмәткәре Мария Жукова регион башлыгына “Россиянең йөрәгендә туганнар” дип аталган милләтара фестивальне үткәрүдә иҗади инициатива күрсәтүе өчен рәхмәт сүзләрен белдерде. Большая Глушица районында эшләүче хормейстер Александр Дмитриев та авылларда яшәүчеләргә игътибарлы булуы өчен губернаторга рәхмәтле.

Губерна бүләкләреннән тыш, әле тагын тугыз кеше һәм оешма мәдәният һәм сәнгать грантларына ия булды. Шулар арасында өлкә татар милли-мәдәни автономиясенә бирелгән “Гакыйль Сәгыйров үзе турында һәм барсы да аның турында” дип аталган проектның авторы һәм җитәкчесе, “Бердәмлек” өлкә татар газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин да бар иде. Өлкә губернаторы Николай Иванович Меркушкин кулыннан сертификат кабул итеп, ул өлкә башлыгына һәм мәдәният министры Ольга Васильевна Рыбаковага рәхмәт сүзләрен белдерде. Татар җәмәгатьчелеге вәкилләренең каһарман якташыбыз, күренекле татар шагыйре һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровның тормыш юлы һәм иҗаты турында мондый китапны нәшер итү

турында әле аның үзе исән чагында ук хыяллануы һәм менә, ниһаять, бу хыялның тормышка ашачагына шатлануы турында әйтте. Бу Гакыйль Сәгыйровның исемен мәңгеләштерүгә тагын бер адым булачак. Ә алда тагын бер зур бурыч тора - Кошки районының Иске Фәйзулла авылында шагыйрьнең йортына ремонт ясатып, анда аның музеен ачу. Өлкә мәдәният министры Ольга Васильевна Рыбакова бу эштә үзенең ярдәм күрсәтәчәген белдерде.

**Рәфыйк НАРИМАНОВ.**


Правительство Самарской области

КОНКУРС НА СОИСКАНИЕ ГУБЕРНСКИХ ГРАНТОВ
В ОБЛАСТИ КУЛЬТУРЫ И ИСКУССТВА
ЗА ПЕРВОЕ ПОЛУГОДИЕ 2015 ГОДА

ГРАНТОВЫЙ
СЕРТИФИКАТ

Грант № 24Г–2

ПРИСУЖДЕН ПРОЕКТУ
Издание книги
«Гакиль Сагиров – о себе и все о нем»

ГРАНТОПОЛУЧАТЕЛЬ
Самарская областная татарская
национально-культурная автономия

Руководитель проекта
Аглиулин Рафгат Набиулович

Губернатор
Самарской области

Н.И.Меркушкин

г. Самара
2015 г.

# Йомгаклау сүзе

Менә башланган эшкә йомгаклау сүзен әйтер вакыт та җитте. Гакыйль Сәгыйров кебек каһарман шәхеснең тормышы, иҗаты турында язу, аны укучыларга җиткерү ансат түгеллеген әле хәзер генә аңлый, төшенә башладым кебек. Шулай да булган мәгълүматларны, шагыйрьнең үзе турында, якыннары, бергә яшәгән, аралашкан кешеләр турында язып калдырган истәлекләре, хатирәләре укучыларыбызга кызыклы булыр, дип өметләнәм. Аның турында башкаларның әйткән уй-фикерләре дә, күрсәтелгән мәгълүматлар да халык күңеленә барып җитеп, үз урынын һичшиксез табачак әле.

Бәлки, киләчәктә Гакыйль Сәгыйров кебек феномен турында башкача, тулырак итеп, аның кичерешләрен ныграк чагылдырган язучылар да булыр. Шуңа күрә китапта кимчелекләр табучылар да табылыр, чөнки бу олуг шәхеснең тормышы турында язу, моны бүгенгесе көнне аягына гына баса башлаган, бу дөньяга киләсе сабыйларга да җиткерү безнең барыбызның да изге бурычы булырга тиеш.

Гакыйль Сәгыйровның үткән гасырның алтмышынчы еллары ахырында, язмыш тарафыннан зур фаҗигагә дучар ителгәннән соң көндәлекләрендә язып калдырган тормыш турындагы уйлары гына да тетрәндергеч. Менә шул юлларны биредә сезгә дә җиткерәсе килә:

*“Нәрсә ул тормыш? Нәрсә ул яшәү? Бу сораулар гасырлар буена кешелекне борчып килгән. Зур галимнәр, акыл ияләре аның күптөрле ягын ачып күрсәткәннәр, мәшһүр язучылар калын-калын китаплар язганнар. Николай Островскийның да ул турыда әйтелгән канатлы сүзләре бар — ул һәркемгә билгеле. Кеше туа. Һәрнәрсәнең дә чиге булган кебек — гомер дә ул сыйфаттан читтә кала алмый. Кеше яши һәм беркөнне юкка чыга. Бу гасырлар буена шулай дәвам иткән һәм итәчәк. Безгә кадәр Җир өстендә күпме кеше яшәп киткән, без яшибез. Бездән соң мең ел үтәр, кешеләр ул вакытта да яшәячәкләр. Әмма без ул көннәрне күрмибез дә, хыялыбызга да китерә алмыйбыз. Ул кешеләр безне гомуми исем белән генә — егерменче гасыр кешеләре дип атаячаклар, ул көннәргә безнең дәвер кешелек дөньясыннан берничә йөз*

*кешенең исеме генә барып җитәчәк. Ә без бүгенге дөньяда 3 млрд. кеше яшибез бит! Йөрибез, эшлибез, көләбез, шатланабыз, биибез, елыйбыз, укыйбыз, кайгырабыз һәм әле тагын иксез-чиксез эшләр эшлибез, хыялланабыз, уйлар уйлыйбыз. Боларның барысын да, безнең һәр адымыбызны вакыт агым су кебек үзенең төпсез хрусталь чоңгылына алып китә бара. Без эшләгән эшләребезне, уйлаган уйларыбызны, кино карагандай, күз алдыннан үткәрә алабыз, тик аларның сурәтләре нур булып аңга сеңеп калган, ә җисемнәрен вакыт урлаган була. Җыр кыска, дөрес әйтә:*

*Үткән гомер кире кайтмый,*
*Сулар борылып акса да.*

*Вакыт - аяусыз рәссам, аны алдау, аның игътибарыннан читтә калу мөмкин түгел. Безнең планетабыз бик кечкенә, тик үзебезгә җитәрлек, акыллы булганда. Җир өстендә һәр кешегә дә бәхетле тормыш кичерергә мөмкинлек бар. Бер-береңә яхшы мөгамәләдә булу, икенче берәүгә һәрвакыт кирәк булу, күңелеңдә дуслык, туганлык хисе саклау! Бу турыда кемнәр генә язмады, кемнәр генә сөйләмәде! Яшәлгән һәр минутың гомереңнең бер кисәкчеге бит ул. Син башкаларның шатлыгын сакларга, үзең дә шуннан ләззәт табарга тиешсең. Шушы кыска гына гомеребезне күбрәк башкаларга файдасы тиярлек итеп яшәргә тиешбез. Гомернең озынлыгы, яшәүнең мәгънәсе шунда. Дусларың, туганнарың, кешеләр күңелендә үзең турында яхшы истәлек, җир өстендә матур эшләрең калса, үләргә дә куркыныч түгел. Кешенең гомере калган истәлеккә, кылган эшләренә бәйләнгән. Без — егерменче гасыр кешеләре, тарихка шул гомуми исем астында керәчәкбез. Тик безнең һәрберебезнең үз шәхесе бар, үз туганнары, үз дуслары, үз кайгысы, үз тормышы бар: үз иле, үз туган җире бар..."*

Менә нинди тирән мәгънәле сүзләр әйтеп калдырган безгә шагыйрь. Аның һәр шигырендә дә зур фәлсәфә ярылып ята. Шуларны укыйсың да, уйга чумасың: "Киләчәктә безнең туган илебез нинди булыр?" Шунда ук күңел бу сорауга җавап та бирә: "Бүгенге сабыйлар кем булып үссәләр — үзләренең тамырларын белеп үссәләр яисә манкортка әйләнсәләр, илебез дә шундый булыр".

Илебезнең, халкыбызның киләчәге үз кулыбызда. Барыр юлыбызда каһарман якташыбыз - Гакыйль Сәгыйровның күпләребезгә үрнәк булырлык тормышы якты маяк булып янарга тиеш. Ә моның өчен аның тормышын, иҗатын ныклап өйрәнергә, исемен мәңгеләштерергә һәм киләсе буыннарга да түкми-чәчми җиткерергә кирәк.

Кешелек дөньясы яшәгән вакытта тарих дәвам итә. Безгә алмашка киләчәк буын кешеләре Гакыйль Сәгыйров феномены турында тулырак итеп, аңлаешлырак итеп тә язарлар әле, дип ышанасы килә.

Ә бу беренче китапны язуда, төзүдә һәм дөньяга чыгаруда ярдәм итүчеләргә, бигрәк тә өлкә хөкүмәтенә чын күңелдән рәхмәт әйтергә кирәк.

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН,**
**проектның җитәкчесе һәм китапның авторы.**

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз ........................................................................ 5
Әхмәт авылында башланган тормыш ......................................9
Утлы кәгазь ......................................................................27
Укытучы апа һәм мин .......................................................31
Ике прәннек, бер кап шырпы һәм бер стакан .......................36
Беренче саф мәхәббәт .......................................................41
Кунакчыл, якты чырайлы монда һәрбер бусага... ..................43
Яшьлек канатланганда .......................................................52
Шулай да була.....................................................................60
Матур, кайнар мәхәббәт көтә иде Эля! ..................................61
Ут эчендә янсам да мин, ахыры яшәп туймамдыр... ...............70
Без аның янына вертолетта очып барган идек... .....................85
Ул чын ир-егет иде ............................................................90
Бу сәяхәттән без яңа шагыйрь алып кайттык... .....................92
Ул язгы кояшлы көн әле дә исемдә .......................................97
Юныс - Пәйгамбәр исеме ....................................................99
Милләтебез яшәсен дисәк... ...............................................105
Чын бәхетне белгән кеше ...................................................109
...Күпме әле яңа җыр язасы бар... ......................................113
Лимонлы чәй .....................................................................119
Безне дөньяда изгелек яшәтә түгелме?! ...............................121
Сагынам авылымны ...........................................................126
Минем күршем ...................................................................128
Кеше була белик... ............................................................131
Яшәвебез юкка түгелдер... .................................................133
Кызыл розалар ..................................................................142
Бар да якын туган якның бизәге... ......................................146
Самара өлкә Сабан туенда — рәсемнәр күргәзмәсе .................152
Алты лауреат арасында .....................................................154
Сизгер зиһенле Гакыйль ....................................................157
Гакыйль рәсемнәре ...........................................................162
Ике кояш бар дөньяда... .....................................................168
Изгелек һәм игелек бергә йөри ..........................................174

Гакыйль СӘГЫЙРОВ:
“Мәскәүдә яхшы, ә өйдә - әйбәтрәк” ....................................179
Шагыйрьнең йөрәк авазы ....................................................186
Әдипләр салган дуслык күпере ...........................................190
Ул яшәгән йорт таралмасын иде ..........................................192
Табигатьнең нурлы җырчысы .............................................197
Елавык көннәр хатирәсе ......................................................202
Иртәгәме? Нигә — иртәгә? ..................................................210
Кыядагы көчле бөркет кебек ................................................213
Чын кеше булу өчен нәрсә кирәк? .......................................217
“Бердәмлек” безнең ярдәмгә мохтаҗ ....................................219
Гакыйль дустыбыз — бездә кунакта ....................................222
Йөрәк серен ачканда ...........................................................224
Аның тормышы һәм иҗаты - безгә үрнәк ..............................226
Бер көрешү - үзе бер гомер ..................................................228
Халкыбызның асыл улы .......................................................232
Илле елдан соң кабат очрашу ..............................................235
Җүрәйләрдә йөреп гыйбрәт ал ..............................................238
Тегермәнле авыл егете .........................................................242
“Мин үземне бүген бәхетле кеше дип саныйм” .......................245
Васыятеңне һичшиксез үтәячәкбез! ......................................252
Ятим өйнең бакчасындагы алмагачта биш алма ......................254
Бу дөнья бит минсез торган кайчандыр,
Бу дөнья бит минсез калыр кайчандыр... ...............................260
“Яхшылыклар белән искә алып,
сагынсалар иде безне дә...” ................................................261
Васыять ..............................................................................266
Шагыйрьнең борчулы уйлары... ............................................271
Шагыйрьнең өметләре тормышка ашарга тиеш... ...................275
ОБРАЩЕНИЕ .......................................................................282
“Каурый каләм эзеннән” ......................................................284
Без татарлар бит әле!... .......................................................287
Тик нигәдер вәгъдәләр бирешәбез дә онытабыз... ...................291
Гакыйль Сәгыйров турында китап, ниһаять, дөнья күрәчәк...297
Йомгаклау сүзе ....................................................................299

**Автор и редактор книги Рафгат Аглиулин**

# Гакиль Сагиров

# *О себе и все о нем...!*

**Компьютерный набор:**
Гельгена Салахова, Алия Арсланова
**Верстка, дизайн:**
Гульнур Мусина, Эльмира Варфоломеева
**Корректор:** Зайнап Аглиуллина

*В книге использованы фотографии из семейного архива Гакиля Сагирова, а также фотокорреспондентов Аняса Мингалиева, Геннадия Тимофеева, Светланы Осьмачкиной, Вадима Воеводина, Хамзы Муртазина и других.*

Предпечатная подготовка - редакция газеты «Бердэмлек»

Сдано в набор 15.05.2015 г. Подписано в печать 09.09.15 г.
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная. Гарнитура FF Academy.
Усл.печ.л. 15,5. Тираж 700 экз.

Отпечатано ООО «Медиа-Книга».
Адрес: 443070, г. Самара, ул. Песчаная, д. 1.